# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ–1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**9**

СЕНТЯБРЬ
1976


## Бу санда


Р. МИНГАЛИМОВ. Ышаныйк. Шигырьләр . . . . 3
М. МӘҺДИЕВ. Каз канатлары. Роман . . . . . 5
Ф. ЯРУЛЛИН. Замана портреты. Шигырьләр . . 86
М. ГАЛИЕВ. Күңелеңә үзең шаһит. Хикәя . . . 89
Э. МОСТАФИН. Беренче яшен кебек. Шигырьләр 102
Ф. САФИН. Иптәшләр! Шигырь . . . . . . . 103
Р. ВӘЛИЕВ. Бәхет. Шигырьләр . . . . . . . 104

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 108
М. ЗАРИПОВ. Балыкчылар . . . . . . . . . 112

Г. ШӘРӘФИГӘ 50 ЯШЬ

Г. ШӘРӘФИ. Үҗәт. Повестьтан өзек . . . . . 117

А. РАСИХКА 60 ЯШЬ

Ф. МУСИН. Еллар һәм юллар . . . . . . . . 122

М. ГАЛӘҮНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Ф. ГАНИЕВА. Әдип гомере . . . . . . . . . 133

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

И. ИЛЯЛОВА. Буын ныгыткан буын . . . . . . 145

ТӨРЛЕСЕННӘН

Н. ФӘТТАХ. Ерак гасырлар авазы . . . . . . 152
Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Толымбай авылы . . . . . 172



КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ж. ТӘРҖЕМАНОВ. Шигърият һәм ... ЭВМ . . . 176
Р. БӘДЫЙГОВ. Инкыйлап байракчысы . . . . . 178

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Х. ХӘКИМОВ, З. ШӘРӘФЕТДИНОВ. Мәгърифәт учагы . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Х. КУМЫСНИКОВ. Халык күңелендә . . . . . 184
Л. ИХСАНОВА. Ир язмышы . . . . . . . . . 186
А. СӘЛӘХЕТДИНОВ. Заманасы шундый . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 3/VI-1976 ел. Басарга кул куелды 10/VIII-1976 ел. ПФ 09028. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90744 экз. Заказ К-220. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

## Рөстәм Мингалимов

### Ышаныйк

Хезмәттә —
Югары сыйфат!
Һәр эштә —
Сыйфат!
Партиянең бу чакыруын
мин шатланып ишетәм.
Кырлар өстендә яңгырый бу сүзләр,
Заводлар, шахталар эчендә яктыра.
Бүлмәләргә үтә.
...Сыйфат өчен яңа көрәш бара.
Җиңү ансат кына булмас.
Ләкин яхшыга ышаныйк, каләмдәш,
Яхшыга ышаныйк, юлдаш.
Юлдашларга ышаныйк,
Без бит бергә-бергә
Ничә көрәшләрдә җиңеп үттек.
Үлемнәрне җиңеп үттек.
Йөрәкләрне тагы да яхшыга
Үзгәртергә
җитәр бездә куәт
һәм егетлек.
Яшәүне тагы да матуррак итик,
Җырларны гүзәлрәк итик!

### Имтихан биргән заман

Акыллы заман булды бу,
Киң заман, тирән заман.
Мәңге ахмак тимерләргә
Зур акыл биргән заман.
Ташка җан өргән заман бу,
Агачлар очар заман.
...Ак ипи кинәт кап-кара
Күзләрен ачар сыман.
Акыллы заман булды бу,
Киң заман, тирән заман.
Тезенә кул җитмәсләрнең
Башына биргән заман.

Ак сорау кебек көннәрең,
Төн кара сорау кебек.
«Миңа кайчан киләсең?» дип,
Каберең сорар кебек —
Кычкырып ук сорар кебек,
Ә синең көлгән заман,
Сорауларга җавапларны
Шәп бирә белгән заман.
Бу заман сине ныгыта
Мең төрле сынау белән.
Эндәшә сиңа кешеләр
Мең төрле сорау белән.
Сынатмаслык җавабың әйт,
Кыюрак бул, тизрәк!
Шыр тиле сорау булса да,
Акыллы җавап кирәк!
Бу акыллы заман булды,
Киң заман, тирән заман:
Киләчәккә узу өчен
Имтихан биргән заман.

## «Яшел төш»

Таш тезелгән якты чишмә юлына,
Киң маңгайга охшаш сырлы ташлар бар.
Монда вак таш, соры ташлар, сарылар...
Бар йөрәккә охшаш сәер зур ташлар.
Чишмә суын алар моңлы кыл иткән,
Шуңа кагылып үз көйләрен уйныйлар:

Маңгайлары белән кагылып уйныйлар,
Иякләре белән кагылып уйныйлар,
Бармаклары белән кагылып уйныйлар,
Йөрәкләре белән кагылып уйныйлар,
Исеме ташлар көенең — «Яшел төш».

Таш тезелгән якты чишмә юлына,
Ташлар бетсә, чишмә суы җырламас.
Монда вак таш, соры ташлар, сарылар...
Ташлар бетсә, чишмә суы җырламас.
Чишмә кипсә, ташлар елар тын гына.
Суга кагылып алар бүген уйныйлар:

Маңгайлары белән кагылып уйныйлар,
Иякләре белән кагылып уйныйлар,
Бармаклары белән кагылып уйныйлар,
Йөрәкләре белән кагылып уйныйлар,
Исеме ташлар көенең — «Яшел төш».

Мөхәммәт Мәһдиев

# КАЗ КАНАТЛАРЫ

РОМАН

## Камәргә ат бирегез...

Безнең авылның Шәйдулланы кырык алтынчы елда ФЗӨгә җибәрмәкче булдылар. Авыл советына наряд килгән иде. Шәйдулланы җибәрмичә, анда кемне җибәрәсең? Барыбер укымады. Биш класстан ташлап чыкты. Җиденчене бетерергә йөргәннәрне мәктәптән алып булмый бит инде. Шәйдулла исә, тимер-томыр түгел, чүкеч-кискеч түгел, ә җирне, ат-арбаны, тырманы, сәнәкне ярата иде. Ул бала вакытында һәр көн диярлек ат абзарларында кайнашты. Әтисе ат караучы иде. Шәйдуллага укы димә, мәктәп димә, әмма эш бир. Колхоз эшендә ике смена эшли ала ул. Атларга мичкә белән су ташый, клевер чабып төяп алып кайта, утлыкларына сала, тирес чыгара. Мондый эшне ул бигрәк тә сентябрь аенда зур канәгатьләнү белән эшли, чөнки башка иптәшләре мәктәптә вакытта авыр эш башкаруын ул аеруча зур бәхет дип саный. Укытучылар ничәмә-ничә тапкыр Шәйдулланы ат абзарыннан туп-туры мәктәпкә алып китеп карадылар. Ләкин класста ул давылда корабы ватылып, коры җиргә чыгарып ташланган диңгез юлбасары кебек утыра. Караңгы чыраена нәфрәт чыгарып, мәктәп тәрәзәсеннән камыллы басуга, яшел уҗым түшәлгән киңлекләргә карый. Шул вакытта аның күзләрендә искиткеч сагыш, кемгәдер рәнҗү, үпкәләү чагылып ала. Хәтта нинди кырыс математика укытучысы да акбурга буялып бетеп формула аңлатып яткан җиреннән Шәйдуллага күз төшереп алса, тынып кала. Бер дәрес, иң күбе ике дәрес утыра Шәйдулла. Мәктәп ишегалдына, авылның чыгу юлларына пионер, учком члennарыннан күпме генә каравыл куелмасын — Шәйдулла кача. Шундый итеп кача, — сокланырсың. Тәнәфес вакытында качмый ул. Учком члennары исә үзләренең беркатлылыгы белән шул вакытта күзәтәләр. Тәнәфес вакытында Шәйдулла мәктәпнең утын лапасы, складлар арасында басып кына кала. Дәрес башлана. Аны эзләүчеләр инде кайтып класска керәләр. Юк, күренмәде. Юк, тапмадык. Ләкин дәреснең урта бер җирендә тәрәзәдән күз

салсалар, ни күрсеннәр: камыл басуын уртасыннан ярып, авылга таба бер бүре баласы тәгәри. Юыртып-юыртып. Хәтта кыеклап-кыеклап. Бу — Шәйдулла. Иптәшләре мәктәптән кайтканда Шәйдулла инде клевер йөге өстендә килә, йөк өстендә ул хуҗаларча дилбегә тотып утыра. Колхозның ат абзарлары — аның туган йорты. Бу эш — аңа газиз. Математика кирәк түгел. Ләкин мәктәпкә үзен бурычлы итеп калдырмас өчендер инде, ат бүлмәләренең өстенә яшел буяу белән ул исемнәрен язып чыккан. Анда «Алгебра», «Зоология», «Физика» исемле атлар бар. Председатель җигә торган кара туры хәтта «Грамматика» исемле. Бу исемнәрне Шәйдулла үзе бик яратып куллана һәм мәктәпнең аңа дәгъвасы шуның белән беткән дип исәпли. Дөрес, эчтән генә сызып-сызып бер уй борчый аны: укыр иде ул, бик зур белемле кеше булыр иде. Бөтен фәнне ярата ул болай. Әмма мәктәпнең бер яман гадәте бар: анда һәркөнне сөйләтәләр, үзеңнән уйлатып яздырталар. Сөйләү, үзеңнән уйлап язу дигәндә — Шәйдулладан юк инде. Булмагач булмый, табигать аңа андый сәләт бирмәгән. Дүртенче класста яңа килгән укытучы иде, беренче сентябрь көнне үк инша язарга кушты. «Мин җәйне ничек үткәрдем». Шәйдулла җәйне бик шәп үткәргән иде, җәй буе урманда ат саклады ул. Учак янында кунган ул төннәр, бүре тешләгәч әсәренгән атлар! Умарталыктан Галләмгали агай чыгып, урман аланында ат саклаучылар белән төн үткәрә иде. Анда сүз тәмле була. Атлар пошкырына-пошкырына утлап төрле якка тарала. Иртәгесен аларны, чыклы үлән ерып, агач арасыннан эзләп йөрисе була. Галләмгали агай, әгәр иртәнгә кадәр малайлар янында утырса, эш җиңел: ул җиргә колагын куеп ята да, бераз гына тын тора. Башын күтәрә дә әйтә:

— Атларыгыз, — ди, — әнә теге якта, юкәлек аланында. — Һәм ул бер тапкыр да ялгышмады.

Аның бер колагы сугыштан чукракланып кайткан иде. Кайсы колагы белән тыңлаган ул җирне — белмәссең.

Әнә шуларны язар иде берәү булса...

Шәйдулла исә иҗади язуны, сөйләүне булдыра алмый. Тирләп-пешеп шактый утыргач, ул укытучыдан котылу, чиратны уздыру өчен генә ике җөмлә язып куйды: «Җәй көне мин әти белән урманга барганыем. Анда мин аю күрдем». Укытучы да бик вак кеше булып чыкты. Бастырып куйды да бәйләнде:

— Я инде, Һидиятов, ник ялганлыйсың, аю күрмәдең бит син, бу урманда аю юк бит, — диде.

Шәйдулланың ачуы ташып тышка чыкты. Үкереп елап җибәрде дә китап-дәфтәрләрен җыештыра башлады.

— Берәү дә мүгезле итеп язмый, — диде ул, җиңе белән күзләрен сөртә-сөртә. — Син миңа канығасың гына. Берәү дә мүгезле итеп язмый.

Шулай дип чыгып китте дә ике көн мәктәпкә килмәде...

Шулай кырык алтынчы елның сентябрендә аны әнисе белән бергә кәнсәләргә чакырдылар. Һәм ФЗӨ турында әйттеләр... Әнисе икеләнеп калды. Чөнки Шәйдулла йортта сугыш елларындагы җил-давылдан исән-имин калган эшкә яраклы бердәнбер ир заты иде. Ана кеше күнде. ФЗӨгә җибәрү — сугышка, үлемгә җибәрү түгел, малай дөнья күрсен, кеше арасына керсен, дип күнде. Мәктәп коллективыннан читтә булып, гел атлар тирәсендә дә кырда ялгыз йөргәнлектән, авыл балалары арасында Шәйдулланы туксан тугызлы дип исәпләүчеләр дә байтак иде...

Иртәгә юлга чыгасы көнне Шәйдулла атлар абзарына барып, атлар белән саубуллашып йөрде. Ул күз йомып та караңгы абзарда кайсы аратада кайсы ат торганын әйтә ала, кайсы аттан нинди рәк ис килгәнен, кайсы атның ни формада басып торганын әйтә ала. Чөнки — шунда

үсте, әтисе кырык икенче елга кадәр шунда эшләде, әтисе үлгәч, аның эше әнисенә калды. Ә Шәйдулла беркайчан да авыр эшне әнисеннән эшләтмәде. Салам, клевер, вика күтәртмәде... Ат абзарларыннан чыккач, Шәйдулла еракта клевер эскертләре күренгән басу сыртына карап торды. Эскертләрнең теге ягында, горизонтта, таш юл сузылган, ул юлдан анда-санда йөк машиналары уза, ул юл шыксыз таш шәһәрне, ФЗӨне күз алдына китерде. Шәйдулланың йөрәге өшеп китте. Ул эскертләргә таба атлады. Һәм шул китүеннән кайтмады...

Аларның өенә авыл советыннан берөзлексез кеше килде. Малай юк иде. Аннары пүнәтәйләр белән оперуполномоченный килде. Өй астын, печәнлекләрне тикшерделәр. Малай табылмады. Кырдагы эскертләрне тикшерделәр. Бары тик төннәр суыткач кына таш юл астыннан аркылы узган бетон труба эчендә ябыккан, йончыган Шәйдулланы күрше колхоз тракторчылары табып алып, авылга китереп куйдылар.

Авыл советында да, колхозда да Шәйдуллага бер сүз әйтүче булмады...

Еллар узды. Шәйдулла күзгә күренеп ныгыды. Ул хәзер әнисен тулысынча авыр эштән азат итеп, егерме баш атка бер үзе хуҗа иде.

Армиягә каралган елны ул иртән ашарга бит юып утыра башлады. Бераздан кесәсендә кульяулык күренде. Бераздан ак күлмәкнең җиңен сызганып кич урамга чыга башлады. Көзен исә, һич тә сыкранмыйча, ниндидер эчке дәрт, горурлык белән армиягә озату көнен көтте. Соңгы көнне әнисе, сеңлесе белән ирләрчә саубуллашты да, капка төбенә килеп җиткән клевер төшәлгән тимер ходлы арбага утырды һәм китүче егетләрнең җырына кушылды. Ул караган таза атлар военкомат юлын беләләр иде...

Шуның белән авыл тарихында Шәйдулла солдат дигән яңа кеше барлыкка килде.

Әнисе Камәр түти яңадан ат карауга керде.

Ике ел узды. Шәйдулладан тәртип белән генә хат килеп торды. Хатында ул күп сүзле түгел иде. Тик бер хатында гына сиздереп алды: аның хезмәтеннән командирлары чиксез канәгать икән. Әмма, күпме генә канәгать булмасыннар, ялга җибәрмиләр. Шәйдулланың исә өзелеп-өзелеп туган авылга кайтасы килде. Тик өч кенә көнгә!.. Бераздан мондый хатлар ешайдылар. Шәйдулла әнисенә ялына башлады: «Әни! Нужәли синең бер төшең дә авыртмый? Син карт бит инде. Ничә ел кәнүшнидә эшлисең. Берәр справкы табып Мәскәүгә Шверникка нужәли җибәрә алмыйсың? Миңа бит өч кенә көн кирәк. Бик сагындым бит! Төз лапас өстен көрәдегезме? «Зоология» быел да колынладымы? Шверникның адресы бик асат: Мәскәү, президиум. С приветом писатель Шәйдулла».

Шундый хатлар яза-укый өч ел үтеп тә китте. Февральнең җәяүле буран себерә торган салкын көне иде. Көннәр инде ун сәгатькә җиткән, сыерлар бозаулый, төштән соң кояш җәяүле бураннан талчыгып маяклы юл артына — җир белән күк тоташкан кар дәрьясына кереп югала, кар өстен кызыллык каплый, тәрәзә пыялалары бакыр төскә керә... Шундый салкын, кырыс көннәрнең берсе кичкә авышканда район юлыннан авылга таба берәү атлый иде. Аягыннан чыккан шыгыр-шыгыр тавыш бөтен авылга ишетелгән сыман. Кояш батышында аны танып та булмый. Ләкин зур гәүдәле һәм кыска киемле мәһабәт бер ир икәнлеге бәхәссез иде.

Бу — ефрейтор Шәйдулла икән. Әйе, бер дә киметеп әйтмичә, ефрейтор Шәйдулла икән. Мундирдан, фуражкадан, хром итектән, ак перчаткадан, күкрәгендә өч значок: ГТО, ГСО һәм Кызыл Хач.

Камәр түти өнсез калды. Йортта мондый шатлыкның бу йортка нигез салынганнан бирле бөтенләй булганы юк иде. Андый вакытта нишлисе икән? Шатланасымы? Елыйсымы? Самавар куеп җибәрәсеме?

Көрешәсеме? Ат караучы Камәр түти аны каян белсен? Беравык тынсыз торгач, ул аңына килеп, келәткә чыгып йөгерде. Аннан бер уч каз мае алып керде. Шәйдулла әле һаман түргә узмаган иде. Аннары Камәр түти ефрейторны сәке кырына утыртты да колагын, битләрен каз мае белән уды. Колаклар биялэй, бит урталары пәрәмәч булган иде.

— Ничек кайттың? — диде ана.

— Утпыска бирделәр.

— Ничек итеп? Шверникка яздыңмы?

— Юк. Әйбәт служить иткән өчен. Ун көнгә.

— Алланың биргәненә шөкер. Бик рәхмәт. Өс-баш бирмәделәрмени?

— Барысы да бар. Но мин аларны стансада калдырдым. Камера хранениедә.

— Нәрсәләр ул?

— Шинель, бүрек, биялэйләр. Сиңа, сеңелгә күчтәнәчләр.

— И бала, бала... Шушы суыкта ялан өс кайтмасаң. Кичә Галимуллаларның бозавы катып үлгән. Быел иртә бозаулыйлар. Бүрек белән шинелең була торып...

Шәйдулла дәшмәде.

Камәр карчык исә бер нәрсәне аңламый иде: Шәйдулла чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. Чик буе солдатларына парадный мундир бирәләр. Фуражканың түбәсе ямь-яшел. Мондый матур форма башка бер генә солдатта да юк. Ә шинель белән соры бүрек солдатның барысына да бирелә. Ничек инде авылга шинель белән кайтып керәсең? Аны бит иртәгә районга барган теләсә кем аркылы кайтартып була. Камәр түти — тормыштан артта калган. Надан булмаса ул шундый сорау бирмәс иде. Чәй кайнаганчы, Камәр карчыкның ай-ваена карамыйча, Шәйдулла ат абзарына китте. Әнисе күпме генә ялынып караса да, файдасы тимәде: мундир өстеннән Шәйдуллага һич кенә дә этисеннән калган буй-буй тышлы җылы тунны киертеп булмады.

Атларның картраклары, баштарак бераз сискәнешсәләр дә, Шәйдулланы танадылар. Араталардан муеннарын сузып кайсы аның яшел фуражкасын иснәп карады, одеколон исе килеп торган «шерстауный» мундирны апарага буяды, кайсы кызыл пәрәмәч булган каз майлы битен иснәде, җилкәсен тешләде. Бу минутта Шәйдулла бик-бик бәхетле иде. Мондый бәхетне дөньяда беркем дә татымас, моның нәрсә икәнен аннан башка беркем дә аңламас кебек тоелды аңа. Шул бәхеттән мәхрүм кешеләрне ул кызганды: хәрби академия тәмамлаган, сугыш кичкән, Советлар Союзы Герое застава начальнигы полковникны да, кызларның башын әйләндереп бетергән, ике-өч чит тел белүче взвод командиры өлкән лейтенантны да Шәйдулла чын күңелдән кызганды.

Ат абзарында ул йөрәгенә якын хуш ис — җылы печән исен, башак тагарагы исен сизде.

...Чәй янында эре сөякле, киң җилкәле Шәйдулла солдат утыра иде. Солдат аз сөйләшә, җөмләләре кыска.

— Я, әни, тормышлар ничек?

— Алланың биргәненә шөкер. Саимә укуга синең төслерәк булып чыкты. Фирмедә эшли. Уңыш әйбәт кенә булды. Тана суйдык, уникe бала каз. Аннары...

— Нәрсә аннары?

— Кискән урман барые. Дүрт йөк булыр. Ат бирмиләр.

— Кемнең бирмәскә хакы бар?

— Үзем эшләмим. Саимә кыюсыз. Бик яшь тә бит әле. Прсидәтел һаман суза. Лапаста ике көнлек утын калды.

— Прсидәтел минем кайда икәнне онытканмыни? Ничек смить итә ул шулай шаярырга?

— Әйттем: ничә ел колхозда эшләдем, малаем яшьтән күпме эшләде, дидем. Хәзергесе көнне, дидем, Каф тавы артында әрмислектә хезмәт итә. (Шәйдулла, чыннан да, Кавказда, Төркия чигендә иде.) Берсе сутышта ятып калды, дидем.

— Ул нәрсә ди?

— Гел иртәгә дип йөртә. Аның атлары да бик азайды. Буазларын ялга куйдылар...

Шәйдулла бер бит кәгазь сорап алды. Дәфтәр битен дүрткә бөкләп ертты. Зур гына куен сәгатен чыгарып карады: сәгать кичке алты — кояш баткан иде.

— Прсидәтел бу вакытта кәнсәләрдә буламы?

Әнисе тәрәзәдән тышка күз салды.

— Нәрәт биргән вакыты.

Шәйдулла әнисенә кечкенә кәгазь кисәге сузды.

— Менә шушы язуны чыгарып бир үзенә. Утын иртәгә кич лапаста булыр.

Камәр түти, ике дә уйлап тормастан, язуны алып идарәгә китте.

...Урман заданиесен үтәүдә артта калган өчен бу атнада гына соңгы кисәтү алып кайткан председатель Вәлиулланың өч-дүрт көн инде елмайганы юк иде. Камәр түти сүзсез генә китереп тоттырган кәгазьне укыгач рәхәтләнеп бер көлде. Кәгазьдә нибары дүрт сүз язылган иде: «Камәргә ат бирегез. Һидиятов».

Икенче көнне кичкә, чыннан да, утын төягән дүрт ат ишегалдына килеп керде. Һәрберсенә уртача берәр кубометр төялгән иде. Күрше Галимулла да районнан кайтышлый чоланга сугылды: Шәйдулланың зур чемоданын һәм өс-башын алып кайткан иде.

Камәр түти исә олы табакка зур казаннан итле шулпа бушата, Шәйдулла ипи турый иде. Өмәче егетләрнең чоланда аяктан кар себергәннәре, бияләй-тун якканнары ишетелә, ишектән, ачылган саен, итле шулпа исе катыш пар бәреп чыга иде...

Халыкның бик күркәм бер йоласы — өмә бар. Бу бик борынгыдан килгән гадәт булса кирәк, өмәдә катнашкан өчен акча алмыйлар, өмәгә әйтмиләр. Иртәгә фәлән кешеләрдә өй өмәсе икән, дисәләр, димәк, аларда өй күтәрү була. Авылның балта остасы булган бөтен кешесе үзе теләп шул өмәгә килә. Камәр карчыкның исә «утын өмәсе» иде. Өмә — кешенең кешегә ярдәм кулы сузуы, ярдәмгә һәр вакыт әзер булуы дигән сүз. Өмә ахырында җыелышып утырып ашау — шулай ук күркәм гадәт. Бу ашау — ашказанын тутыру, ачыкканны басу гына түгел. Бу — үзенә күрә бер тәрбия дәресе, әхлак чагылышы. Ашны беренче кабып караган кеше монда, һичшиксез, «фәлән апаның ашы бик тәмле булган» дип әйтергә ашыга. Җоррак теллесе, әгәр йортта кыз булса, бу ашны шул фәлән пешергәндер инде, дип өсти. Өченче берсе, өлкәнрәге, «кызлар пешергән ашка фәрештәләр канатын тыгар» дип әйткәннәр борынгылар» дип үк җибәрә. Халыкта тәлинкә төбендә аш калдыру юк. Шәйдулла, югыйсә, чит илләрдә булган өлкән лейтенанттан ишеткән иде: тәлинкә төбендә бераз гына аш, стакан төбендә бераз гына эчемлек калдырып китү Европада яхшы гадәт санала, имеш. Юк, бездә алай түгел, аштан олы булырга ярамый! Өстәл янында ашый торган ипиеңне дә калдырып китәсе түгел. Синнән калган ипине кем ашасын? Әрәм була бит ул. Адәм баласын моннан ничек тыярга? Бар, анысына да әмәл бар. Ашаганда бер кабарлык ипиен калдырып киткән кешене хатыны ташлап китә. Татар малаена дөньяны аңлый башлаганнан бирле тукыла торган сүз бу. Куркыныч хәл бит!

Бабайлар ашау тирәсендә комагайлыкны да яратмаганнар. Мич алдында кабартма-коймак пешергәндә, мәсәлән, беренче табадан төшкәненә ашыгып ябышасы түгел. Беренче табаныкын ашаган кешенең хатынының башы таз була. Әнә шулай, ашау тирәсендә сак, әдәпле булсаң, синең хатының да әдәпле, нык, таза булыр. Алыначак хатын әнә шулай бала чактан, табын янынннан әзерләнгән. Өмәдә бу матур гадәтләрнең барысы да күзгә ташлана, үтәлә иде.

Ат җигүче дүрт егет, бишенчесе Шәйдулла, әнә шулай шаяртып та әңгәмәләшеп, токмачлы аш ашадылар. Бәлеш чыккач, «бәлеш астына салып калдырыйк» дип, тагын берәрне әдәп белән генә төшерделәр. Аннары арадан берничәсе стаканнарын уртага этте. Бу инде «булды, рәхмәт, башкача кыстамагыз» дигән сүз иде. Ашыга-ашыга бәлешне мактадылар. Шәйдулла рәхәт чигә иде: туган нигез, туган авыл, яшьтәш егетләр, ата-бабадан килгән гадәтләр, әни исән, өй җылы, ишегалды тулы утын...

## Камәр карчыкның үлеме

Марат белән Ленар — икесе дә авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган егетләр. Марат — өлкәнрәк. Икесе бер авылдан. Сирәк кенә очрашалар да шәһәр читендәге берәр ресторанның иң почмактагы аулак бер өстәлен сайлап алалар. Марат — колхоз председателе Вәлиулла агай улы.

Кыш. Елга портының рестораны. Анда кышын кеше аз була. Музыка да уйнамый. Рәхәтләнеп сөйләшәсең. Хәтерлисең. Яшьлекне, авылны. Югыйсә, үзәк рестораннарда сөйләшү өчен бер мөмкинлек юк. ГПТУдан, институтлардан «Шабашка»га килгән озын чәчле малайлар кулларына микрофон тоталар да теләсә нинди телдә ультра җырлар акыралар. Теләсә кемгә микрофон тоттыралар. Колхоз председателе Вәлиулла агай, мәсәлән, илле алтынчы елда колхозга радиоузел кайткач, шулай, бригадирларга микрофон тоттыра башлаган иде. Әйбәт кенә бригадир Фәхрислам — микрофоннан сандугач булып сайрады бервакыт.

— Фәния, синең иртә белән үз-үзеңне зыештырып (Фәхрислам сугыштан сакауланып кайткан иде) бетерми торган гадәтең бар. Суңа күрә көтүчеләр синең сыерларыңны вакытында алып сыга алмыйлар.

— Галимзан, син дә йокыны бик яратасың. Кырыкка зиткәс әзрәк уяурак булсаң да месәйт итмәс иде...— Фәлән-төгән дип Фәхрислам рәхәтләнде. Микрофон тоттырганына сөенеп председатель дә шатланып утырды. Әйдә, гел председатель генә сөйлисе димәгән. Фәхрисламга ул ияк кагып мактагандай ишарә ясады. Шуның белән дәртләнеп китеп Фәхрислам исә сүз ахырында бераз гына кыландырып җибәрде.

— Суның белән минем сүзем бетте, сәлам белән Идиятов, — диде дә микрофонны председательгә тоттырды. Ачуына буылган председатель микрофонны учы белән каплап торып шунда ук Фәхрисламны эт итеп сүгеп ташлады.

— Тиле тәре,— диде ул, тыны буылып,— сиңа микрофон тоттырган мин юләр. Тилегә намаз укырга кушсаң маңгаен ярыр, дигәннәр. Колхоз идарәсенең дәрәҗәсен төшереп...

Ләкин Фәхрислам шат иде. Әлбәттә, шуннан соң ул микрофон күрмәде. Бригаданы микрофонсыз гына җитәкләде. Моңа ул гаҗәпләнмәде дә: чөнки микрофон мәсьәләсендә аларның нәселендә бер вакыйга булган иде инде. 1939 елда беренче тапкыр халык талантларының

олимпиадасы булды. Фәхрисламның этисе Һидиятулла карт скрипка уйный белә иде. Авыл смотрыннан узды. Районга килде. Район сәхнәсендә «Ончы Фәхри»не уйнап республикага узды. Шул көнне кичен культура бүлеге олимпиадада җиңүчеләрнең район радиочелтэреннэн концертын оештырды. Һидиятулла абзыйга башта бик каты инструктаж бирделәр. Менә бу тимер ящикның бу төшендә яшел лампа януга тынынны да чыгарасы булма, уйна гына, диделәр. Йөткерәсе дә түгел, безгә дә бер сүз дәшәсе түгел һәм башкалар... Тимер ящик янындагы микрофонга бөкрәеп район кешесе бөтен поселокка белдерде:

— Район олимпиадасында җиңеп чыккан, «Маяк» колхозының ат караучысы Һидиятулла абзый...

Һидият абзый боларны ишетмәде. Яшел лампа кабат януга ул нык кына каушап смычогын сызып җибәрде. Сызды... һәм скрипканың бер кылы шартлап өзелде. Бер мәлгә бөтен дөнья «зың-н» итеп көйләп торды. Гадәттән тыш куркып калган Һидиятулла абзый бөтенләй онытылып шунда бер хата эшләде.

— Тфү,— диде ул йөрәк ачысы белән. Аннан бер яман сүз әйтте. Ул сүздән соң җөмләне йомшартты:— чукынып кына киткере...

Яшел ут сүнде, аның алдыннан микрофонны тартып алдылар, үзе исә өч көн утырып кайтты.

Шулай, микрофон җаваплы нәрсә.

Һидиятулла карт Камәр түтинең ире иде. Фәхрислам исә сугыш вакытында хәбәрсез югалып, аннан табылып, Япония чигенә җибәрелеп, шунда яраланып, госпитальдә озак ятып, кырык җиденче елда гына колхозга кайтып бригадирлыкка кергән уллары, Һидиятулланың беренче хатыныннан туган ул иде. Шәйдулла белән Фәхрисламның ана башка, ата бер иде.

...Тормыш Камәр карчык белән кырыс мөгамәләдә булды. Кырык икенче елның рәхимсез салкын көннәрендә аның Шәйдулладан олы улы сугыш кырында үлеп калды. Үлем хәбәре килгән көннәрдә бүрәнәләр чартлап торган салкын төннәр иде. Карчык йокысыз калды. Әнә шул суыкларда аның улына кемнәр, ничек итеп кабер казыдылар икән дигән уй тынгылык бирмәде. Ничектер үлемнең үзе турында түгел, ә шул соңгы мәшәкате турында гына уйлады. Тирән казыдылармы икән? Күмгән чакта ләхет ала белүче мөселман булдымы икән? Җирнең туңы калынмы икән? Ике-өч атна шул турыда гына уйлады. Өстәл-өстәл булып кубарылган туң җир, кар белән буталган балчык күз алдына килеп аның җанын өшетә иде һәм җылы түшәгендә дер-дер калтырап ул кышкы төннәрне керфек какмыйча уздырды. Пермь ягына урман эшенә киткән халык февраль ахырларына таба кайтасы дигән хәбәр таралды. Камәр карчык та бераз тынычлана төште: ире Һидиятулла кайтып җитсә, әллә өшегән җанга җылылык керер иде дип өметләнде. Март урталарында кояш карый башлап, туңган күңелләргә тормыш җылысы өстәде. Ул арада төркем-төркем булып урманчылар да кайта башлады. Йончыган, ябыккан, колаклары, битләре, бармаклары өшеп кутырлаган кешеләрдән сорашып, Камәр карчык иренең соңгы төркем белән кайтырга калганын белде. Ниһаять, авылга соңгы ат та кайтып җитте. Һидиятулла күренмәде. Камәр карчык кайнаган самаварын өстәлгә утыртты да, Әптел картка чапты. Ул барып кергәндә Әптел карт сәкегә менеп аякларын бөкләгән, табак тулы ярмалы бәрәңгене ашыга-ашыга сыптырап утыра иде. Әптелнең яңак сөякләре чыккан, күзләрендә май беткән, кәҗә сакалы сирәгәеп калган. Камәрне әллә күрде, әллә күрмәде — һаман да йотуын дәвам итте. Эссе бәрәңгене авыз эчендә әвәли-әвәли, үзе сөйли бирде.

— Көн саен кырыклы, кырык икеле суык булды. Пычкыны тотар кәл юк. Ут ягып җылынып алабыз — норма үтәлми. Ул халык, ул халык, Арча базары диярсең. Кайсы өши, кайсы эченә суык төшеп егыла. Кич кайткач бәрәңгене пешерәбез дә кычкырып бүләбез. Мине борып куялар да: «Әптел абзый, бусы кемгә? Бусы кемгә?» дип сорыйлар...

Әптелнең сүзе озын булды, Камәр карчык сабырсызланып сорады:

— Я, син аларын сөйләргә өлгерерсең, Һидиятулла кайда? Ник бергә кайтмадыгыз?— диде.

Әптел ык-мык итте, кәҗә сакалын сыпыргалады, үзе янадан бәрәңгегә тотынды.

— Анда, беләсең килсә, тимпиратур көн саен кырык та кырык ике. Откомнан килгән ләчәнство көн саен үлчәп кенә торды, аның градыснигы сумкасында гына...

Камәр карчык түзмәде, сәке каршына ук килеп басты:

— Син нәрсә, әллә үрдәкнекен ашадыңмы? Һидиятулланы күрдеңме, юкмы?

Бераз буталгач, Әптел карт, Һидиятулланың кайдалыгын повар Минҗиһан белер, диде. Камәр тиз генә Минҗиһанны эзләп китте. Ләкин анысы Вятские Поляныда эшкә урнашырга калган икән. Минҗиһан урман кисәргә баргач та кулына пычкы тотмаган, чибәрлеге бар, мутлыгы күзгә бәрелеп тора, тиз генә кухняга урнашып алган. Кайтышлый Вятские Поляныга урнашуын да шундагы бригадирларның берсе оештырган, имеш. Авыл буенча чабып йөргән Камәргә бер генә кеше дә төгәл җавап бирмәде. Барысы да Минҗиһан белер, дип котылдылар. Карчыкның йөрәге, киләчәк хәсрәтне алдан сизеп, шөбһәләнеп сызлый башлады.

...Карчык йөрәгенең ялгышмаганына ике-өч көн үткәч ышанды. Поляныда ашханәдә повар булып урнашкан Минҗиһан авызыннан чыккан хәбәр авылга килеп житте: кайтканда атлары аргач бер авылга кереп кунарга булганнар. Җирдән себергән буранда өч юл чатында озак уйлап торганнан соң чанада Минҗиһанны калдырып Әптел белән Һидиятулла икесе ике авылга фатир сорарга киткәннәр. Бераздан Әптел фатир килешеп кайткан, ә менә Һидиятулла кайтмаган. Икенче көнне кайту юлына чыкканда каршыларына ат җиккән ике рус очраган. Чанада кызыл ашъяулык белән каплаган кеше гәүдәсе ята икән. Минҗиһан ашъяулыкны ачып караган һәм Һидиятулланы таныган.

— Кырда маяк төбенә утырып катып үлгән, дигәннәр тегеләр. Менә врач килмичә күмәргә кушмадылар.

Шулай итеп, Камәр карчыкның йортыннан тагын бер кеше салкын кышта туфрак астына керде. Карчык күз яшен кешегә күрсәтмәде, күңеле таш булып катты. Тик кичләрен юрганын ябынган вакытта гына: «Ярабби ходаем, салкын кышларда җир астына кертмә»,— дип әйтергә гадәтләнде.

Еллар узды, иренә һәм сугышта үлгән малаена булган йөрәк жылысын Камәр карчык акрынлап төпчек кызына күчерде. Аның өчен хәзер дөньяда бер генә кеше бар иде: ул да булса — кызы Саимә. Дөрес, бу бала элек-электән кадерле булды. Яшь, таза вакытында Камәр ике малай тапты — үзе һаман кыз көтте. Гомерләр үтте, кыз күренмәде. Бары тик олыгайгач кына Камәрнең хыялы тормышка ашты. Күрше-күлән, туган-тумача алдында бераз оялып йөрсә йөрде, әмма бишенче дистәне ваклагач дөньяга бер кыз бала китерде. Бик көтеп алынган булганлыктан, өч яшенә кадәр баланы кешегә күрсәтмәде. Почмак якта, бишектә генә асрады. Күз тимәсен өчен, битләренә кызыл буяу тидерде, башлыгына миләш агачыннан бер шакмак тегеп куйды. Җен кагылмасын өчен, ишек өстенә артыш ботаклары кыстырды. Саимә шулай кадерле булып үсте.

Кызы буй җитеп фермада сыер саварга кергән елны Камәр карчык бөкрәеп, ике кулын беләнә салып йөри башлады. Аның тыны кысыла иде һәм гомер буе кара эшне җиңел кулдан әйләндереп йөргән Камәрне бу хәл бик җәберсетте. Нигәдер тыны кысылуын кешегә белдертергә оялды. Таудан менгәндә тыны беткәнне кеше сизмәсен өчен туктаган җирендә я киртәгә таянып берәр әрекмән өзеп караган була, я кулын каш өстенә куеп су буена таба карап тора иде. Янәсе, нәрсәдер эзли, тын бетүдән туктау түгел. Дөрес, үлем турында уйларга әле иртә иде, шулай да:

— Ярабби ходаем, салкын кышларда җир астына керүдән үзең сакла,— дип ешрак әйтә башлады.

Саимә эшкә бик каты куллы булып чыкты. Камәр карчыкның тормышы яңадан үз эргәсенә керде. Кызы иртәнге савудан кайтканчы көн саен таба ашы пешерүне үзенә гадәт итеп алды. Юмартлыгы белән күрше-тирәдә дан тоткан Камәрнең моржасыннан һәр көн майлы таба исе катыш төтен күтәрелә иде. Бердәнбер сердәше булып калган Саимәне ул кыстый-кыстый ашата, чынаягын каплагач та берне кыстап эчертә. Коймак-кабартманы мул итеп майларга ярата. Әгәр арпа коймагы пешерсә:

— Әйдә, майлап аша, арпа чыкны ярата ул,— дип кыстый.

Саимә эшләргә таза булган кебек, ашауга да таза иде. Кызарып янып, өстәл яныннан торып киткәндә ул әнисенә рәхмәт әйтә, әнисе исә тагын кыстый.

Җиләк вакытында Камәр карчык берүзе урманга әллә нинди ерак урыннарга китә, бер дә шикләнмичә ялгызы гына йөри, көндезге чәйгә дип урман буендагы сыер фермасындагы кызына җиләк чыгара. Алып кайткан җиләген күрше-тирәгә, өйдә яшь бала карап яткан карчыккорыга өләшә. Кешедә дә ул үзен өендәге кебек хис итә. Күршеләре аш ашап утырган вакыт булганда, ул стенадагы кыстырмадан кашык, чәй вакыты булса: «Кая, тәм-томыңны китер, әйдә»,— дип, чынаяк ала кила. Моны берәү дә гаеп итми. Бары тик Камәр булганга гына гаеп итми.

Камәр карчык белән бервакыт район вәкиле кызык кына итеп танышты. Вәкил яшь иде, тормышның тегенди-мондый чыгармаларын белми иде. Кызу эш өстендә басу уртасыннан ярып җиләк күтәреп кайтучы карчыкка эрәгә генә бәйләнде.

— Нигә эш өстендә кеше котыртып йөрисең син?— дип, мотоциклын сүндермәгән көе генә Камәр карчыкның юлын бүлде. Карчык вакланмады.

— Мена,— диде,— әллә нәрсәсенә җиләк белән чәй эчәсем килеп китте әле...

Вәкил аның саен кызды. Бәрелеш «М-72» мотоциклының бишегенә Камәр карчыкны утыртып идарәгә алып кайту белән тәмам булды. Хәер, тәмам булды дип моны вәкил генә уйлады. Идарәгә кайтып кергәч Камәр карчыкка тел керде.

— Мена әйбәтләп кенә өйгә дә кайтарып куй инде, яме. Билләремне дә бик селкеттең,— диде. — Мин,— диде,— шушы колхозда гомер буе ирем белән ат караган кеше булырмын. Минем ирем кырык икенче елның март числосында урман эшеннән кайтканда үлде. Малаем сугышта бетте. Бер малаем армия хезмәтендә. Кече кызым шушы калхузда иң тырыш сыер савучы. Инде өемә кайтарып куй. Кызыма җиләк белән чәй эчерәсем бар. Төш вакытына кайта ул.

Бөтен урамның гаҗәпләнүенә каршы, Камәр карчык үз йортына мотоцикл бишегенә утырган килеш кайтып төште.

Сыер савучыларның дәрәҗәсе бик күтәрелеп киткәч, Камәр карчыкның тормышы тагы да ямьләнде. Саимә иң алдынгы савучы булып исәпләнде, ел саен күргәзмәләрдән зур-зур бүләкләр алып кайтып

йортны тутырды. Авылда беренче булып электр самавары Камәр карчык өстәленә менде. Мәскәү күргәзмәсендә Саимәгә күче белән фарфор чынаяклар бүләк иттеләр. Камәрнең моржасыннан хуш исле сыек төтен көн дә күтәрелде. Саимә йортны баетты да баетты. Инде кияүгә чыгу яшеннән узып барса да, бу турыда ана белән кыз нигәдер бер дә сөйләшмәделәр. Саимә шәһәргә барган җиреннән әтисенең һәм сугышта үлгән абыйсының фоторәсемнәрен зурайтырга бирде. Һидиятулла картның утызынчы елларда ук урман эшенә барган җирдә документка дип төшкән бармак бите кадәр генә, саргайган, таушалган фоторәсеме бар иде. Шәһәр фотографы шул тонык рәсемнән могҗиза ясады: ап-ак күлмәккә кара галстук таккан, яхшы пиджак кигән тап-таза яшь бер кеше зур рам эченнән Камәр карчыкның өстәлендәге самаварына карап тора иде. Һидиятулланың үлгәненә күп гомерләр үткәнлектән, Камәр үзе дә, рамдагы бу кешенең фотограф могҗизасы икәнлеген уйлап тормастан, аңа Һидиятулла дип карап яши бирде. Теге оста фотограф карчыкның сугышта үлгән улын да шулай бизәде. Аның фронтта вакытта чәчсез, кайгылы кыяфәттә төшкән бармак башы кадәр саргылт рәсеменнән кокардалы фуражка, йолдызлы погоннар таккан әллә ниткән карчыга борынлы егет килеп чыкты. Камәр карчык монысына да минем улым дип ышанды. Ике рам стенага менеп урнашкач, гаилә бөтенәеп китте. Ул арада Саимәне район советына депутат итеп сайлап куйдылар. Камәр карчыкның шатлыгына чик булмады. Аның өчен бәхетле көннәр башланды.

Дөрес, депутатлык карчык өчен генә шатлык булды. Саимә өчен аның иң авыр мәшәкате әле сайланганчы ук башланды. Иң башта аңа «доверенный» дигән бер кеше беркеттеләр. Бу кеше — башлангычта Саимәне дүрт ел буе укыткан илле-илле биш яшендәге укытучы абзый иде. Әнә шул «доверенный», кучерлы атка утыртып, аны авылдан-авылга йөртте. Иң беренче авылда очрашу бик кызык булды. Клуб бизәлгән, халык бәйрәмчә киенгән, клуб шыгрым иде. Кул чабулар, биография сөйләүләрдән соң Саимәнең үзенә сүз бирделәр...

Нәрсә дип сөйләсен соң ул?

Иптәшләр, рәхмәт сезгә, бик зурладыгыз, мин үзем турында андый ук зур фикердә түгел идем, дипме? Минем сыерларны яратып каравым һәм күп сөт савып алуым һич тә моның өчен түгел иде, дипме? Нәрсә әйтсен соң ул? Мин бер дә сөйли белмим, мине болай газапламагыз, мин эшли генә беләм, дипме?

Камәр карчык, стена сәгатенә карый-карый, бу минутта токмач җәйде. Җыелыш инде бетеп килер вакытлар иде.

Саимә исә трибуна артына чыгып баскан килеш бу вакытта тик тора бирде. Үзенең сөйли алмавыннан ул кып-кызыл булып янган, читкәрәк карап тора иде. Аның өчен «доверенный» сөйләде.

— Иптәшләр,— диде ул, җиз чыбыклы күзлеген колакларына эләэлә,— иптәш Һидиятуллина бик дулкынланган. Ул сезгә ышанычыгызны акларымын дип әйтә. Ул сезгә рәхмәт әйтә. Ул әйтә...

Сөйли торгач анысы да каушады.

Аннан соңгы җыелышларда Саимә язганнан укып сөйли торган булды.

Камәр карчык исә бу мәшәкатьләрне белми, ул гел шат иде.

Дөнья дигәнең тәгәрмәч кебек әйләнә дә тора. Тигез генә тәгәрәгән җиреннән бервакыт Камәр карчыкның тормышы тагын сикәлтәле юлга барып керде. Бу болай булды. Район советы сессиясеннән Саимәне урман артындагы колхозның бригадиры Хөснулла мотоциклы белән авылга кайтарып куйды. Капка төбендә Саимәне төшереп, тыр-пыр килеп урман юлына чыгып чапты. Саимә көләч йөз белән капкадан керде, әмма койма ярыгыннан барысын да күреп торган карчыкның шул минутта йөрәге чәнчеп алды.

— Бу кеше зрэгэ йөрми,— дип уйлады карчык. Бер-ике көннән капка төбендә тагын мотоцикл туктады. Аннары тагын. Ләкин ана да, кыз да бу турыда телгә алып сөйләшмәделәр. Ә бер айдан соң Саимә, ферма мөдире һәм урман арты колхозы бригадиры Хөснулла Камәр карчыкның өенә бергә килеп керделәр. Хөснулла комбинезон кесәсеннән кыйммәтле конфетлар чыгарып өстәлгә куйды, ә ферма мөдире Камәр карчыктан ике стакан сорап алды. Шуннан әллә ниләр булды, әллә ниләр булды... Камәр карчык боларны төштә күргән кебек кенә тоеп йөрде. Октябрьның коры салкын иртәсендә ишегалдына ялтыравыклы җиңел ак машина килеп кергәнен дә, өч-дүрт кызмача егетнең зур сандыкны йөк машинасына мендергәннәрен дә Камәр карчык төштә күргән сыман гына тойды.

Йорт мәет чыккандагыдай бушап калды.

Камәр карчык түшәгенә менеп ятты һәм:

— Ярабби ходаем, салкын кышларда җир астына керүдән үзең сакла,— диде.

Өч көн буе карчыкның морҗасыннан төтен чыкмады. Ә дүртенче көнне бер төенчек кипкән җиләк, каклар алып карчык урман артындагы авылга чыгып китте. Кияү белән кыз карчыкны алып килергә дип ат җигеп яталар иде, капкадан бөкрәйгән, төенчек аскан әниләре килеп керүгә каушап калдылар.

Ялгызлык төрлечә була. Карт кыз ялгызлыгы була, ул әле үзенең эшен, үзенең пөхтә итеп җыештырган урын-җирен яратып, юлдаш итә. Өч көн саен кер юып, бөтен әйберен ап-ак итеп саклау белән ул үзенең йөрәген баса. Тол калган карт ир ялгызлыгы була: я ул лапасында балта эшенә тотына, кызларының, уларының балаларына агач карават ясап юана, я сакал-мыек үстерә, атнасына ике-өч тапкыр көзге каршында шуларны рәтләп юана. Аргы як урамдагы тол хатын Габделбануга сүз салып карасам, карт дип әйтмәсме икән, диген авыр, ләкин татлы уй белән аның каны җылынып-җылынып ала.

Ә карчыклар ялгызлыгы? Яман! Ят та үл!

Көзге пычраклар башланганда карчык ялгыз калды. Фәхрислам да, килен дә үзләренә чакырып карадылар, карчыкның нигезен ташлыйсы килмәде. Көзге кичләрдә урам аркылы чыгып булмаслык пычракта кунарга керергә күрше карчыгын чакырып карады — карчык пычрак ерып урам аша чыга алмады: озын куныччы «бутый»лары юк икән. Камәр карчык аңа икенче кичне Саимәдән калган «бутый»ларны ыргытты. Итекнең берсе исә урамны аркылы чыга алмады, машина эзенә пычракка барып төште... Кыскасы, пычраклар бетмичә кунарга иптәш кертү турында уйларга да ярамый иде.

Бервакыт туңдырды. Урамда йөрерлек булды. Коры һава карчыкның бераз гына кәефен күтәрсә дә, йортка ямь өстәмәде. Карчык өеннән чыга да китә. Бара, бара, Фәхрисламнарга таба. Бара торгач кинәт кенә туктый да басып тик тора. Аннары кире борылып кайта. Урамның икенче башына таба барып карый. Кемнәргә, нинди йомыш белән бара ул? Моны белү дә белми. Хәтта карчык үзе дә. Аның тузган, картайган миеннән әллә кайчан булып үткән вакыйгалар уза.

Зур сулы, болынлы авылдан урман буендагы бу авылга ул уналтынчы елның кышында килен булып төшкән иде. Әнисе аңа бик игелекле бер ана каз биреп җибәрде. Ел саен уникe бәбкәдән дә ким үстерми иде. Яз җитү белән уңган каз яңа нигездә унөч йомырка басып утыра башлады. Май уртасында тупырдашып унбер бибы чыкты. Әле иренә һәм үги Фәхрисламга иләнеп бетмәгән яшь килен казны үзенә иптәш, сердәш итеп тойды. Бер нигездән бит алар...

Берничә көн урамда киләп сарып йөргәч, Камәр карчык та үзенең бердәнбер Саимәсенә таба юл алды. Һәм барып җитте. Шул ук көнне

әйләнеп кайтты. Шуның белән тормыш ямьләнеп, күз кыскарып китте. Урман аркылы карчык үзе генә белгән изге, кадерле сукмак салынды...

Камәр карчык салган сукмакны кышкы бураннар күмде. Яз житүгә, карчык, баласын югалткан ана бүредәй, тагын урман сукмагын таптый башлады. Көн аралаш морждадан хуш исле төтен чыга иде. Көн аралаш Камәр карчык бөкрәеп, төенчеген асып урман юлына чыгып китә иде. Моны кияү дә, кызы да, кодагый да тыя алмыйлар, тыяргa да уңайсызланалар иде. Ә бер көнне Саимә әнисен озата килгән жирдән нигәдер авыз суын корытып чөгендер пәрәмәчен телгә алды. Карчык моңа бик нык игътибар бирде. Кайткан көнендә үк узган елдан калган чөгендерләр эзләп тапты, төне буе аны пешерде. Район сабан туе көне иде, урамнан шау-гөр итеп машиналар узып торды, карчык капкасыннан башын да тыгып карамады. Пәрәмәчне бүген үк илтеп житкерергә уйлады ул. Мич янында матавыкланганда үзе бер өзлексез теләк теләде:

— Бәхете-тәүфигы белән дөньяга килсен, хәерле эшләр булсын!

Камәр карчык пәрәмәчне никадәр тиз илтеп житкерсә, туачак бала шул кадәр таза, сәламәт булыр дип уйлап рәхәт чикте. Алла сакласын, юк кына бер әйберне вакытында авыз итми калсаң, битендә, маңгаендa миң белән тууы бар.

Жәйге озын көн кичкә авышып, кешеләр сабан туйдан кайта башлаган сәгатьләрдә карчык төенчеген күтәреп, житен басуы арасыннан урманга таба чыгып китте. Аның адымы башка вакыттагыга караганда кызурак иде.

...Камәр карчык жәйге жылы кичтә урман эчендә аңгыраеп-адашып йөргәндә Саимә белән Хөснулла колхоз болынында алдынгылар өчен хәзерләнгән аш мәжлесендә утыралар иде. Хөснулла, чирәмгә кырын ятып, Саимә белән бергә жырлый. Бер төркем ферма кызлары район кунаклары белән бииләр, паласлар тулы ризык, эчемлек. Туклык, күңел күрлеге, шатлыктан башка дөньяда әйтерсең лә бүтән берни дә юк иде.

Сабан туйның икенче көнендә иртән жылы яңгыр явып узды. Ялт итеп кояш чыкты. Бөжәкләр, кош-кортлар гөж килделәр. Жир йөзе бал исе, өлгереп килгән арыш исе белән тулды. Жәйге тымызык көндә бакчадагы тополь яфраклары моң гына кыштырдашалар иде. Ул көнне зираттагы хуш исле каеннар арасында тирән бер чокыр казылды. Чәчәкләр, чирәм өстенә өелгән кызыл балчыкны июнь кояшы жылытты да жылытты.

Камәр карчыкның теләге үтәлде: ул жәйнең иң жылы, иң матур вакытында жир куенына керде.

Камәр карчыкның өй тәрәзәләренә тактаны аның үги улы бригадир Фәхрислам какты. Шәйдуллага телеграмманы әнисен жирләгәч кенә суктылар: ул еракта, Батумидан ары, чик буе гаскәрләрендә сверхсрочный хезмәттә иде. Татар халкы мәетне өйдә озак тотмый...

## Бер ямьсезгә бер матур

Шәйдулла сверхсрочный хезмәткә нибары ике генә елга калган иде. Әнисе үлгәндә үзенең өйдә булмавына ул бик үкенде. Срок тутырып бөтенләй кайтырга өч-дүрт кенә ай калган иде, югыйсә.

Солдатлар сверхсрочникны яратмыйлар. Алар арасында сверхсрочникның исеме — «макаронник», флотта — «сундук». Шәйдулла бу исемнән бик гарьләнә иде. Сүз тыңлап кына калды бит ул. Аны сверхсрочникның хезмәт хакы да, льготалары да кызыктырмады. Демобилизация алдыннан мәсьәлә шулай куелды ки, әйтерсең лә Шәйдулла

кайтып китсә, хуҗалык взводы бөтенләй таркалачак иде. Һәм Шәйдулла калды. Әнисе үлгән көннәрдә яман төшләр күреп саташты, онытылган, томан артында калган этисе төшкә керде: әнисен житәкләгән дә, ындыр артындагы ат абзарларына таба китеп баралар. Төшкә ышанган кеше өчен яман төш бу!

Житмәсә, шул көннәрдә генә Шәйдулла отделениесендәге бер солдат бәхетсезлеккә очрады. Коля Шмагин дигән Ютазы егете. Армиягә алынырга бер атна кала гына өйләнгән булган. Килүгә хәсрәткә батты. Присяга кабул итеп, беренче тапкыр постка куйгач, постын ташлап киткән. Аны тимер юл вокзалыннан патрульләр тотып комендатурага китерделәр. Часть командиры катнашында беренче тапкыр сорау алганда Шмагин башын түбән иде һәм бер генә җөмлә әйтте.

— Хатынымны сагындым. Бер генә көн өйдә торып килмәкче идем,— диде һәм үкереп елап җибәрде.

Туган ягын Шмагин кадәр сагынучы булырмы икән! Бервакыт кызыл почмакта утырганда Шмагин Казан радиостанциясен тотты. Күп эзләп, күп борып. Нәкъ ял концерты вакытында. Татарча концерт. Ләкин ул концерт Шмагинга татарча булып түгел, ә туган як, туган йорт музыкасы булып ишетелде. Сөләйман Йосыпов «Умырзая»ны җырлый иде. Ерак Төркия чигендәге погранзастаЕаның таулар арасындагы казармасында Ютазы егете Коля Шмагин шул чакта елады. Сагынып, яратып елады.

Теге вакытта командование Шмагинны трибуналга бирмәде. Унбиш тәүлек гауптвахтада утырып чыкканнан соң Шмагин йомылды. Шәйдулла, сверхсрочник булса да, квартирага күчмәгән, солдатлар белән бергә казармада яши иде. Шмагинның караваты аннан ерак түгел. Соңгы вакытта болай да йокысы качкан Шәйдулла төннәрен Шмагинның уфылдап әйләнгәләп ятканын сизә иде. Ә бер төнне әнисе хакында әллә ниткән чуалчык төш күреп уянып китсә — ике катлы караватлар арасында елаган тавыш ишетелде. Шмагин икән. Шәйдулла урыныннан торды, яшь солдатның янына килде. Шмагин мендәргә капланып яткан да тыела алмыйча елый, аның таза, куәтле гәүдәсенең дерелдәвеннән караватлар селкенә иде. Шәйдулла каушап калды. Солдатның аркасына кулын куйды.

— Я, нәрсә син, туганкай,— дип чак әйтә алды.

Солдат юеш мендәрдән башын күтәрде.

— Тотмыйлар, тотмыйлар аны минем кулда, иптәш сержант,— диде ул яшь аралаш.— Мена әйткән иде диярсез. Барыбер Костя сугып алачак аны. Аларның элек-электән танышлыклары бар. Әйткән иде диярсез...— Солдат яңадан дерелдәп елый башлады. Аннары бераз тынычлангандай итте. Торып күлмәген киде, аскы катка төшеп Шәйдулла янына килеп утырды.

Шмагин шунда беренче мәртәбә ачылып китеп Шәйдуллага эч серен сөйләде. Костя— тимер юл техникумын бетереп чыккан чибәр егет, футболчы икән. Венера белән алар электән таныш булганнар. Ләкин Венера аның үз-үзенә бик нык ышанганын, җиңүчән кыяфәтен, борын күтәреп йөрүен яратмаган. Ул арада бию кичәләренең берсендә Венера белән Шмагин танышкан. Шмагин буйга да кечерәк, белеме дә ремесленныйдан узмаган. Шулай да ике айга сузылган танышлык мәхәббәт булып бөреләнгән һәм Коляның военкомат кушуы буенча чәчен кырдырып алдырган көнне аларның туе булган. Шулай итеп фельдшер-акушерлык мәктәбенең өченче курсындагы Венера Колялар өенә килен-солдатка булып килгән. Өйдә алар ике хатын — Коляның тол әнисе белән яшәп калганнар. Хәрби эшелон киткәндә, Коляны озатучылар арасында Костя да булган. Аның күзләре яман елтырап калган. Хәрби эшелоннан «утырырга» дип команда биргәндә дә Коля аның салкын карашын күреп алган. Шул караш аңа тынгылык бирми икән...

Казарма синең йокысыз төннәрең белән исәпләшеп тора алмый. Иртән гадәти тормыш башланды: физзарядка, иртәнге аш, занятиеләр. Солдат өчен иң күңелле вакыт — көндезге аш алды. Бу вакытта почта килә. Хатны кадерләп кенә кесәңә саласың, ашханәдә аны әле укымыйсың. Ул синең тәнеңә туган як җылысын бәреп тора. Төшке аштан соң ял сәгатендә хат уку моменты — солдатның иң изге, иң кадерле минутлары... Солдат тормышының бөтен авырлыгы әнә шул минутта юкка чыга да бетә.

Шмагинга ул көнне посылка кәгазе килгән иде. Аның түбәсе күккә тиде. Төштән соң ана бер сәгатьлек увольнительный бирделәр. Почта бүлегеннән кайткач Шмагин кичкә кадәр кая басканын белмичә йөрде. Кеше саен сигарет, конфет өләште.

— Венера салган!

— Венера җибәргән конфетлар!— дип сөйләнде.

Шмагин сабый баладай шатланган иде. Аңа карап Шәйдулла да шатланды.

Кичке почта исә ике телеграмма китерде. Аларның берсе Шәйдуллага, икенчесе Коляга иде. Шәйдулла эченнән бу хәлгә инде әзер иде. Фәхрислам абыйсының артык кайгырмыйча гына, ләкин олы кешеләрчә ихтирам һәм тәгаллек белән әнисен җирләгәнен ул телеграмма текстыннан аңлады...

Коля телеграммасын берәүгә дә күрсәтмәде.

Төн уртасында аны туалетта кулына бау тотып йөргән вакытта дневальныйлар күреп алалар... Иртән солдатлар торганда, ул инде хәрби госпитальнең тәрәзәсе тимер рәшәткәле палатасында иде. Гимнастеркасын салдырып, госпиталь халатын киерткәндә военврач аның күкрәк кесәсеннән телеграмма бланкысын алып укый. «Венера соңгы вакытта Костя белән очраша. Сиңа яхшылык телә үче».

...Ике еллык договор срогы тулгач, Шәйдулла бернинди кыстауларга бирешмичә кайтырга булды. Соңгы документлар, билетларны кесәсенә салгач, ул, кучтәнәч алып, Коля Шмагин янына барды. Госпитальдә авырулар белән очрашу сәгате инде тәмамланган иде. Ул Коля белән бакча яктан тәрәзә аркылы гына сөйләште.

— Сез дә китәсезмени инде, иптәш сержант?— дип, ялварулы караш белән Коля аңа текәлде. Ул ябыккан куллары белән тимер рәшәткәләргә тотынган, ачык форточка турысына битен терәгән иде.— Сез дә киткәч миңа бик күңелсез булыр бит...

Шәйдулла үзенең тавышын көрәйтергә маташты.

— Кайгырма, туганкай, кайгырма. Менә командованиедә шундый сүз булган: бер атнадан сине чыгаралар. Тазарып беткән бит инде синең нервалар. Аннары сине өегезгә кайтарып җибәрәләр. Бераз ял итеп килерсең. Үзем ишеттем.

Коля дерелдәп китте.

— Бөтенләйгә комиссовать итмиләрдер бит? Минем кеше белән бергә хезмәтемне тәмамлап кайтасым килә.

— Юк, нигә алай булсын. Мин ишеттем, сиңа нибары ун көн ял бирәләр икән. Ә теге мәсьәлә ачыкланган: Венераның иптәш кызларыннан берәү үч итеп эшләгән аны. Анда бөтен Ютазы шаулаган: ул кызны комсомолдан куганнар, газетага язганнар.

Коляның күзләрендә яшь күренде.

— Мин аның шулай буласын белгән идем, иптәш сержант. Мин шулайдыр дип уйлаган идем...

— Ә Венераң сине кунакка көтә. Анда, командир өстәлендә, сиңа бер пачка хат. Үзеңне көтәләр. Я, тизрәк чык. Бөтенләй кайткач безнең районга килегез. Теләсәгез — бөтенләй күчеп. Адресым сиңа билгеле. Анда авылда минем бер үземә бер йорт. Я, Коля дускай, хуш!

— Рәхмәт, иптәш сержант! Мәңге онытмам сезнең бу яхшылыгызны. Мин шулайдыр дип уйлаган идем...

Батуми-Мәскәү поезды китәргә ике сәгать кенә вакыт калган икән.

... Сержант Шәйдулла туры аргы яктагы Фәхрислам абыйларына барып төште. Кич иде, кырыс октябрь киче иде, чәй эчкәч ай яктысында зиратка барып килделәр. Зират коймасы буенда такта чардуган эчендәге зур кабер Камәр карчыкка мәңгегә бирелгән, черми-тузмый торган соңгы йорт иде.

— Рәхмәт, абый,— диде Шәйдулла, чардуганга сөялеп,— энине олылагансың.

Фәхрислам аз сүзле, нык куллы хуҗа иде, артык тәфсилләп тормады.

— Кабер өстенә сардуган кору саваплы эс,— диде ул.— Кесе арасында минем автаритны күтәрә торган эс ул.— Аннан кинәт кенә сүзне борды.— Инде өйлән,— диде ул.— Зәмзәмбикә сине көтә. Өеңнең тәрәзәсенә суккан тактаны иртәгә асыйк. Берсекөнгә Зәмзәмбикәне алып кайтыйк...

Шәйдулла Зәмзәмбикә белән ялга кайткан чакта танышкан иде. Фермада учетчица кыз. Таза тәнле, көр тавышлы. Тормышны эһ тә димичә алып барачак. Тик саңга сугып бетермәде бугай, Шәйдулланың өч хатына бер хат белән җавап биреп торды... Этисе — Галләмгали агай шундый һавалы кеше.

Икенче көнне клубта Шәйдулла бөтен кеше алдында Зәмзәмбикә янына барып күреште. Кино беткәннән соң, түгәрәк уен бара иде. Зәмзәмбикә белән алар клубтан бергә кайтып киттеләр. Сүз ябышмады, сержант Шәйдулла үзенең нык, дәү кулларын кызның җилкәсенә куйды да туры ярып әйтте:

— Яшьтәшләр өйләнеп беткән. Мин ялгыз калганмын. Минем хатын булырга ризамы? Абый белән җиңги иртәгә тана суялар. Иртәгә кичкә алар йортына төшәргә ризамы? Берсекөнгә үзебезнең йортны ачып кирәбез.

Зәмзәмбикә бик борнай булып чыкты. Баш та тартмады, өзеп кенә ризалык та бирмәде. Сержант тирләде. Бөрезлексез таптанып торды. Солдат вакытта ул җиккән карт ат шулай аяк алыштыра иде.

— Иртәгә кич мин клубта булам, шуннан шома гына итеп урлый алсаң инде, — дип көлде. — Эти-энинең авылга бирергә исәпләре юк. Кизилдагы апалар янына озатасылары килә. Үземнең дә күңел ике арада...

Икенче көнне кич Фәхрисламнар өендә мул итеп ит пешерелгән, тутырма тутырылган, шкаф астына дүрт ярты алып куелган иде. Шәйдулла белән Фәхрислам йорттагыларга чоланда ут кабызырга кушып клубка киттеләр. Клубның ишегеннән пар бәреп тора, яшьләрнең октябрь бәйрәме алдыннан була торган күңел күтәренкелеге урамнан ук сизелә иде.

Барып керделәр. Кара-каршы бию икән. Шәйдулла түр як стена кырыенда утырган, бик хәтәр итеп бизәнгән Зәмзәмбикәне күреп алды. Зәмзәмбикәнең башында кыйммәтле мамык шәл, өстендә әлегә Вятские Поляны маржалары гына кия торган кара плюш жакет, аякларында ялтыравык «бутый»лар иде. Фәхрислам да җаваплы эш алдыннан, гадәт буенча, «Прибой» чыгарып авызына капты. Зәмзәмбикә дә боларны күрде. Шулчак кемдер аны уртага чакырды. Зәмзәмбикә бии башлады. Монда вакыт чикләнмәгән, һәркем үзе теләгәнчә, теләгән кадәр бии, теләгән кешесен каршысына чакырып бии иде. Шәйдулла ременьнәрен рәтләде, яшел түбәле фуражкасын турылап киде. Авыл клубында аның әле беркайчан да биегәне юк иде. Менә хәзер ничек тә башкарып чыгарга туры киләчәк. Әйдә, ярар, тизрәк чакырсын гына. Бүген — җаваплы көн, беренче һәм соңгы тапкыр биеп алудан дөнья җимерелмәс...

Зэмзэмбикэ исэ Шэйдулланы түгел, Шэйдулла танымаган яшь, ыспай бер егетне чакырды. Кунак егет-мазардыр. Биергэ оста икэн. Чүгэчүгэ дэ, бармак шартлатып та, Зэмзэмбикэнең бармак очын тотып эйлэндерэ-эйлэндерэ дэ биеде. Шэйдулла үзенең ременьне артыграк кысканлыгын тойды. Колаклары янды. Зэмзэмбикэ исэ теге яшь егет белэн һаман биеде. Аның инде шэллэре шуып төшкэн, битеннэн-башыннан кершэн катыш пар бэрэ. Гармунчы да саташа башлаган иде инде.

... Шэйдулла белэн Фэхрислам бер-берсен сүзсез аңладылар. Тышта коры һава, чалт иткэн аяз иде. Аяк асты каткак, юлда хэтта тузан да бар. Ике туган сөйлэшмичэ генэ авыл читенэ таба атладылар. Клубның ачык ишегеннэн җыр ишетелеп калды:

Аягыңдагы бэтинкэң
Шыгырыммы, хроммы,
Бөтен дөньяны балкыта
Бар да синең нурыңмы?

Бию туктаган, түгэрэк уен башланган икэн. Колхозның идарэсе урнашкан күрше авылда клуб мөдире булып Сөембикэ эшли иде. Фэхрислам белэн очрашкан саен шаярып:

— Я, энекэшең кайчан кайта, мине кайчан энекэшеңэ димлисең инде, — дип челтерэп көлеп сөйлэшэ иде.

Сөембикэ бөтен тирэ-якка билгеле матур кыз иде. Җырга, биюгэ оста. Агитбригадалар белэн йөри. Нэселен-нэсэбен белгэн кеше юк, еpaктан килгэн дилэр. Шэйдулла исэ чибэрлэрдэн түгел. Тупас гэүдэле, каты куе чэчле, битендэ җирэн сипкеллэр, эре тешлэр. Сүз аз. Уенкөлке дэ юк. Лэкин Фэхрислам абзыйсы гел сөйли иде бит.

— Сыерсык сайраганда,— ди иде ул,— болай сайрый икэн: бер матурга бер ямьсез, бер ямьсезгэ бер матур, дип көннэр буе агач басында утыра икэн. Дөрес, сирэк кенэ «бер матурга бер матур» дип тэ ыскындыра икэн. Лэкин ни Фэхрисламның, ни аның хатынының сыерчыктан энэ шул соңгысын ишеткэннэре юк икэн эле...

Ике туган күрше авыл клубына таба юл тоттылар. Уңышлы сэфэр аларга!

•

## «Алдым-бирдем» алдыннан

Кукуруз чэчэ башлаганга ике ел тулганда колхоз председателе Вэли абзыйны эшеннэн азат иттелэр.

Вэли абзый шэп кеше, үз кеше иде. Колхоз белэн озак еллар житэкчелек итте. Машина бирмэкче булганнар иде, межрайбазаның тузган газигын тэкъдим итеп караганнар иде — алмады. Гомер-гомергэ атка утырып, пычрак вакытта атланып йөрде. Сугыш вакытында эчте. Кичлэрен эш беткэч, үз өендэ шыпырт кына эчте. Сугыштан соңгы елларда да бөтен кайгысын, борчуын шуның белэн басарга тырышты. Алган выговорлары да шактый иде. Лэкин районда да, халык арасында да аңа ихтирам зур иде. Эчкэнен кешегэ күрсэтмэде, э выговорлар я рөхсэтсез чэчү мэйданын үзгэрткэнгэ, я вакытында чэчүне тэгэллэмэгэнгэ бирелэ иде. Гомере буе семья, бала-чагасын кайгыртмады. Балаларына ничэ яшь, ничэнчедэ укыйлар, нэрсэ ашый, нэрсэ эчэлэр — Вэлиулла абзый андый мэшэкатьлэрдэн азат иде. Кызы Нажия һэм улы Марат шуңа этисез балалар чутыннан үстелэр, аларны караучы ата — колхозныкы, җэмэгатьнеке иде. Вэлиулла абзыйның сэер генэ гадэтлэре булгалый иде. Бервакыт процентка бирелэчэк люцернаны бүлэсе көнне иртэн идарэ янына ирлэр җыелды. Кичтэн колхозның печэнен җыю

тәгәлләнгән, акча да өләшенгән, кибет артындагы тавык үләнендә өчәр-өчәр булып кыскача гына утырыплар да алынган иде. Бүген — бәйрәм сыман көн, тракторлар, автомашиналар идарә янына җыелган, процент печәнен өйләргә ташыйсы көн иде. Тик әле кайсы бригадага кайсы басудан бирү мәсьәләсе ачыкланмаган, монда Вәли абзыйның соңгы сүзе кирәк иде. Ә ул килмәде. Үз гомерендә беренче мәртәбә иртән килмәде. Нәкъ ике сәгать көттеләр — башка көнне ул иртәнге биштә монда була иде. Сигезенче китте. Инде таралышабыз дип торганда гына, коймa буйлап хәлсез генә атлап килгән председательне күреп туктап калдылар. Ризасыз гына сәлам бирделәр.

— Әйдәгез, керегез әле минем янга, — диде Вәли абзый, аларга күтәрелеп карамыйча гына. — Керегез әле, сүз бар.

— Без күп бит, — диделәр аңа, — майлы-тузанлы кием белән нәрсә калган анда, сүзеңне монда гына әйт.

— Юк, керегез әле, ирләр генә керсен әле, — диде председатель, һаман күтәрелеп карамыйча гына. — Кәнсәләр идәнен юучы табылыр. Керегез.

Җыелышып керделәр. Вәли абзыйның күз кабаклары шешенгән иде.

— Минә сез мине сүктегез инде бүген, — дип сүз башлады ул, түбән караган килеш. — Сез мине гафу итегез инде, культурно гына әйткәндә. Ни өчен соңладым? Кичтән эчкән идем. Печән эшен тәмамлау уңае белән. Иртән тора алмадым. Минә күпме кешене көттердем, күпме кеше-көнгә зарар салдым. Минә шуннан карагыз да белегез инде: эчкән кеше кадәр зарарлы адәм юк бу дөньяда. Минә сезгә гыйбрәт: я, нинди председатель инде үз колхозчыларын шулай көттерә? Юньле кеше эшеме бу? Минә бер механизатор эчеп шулай иртән көттерсә, председатель белән бригадирның хәле ничек булганын аңлагыз инде.

Ирләр күтәрелеп карарга кыенсынып тордылар.

... Районнагы оешмалардан Вәли абзый бигрәк тә авыл хуҗалыгы идарәсе белән килешә алмады. Выговорларның күбесе әнә шул идарә белән мөнәсәбәтләренең киеренке булуыннан килә иде.

Соңгы ике елда ул берничә мәртәбә каты-каты «янды». Сыерлар белән дә, үзенең үҗәтлеге белән дә «янды».

Сыерларга ашатырга азык аз ел иде, язга бик ябыгып чыктылар. Авыл хуҗалыгы идарәсенең бөтен бәйләнгәне сөт алуның түбән булуына иде. Май ае җитте, сыерлар урманга керде. Сөт саву да нормага житкән сыман иде. Ләкин районга кайсыдыр жалоба җибәргән: Вәли абзыйның, имеш, учетка алынмаган биш-алты баш сыеры бар, уртача савым шуларныкын кушкач кына күтәрелеп китә икән. Районнан ревизия килде. Урман буендагы утарга төш вакытында гына машина белән килеп туктадылар да сыерларның урманнан чыкканын көтәргә булдылар. Вәли абзый эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлады. Ревкомиссия членнары белән улаклар, флягаларны карап йөргән арада Саимәнең җиңеннән тартты һәм өч бармагын күрсәтеп, урман якка карап күз кысты. Саимәне ай күрде, кояш алды. Ярты сәгать утәр-утмәстә агачлар арасында колхоз көтүе күренде. Әле яз башы гына иде, каудан ашап сусаган сыерлар улаклар янына ашыкты. Ревкомиссия эшкә тотынды. Улак янында санау мөмкин булмагач, сыерларны утарга яптылар. Яптылар да кире чыгара башладылар. Комиссия шул чакта санады. Районга бирелгән мәгълүматта йөз дә утыз бер баш иде, утардан да нәкъ йөз дә утыз бер баш чыкты. Вәли абзый йөзенә нахакка кимсетелгән чырай чыгарып читкә китеп барды. Саимә дә хәйләкәр елмаеп флягалар юып йөри иде. Нәкъ шул вакытта урман эченнән үкерә-үкерә зур гына бер куа сыер килеп чыкты. Мөгезендә ярты метрлар чамасы өзек бау кисәге иде. Нигә мине көндезге чәйдән мәхрүм итәсез дигән сыман мөгрәп ул су янына атлады. Вәли абзый шул вакытта сабый баладай кызарды. Алтмышка якынлашып килгән башың белән алдакчы исемен күтәр әле

син!.. Тегеләренең бавы нык булып чыкты, куе куаклыклар арасында күпме генә йөрсәләр дә, комиссия членнары сыер очратмадылар. Вәли абзыйга бавын өзгән бер сыер аркасында выговор эләкте. Бу вакыйга аңа зур сабак булды.

Язгы чәчүнең торышы буенча район башкарма комитеты колхоз председательләрен киңәшмәгә җыйды. Иртә культураларны чәчүнең барышы турында сүз чыккач, авыл хуҗалыгы идарәсе мөдире тагын Вәли абзыйга бәйләнде.

— Җәмәгать, юк, — диде Вәли абзый, — теләсәгез нәрсә эшләтегез. Унбишенче майга мин бетерә алмыйм. Иң уңай килгәндә дә унҗиде-унсигезләренә генә бетәчәк. Ялганлар хәлем юк. Авызым бер тапкыр пеште...

Идарә начальнигы аны шул киңәшмәдә өч мәртәбә талкыды. Башка председательләр инде, унбишенче майга бетерәбез, дип вәгъдә биреп котылганнар иде. Вәли абзыйдан дүртенче тапкыр вәгъдә таләп иттеләр.

— Юк, — дип киреләнде Вәли картлач, — булмагач — булмый. Партия мине ялганларга өйрәтмәде. Ялган миңа килешми дә. Мин инде сөт саву нормасын арттыру өчен бер ялган кыстырып караган идем — миңа килешми ул, әйеме. Анысы да сез бик кыскач кына, сез бик суккәч кенә. Хәзер җаным тыныч, иткә тапшырдым мин ул сыерларны. Ә монысына кыстамагыз да, әйтмәгез дә. Әйтеп торам — мөмкинлегем юк. Ике тракторым тик тора, запчастьне мин үзем ясый алмыйм.

Киңәшмә бетте, Вәли абзыйны алып калдылар.

— Хәзер бюрога алып керәм мин сине, анда әйтерсең сүзеңне, — дип өркетте идарә начальнигы.

— Теләсә кайда әйтәм: унбишенә бетерә алмыйм, — диде Вәли абзый.

— Синең,— диде идарә начальнигы ачы итеп сүгеп,— башың эшлиме, юкмы? Әллә картая торгач, бер-ике ширигы тутыкканмы? Синнән кем сорый аны, бетерә аласыңмы дип? Без аны үзебез дә беләбез...

— Соң, белгәч, ник кысасыз?

— Картайгансың,— диде идарә мөдире,— ә акыл җыймагансың. Безгә кеше алдында синең сүзең генә кирәк иде. Ә син саботаж ясыйсың. Өлгерә алмыйм, имеш. Аны кем белми? — Ләкин эш бюрога ук барып җитмәде, идарә начальнигы болай гына, куркыту өчен генә әйткән иде бугай анысын.

Кукуруз чәчкән вакытта кырга шул ук идарә начальнигы килеп туктады. Вәли абзый төзү материаллары эзләп межрайбазага киткән иде. Идарә начальнигы моңа ышанмады: ничек инде ул председатель кеше кукуруз чәчкәндә кырда түгел? Юлда очрашып кыскача гына сөйләшкән арада Вәли абзыйга «антикукурузник» дигән исем тагылды.

Җәй җитте, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, колхозга Фәхрислам улы Ленар кайтып төште.

Сабан туйга кадәр «алдым-бирдем» җыелышы булачак, Ленар председатель итеп сайланачак, колхоз тагы да ереләнәчәк, ике йөк машинасы, председательгә газик биреләчәк дигән хәбәрләр таралды...

## Бар нәрсә агышта

Вәли абзыйны, әлбәттә, зур почет белән озаттылар. Колхоз эреләнгәч, машиналар кайткач, «квадрат оялы» кукурузлар, яңача утыртылган бәрәңге басулары турында җитәкче сүз әйтергә аның инде хәленнән килми иде. Райкомга өч-дүрт гариза язды. Анда Ленар кайтканны көтәргә куштылар.

«Алдым-бирдем» җыелышына райкомның беренче секретаре үзе килде. Районның Почет грамотасын, көз аена Ессентукига бушлай

путевканы Вәли абзыйга үз кулы белән тапшырды. Вәли абзыйның аксыл мыек очларына әллә каян гына килеп берәр бөртек хрусталь тамчылар кунды. Кул чаптылар, мактадылар.

Бераздан Ленарны, бөтен тәртибен китереп, председатель итеп сайлап та куйдылар. Егеткә егерме алты яшь иде, армияне узган, югары белеме бар. Өр-яңа кара костюм кигән, ап-ак күлмәккә кап-кара галстук таккан, шома чәчле иде.

Җыелыш бетте. Вәли абзый райком секретарен үзенә чәйгә чакырган иде, арага Галләмгали агай керде.

— Ничек инде, миңа чәйгә кермичә, олы кунакны җибәрәсең? — дип, юлга аркылы төште. — Үзең дә рәхим итәсең — икегезне дә алып китәм! — диде.

Вәли абзый каршы килмәде, чөнки колхозга килгән олы кешеләрне, гадәттә, Галләмгали агайга фатир төшерәләр иде.

Райком секретаре исә яңарак кеше, бу колхозда алай иркенләп беренче тукталуы иде.

Яңа председатель белән саубуллашып, ул ике карт уртасына басты да мәктәп бакчасына терәп салынган шифер түбәле зур йортка таба юнәлде.

Галләмгали агай зур канәгатьләнү белән урыс капканың келәсенә басты: өр-яңа, әле сыткый сагызы да кипмәгән саргылт капка, борынга яңа такта исе бәреп, шыңгырдап ачылды.

— Малай комбайнда, — диде Галләмгали агай, аягын баскыч төбендәге резина сөрткечкә ышкып. — Рәхим итегез, өйдә карчык белән икәү генә. Малайның труддин шәп килә, акчаны мул ала.

Хуҗалык таза иде. Чоланда сепаратор, мотоцикл шиналары. Өйдә нарат бүрәнә исе, тәрәзәләрдә капрон пәрдәләр. Шау чәчәккә күмелгән яран гөлләре. Салмак кына текелдәп утырган зур сәгать. Түрдә радиоалгыч, аның өстендә китаплар.

Өстәлгә тәлинкә белән кайнар бәрәңге пәрәмәче килде. Мич алдындамы, керосинка өстендәме май чыжылдаганы ишетелә иде.

Галләмгали агай шкафтан өч данә чәй чокыры алып өстәлгә куйды. Мич артында нәрсәнедер чупыр-чупыр болгатып, авыш-тәвеш китереп бераз матавыклангач, графин тотып өстәл янына килеп утырды. Күбекләнеп торган хуш исле саргылт эчемлекне чәй чокырларына салып чыкты. Күбекләр чымырдап сүнә башлады.

Хуҗа кеше кулына чокырын алды.

— Әйдә, секретарь энем, Вәлиулла кордаш, тотыгыз! — диде. — Бу — яман нәрсә түгел. Бу — тәңгә сихәт бирә торган, юкә балыннан. Узган ел доход зур булды, җәй иңле килде. Өстәмә түләүгә генә унике пот бал алдым. Үи баш үзем дә тотам. Я, рәхим итегез...

Секретарь бераз югалыбрак калды. Вәли агай исә ярты чокырын авыз итеп, пәрәмәчкә үрелде. Чокырын бушатып куйган Галләмгали агай секретарьның тез башына төртте:

— Эчеп җибәр, энем, сездә юк ул, — диде.

Секретарь тагы да уңайсызланды.

— Ну, что сез, абзый, район үзәгендә ник булмасын? Эссе көннәрне, эштән кайткач, бер кружка сыра эчүгә мин дә каршы түгел.

Галләмгали абзый бирешмәде.

— Юк, секретарь энем, син мине аңламадың: сездә барын бар ул, әмма бит аның сездә стаканы бер тәңкә. Ә мин моны бөтенләй бушка эчерәм, сыйлыйм.

Секретарь бөтенләй аптырап калды.

Вәли абзый гына мыек очына елмаеп пәрәмәч ашавын дәвам итте. Чөнки Галләмгалинең холык-фигылен белә иде: бөтен нәселләрендә мактанчыклык, һавалылык бар.

Секретарьны кыен хәлдән чыгарыр өчен, Вәли абзый сүзгә кереште.

— Безнең Галләмгалинең сөйләшү манеры шулай, — диде ул, — аның ата-бабасыннан килә ул. Менә, әйтик, мәсәлән, Галләмгали хәзер пан булып яши. Үзе колхозның умартачысы, малае иң алдынгы комбайнер, килennәре укытучы. Болар пан хәзер. Ә мин беләм: моның ата-анасын хәтерлим. Мәрхүмнәр. Унберенче елгы ачлыкта үләр дәрәҗәгә җиткәч, муеннарына капчык асып миргә чыктылар. Күрше авылларда саилче булып йөрделәр. Ызначит, сөйлиләр иде ул вакытта, берәүләргә кергәч, моның анасы, мәрхүмә, сүз башлый икән: «Хәер-сәдакадан рәхим итсәгез лә, җиребезне боз сукты, балаларыбыз ач, үзебезнең ипи күрмәгәнебезгә ярты ел», — фәлән-төгән дип сорана икән. Ә этисе дәшми. Капчыгын аскан да тик тора. Шулай берәү, чоланда он иләп ятканда, тегеләрнең үзара сөйләшеп чыгып барганын тыңлап торган. Моның этисе хатынын — Галләмгалинең әнисен — сүгә икән. Үзенне ваксытасың, бераз эрерәк тотарга кирәк, дип сүгә ди. Ә менә малае ничек яши хәзер сәвит власты аркасында?

Барысы да көлештеләр.

Галләмгали агай исә тагы да кыюланып китте. Тәлинкә тулы кортлы майны[1] кунакларга таба этәрде.

— Ашагыз, сездә юк ул, әчегезгә чыр керер, — диде...

...Район, өлкә кунагын өйгә төшерү — катлаулы эш. Арада төрлесе була. Беришесе була — һич тә председатель-фәләнгә чәйгә керми. Андый кешеләрне, гадәттә, менә шулай Галләмгали кебек кешегә җибәрәсең. Икенче берсе һичсүзсез председательгә китә. Моны ничек кунак итәргә? Ярты куяргамы өстәлгә, юкмы? Төрлесе була. Берсенә ярты куясың, ә ул тота да кайткач әйтә: председатель эчүче кеше икән, ди. Алай да авызы пешкәләде Вәли абзыйның. Киресе дә була. Колхозның зур җыелышы иде. Республикадан килгән өлкән кунак катнашты. Районның иң зур җитәкчеләреннән дүрт-биш кеше озата йөрделәр үзен. Менә шул кеше җыелыш башланганчы ук Вәли абзыйга әйтә куйды:

— Бәрәңгең бармы? — диде.— Идән астында бәрәңгең бармы? Кара ипиең бармы? Обедка,— диде,— сиңа керәм. Боларны квартирга төшер дә ашау-эчү ягын оештыр. Кабыклы бәрәңге ашыйсым килә.

И йөгерде Вәли абзый җыелыш алдыннан, и йөгерде. Хатынына латинча язып бер кәгазь җибәрде: «Бибиәсма, зур кунак безгә керәм диде. Син инде тәжел генә баскычларны юып ал, бозауны өйдән чыгар. Абзарны тәки ремонтлатып булмады бит көздән. Бәрәңгенең әмерханын гына сайлап пешер, тәгәрмәчле итеп тура. Тозны тастымалга төреп чүкеч белән төй. Ваграк булыр. Ипине үзем турармын. Үзең бик күренмә. Катмәл генә кирәк булсаң, мин тамак кырырмын. Вәлиулла».

Күрешеп авылдан киткәндә зур кунак Вәли абзыйның сүзенә каршы шаяртып алды.

— Тагын килегез, — дигән иде Вәли абзый. — Колхозыбыз ныгыды. Бодай белән балдан доходыбыз зур. Колхозчы бөтенләй үзгәрде хәзер, үзегез күрдегез. Һәрберсе — алпавыт.

— Я, бик мактанма, — диде зур кунак. Вәли абзыйга ул елмаеп кулын бирде. — Председателенә караганда, бер дә әллә кем булырлыгы юк колхозның. Абзарың җимерек. Ашавың да әллә ни түгел. Бәрәңге ничек дип әйткән әле? «Алып баруын барам, кайтырга миңа ышанмагыз», дип әйткән бит...

Вәли абзый шунда бик нык каушады. Оялды. Соңгы вакытта начальство бик үзгәрде. Сыйфаты үзгәрде. Каян гына, кем генә килмәсен — авылдан, түбәннән күтәрелгән кешеләр. Ул сиңа үгез җигеп җир сөр-

---

[1] Киптергән эремчекне бал, май белән кайнатып ясалган затлы ризык (Казан арты сөйләме).

гән булыр, үзе өлкә комитеты секретаре. Ул сиңа сугыш вакытында черек бәрәңге күмәче ашаган булыр, хәзер — министр я райком секретаре. Бөтенесен аңлыйлар. Бөтенесен күреп торалар.

Их, казан тутырып ит пешерәсе дә сандык артындагы «Столичный»-ны чыгарып утыртасы булган олы кунакка... Грамыт белән генә түгел шул, белем дә кирәк.

...Вәли абзый Ессентукига бара алмады. Председательлектән азат ителгәч, үзенә урын тапмады. Электәгечә, иртәнге сәгать дүрттә урыныннан сикереп тора иде. Тора да урамга чыга. Ләкин урам өчен ул кирәк түгел икән. Анда инде Вәли абзыйдан башка да эш бара. Яңа председатель дә иртә тора. Пыр туздырып бишекле мотоциклда узып китә. Комбинезон астыннан булса да галстугын күрсәтеп йөри, шайтан малай. «Москвич» кайтартты...

Вәли абзый шулай капка төбендә басып тора-тора да йортка керә. Каз-үрдәкне чыгара, ишегалдын себерә, җимерелеп бара торган абзары янына килә. Колхозның терлек абзарларын рәткә салып бетерми торып, үзенекенә тотынуны уңай күрмәгән иде шул. Ленардан материал сорап карасы булыр. Малай җәйге ялын монда уздырса, бәлки икәүләп ремонтлап та куярлар әле.

Ләкин каз-үрдәк куып Вәли абзый озак йөри алмады. Атна-ун көн үтмәгәндер, ул йөрәгенең хәлсезләнгәнен сизә башлады. Йөрәк ватык тегермән шикелле кинәт кенә дулап ала да яңадан рәткә керә. Ләкин әнә шул бер-ике секундлык дулавында Вәли абзыйны ул тәмам хәлдән тайдыра.

Урынга яткач кына Вәли абзый аңлады: чабыштан килгән атны менә ни өчен, мәйдан уртасына керткәнче, әле бераз әйләнә-тирәдә чаптырып аягын суыталар икән! Йөгерештән килгән малайларны да шулай куып җибәрәләр бит! Барыгыз, бар, бераз йөгерегез, диләр. Ә Вәли абзыйны алай куучы булмады. Ул бөтен көченә чабып барганда кинәт туктады. Гәүдә туктауны йөрәк күтәрә алмады. Һәм аңа «хәзергә ятып кына торырга» дигән режим куйдылар.

Урынга яткач, Вәли абзый үзенең бөтен гомерен күз алдыннан уздырды. Сугыш вакытын кат-кат исенә төшерде. Сугыштан ул иртә кайтты, нибары бер пуля, адашкан пуля, аның балтыр итен умырып узган иде. Яра тиз төзәлде, ул арада бронь белән аны колхозга беркетеп тә куйдылар. Колхоз милкенә карата каты куллы булды Вәли абзый. Колхоз басуыннан рөхсәтсез билчән күтәреп кайткан кешене дә ачуланды, чара күрде. Колхозчыларга карата гына түгел, үз семьясына да бу мәсьәләдә кырыс булды. Бервакыт баш түбәсенә арыш башагы катыш эт эчәгесе, күк чәчәк күтәреп, урак җиреннән кайтып килгән үз хатыны Бибиәсманы урам буйлатып кәнсәләргә алып китте. Кәнсәләрдә кеше алдында:

— Оятсыз син, мәнсез син, надан син, — дип тәмам сүтелде. — Синең ирең, — диде, — бүгенгесе көнне үз янында, синдә дөнья алып бару кайгысы юк, ә син колхоз милкен талыйсың. Ә солдаткалар нишләргә тиеш болай булгач? Алар, күрәсеңме, тормыш алып бару өчен ничек хикъланалар[1]?

Башаклы печәнне ул ат абзарына илтеп бушаттырды. Бибиәсманың печән күтәреп урамнан барганын бөтен авыл карап калды. Хәзер менә Вәли карт шуларны күз алдына китерә. Артык кыланылмадымы икән? Рәнҗемәдеме икән Бибиәсма? Юктыр. Әнә ул гомер иткән картына эчәргә дип сөт җылытып йөри, аның авыруына, чын йөрәктән булса кирәк, хәсрәт чигә; бүлмә тактасының теге ягында мышык-мышык елап ала.

---

[1] Хикълану — Казан арты диалекты, «җәфалану» мәгънәсендә.

Бибиәсма исә бу вакытта шулай ук узган гомерен чигереп карый. Ул да хәтерли. Ләкин печән вакыйгасын түгел, икенчене.

...Төш вакыты житеп килә иде. Ул вакыттагы Вәли председатель чыгарган закон буенча урактан унбер сәгать утыз минутта гына төшке ашка кайтырга рөхсәт иде. Бибиәсма ул көнне жир бетереп иртәрәк кайтты да казан тутырып яңа бәрәңге турап салды. Самавар куйды. Аргы як урамда әллә ниткән ямьсез ирләр тавышы ишетелде. Аңа чырылдаган хатын-кыз тавышы кушылды. Бибиәсма сәгатькә карады: унбер тулып чирек иде. Урамга чыкты һәм аргы якка күз салды.

Тавышланучы кеше Вәлиулла икән. Ике-өч житкән кызның уртасына баскан да берсен яңаклый. Тегесе кычкыра, ах-ух килә, үкереп елый.

— Ни хакың бар синең, оятсыз, кырдан бу вакытта кайтырга? Ничек смить итәсең син кеше котыртып йөрергә?

Самавар кайнап чыкканда гына капка ягыннан Вәлиулла һәм бәрәңге бакчасы ягыннан бердәнбер кызлары Нажия кайтып керде. Нажиянең күзләре елый-елый шешенгән, бер як яңагы комач күк кызарган, ирене күгәргән иде. Эссе бәрәңгене ул ашый алмады, чәйне дә аскы иренәнә тиермичә генә, суытып эчте дә эчте...

Хәле авыраюын сизенеп, Вәли абзый шәһәрдә яшәүче улы Маратка телеграмма суктырган иде. Вәли абзыйны саклап, Марат карават башында нибары ике көн утырды. Гомердән, яшәүдән картның өмете киселгән иде. Хәл белергә килүче кеше күп булды. Марат аларны чоланда каршы алды, бик күбесен шуннан озатты. Авыл могтәбәр бер кешесен мәңгелек юлга озатырга әзерләнә иде. Арада төрлесе булды. Ибруш малае Миңнулла — хатыны белән бозылышып, дилбегәсе койрык астына кереп йөргән көннәр иде — кызган баштан өйгә үк килеп керде. Чоланда туктатып булмады. Караватъ янына килеп утырды да авыр хәлдәге Вәлиулла абзыйны сөйләштерде, «жиңел башлы» кешегә күпме кирәк — елап та жибәрде.

— Синнән башка ничек яшәрбез, Вәлиулла абый? Бу колхозны кемнәр алып барыр? — дип, кулъяулыгы белән битен-күзен сөртте, идәнгә кесәсеннән отверткасы төшеп тәгәрәде.

Вәлиулла абзый сөйләшерлек дәрәжәдән узган иде, хәлсез кыяфәттә елмайды.

— Барыр, олан, барыр...

— Син безнең даһи юлбашчыбыз идең бит! Синнән башка ничек яшәрбез?

Исерек кеше бер елый башламасын... Елаган саен исерә, исергән саен катырак елый ул. Марат ишекле-түрле марш атлап йөргән жиреннән туктап, Миңнулланың култык астыннан күтәрде дә чоланга этеп чыгарды. Чоланга чыгаргач, тегесе күз яшьләрен сөртте, фәлсәфәгә керешти:

— Син, Марат абый, әтиеңнең бәясен белеп бетермисең төсле... Син аңа житәрлек игътибар бирмисең бугай. Бу, беләсеңме, кем? Син армиядә вакытта, беләсеңме, колхозны ничек аякка бастырды? Син аны кадерләмисең бугай... Бу кеше, беләсеңме...

Исерек белән тапма да, өләшмә дә.

Марат аны култыклап капкага озатты.

— Рәхмәт, энекәш, жылы сүзеңә, безнең әти турында шулай уйлавыңа, — диде. Вәлиулла абзыйга исә бу вакытта беркемнең дә жылы сүзе кирәк түгел иде инде.

...Кеше күмгәндә матәм маршы уйнасалар, сез нәрсә турында уйлыйсыз? Моны бик башлы композитор уйлап тапкан! Юан-юан трубалар авыр, салмак көй чыгара. Тыңлагыз әле! Кеше узган тормыш юлын сөйли бу тавыш. Әнә шунда кинәт нечкә тавышлы трубалар чыелдый башлый. Адәм баласының үз гомерендә күргән кайгы-хәсрәт,

борчулары ул. Музыка әнә шулай әлеге мәетнең биографиясен сөйли. Ләкин шул вакытта кинәт кенә «чың! чың!» итеп җиз тәлинкәләргә бәреп алалар. Шул тавышка әйләнә-тирәдәге бөтен кеше сискәнеп куя. Карт-коры агарып китә. Чөнки теге җиз тәлинкәләр иң башлап аңа дәшәләр, болай диләр: «Әй, сез, кешеләр! Дөньяда беркем дә мәңгегә килмәгән. Һәркемнең ахыры менә шул! Сезне дә менә шушы көтә. Тормыш юлыгызны ничек узасыз? Сез җирдә яхшылык чәчтегезме? Сез бит шуның өчен дөньяга килгән идегез! Чың! Чың!»

Районнан җибәрелгән оркестр авыл халкын әнә шулай тетрәтте. Җиз тәлинкә тавышына карт тал башындагы кошлар да сискәнеп зиратка таба очты. Ләкин тәлинкәләр чынлавы зиратка якынлаша гына барды. Вәли абзыйны соңгы юлга озатырга килгән халык зиратның аланлы, буш почмагына сыймады. Речьләр сөйләделәр.

Кеше күмгәндә тагын бер нәрсәгә игътибар итегез: үлгән кешене гел мактыйлар гына. Бу — халыкның күркәм гадәте. Ләкин мактап сөйләүчеләр арасында кайберләре сиңа шундый караш ташлыйлар ки, әйтерсең исән калуыңа син гаепле. Син башыңны иеп оялып торасың. Менә бит, дисең, нинди әйбәт кеше үлеп киткән, ә мин аның белән чагыштырганда никадәр начар, мин калганмын. Моның белән мин бик зур гаеп эшләгәнмен. Мине, исән калганым өчен, гафу итегез.

Юк, кабер өстендә речь сөйләүче исәннәргә карамаска тиеш. Аның карашы бары тик табутка гына юнәлгән булырга тиеш... Кабер янында Ленар әнә шулай кыенсынып басып торды.

## Иптәш Һидиятуллин

Ленар эшли башлауга, колхоз идарәсендә зур үзгәрешләр булды. Башта ул үзенә кабинет эшләтте. Кара дерматин белән ишекләрен тышлатты. Стена телефонын өстәл телефонына алмаштыртты. Кабинетта газета-журнал подшивкалары булдырылды. Искечә эш итү аркасында, иң беренче чиратта, Галләмгали агайның авызы пеште. Умарта кортларына кышкы нормалар язылган кәгазь тотып, кул куйдырырга гына дип, ул кабинетка килеп кергән иде.

— Кая, энекәш, шушыңа тамгаңны гына салсаң, булгахтыр районга киткәнче, расход кенәгәсенә яздыртып куярга иде исәп, — дип, Галләмгали агай күн бүреген өстәлдәге гәзит подшивкасына куйды. Ленар китап укып утыра иде. Китабын бер читкә алды да күтәрелеп карады. Галләмгали агай, йөнтәс кашлары астыннан елмайган килеш, кәгазен сузып тора иде. Ленар гадәттән тыш салкын кан белән аңа ишекне күрсәтте.

— Хәзергә чыгып торыгыз, — диде. — Аннан ишекне шакып рөхсәт сорарсыз, мин рөхсәт итсәм, керерсез. Аннан соң әйтеп куям: мин сезгә энекәш түгел. Миңа Ленар Фәхрисламович дип дәшәрсез. Ә хәзергә чыгып торыгыз...

Галләмгали агайның ачылган авызы ябыла алмыйча калган иде, шул килеш ул подшивка өстендә бүреген онытып чыгып китте. Аның гаҗәпләнүенең чиге-чамасы юк иде. Чыкканда ул кат-кат әйләнгәләп кабинетын карады: председатель янына ул үзе генә кергән иде. Ни өчен председатель күп кеше бар сыман сөйләште? «Чыгыгыз, торыгыз», имеш. Берүзе бит Галләмгали агай... Әллә исерекме бу җүнсез, ә? Исереккә шулай бер кеше әллә ничә булып күренә дип сөйлиләр иде. Алай дисәң, бу малайны, гомумән, авызына да алмый дип әйтәләр.

Ул көнне төштән соң дерматин ишекләрнең ике ягына көмеш язулы ике кара пыяла беркетелде. Берсенә: «Председатель Л. Һидиятуллин» дип, икенчесенә кабул итү сәгатьләре язылган иде. Кабул итү сәгатьләре болай икән: колхоз эшенә кагылышлы мәсьәләләр буенча һәр көн-

не иртән алтыдан сигезгә кадәр, шәхси мәсьәләләр буенча шимбә көн икедән кичке алтыга кадәр.

Колхозда, шулай итеп, «иптәш Һидиятуллин» дигән шәхес барлыкка килде.

Иптәш Һидиятуллинның ничек өйләнгәне — озын булмаган бер хикәя.

Ул Свердловск тирәсендә стройбатта[1] хезмәт итте. Стройбаттан егетләр гадәттә шактый акча белән кайталар. Бер мең дә, ике мең. Ленар да акча туплады. Солдат тормышында иң күңелле минутлар нинди? Кызлардан килгән хатны уку. Кызлар хаты булмаса, солдат тормышы бик күңелсез булыр иде. Ленар, мәсәлән, бер кыз белән «заочно» таныште. Адресын күрше авыл егете биргән иде. Ничәмә-ничә төрле карточкаларын җибәрде солдат: ул сиңа гимнастерканы чишеп күкрәктән матрос тельняшкасын күрсәтеп төшү дисеңме, ул сиңа иптәше белән бер-беренә тәмәкегә ут биргәндә төшү дисеңме — барысын әлеге «заочница»га җибәреп торды. Тегесе матур итеп хатлар язды, әмма безнең авылда фотограф юк дигән сылтау тапты, рәсемен җибәрмәде. Мәхәббәт кызды. Сүзләр куерды. Кыз егетне, егет кызны сагыныштылар. Бу хатлар ике еллык кырыс солдат тормышын җылытып торды. Ниһаять, сентябрьнең кояшлы, җылы бер иртәсендә Ленар хезмәтен тутырып авылына кайтып төште. Егет, чыннан да, калын кайткан иде: өр-яңа «М-72» маркалы мотоцикл. Күн пальто. Баян. Эче йонлы яхшы перчаткалар. Фотоаппарат. Иң зурысы — урта мәктәп тәмамлаганга аттестат. Менә егет дисәң егет! Сигез класс белән китте, баргач бульдозерга утырган, кичләрен мәктәпкә йөргән. Биш-алты грамотасы гына бар. Яхшы күрсәткечләр өчен...

Иртәнге чәйдән соң ул, мотоциклына утырып, күрше авылга — «заочница» янына китте...

Кызның исеме Әминә иде.

Әминә юаш, эшчән кыз. Әтисе сугышта үлгән. Әнисе гомере буе хатын-кыз авыруы белән җәфаланып саргайган, ыңгырашып йөри торган хатын. Әминә егет белән чуалган кыз түгел. Яшьтән гел эш булды. Егет күзенең явын алырлык чибәрлеге юк. Әмма эчтән бай. Әгәр шушы авыру әнисен карыйсы булмаса иде, Әминә, һичшиксез, берәр институтны тәмамлар, газета-журналлар тирәсендә бәлки шагыйрь дә булып йөрер иде. Чөнки аның күңеленнән гел моң ташый, моң агыла иде... Тик ул тугыз класстан ары укый да алмады, авылдан чыгып китә дә алмады.

Ленар кайтасын көтте. Кайткан көнен сизде. Чөнки төш күрде. Фермага барышы, имеш. Болын уртасыннан киң җилкәле, хәрби фуражкалы бер егет каршыга атлады. Якты елмаеп, каршыга килде, Әминәнең ике кулыннан тотты.

— Я, — диде, — мине танымыйсыңмыни? Мин бит синең киявең.

Үзе Ленар икән, үзенең исеме алай түгел икән...

Ул көнне Әминә егетне көтте.

Фермадан көндезге чәйгә кайткан вакыты иде, урамда ят мотоцикл тавышы ишетелде. Кызның йөрәге урыныннан купты, самавар борынын ябарга онытып, подноска кайнар су агызды, урыныннан кузгалганда, эскәтерне эләктереп әнисенең чәен түкте. Саргайган йөзле ачулы хатын явыз ыңгырашты:

— Чисти дәртең почмакланды, җүнсез, ташың кызды, — диде. — Юньлегә генә булсын... Штиеңне суытмасыннар...

Капка төбендә зәңгәр галифе чалбарыннан тузан каккалап, терсәккә кадәр күн перчаткалар кигән чибәр старшина тора, яңа мотоциклдан буяу, резин, бензин исе таралган иде.

---

[1] Стройбат — строительный (төзү эшләре белән шөгыльләнүче) батальон.

Старшина өйгә кермәде. Әминә дә көндезгене ашамаган көе фермага китте. Юлда, мотоциклны болын уртасында калдырып, алар сөйләшеп бардылар. Бераздан кире килделәр. Бөтен авыл, бөтен ферма күзәтеп торды: Әминәнең солдаты кайткан. Алып китәрме? Авыру энисен ташлап китәргә йөрәге җитәрме? Берәр елга сабыр итик диярләрме? Нәрсә икән?

Ләкин юкка баш ваттылар. Әминә сизде: егет аны ошатмады. Сүз суына төште. Егет кыен хәлдә иде. Ул хәзер ялган сөйләргә тиеш иде. Ә үзе кыяфәте буенча чиста күңелле егеткә охшаган. Берничә көннән тагын килергә вәгъдә итеп, егет мотоциклның педаленә басты. Яшел тугай кинәт кенә чытырдаган мотор тавышына сискәнеп китте. Су буендагы камышлыклардан кошлар күтәрелде. Тугай уртасында Әминә ялгызы басып калды. Бераздан тугайның теге ягында тау битендәге соры юлда тузан күтәрелде. Камыллы басу уртасындагы аксыл юлдагы бу тузан Ленарны да, аның мотоциклын да күмгән иде. Әминә ул тузанга озак карап торды. Ленар бүтән килмәячәк иде...

Бераздан Ленар укырга, авыл хуҗалыгы институтына китеп барды. Ул көзне Әминәнең дә әнисе гүр иясе булды. Ялгыз йортка кышлык утын әзерлисе, ялгыз яшисе бар иде. Нәсел-нәсәп җыелышып киңәштеләр. Сахалиннан хатыны үлгән кырык биш яшьләр чамасындагы берәү кайтып төште. Башында тупый бүрек, өстендә бобрик пальто иде. Имеш, чыбык очы буенча Әминәгә җизни икән. Аны шуңа димләмәкче булдылар. Әминә паспорт алырга рөхсәт сорап идарәгә барды. Аңа хәзер барыбер иде.

Тупый бүрекле никах укытып, авыл советында язылышкач, аны еракка алып китте. Китәсе көнне генә йорт-җирне, абзар-кураны саттылар. Акчасын тупый бүрекле үзенең кара ялтыравы тузган, китап зурлыгындагы бумажнигына санап салды да куен кесәсенә тыкты. Ә бер айдан авылга хәбәр килде: тупый бүрек яман кеше икән, элекке хатынын да газаплап үтергән икән, хатын-кызны санга сукмый икән. Әминәне ул балаларын карар өчен генә алган икән, йорт акчасын тотып бетергәннәр. Әминәне эшкә урнаштырмый, дөньяга чыгармый, ишегалдындагы 80 яшьлек карттан да көнләшә, каршы сүз әйтсә, кыйный икән...

Ярдәмчесез кыз ерак Сахалинда кая барсын?

Ярты еллар чамасы узгач, авылдагы туган-тумачаның берсенә Әминәдән хат килде. Хат кулдан-кулга йөрде, укыдылар да еладылар, укыдылар да еладылар. Еламый да булмый, хатның ахырында Әминәнең үзе чыгарган шигыре бар иде.

Минем исемем Әминәдер, Әминә!
Алтын путалар бәйләдем билемә.
Инде төштем бер явызның кулына
Ярдәм итегез, туганнар, мине моннан алыгыз!

Төннә килеп сарыр тәнен тәнемә,
Иртүк торып биклэп китэр өенә.
Инде төштем бер явызның кулына,
Ярдәм итегез, туганнар, мине моннан алыгыз!

Кич җитдисә, килеп ятар янымa,
Тынгы бирмәс минем газиз җанымa.
Карагызчы минем яман хәлемә,
Ярдәм итегез, туганнар, мине моннан алыгыз!

Мин авылның эшчән бер кызы идем,
Бакчадагы моңлы бер былбыл идем,
Ачылмаган, тотылмаган гөл идем,
Ярдәм итегез, туганнар, мине моннан алыгыз!

...Әминәне, әлбәттә, алып кайттылар. Туганнары үз яннарына сыйдырдылар. Бераздан ул фермада эшли башлады. Колхоз аңа йорт са-

лып бирергә булды. Хатта килгән теге җырны Әминәгә белдермичә генә күчерделәр, өйдән-өйгә тараттылар.

Тик Ленар гына боларны белмәде. Ул инде бу вакытта авыл хуҗалыгы институтының дүртенче курсында, тулай торакта студсовет председателе иде.

Ленарның өйләнүе дә кызык. Кайтты, сайлап куйдылар. Председатель буларак китте объектларын карарга. Юл өсте иде — балалар бакчасына керде. Бакчада балалар белән чәчәк арасында йөргән бер кызга барып эндәште. Бакча мөдире икән. Таныштылар. Авыл кызы. Читтән торып институт тәмамлаган. Егерме биш яшьтә! Ленар егерме алтыда. Ни кирәк тагы? Кызның исеме — Разия. Дөньяны, тормышны конкрет күзаллый. Конкрет уйлый.

Озак та үтмәде, нык кына туй мәҗлесе ясалды, бергәләп тормышның ныклы перспективалары сызылды. Ленар үзенә нарат бүрәнәләрдән яхшы йорт салдырды, әтисен иске нигездә калдырып, аерылып чыкты.

Республика газетасыннан яңа председательнең эш стилен өйрәнеп, матбугатта яктырту максаты белән, бер хәбәрче килгән иде. Унбиш ел буе газетада эшләгән тәҗрибәле журналист бер кәлимә сүз яза алмыйча, буш кул белән китеп барды. Югыйсә, ике көн буе председатель белән бергә йөргән иде. Беренче көнне үк журналист берни дә яза алмаячагын белде.

...Иптәш Һидиятуллин белән алар кырда йөрделәр. «Москвич» җинел генә тирбәтеп арыш басуы арасыннан чаба. Бераздан елга буена килеп чыктылар. Председатель машина эчендәге сумкадан Япониядә эшләнгән плавкиен алып киде.

— Кеше юк бит,— диде журналист,— нәрсәгә мәшәкатьләнәсез?

— Ну, што син, — диде Һидиятуллин, — авыл мужигы шикелле, суга штансыз кереп йөрергәме?

Алар йөзделәр. Яр буена чыгып сигарет кабыздылар. Председатель машина артында трусигын сыгып яткан шофер Хәйбригә команда бирде:

— Яле, Мәскәүне тот. Шушы вакытта транспорт морякларының соравы буенча концерт тапшыралар.

Хәйбри кабина ишеген ачып радиоалгычны кабызды. Су буена йомшак көй таралды.

— Иртәгә уракка төшәм мин, — диде Һидиятуллин, — унсигез комбайн белән. Җитмеш ике сәгатьтә арыш урагын хәл итәргә тиешмен. Ә «Тангейзер»ны яратам, дөресен әйтим. Вагнерга шушы операсы өчен генә дә һәйкәл куярга ярый.

Журналист «Тангейзер»ның нәрсә икәнен белми иде, уңайсызланып, ашыга-ашыга ботинкаларын шнурлады.

— Ә гомумән, — дип дәвам итте Һидиятуллин. — Григ кадәр нечкә художникны белмим мин. Син аның бер бию көен генә тыңлап кара...

Машина янында чирәмгә утырдылар. Һидиятуллин — әңгәмә өчен искиткеч яхшы кеше.

— Менә без авылда ятабыз инде, шайтан алгыры. Җәй көне үзеңнең эчке дөньяң турында уйларга вакыт калмый...

Бераздан ул Рубенс картиналары турында сөйләп китте. Аннан Стамбулдагы Айя-Суфия мәчетенең салыну тарихын сөйләде.

Тирбәлеп арыш арасыннан кайтканда бозау җитәкләгән ике карчыкны узып киттеләр. Һидиятуллин шофер Хәйбринең уң җилкәсенә кагылды. Машина йомшак кына төртелеп тукталды да алга таба бер тирбәнеп алды. Һидиятуллин машинадан чыгып, карчыклар янына китте.

— Сез нәрсә, колхоз җирендә бозау ашатасызмы?

Журналист Һидиятуллинның тавышын танымады.

— Ни битегез белән сез бозауларыгызны көтүгә кумыйча межада йөртәсез. Оятыгыз кая сезнең?

Карчыклар дер-дер килделәр. Председатель кызды.

— Кара син аларны, ә? Вөҗдансыз сез! Картаеп беткән башыгыз белән. Сезгә кәфен турында уйларга кирәк, бессовестныйлар! Ә сез монда колхоз җиренең межасында бозау симертәсез...

Кайтканда Һидиятуллин Кафка әсәрләре турында сөйләде. Поляк профессоры, зоолог Фильдингнең соңгы хезмәте турында сөйләгәндә машина авылга килеп керде. Авыл кырыендагы зәңгәр тимер рәшәткәле бакча эчендә нарат бүрәнәле шәп йорт күренде. Машина шул койма буенда туктады. Һидиятуллинның үз хуҗалыгы икән. Рәшәткә буенда бер көтү казлар ял итеп ята иде. Һидиятуллин аларны куып җибәрде. Аннары бакча рәшәткәсеннән үрмәләп урамга чыккан гөл сабагын сүтеп, бакча эченә төшерде.

— Бер сәгатьтән монда бул, — диде ул Хәйбригә, — без тамак ялгап чыгыйк. Бүген кич телевизордан «Айсревю»не бирергә тиешләр. Мин болай ошаттым, беркөнне Казанның Спорт сараена барып караган идек. Режиссер Петерны әйтәм: никадәр пластик яңалык! Никадәр идея! Ә менә Штольцның музыкасы белән Чайковскийны аралаштыруларына мин һич тә риза булмадым...

## Алайса, китәм инде...

Кардәшең белән дошманлашудан язмыш үзе сакласын. Ленарның дөнья куптарып колхозны яңартып йөргән вакыты иде. Күрше колхоз белән кушылгач, партоешма зурайды. Партоешманың һәр җыелышында эреләндерелгән колхозның перспективалары, генеральный планнар, культура сарайлары турында сүз китте. Һәр бригада җыелышында диярлек, колхозның киләчәге турында Ленарга яртышар, берәр сәгатьлек речь сөйләргә туры килде.

...Борынгы римлылар Карфаген белән сугышканда Катон дигән бер патриций Рим сенаты утырышында һәр вакыт речь сөйли икән. Нәрсә турында гына сөйләмәсен — гладиаторларның Колизейда кичәге чыгышлары турындамы, Рим шәһәрендә яңадан бер мунча салу турындамы, үзенең чыгышын Катон бер генә төрле тәмамлый.

— Менә шул эшләрне башкарганнан соң мин Карфаген безнең тарафтан җиңелер дип уйлыйм.

Ленар моны белә иде, институт китапханәсендә ничектер бер кызыклы гына китап очратып, шуннан укыган иде. Хәзер исә колхозның гомуми яки бригада җыелышы саен шул эпизод исенә төшә башлады. Юк, ул үз чыгышын алай тәмамламый иде. Үзе ул сөйли белә, математик исәп белән, фактлар белән сөйли. Җыелышларда аның дәртләнеп сөйләгән речена салкын су сибүче, гадәттә, Шәйдулла була. Аның фикерен җайлап-сыйпап кына Галләмгали агай куәтли. Монысы җай белән, ип белән.

— Ни өчен колхозда атларга игътибар юк?

Шәйдулла, колхозның өлкән ат караучысы, һәр җыелышта председательгә әнә шундый сорау бирә. Ә бит бер дә чит кеше түгел, өлкән абзыйсы Фәхрислам малае гына бу председатель, якын кеше — нәсел.

— Ни өчен колхоз тиклем колхозда атка сан юк?

Җыелышның ахыры әнә шул «Карфаген мәсьәләсенә» килеп төртелә. Шәйдулланың шәплəп сөйләргә сәләте юк. Ләкин ул белеп тора: колхоз елына әллә ничә йөз баш сыер симертә, меңләгән сарык асрый. Тавыкларга гәрәбәдәй бодай ашаталар. Мөмкин булса, сыерларны төнлә уятып авызларына труба белән тутырырлар иде. Терлекләр өчен

ниләр генә әзерләмиләр, ниләр генә кайтартмыйлар хәзер? Фермада түгел алар, курортта! Ә атка сан бетте. Атка кыш көне каты борчак саламы, бер кило он, ярты кочак люцерна. Язга таба люцерна да бирелми. Оны кибәктән генә тора. Шәйдулла зур белемле булмаса да белә: бер атның көчен таза җиде ир кеше көченә тигезлиләр. Ә таза солдатка көненә өч тапкыр аш, ботка, балык, бәрәңге, винегрет, тагын әллә ниләр ашаталар да уртача 950 грамм исәбеннән менә дигән кәрәз күк ипи бирәләр. Хәер, солдат хезмәтендә хәзер ипи үлчәү белән йөрми дә. Ул норма болай гына, шуннан да кимемәсен дигән сүз генә инде...

Аннан сбруе... Ат шлеясенең тәңкәсен хәзер малай-егетләр чалбар балагына тезәләр. Тәгәрмәч ясаучы комбинатлар бетте. Дуга бөгүче осталар бетте. Атны җигә белмәү егетлек исәпләнә. Элек ат җиккән кеше белә иде, ат арбасының нормасы — алты, җиде кеше. Хәзер исә озын чәчле егетләр ат арбасына төяләләр — унар, унбишәр кеше. Ат нишләсен? Бичара, иң юаш хайван бит ул. Аннан үр менгәндә, тау төшкәндә... Элегрәк сөйлиләр иде: үр менгәндә ат уйлый икән: алтмыш ир кешене тартыр идем, алты хатын-кызны тартмас идем. Чөнки әүвәл-әүвәлдән килгән: хатын-кыз, бары тик хатын-кыз гына үр менгәндә чанадан, арбадан төшмәгән. Ат кадерен белгән ирләр үрдән җәяү атлаганнар. Ә хәзер... Үрдә түгел, текә тауда да төшмиләр. Элегрәк атны куркыту өчен каеш чыбыркылар була иде. Адәм рәтле кеше бервакытта да атка чыбыркы белән сукмады. Ул аны атның колагы төбендә шартлатып өркетә генә иде. Ә хәзер... Үрдән ун-унбиш егетне тарта алмый туктаган атка, мөмкин булса, трактор тросы белән сугарлар иде...

Шәп егетләр, механизаторлар, колхозның таткасы болар. Алар — төп житештерүчеләр. Әмма Шәйдулланың бәгырен телгәләмәсен иде алар...

Ленар җыелыш саен аңлата:

— Атчылыкның үзкыйммәте бик югары, — ди, — алар прибыльный түгел... Хәзер машина заманы. Ләкин егерме-егерме биш елсыз атлардан башка яшәп булмый әле.

Монысы белән бәхәсләшергә Шәйдулланың белеме җитми. Әмма ата-бабадан калган гадәт аның канына сеңгән: ат асрап иген иккән кешенең күңеле яхшы була. Я, карагыз инде, хәзерге яшьләр ат җигә белмиләр. Ә бит Шәйдулла үскәндә, әгәр авылга шундый даның таралса, ят та үл — зур хурлык иде. Элегрәк колхоз атларының һәрберсенә аерым сбруй, аерым арба бар иде. Сбруй элә торган лапаслар, штатта шорник дигән бер кеше, көйләнгән камыт баулары, көйләнгән тәртә баулары. Камыт покрышкасы майланган, йөгән майланган, аркалыктүшлек каймак кебек... Хәзер нәрсә? Атны теләсә кем ат абзарыннан алып чыга да теләсә нинди сбруйга җигә. Камыт бавын, тәртә бавын көйләүнең ни икәнен дә белмиләр. Алып кайтып туаргач, сбруйлар ишегалдында кала, кар явамы, яңгырмы — барыбер...

Ат — татар халкының борынгыдан килгән юлдашы бит ул. Нечкәләбрәк карасаң, кешедәге явызлык, яхшылык сыйфатлары күпмедер дәрәҗәдә атта да очрый бит. Их, әйбәтләп шуларны сөйләргә иде җыелышта бер.. Ат сугарып үсмәгән малай ничек җирне, колхозны яратсын? Әтиләре бай булгач, малайларына ел саен бер велосипед алып бирә торалар, тегеләре аны вата тора. Димәк, техника кадерен дә белми алар. Бар иде шундый еллар: ат туаргач, абзарларга кертканче, атланып су буена китәсең. Төшәсең инешкә. Тезгенне бушатасың һәм... сызгыра башлыйсың. Моның аерым көе бар. Моны авылда иң моңлы сызгыручы кеше Һидиятулла карт иде. Шәйдулла әтисеннән өйрәнде. Сызгырасың — ат иреннәрен суга тиерер-тиермәс кенә эчә. Егетләр булган мәҗлестә унҗиде яшьлек кыз сөтле чәй эчә дип белерсең. Бе-

раздан ат башын күтәрә, сиңа күзләрен мөлдерәтеп карый. Аның аскы иренендә кара төкләр була, шулардан су тама. Тагын сызгырып көйлисең. Ат тагын авызын суга төртә. Шуның рәтен, шуның матурлыгын белми үскән кешедән нинди колхозчы чыксын?

Ә атлардагы гадәт, холык! Кешеләрмени! Шәйдулла малай гына иде әле, колхозга каяндыр яшь айгыр кайтарттылар. Элеккеге айгыр — зур тояклы, болыт кебек тузган калын яллы ат — инде картаеп килә иде. Бичара, яшь айгырның күрәчәгенә каршы, бер көнне бияләр янына утарга икесен дә чыгарганнар иде. Ат заводыннан китерелгән шома тиреле яшь айгыр тирәсендә бияләр күбрәк уйнаклады. Карт айгыр моңа күп булса чирек сәгать түзде. Һәм яман акырып кешнәп (бу тавышны авылда бөтен кеше ишеткән) яшь айгырга ташланды. Күз ачып йомганчы, тегенең бугазын кабып та өзде. Яшь айгыр гөрселдәп утар кырына барып төште, бияләр исә элеккеге «монарх» янына җыелышып, куштанлана башладылар. Шәйдулланың әтисен шул эш буенча җавапка да тартмакчы булганнар иде. Колхозның гомуми җыелышына куйдылар. Колхоз милкенә саксыз караштa гаепләмәкче иделәр. Әмма председатель Вәлиулла коткарды.

— Ат белән эш иткәндә андый хәлләр була ул, иптәшләр, — диде Вәлиулла. — Була, әйеме. Менә монда хатын-кызлар да бар, әйеме. Оят булса да сөйлим инде. Уналтынчы елны Ишморатов байның ат заводында көтү көттем мин. Нәкъ шундый хәл булды. Минзәлә ягыннан бик зур хакка сатып алган яшь айгырын көтүгә беренче көн җибәрде генә байның правляющие. Нәрсә булды дисез, әйеме? Күз алдында карт айгыр дөнья җимереп чабып та килде, калын күкрәге белән тегене бәреп тә екты, әйеме... Умырып... өзеп тә алды, оят булса да әйтим инде. Һидиятулла агай эшенә намус белән карый, колхоз өстенә килгән бәла икән, колхоз белән күтәрик...

Ләкин Вәли карт күптән кабердә инде. Атны кайгыртучылар бөтен авылда бер-ике генә.

...«Үзкыйммәт», «прибыльный» дигән сүзләр Шәйдулланы беткәнче адаштырдылар. Элек ат абзарлары янында 3—4 гектар киндер орлыгы була иде. Көзен колхоз хезмәт көненә киндер орлыгы өләшә, и китә пешеренү, и китә орлык төю, кыстыбый пешерү. Хатын-кыз мәш килә, майлы таба исе урамны тутыра, күңелле була. Биш-алты гектар җирдә чөгендер, кишер була иде, көзен анысын да өләшәләр, кишер бөккәне, чөгендер пәрәмәче пешерелә иде — яңа председатель ике-өч ел эчендә барысын да бетерде.

— Ник?

Берничә җыелышта Шәйдулла шулай дулап карады.

— Аларның үзкыйммәте югары, прибыль бирмиләр алар колхозга,— диде яшь председатель.

— Соң бит элек нинди ярлы вакытта да чәчә идек, ә хәзер ник үстермибез?

— Әнә сез нәкъ шуңа күрә дә ярлы булгансыз инде, — дип, белемле председатель Шәйдулланы төп башына утырта. — Үзкыйммәт дигән нәрсә белән исәпләшмәгәнсез. Без хәзер специальләшәбез: бездә төп ике тармак калачак. Сөтчелек һәм бодай белән арыш.

Шәйдулла тыңлый, ачуы эченә сыймый. Чөнки яхшы белә: яшь председательнең үз бакчасында чөгендер дә, кишер дә, кыяр да, кабак та үстерелә. Аның тавык кермәслек итеп биек койма коелган бакчасы бар. Ул нефтьчеләрне яллап бакчасына кое ясатты, су аңа үзе килә. Ул, әлбәттә, ашый чөгендер пәрәмәчен дә, кишер бөккәнен дә.

— Хатын-кыз үнәрсезләнде, — дип, кайвакыт Галләмгали агай белән Фәхрислам да зарланышалар. Фәхрислам да хәзер тавыш бирә: малай председатель булганнан бирле ул инде бригадир түгел, ярдәмче генә. — Хатын-кыз бозылды. Элегрәк, мин сиңайтим, пич ашы, таба

ризыгы пешерәләр иде. Хәзер эшлисен эшли, уч тутырып акча ала, кибетенә йөгерә. Ала прәннек, ала кәнфит, бүген пешкән күмәч. Күн сумкасын тота да кибеткә йөгерә, тота да кибеткә йөгерә. Ә хатын-кыз пешерергә-төшерергә әбәзен.

Моны Галләмгали агай сөйли. Ул моны үзенең килененә карата сөйли.

— Болынны бетерделәр, — дип кушыла аңа Фәхрислам. — Дөньяның ямен бетерделәр. Элек тегермән буасына төсеп аяк тибеп бер йөзә идең. Болында күкрәп песән үсә иде. Хәзер нәрсә?

Тегермән һәм болын мәсьәләсен шулай ук идарә утырышында күзгатып карадылар.

— Арба, көрәк заманында да үзебезнең кул көче белән тегермән буасын буа идек. Хәзер бульдозерлар бар, нигә бумыйбыз? — дип тавышландылар.

— Бусагыз, сез аны бушка эшләгәнсез, — диде Ленар аларга каршы. — Ә хәзер колхозчы келт иткән саен акча ала. Я, кайсыгыз бушка тегермән буасын буа? Сабыр итегез, Ленинград институтыннан инженерлар килергә тиеш, картасын ясарлар, сметасын төзерләр, урынын билгеләрләр. Капитальный итеп эшләрләр. Ә сез әйткәнчә, ул рентабельный түгел.

Шулай диде дә, сусыз болында кара яр өстендә каралып утырган тегермән йортын сүттерде һәм фермага күчертеп торак йорт итеп эшләтте. Су буе ятим калды, үлән көйде, су җәелеп яткан урыннарда тузан болыты йөрде.

Картлардан Галләмгали белән Фәхрислам, яшьрәкләрдән Шәйдулла җыелыш саен яңа председательне шул мәсьәләләр белән борчыдылар. Ленар аларны «искелек тарафдарлары» дип атады, ә бер җыелышта «наданнар» дип тә ычкындырды.

Һидиятулла абзый ат караган заманда район газетасында атчылык турында мәкаләләр, ат караучыларның рәсемнәре бирелә иде. Хәзер анысы да юк. Атсыз авыл авылмыни ул? Элегрәк атчылык буенча күп китаплар бар иде. Һидиятулла абзый җиделе лампа яктысында бу гыйлемгә төшенергә тырышып, күпме кичләрен уздырды. Хәзер ләммим. Хәзер ат дәвалау да юк. Теге-бу булса, егып суялар гына.

Шәйдулла боларның барысын да бик авыр кичерде һәм акрынлап авылдан сүрелде. Ленар белән тәмам аралары бозылды. Җитмәсә, туган буларак мәҗлесләрдә бергә утырырга туры килә, теләсәң-теләмәсәң дә йөрешергә кирәк. Шуның өстенә Ленарның хатыны тиктомалга килендәше Сөембикәдән көнләште. Көнләшү өчен күпме кирәк? Ленар белән Разиянең бу дөньяда бар ягы килгән — тартмадай каралты-кура, барысы да яңа, җиләк-җимеш, яшелчә бакчасы, бакчасында коесы, мунчасы, персональ машина. Акча күп, продуктны сатып аласы түгел, колхоз күтәрелде. Ленарның район җитәкчелеге алдында дәрәҗә зур. Рәхәтен күр дә яшә! Ләкин көнләшүнең фәлсәфәсе бик тирән аның. Әгәр ярлы байдан, көчсез көчледән, ямьсез матурдан гына көнләшә торган булса, көнләшү бик гади һәм бар кешегә дә аңлашыла торган хис булыр иде. Юк бит, алай түгел. Шәйдуллалар, югыйсә, бик гади яшиләр: ат караучының колхозда ни дәрәҗәсе, ни исеме юк. Хәзер бит колхозда механизатор белән сыер савучыны күбрәк күрәләр, шуларны күбрәк мактыйлар. Әмма председатель хатыны Разия беренче күрүдә дә Сөембикәдән көнләште. Бары тик тегенең мәҗлестә матур итеп җырлаганы өчен генә. Сөембикә исә Алабугада культпросвет мәктәбен тәмамлаган икән. Менә инде мәҗлестә ул җырлый! Кунакта бергә очраштылармы, берәрсе кулына гармун алдымы, Разиянең йөрәге ешрак тибә башлый: менә-менә Сөембикә җырларга керешер. Ләкин тегесе дә алай гади түгел, мәҗлестәге бөтен кеше үзенең җырлау сәләтен күрсәтеп бетергәч кенә тотына ул. Мондый мәҗлестә беренче тапкыр кат-

нашкан хатыннар гел «янып», «харап булып» кына торалар. Һәркем, әйләнә-тирәдәге тавышны бераз чамалагач, вәкарь белән генә җыр башлый. Кунак хатын шәбәеп җырлый, ире дә масаеп утыра. Мәҗлестә хатыны җырлаганга масаймый калган ир дөньяда юк. Күп ирнең хатыны белән масая торган бердәнбер очрагы ул. Әйе, шулай, теге хатын да шәп җырладым дип куанып, канәгатьләнеп утыра. Ире аңа сокланудан хәтта хатынының аркасына кулын сала — масаеп, яратып кочаклау инде ул, бер дә бүтән түгел! Әнә шундый хаталар эшләп бетерелгәннән соң гына Сөембикә җырлый башлый. Һәм кешене үзенең саф, көчәнүсез күкрәк тавышы белән өнсез калдыра.

Башта җырлаган теге хатыннар Сөембикәгә, гадәттә, дошман булып таралалар. Хәер, беренче мәҗлестә Разия да шулай харап булган иде. Хәзер Разия үз хатасын эшләүче хатын-кыздан андый мәҗлесләрдә астыртын гына көлеп утыра. Җим киерткән кармакка якынлашкан шыртлаканы тәҗрибәле хәйләкәр чуртан күзәткән сыман...

Була берәүләр, үзләренең ирләре кыстаган аркасында гына җырлап карыйлар да, Сөембикәне ишеткәч, аны чын күңелдән мактыйлар, аңа сокланалар.

— Һи-и, кара инде, син нинди тавыш белән авылда әрәм булып ятасың, ник артистлеккә китмисең? — диләр.

Яңа бер җыр була. Я ул, мин сиңа әйтим, Сара Садыйкованыкы, я Рим Хәсәновныкы. Хәзер композиторлар күп, матур җыр язучылар күп! Элеккеге буын гына өч-дүрт композиторны ишетеп үсте. Менә шул яңа җырны берәр мәҗлестә Сөембикә яра да сала. Клуб мөдире булып эшләгәч, бу җыр аңа беренче чиратта килеп җиткән була. Китә мәҗлестә Сөембикәне мактау!

— Кара инде син, нинди матур җырлый! Көе дә нәкъ синең тавышка гына җайлап чыгарылган, — дип, кайберләре Сөембикәне күкләргә күтәрәләр, Разияның йөрәгенә кан саудыралар.

Разия андый вакытта шулай ук мактый. Ләкин җырчыны да, композиторны да түгел, сүзләрен язучыны мактый, сүзгә актив катнаша.

— Ие, гаҗәп матур сүзләр инде. Бу шагыйрьләр дә каян табып әйтеп бирәләр шундый мәгънәле итеп...

Ялгыша Разия, һай, ялгыша. Яңа җырлар арасында композитор таланты белән генә халык күңеленә кереп утырганы күп, бик күп! Көеннән аралап, ялгыз чишендереп карасаң, бичара җырдан берни калмый. Әллә кайчан әйтелгән Зөһрә йолдыз, зәңгәр күз, айлы кич, туган ягым, кабул ителмәгән мәхәббәт... Ләкин мәҗлестәгеләр, гадәттә, андый поэтик анализга ук барып җитмиләр...

Әнә шулай Разия Сөембикәдән суынды, җыр аркасында гына. Әнә шулай Шәйдулла туганы Ленардан суынды, ат, болын, чөгендер-кишер аркасында гына. Моны акыллы Ленар күреп, сизеп яшәде, әмма вакланмады. Бары тик Сөембикә генә рәхәт яшәде, бәхетле гомер кичерде. Ире акыллы, эшчән, сүзсез һәм хатын кадерен белә торган иде. Сөембикә дә андый ирнең кадерен белде. Ул кичләрен күп укый иде. Шәйдулла янына ятып, яңа чыккан бөтен китапларны кычкырып укып барды.

Ә бер көнне кич Сөембикә әдәби журналдан «Күтәрелгән чирәм» әсәренең тәрҗемәсен укыды. Шәйдулла ул кичне атларга фураж мәсьәләсендә идарәдә тавыш чыгарып, нервланып кайткан иде. Сөембикәнең сүзләре аның миенә чүкеч белән бәреп юри мыскыл иттеләр. Сөембикә әсәрдән мондый урынны укып күрсәтте: үләр алдыннан бер казак янына гөнаһлардан чистартырга дип поп килгән. Алар арасында мондый сөйләшү булган:

«— Митрий ата, теге дөньяда атлар бармы?

— Ни сөйлисең, ни сөйлисең, алла колы? Анда нинди атлар булсын! Җаныңны коткару хакында уйла!

— Анда атлар юк дисеңмени инде? Кызганыч икән! Югыйсә, мин анда да ат көтүчесе булып ялланыр идем... Ат булмагач, минем анда хаҗәтем юк. Алайса, үлмим инде, сиңа сүзем шул!»

Иртәгесен атларга башак биргәндә Шәйдулла тагын чыгырыннан чыкты. Председатель җигә торган атны да ул карый иде. Җиңел юлга гына тотыла торган бу атка көненә бер чиләк солы бирелә. Ат та адәм шикелле бит: бер явызланса явызлана. Кичтән биргән үзенең солысына тимәгән, бер кило кибәкле он һәм борчак саламы белән генә тереклек итүче «рядовой» бер атның утлыгын ваткан да, тегене куркытып, башагын ашап ята. Юашның-юаш инде: тege, бичара, күршедән ватып кергән шома, елтыр аттан бөтенләй шүрләп, читкә елышкан. Ач калган. Ә бит моны бераздан кемдер килеп җигәчәк, көне буе эштә йөртәчәк. Я бу тук сыерларга көне буе фураж ташыр, я утарда симереп беткән сарыкларга печән ташыр. Ә үзенә?

Ул көнне кич идарәдә Шәйдулла яңа председатель белән ут ягып талашты. «Яңа кулак син, белдеңме шуны!» — дип ычкындырды. Ленар, йомшак сүз белән җиңә алмагач, өркетеп карады. Ике туганның кычкырышуы бик яман! Туган булганга үзен шулай тота да ул, теләсәни әйтә. Югыйсә, башка колхозчылар яңа председатель белән бик итәгатьле сөйләшәләр.

— Син мине өркетәсеңме? — диде Шәйдулла, каты чәчен сыпыргалап.— Өркетәсеңме? Алайса, менә шул: мин бу колхоздан китәм инде. Паспортым кесәдә. Алайса, китәм инде...

## «Каз канатларын санадым»...

Тигезлек белән гомер иткән кешеләр, бер-берсен югалткач, тиз какшыйлар. Бибиәсма җиңги, картын мәңгелек йортка озаткач, озак яшәмәде.

— Вәлиулла абзый артыннан кайтып китәргә самалый бу,— дип, Фәхрислам аны бер күрүдә диагноз куйды. Эченнән генә, әлбәттә. Авылда «үлде», «җан бирде» дигән ямьсез сүзне өлкәнрәкләр бөтенләй кулланмый. «Кайтып китте» — янәсе, адәм баласы бу җирдә, бу дөньяда кунак кына. «Агачлыкка илтеп куйдык» дип тә сөйлиләр. Агачлык — зират. Әдәп белән генә, сак кына әйтәләр.

Бибиәсма җиңги дә, үз чиратында, Фәхрисламны күргәч, соңгы йомышын әйтте: «Күмәргә килерсең, яшь-җилбезәк рәтен белми, ләхетемне мул алырсың, тар булмасын, тын кысылырлык булмасын», — диде.

Үзенең йөзе саргайган, күзендә яшәү чаткылары беткән, таякка таянып, капка төбенә һава иснәргә чыккан иде.

Фәхрислам — реалист кеше, юк-бар сүз сөйләп юатып маташмады. Белми түгел, яхшы белә — кеше үлем түшәгенә яткан була, хәл белергә керүчеләр аның рәвешен күрәләр, аңлыйлар: соңгы көннәре моның.

— Терел, — диләр, — минем аягым җиңел булсын.

— И-и-и, ходайның рәхмәте бик киң аның. Әле менәтерәк йөгерәйөгерә көтү куарсың, каз-тавык ашатып йөрерсең.

— И-и-и, әнә безнең Күпербаштагы тәтә нинди хәлдә яткан иде. Җиде ясиннар чыгып, балаларын телеграм сугып кайтардылар. Газраилнең килер сәгате җитмәгән булгач, әнә хәзер тәтә йөгереп йөри. Йөгереп. Әле синнән-миннән калып җөз җыл яшәр.

Бу инде, әлбәттә, халыкның күңел яхшылыгы, әдәбе.

Шулай ди-ди юаталар, әмма белеп торалар: Күпербаш тәтә язмышы бар кешегә дә эләкми. Газраил бер юлга чыкса, буран дип, яңгыр дип тормый. Аның өчен ял көн дә, ял алды көн дә юк. Фәхрислам

мәетне күп күргән, күп күмгән. Шуңа күрә сыйпап-җайлап маташмады, сүзне туры ярды:

— Барыбыз да сул агаслыкка барасы, зинги,— диде,— бер дә борсылма. Исән булсам, барысын да үзем как наять эсләрмен...

Әйтерсең сүз морҗа башы сылау турында бара.

Фәхрислам башкасын да белә: тормыш бу. Үлем зур кайгы, әмма бер кеше үлде дип тормыш тукталмый. Хәтта болай да була: үлем түшәгендәге хатынның хәлен белергә киләләр, баллы төш, лимон, сөзмә, тавык шулпасы күтәреп киләләр.

— Сихәтләнмәссеңме, ризык килешсә, бәлки, җиңеләеп китәрсең,— дип, авыруның башын мендәрдән күтәреп, авызына ризык каптыралар. Әмма уйлап куялар: моның алтмыш өч яшьлек карты ялгыз кала инде. Яшьсенмәсә, Казиледәге безнең Шәмсенурны димләсәң ничек булыр иде микән? Шәмсенур, дөрес, әле кырык тугызда гына. Әмма ир заты карт хатыннан соң яшьне эзли. Һи-и, ирләргә ышансаң, аларга таза тән генә булсын. Алар әллә кемеңне дә сорый барырлар...— Әйдә, әйдә, менә лимонлы чәй эчеп җибәр. Сихәтләнеп китәрсең, алла боерса...

...Бибиәсма яшь чакта чибәр иде. Авылның бер дигән кызы иде. Ә хәзер саргайган йөз, зәңгәрләнгән куллар, корышкан тез башлары, күгәргән иреннәр... Төп йортны ябып, аны кызы — ике йорт аркылы гына яшәүче Нажия — үзләренә китереп салды. Шәһәрдәге зур укымышлы малайга, Вәлиулла картның горурлыгы һәм мактанычы булган Маратка хәбәр бирделәр.

Үз хисабына бер айлык ял алып, Марат кайтып төште. Бер айлык? Димәк, шушы бер ай эчендә ике якның берсен кара инде син, әни! Я теге, я бу! Шуннан да артык торып булмый бит.

Юк, Марат алай уйламады. Аңа егет буларак, ир буларак чыдарга, барысын да күтәрергә кирәк иде. Бер ел өчен, әлбәттә, күбрәк болар. Әле этисен җирләгәнгә нибары өч ай үтте. Ә аңарчы эшендә күпме мәшәкать, күпме борчулар. Дөньяның барышы шактый каты кануннарга нигезләнгән. Марат эшли торган институтта илле яшьлек бер галим — Ибраһимов еллар буена докторлык диссертациясен әзерләде. Бөтен дус-ише, лаборатория кешеләре моның яклаганын зур өмет, шатлык белән көттеләр. Диссертация кызык һәм тормышның барышы өчен практик кирәкле иде. Яклау сроклары билгеләнде, хәбәр таратылды. Әмма галимнең гомер иткән юлдашы — хатыны авыр хәлдә, урын өстендә иде. Яклау атнасы җиткәндә, ул хатын инде вакыт-вакыт аңын югалта иде. Галим аның баш очында утырды, яклауны күчерделәр. Галим хатынын больницага салды, Гыйльми совет яклауның яңа срогын билгеләде. Ул арада авыру хатынга операция булды һәм докторлар операциядән соң аны өенә кайтаруны яхшырак таптылар. Авыруның көннәре санаулы иде. Авыруның соңгы көне — диссертация яклау көненә туры килде. Яклауны өченче срокка күчерү мөмкин түгел иде.

— Бар,— диде хатыны, аңына килеп.— Бар. Бәхил бул. Кызны йорттан читкә җибәрмә. Үзең өйлән.

Гыйльми советка галим хатыны белән бәхилләшеп чыгып китте. Ул диссертациясен яклап кайтканда, хатынны борып куйганнар иде... Әйе, тормышта андый хәлләр дә була.

Маратның этисе үлгән көннәр иде, өлкән галимнең бу фаҗигасен ул барыннан да тирәнрәк аңлады, аның хәленә керде.

Доцент Ибраһимовны студентлар ярата иде. Реалист булганы өчен. Һәм авыл хуҗалыгы темасына әйбәт итеп укыган лекцияләре өчен. Хатынын күмгән көнне дә ул үз лекциясен күчермәде. Беркемгә берни сиздермәде, гадәттәгечә матур, әдәби җөмләләр белән гадәти лекция укыды.

— Җир, — дип башлады ул үзенең лекциясен, — безнең көчебезнең һәм байлыгыбызның чыганагы. Бу сүзләрдә бөек мәгънә бар. Авыл

хуҗалыгында экономия режимы турында сүз алып барабыз икән, беренче чиратта, шуны истә тотыйк: җир ул — авыл хуҗалыгында җитештерүнең төп чарасы, һәм экономия режимы җиргә сак мөнәсәбәттән башлана.

Аның күзләре кызыл, тавышы карлыккан иде. Хатынын җир куенына тапшырып кайткан кешенең җир турында сөйләве күңелгә авыр тәэсир ясый иде, әмма Ибраһимов дәвам итте.

— Пространство ягыннан җир чикләнгән. Җәмгыять үсеше процессында авыл хуҗалыгыннан тыш максатларга котылгысыз рәвештә яңа мәйданнар алырга туры килә. Шәһәрләр үсә, яңа промышленность объектлары төзелә, геологлар тарафыннан ачылган җирләр, авыл хуҗалыгыннан алынып, эксплуатациягә бирелә, сусаклагычлар, аэродромнар, юллар төзелә. Боларның күбесе авыл хуҗалыгыннан алынган җирләр хисабына эшләнә. Әнә шуның аркасында икмәк үстерә торган, терлек көтүләре йөри торган җир мәйданнары кечерәя бара. Җир мәйданнарын рациональ файдалануның нинди юллары бар соң?

Ибраһимов тыныч сөйләде: әйтерсең өченче көн генә әле ул докторлык диссертациясен якламаган, әйтерсең моннан бер сәгать элек кенә әле ул зиратта кулына көрәк тотып балчык ишмәгән...

Ел авыр килде. Апрель аенда Марат кандидатлык диссертациясе яклады, әле әтисе исән иде. «Йөрәк шаяра» дип, Вәлиулла абзый яклау көнне шәһәргә килә алмады. Югыйсә, Марат эшләгән институтта аның таныш галимнәре бар иде. Элек-электән бу галимнәр колхозга кайтып төрле тәҗрибәләр куялар иде. Бара алмады. Барса, әлбәттә, борчылган булыр иде, барысын да белсә, бәлки егылып та калган булыр иде. Марат үзе генә белде, үзе генә кичерде. Ә эш болай тора иде: гыйльми совет җыелырга өч көн кала гына кемдер, әгәр Марат Вәлиевич уңышлы якласа, аны профессор Хәсбиев урынына тәкъдим итәләр икән, дип хәбәр тараткан. Марат үзе әлегә моны белми иде. Ләкин яклауга ике көн кала кинәт кенә профессор Хәсбиевнең үзенә карата бик кискен үзгәргәнен сизде. Моңарчы, безгә яшь кадрлар кирәк, әйдә үс, менә мин дә картайдым, син якласаң, пенсиягә чыгам, дип сөйләнгәләп йөргән профессор кинәт кенә үзгәреп, коридорда, җитәкчелекнең кабул итү бүлмәләрендә ыгы-зыгы йөрене башлады. Фикердәшләр таптык, киң балаклы чалбар, күпертмә җиңле пиджак киеп йөри торган тагын бер-ике карт активлашты, чыш-пыш сөйләшүләр китте. Фән бүлеге хезмәткәре Тамара исемле чибәр кызый Маратка эшнең нидән торганлыгын ачты. Маратның диссертациясе берничә район базасында шәһәрне азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләләренә караган һәм ЭВМ исәпләүләренә корылган иде. Моның нәтиҗәләре белән шәһәр сәүдә оешмалары, Сәүдә министрлыгы һәм Авыл хуҗалыгы министрлыгы кызыксына иде. Профессор Хәсбиев пенсиягә китүе турында болай гына сөйләп йөргән булып чыкты. Бу — үзенә күрә картларның яшьләрне сынавы. Янәсе, нәрсә дип әйтерләр? Әйе шул, сезгә ял итәргә кирәк дияләрме? Әллә, ну, что сез, сездән башка ничек сектор яши алсын, дияләрме? Картлар әнә шулай мәгълүмат җыялар. Марат исә андый очракларда дәшми иде. Чөнки күреп тора, Хәсбиев инде тузган, аннан ни фәнгә, ни җәмгыятькә инде файда юк. Дәрәҗәсе бар, әнә шул дәрәҗәсе белән ул фәндәге һәр яңа фикергә аяк чала. Чөнки яңа фикерне реальләштерергә кирәк була, ә ул — мәшәкатьле. Иң яхшысы — гыйльми утырышларда, перспектив план төзегәндә матур сүз сөйләү, абстракциягә бирелү, фән эшлеклесенең җәмгыять алдындагы бөек изге бурычы турында сөйләү, Маркстан, Дарвиннан, Лысенкодан, Эйнштейннан цитаталар китерү, пафос белән сөйләү. Боларын инде Марат белә иде. Әмма профессорның яклау алдыннан гына үз шәкертенә каршы чыгу мөмкинлеген ул башына да китерми иде. Имеш, Марат Вәлиевичның методикасы дөрес түгел. Имеш, фәндә бу алым инде

яңалык түгел. Харьков институтында инде шәһәр тирәсе колхозларын шәһәрне тәэмин итүгә көйләү буенча әллә ничә диссертация якланган. Берничә җыелышта югары стильдә оча-куна сөйләп Маратны яклаган профессорның мондый кинәт борылышы, әлбәттә, көтелмәгән хәл иде. Хәер, өлкәннәрдән берәү профессорның үткәне турында сөйләгән иде бервакыт. Марат аңа ышанмаган иде. Имеш, Хәсбиев әле аспирант чакта ук берничә өлкән галим өстеннән язылган пычрак кәгазьләргә кул куйган. Марат моңа ышанмаган иде... Аннары колхозга командировкага барганда поездда өлкән бер журналистны очратып сөйләшептанышып киткәч, теге журналист та, Маратны кисәтепме, нигәдер бер эпизод сөйләп ташлады. Хәсбиевне утызынчы еллардан бирле белә икән.

— Федосеев урамының Кремль башында ук яши идек, — дип сөйләп китте ул. — Яңа гына өйләнгән чак. Тар гына булса да фатирыбыз бар. Газетада эшлим, авыл хуҗалыгы бүлегендә. Катлаулы чор. Без, яшьләр, аңлап та бетермибез. Утыз җиденең көзе. Хәсбиев авыл хуҗалыгы темасына аз-маз язгалый. Менә шулай... Иң авыр көннәр иде. Бердәнбер ышанычыбыз — партия, иманыбыз — шул. Вакытлы хәл, партия юлын табар, дөреслек өскә чыгар, дибез. Кемнәрдер эшне буташтырганын сизәбез. Бер кич ашадык-эчтек, баланы йоклаттык, үзебез хатын белән газета-журнал караштырып ятабыз. Аспирант Хәсбиевнең шул көнне генә мәкаләсе чыккан иде, минем бүлектән. Ун кат укылган булса да, газетада басылгач, тагын бер карадым. Төн уртасы иде, яңгырлы караңгы төн. Кемдер ишек кага. Мин дә яшь кенә булсам да курыктым. Төнлә ишек кагу ул чорда шәп фал түгел иде. Куркынып кына ачсак — Хәсбиев. Яңгырга чыланган, озын чәчләре маңгаена ябышкан, күзләре пыялаланган. Керде, чишенде. Аһ та ваһ килә. Чалбар кесәсеннән бер шешә чыгарып утыртты, хатын керогазын кабызды.

— Ни булды? — дим.

— Алалар безне бүген-иртәгә, — ди бу үксеп. — Алалар. Минем мәкаләдә бер төгәлсезлек сизелә.

Шунда ул чәченә бармакларын тыгып башын йолыккалый башлады:

— Син дә... редакциядә эшләп шуны күрмәгәнсең. Минем кульъязмада алай түгел иде. Син мине бетерәсең. Колхозларның киләчәктәге чәчү әйләнеше турында мин болай әйтергә теләмәгән идем. Синең аркада....

Аракыны мин эчмәдем. Ул исә керогаз өстендә йомырка өлгергәнче, бер чәй чокыры аракыны әйләндереп салды да дулап чыгып китте. Шул вакыйгадан соң дошман булып калды. Аннары тагын бер яман хәбәр ишеттем...

Марат шул вакыт үз станциясенә төшеп калды.

Диссертация яклаганда бу вакыйгалар берәм-берәм күз алдыннан узды. Яклау вакытында Хәсбиев дәшмәде. Әмма аның дусларыннан булган киң балаклы бер профессор (институтта ни өчендер аны хәлфә дип йөртәләр, бу сүзнең нәрсә икәнен белмәгән рус аспиранткасы бервакыт үзе барында чын күңелдән «вот хальфя что скажет?» дип сөйләп харап булды) болганчык кына чыгыш ясады, Маратның методикасын шик астына куйды. Хәсбиев бу вакытта хисләнеп, очкынланып утырды. Оппонентлар, югыйсә, яхшы бәяләгәннәр иде.

Тәнәфес булды. Сары, кабарынкы прическалы Тамара коридор тулы галим-голәмә арасыннан Маратны эзләп тапты.

— Чама белән алты кеше кара шар салачак, — диде ул, тынына буылып.— Хәсбиев бөтен кешегә тараткан: сезнең эш, имеш, фән өчен узган этап. Чарасын күрергә кирәк, нишлибез?

Икенче яклаучының оппоненты килеп җитмәгән иде, тәнәфес ярты сәгатькә сузылды. Галимнәр фән бүлегенең алгы бүлмәсенә җыелдылар, анда Тамараның буфетында һәр вакыт «Шифалы су» була иде, Тамара өч-дүрт шешә ачып куйды. Гыйльми совет членнары белән Марат та су эчте. Стакандагы газ бөртекләренең сүнгәнен карый-карый, Марат суны бик озак эчте. Галимнәрнең берничәсе тәмәке кабызды. Я, кайсыгыз мине батыра бүген? Марат берәм-берәм галимнәрнең һәркайсын күзәтеп чыкты. Нигә сез шатланмыйсыз? Мин бит сезнең шәкертегез! Мин бит буразнадан килдем. Авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерүнең нәрсә икәнен мин бит үз җилкәмдә татыган кеше. Мин бит «Беларусь»та, комбайнда эшләгән кеше. Колхозда эшләгән килеш кичке техникумны тәмамладым. Мин бит армиядә хезмәт иттем. Нигә мине батырасыз? Мин бит үз эшемнең кирәкле һәм нәтиҗәле икәненә ышанам. Ярый, сез миңа кандидатлык бирмәдегез, ди. Ләкин минем идеямне, минем исәпләүләремне бит инде Сәүдә министрлыгы файдалана. Шәһәр сәүдә оешмалары бит хәзер минем хезмәтнең нәтиҗәсен өйрәнәләр, аны эштә кулланалар. Карт этигә генә җайсыз булыр. Югыйсә, ул минем белән мактана иде. Ә кайсы ата юньле юлдагы малае белән мактанмый? Мине батыруыгыз — аны үтерү булачак... Стакан стенасында газ куыклары инде сүнеп беткән иде.

Кинәт... бүлмәдә музыка тавышы яңгырады. Ялтыравык тәбәнәк өстәл янында Тамара кайнаша икән. Магнитофон уйната. Шактый көчле итеп. «Каз канатлары», баянда Марс Макаров уйный. Галимнәр тын калдылар, сигаретлар көл савыты кырыенда төтен сузды. Макаров бу көйне моңарчы беркем дә уйнамаганча ашкынып, ярсып уйный. Әйтерсең ул тарихның үзенә, җиде-сигез гасыр тирәнлеккә экскурс ясаган да күргәнен кешеләргә сөйли: менә, ди, тыңлагыз, безнең бабаларыбыз — игенче һәм терлекче хезмәт халкы — әнә шундый көй иҗат иткән. Бу көйдә аның тарихы, хезмәте, бөтен рухи байлыгы, кайгыхәсрәте, киләчәккә ышануы... Макаров баянының басларына зур игътибар бирә. Кайбер урыннарда баслар гына моңлана, бу вакытта авылның бодай басуында ата каз каңгылдап алгандай була. «Гаң-гаңгаң!» Икенче тыңлыйсың — егермеләгән ап-ак казның кыйгылдашып көзге, кояшлы басудан тегермән буасына очып кайтканын ишеткәндәй буласың. Дөнья саф бит, дөньяда гүзәллек бар бит. Дөньяда моң бар бит, сагыш бар, бәхет бар, узган гомер бар, илгә игелек китерү бар! Ә Макаров оста! Бөтен татар халкының мең еллык хезмәт тарихын, сөю-кавышуын, аерылышуын шушы көйдә әйтеп бирә ала. Ә баянга кушылып бер җырлыйсы килә... Баслар «гаң-гаң» килеп җыр иҗекләрен үзләре әйтәләр. Әһә, кемдер шыпырт кына моңая икән.

Каз канатларын санадым
Тез-зелеп каг-гын-ган-да-а.
Инд-де кем-нәргә кар-рар-мын
Өз-зел-леп саг-гын-ганда-да-а.

Юк, бу көй авыз тутырып, бөтен тамакка җырлауны сорый. Марат, стаканын куеп, үзенә каршы тавыш бирәчәк өч-дүрт галимнең йөзләрен күзәтте: каз канатлары аларны, әлбәттә, әле генә әзерләнеп яткан интригадан, ваклыктан суырып алган, чиста, пакъ кырларга, сихерле камышлар белән уралган су буйларына, яшьлек хыялларына алып киткән сыман иде. Авылдан чыккан кешеләр бит болар...

Тамара — көчле психолог. Гыйльми советның унтугыз әгъзасыннан унсигезе Маратның эшенә уңай бәя бирде. Аның кулын кыстылар, матур сүзләр әйттеләр. Тәбрикләгән галимнәр арасында чәчәк тотып Тамара да йөгереп йөри, тик Хәсбиев кенә күренми иде...

Документларын туплап эшен бетергәч, ВАКтан хәбәр көтеп йөргән көннәрдә генә Маратның этисе үлеп китте.

Озак та үтмәде, ВАКта Маратның диссертациясе өстеннән аноним жалоба килгәнлеге мәгълүм булды. Ибраһимов үзенең докторлык дипломын алырга баргач, зур шәһәрдәге агай-эне арасыннан бу турыда ишетеп кайтты. Марат, әлбәттә, борчылды, кешегә генә сиздермәде. Әмма шул ук галим аны тынычландырды да.

— Пифагор, — диде ул, — үзенең мәшһүр ачышын ясагач, шатлыгыннан кырык үгез чалып аллаларга корбан биргән. Шуннан бирле һәрбер фәнни ачыш алдыннан хайваннар дер калтырап торалар икән. Борчылма! Егет бул! Егетлек таза, чибәр, мускуллы булу гына түгел, борчуларга да түзә, аларны кичерә белү дигән сүз...

Һәр шатлыктан соң кайгы, һәр рәхәттән соң михнәт, һәр авырлыктан соң җиңеллек, һәр көлүдән соң елау — һинд халкының мәкале әнә шулай ди. Бер көнне иртән эшкә килсә, ай балтадай көләч Тамара кайнар кулын Маратның зур, каты учына китереп салды.

— Сездән бер шампанское, Марат Вәлиевич, — диде, — ләкин икәүләп эчсәк кенә.

Институтның проректоры, Мәскәүдә вакытта ВАКка кереп, Маратның диссертациясе расланганны белеп кайткан икән.

Тамара белән кичен алар кафеда шампанское эчтеләр. Өенә кайтканда, караңгы подъездда Марат почта ящигын ачып калын гына бер хат алды. Авылдагы апасы Нәҗиядән икән. «Әнине безгә күчердек. Инсульт бугай. Саташа, бутала. Сине еш телгә ала. Күп булса, атнаун көн торыр, диләр. Янында кешесез мөмкин түгел. Кайт, үкенерлек булмасын...»

Дөньяның Хәсбиевләре, анонимкалары, тузган, искергән фикерле галимнәре бик кечкенә, ком бөртеге булып кына калды...

Сентябрьнең егерменчеләреннән яңгыр башланды. Урамнарда «Беларусь» корсагыннан пычрак, автомашина йөри алмый, колхозның казып куелган бәрәңгесе ялтырап кырда ята, чүпли торган әмәл юк. Җитмәсә, җиңел ботинкалардан гына кайтылган иде. Бер атна яңгырдан соң электр энергиясе өзелде, электр белән яшәп өйрәнгәнлектән, я керосины, я лампасы алынмаган, каралмаган. Шәһәр белән юл элемтәсе өзелде, телефон эшләми. Алып кайткан сигарет бетте, нәкъ шул көнне генә «ревизия» дип кибетне дә яптылар. Авыл кибетендәге ревизия кадәр мәгънәсез эш юк. Айлар буе теләсә ничек, расписаниесез, товар бәяләрен төрлечә куеп сәүдә итеп буталып бетәләр дә, ревизия килеп төшкәч, атна буе очына чыга алмыйча халыкны тилмертәләр. Ичмаса, шушындый яңгырлы күңелсез көндә авыру саклап утырганда, шкаф тирәсендә бер шешәң булсын иде.

Ә Бибиәсма җиңги саташа. Вәлиулласын телгә ала. Хәл белергә кергән карчык-корының диагнозы бер генә: «Вәлиулласы чакыра аны... Бичара...» Аннары мышык-мышык елау... Ә син барысына да түз, тыңла. Нажия көне буе фермада, кияве көн-төн тегермән тарттыра. Балалар мәктәптә. Авыру хатын-кызны ирләр күпме карый ала! Ә карарга кирәк. Ул — синең бердәнбер ышанычлы, газиз кешең. Бу — синең соңгы бурычың.

Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Марат Вәлиевич шулай, бер дә сыкранмыйча, әнисенең ябык гәүдәсен караваттан күтәреп алып төнге чүлмәккә утыртты, чүлмәкне чыгарып түкте. Көненә ничәшәр мәртәбә. Аннан арка кочтырып мунчага алып барды, мунча алдында Нажия апасына тапшырды. Юындыргач тагын килеп, күтәреп кайтып китте. Бибиәсма җиңгинең соңгы юынуы иде бу — моны беделәр. Соңгы көннәрдә төнге чүлмәкнең дә кирәге калмады, урын-җирне Марат үзе алыштырып торды. Сине табып үстергән, синең өчен бөтен гомерен багышлаган, кайчандыр таза, куәтле булган бер ананың күз алдында сүнә баруын карап утыру әйтеп бетергесез газап иде. Иң авыры — иң

кадерле бу кешегә син бернинди ярдәм итә алмыйсың. Синең монда утыруың — авыру өчен нуль. Бу — котылгысыз хәл, син монда көчсез. Ми берәзлексез сиңа шуны тукый, әмма йөрәк килешми. Әниең бит ул! Ярдәм ит! Ярдәм ит!.. Йөрәк әнә шулай суга. Ярдәм ит!

Тышта кар катыш яңгыр ява. Урамнан кирза итекләр, кожан кигән Ленар бара. Ак күлмәк, галстук. Аларына зыян китерми. Ленар борчулы — ничә гектар җирдә бәрәңге җыелмаган. Җитмәсә, ашыгыбрак актартып ташланган иде. Менә ул авыл хуҗалыгы! Хәзер сәгать өч, бер-ике сәгатьтән караңгы төшә дә башлар. Институт бүлмәләрендә бу вакытта әңгәмә кыза, почмакларга җыелып, шәп-шәп итеп тәмәке тарталар, бәхәсләшәләр. Анда коры, җылы. Астагы буфетта Җигули сырасы, «Опал» сигареты өзелми.

Бу вакытта җыелышлар башлана. Докладлар тикшерелә. Сәгать өчтә галим-голәмә гомумән кыза, портфельләр бер ачыла, бер ябыла, бер-берсенә рецензиягә әйберләр бирү, яңа чыккан монографиягә рецензия язу, проспектлар карау, диссертациягә отзывлар язу — барысы да шушы сәгатьләрдә сөйләшенә, иртәге көннең сәгатьләре билгеләнә, «алай булса теге атнаның башында», «бу атнаның ахырында» фәләнтөгән дип кызалар... Тик анонимкалар турында гына монда сөйләшенми. Анысы явызларның үз өйләрендә балалар йоклагач язылa.

Бу вакытта гыйльми советта кызыклы гына чыгышлар була. Сәгать өчтә доклад әйбәт тыңлана, чөнки инде көн бетүгә авышкан, ике сәгатьтән эш көне тәмам, аннан җылы өендә, телевизор янында хоккей, футбол. Портфельдә берәүнең мәкаләсе әле хәрәкәтсез ята, аны иртән укыйсы. Ул мәкаләдә, әйтик, яңа бер мәсьәлә күтәрелә: «Явымнар озак дәвам иткән шартларда басудан бәрәңге алу мәсьәләләре». Ах, галимнәр... Әнә ул — бәрәңге алу мәсьәләсе урамнан узып китте. Кырда бер кеше юк, урамда эт заты юк, аннан бары тик председатель генә узып китте, аның эчендә — ут.

Чоланга сөялеп, Марат һәр көнне шулай апасы кайткан арада тышта уйланып тора, тәмәке тарта. Менә бу яңгыр туктамаса, Ленарга беркем дә ярдәм итә алмый. Бер мәкалә белән дә син бу бәрәңгене җыеп ала алмыйсың. Җитмәсә, казытып ташланган. Инде октябрь уртасы — карлы яңгыр китте. Менә кеше ярдәм итә алмаслык хәлләр. Өйдә дә, тышта да...

Күңел өшетерлек шыксыз җил исә, кар ябышып калынайган тополь яфраклары шапылдап юеш җиргә килеп төшә, карт топольләр ыңгыраша. «Дөнья фани, фани, фани... Гомер кыска, кыска, кыска... Теге дөнья дигәннәре буш сүз, буш сүз, буш сүз... Яхшылык эшләгез, яхшылык эшләгез, җирдә әйбәт эз калдырыгыз...» Карт топольләр шулай ыңгыраша сыман....

Кемдер бәхетсез мәче баласын адаштырган. Юешкә калтырап чиелдый-чиелдый, ул баскыч төбенә килде. Күзләрен мөлдерәтеп Маратка карап тора. Бетkән, бичара, үлем — котылгысыз. Җылы эзләп ул кемнеңдер ишек төбенә килеп сыенган, аның, күрмичә, ишек ачып чыккан хутка эченә басканнар. Я ишеккә кысканнар. Аның арт саны карлы пычракка өстерәлеп йөри. «Мияү, мияү... Ярдәм-м-м»... Юк, брат, беркем ярдәм итә алмый.

Ах, шундый могҗизалар эшләрлек сәләтең булса. Ялт! Кояш чыгардың, бер көн эчендә басулар, юллар кипте. Икенче көнне бөтен халык бәрәңгедә. Ленар Фәхрисламович кожанын салган, йөзе шат... Я телефон трубкасын күтәрдең, бер машина медицина галимнәре килеп төште. Карадылар Бибиәсма җиңгине, хикмәтле укол бирделәр, торып басты, морҗа буендагы сәгатькә карады да берни дә булмагандай сорады:

— Казларга ашарга куйдыгызмы?

Ә Маратка нервларын тынычландырырга дип төп-төгәл бер стакан

әчемлек алып килгәннәр, эчертәләр, бер пачка «Опал» бирәләр дә әйтәләр: институтта сиңа кандидатлык дипломы килгән. Барып ал да эшеңә тотын...

Ә мәче баласы?.. Теге галимнәрнең берсе ветеринария докторы икән, бу мәхлукны юды, тегеләй итте — болай итте, терелтте, киптерде, әнисен, хуҗасын таптылар...

Ярым ачык өй ишегеннән чоланга пар бәреп тора. Кемдер, бер карчык искергән, тузган тавыш белән көйләп китап сөйли: «Аллаһы хак, үлмәк хак, үлгәннән соң терелмәк хак, терелгәннән соң кабер газаплары хак...» Аның тавышы Маратның колагына гел бер төрле булып ишетелә: картаю яман, картаю яман, яман... Бибиәсма апа моннан бер ай элек, әле үз йомышына үзе йөргәндә, ишегалдына ялгыз чыккан да керешли бусагага егылган. Шул көе яткан. Гомерне бергә уздырган күрше карчыгы эч пошуданмы, нәрсәдән, аның янына кергән. Керсә — Бибиәсма егылып ята. Я инде шундый вакытта ничек ярдәм итмисен? Күрше карчыгы карап торган да:

— И Бибиәсма, син дә бик беткәнсең икән, — дип, аны шул көе калдырып чыгып киткән. Яманлыктанмы? Юк. Авыр елларда ул карчык актык чеметем чәен, актык шакмак шикәрен Бибиәсма белән уртак тоткан. Күрше хакы — тәңре хакы, дип яшәгән бу юньле карчык ник соң бусагада яткан ахирәтен шул көе калдырып чыгып киткән? Картаю бу. Аның инде мие тузган. Бусагада аркылы ятуны ул һич тә авыр хәл, көтелмәгән хәл дип кабул итми, ул аны кабергә таба барышның билгеле бер баскычы дип кенә кабул итә һәм «фактны констатацияли»:

— И Бибиәсма, син дә бик беткәнсең икән, — ди.

Чөнки ул үзе шул хәлдә...

...Өй ишеге ярым ачык. Анда үлем. Үлем саңгырау, карлыккан тавыш белән үрмәли-үрмәли килә. Китап сөйли торган карчык аның ничек, кайчан киләсен белгәндәй, репертуарын үзгәртә. Хәзер ул догага күчте. «Раббанә атина фить-дөнья хәсәнәтән вә филь-ахирәтен хәсәнатән вә-кыйна газабен-нар...»[1]

Тыгыз соры болытлы күк гөмбәзеннән кыр казлары китеп бара. Серле, сихри тавышлар йөрәкне телеп-телеп ала. Алар ничектер елашып аерылышалар сыман. Юк, язгы казлар тавышы түгел бу. Ачык форточкадан бу тавыш Бибиәсма җингигә дә ишетеләдер бәлки. Ләкин бу казларның язгы тавышын кабат ишетмәс инде ул, бичара. Актык мәртәбә ишетү бу. Шуны уйласаң — котчыккыч. Һәркем бит гомере буе нәрсәнедер актык мәртәбә күрә. Кешеләрне, шәһәрләрне, аэропортларны, трамвай вагоннарын, бу тавыкны, теге кырыкмышны син актык мәртәбә күрәсең... Күп нәрсә үлем алдында шул кадәр кечкенә, мәгънәсез, вак булып кала... Марат үзенең беренче лекциясен, беренче аудиторияне хәтерли. Ибраһимов кебек укырга тырышкан иде ул аны. Җир, икмәк турында әдәби итеп лекция укырга. Аның бөтен кызыкканы шул иде. Ул лекция менә болай башлана иде бугай: «Яхшы иген уңышы алу өчен кеше бик күп көч һәм белем сарыф итә. Илебез кырларында елның һәр көнендә икмәк өчен көрәш бара. «Көрәш» сүзе монда һич тә арттырып кулланылмый. Коры җилләрнең кайнар сулышы, коеп яуган яңгырлар, уртача яки көчле җилләр, өермәләр, үсемлекләрнең яшь, көчсез вакытларында була торган көтелмәгән кыраулар — менә болар барысы да иген басуына һәр вакыт зарар салып торалар...»

Бәхетле көннәр, бәхетле айлар иде ул. Ә кеше тормышының ахыргы минутлары белән чагыштырсаң, бу сүзләр бик кечкенә икән...

---

[1] Аллабыз безгә дөньяда изгелек бирсен, һәм ахирәттә изгелегебезне сакласын һәм безләрне ут газабыннан сакласын (гарәпчә).

Тамагы карлыккан күрше карчыгы китап сөйли. Фал китабы бугай. Тукта, нәрсә ди? Бибиәсма җиңгине үләр алдыннан алдый түгелме? «Бу айда туган бала изге, гакыллы һәм фикерле, сагышлы булыр. Гыйлем вә һөнәргә кабилиятле булыр, гыйлем вә һөнәр аркасында дәүләткә ирешер. Әгәр кыз бала булса, бик хәйләкәр булыр. Әгәр 22 яки 29 яшеннән үтсә, 75 яшькәчә гомер итәр...» Бибиәсма җиңгигә, болай исәпләгәндә, тагын дүрт ел гомер бар икән әле. Әмма — юк инде. Бетте, бетте, аңа бернинди фал ярдәм итми хәзер. Ул инде күкрәк белән генә сулыш ала, аның аяклары суына башлаган. Юк, булмый инде...

...Фәхрислам ләхетне мул алды. Төш вакытында Бибиәсма җиңги Вәлиулласы янына барып ятты. Мәет төшергәндә килгән кешеләр «каберләр нурлы булсын» диештеләр. Моңа каршы нәрсә әйтәсен Марат белмәде, бу — яңа йола иде. Каберне күтәреп, рәтләп бетергәч, Фәхрислам:

— Рәдом яттылар, яхсы булды анысы, — дип, «Прибой» кабызды.

Мәет чыккан йортта ашау-эчү булмый, зираттан кайтышлый, Маратны капка төбендә Ленар көтеп тора иде. Көн аязып килә, көньяктан коры җил исә, аяз һава юрап әтәчләр кычкыра иде.

Ленар — акыллы егет, аш янына утыруга Марат алдына бер стакан куйды.

— Миңа ярамый, колхозчылар янына барасым бар. Сиңа бүген кирәк, — диде.

Бераздан, сөйләшеп утыра торгач, радиоалгычны кабыздылар. Ял көне икән, Казан радиостанциясе концерт бирә икән.

«Маяк» колхозының алдынгы сыер савучылары.... соравы буенча татар халкының борынгы көе «Каз канатлары»н тапшырабыз...»

Көй фани дөньяны оныттырды. Таныш, дәһшәтле, мәгънәле баслар. «Гаңң-гаң-гаң».

Аяк астында идән юкка чыкты. Шәхес каядыр билгесезлеккә күтәрелде. Анда бары тик музыка тавышы гына бар, ул дөньяда бары тик чисталык кына, яктылык кына. Тик нәрсәдер югалган, нидер өзелгән, мәңге ялганмаска дип өзелгән.

— Син тарт, кунаклар белән утырганда Разия өйдә сигарет тартканны бик ярата, гөлләргә файдасы бар, ди. Бакча кешесе бит, белми әйтмидер...

Монысы Ленар икән...

Көй өзелде, сүнде. Өзелде, бетте... Юк, тагын да зур куәт белән халык йөрәген, мең, миллион йөрәкне актарып, тагын билгесезлеккә алып китте... Марат эчтән генә кабатлады:

Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда

Тышта аяз, атналар буе лапас астында тилмереп яткан председатель казлары биек нарат капка янына килеп өелгәннәр, иркенгә чыгасылары килеп шаулашалар. Барыннан да бигрәк күк ата каз шаулый: гаң, гаң, гаң! килә...

Ике көнгә соңга калып, Марат эшкә чыкты. Бер айга алган административ ялның чын сәбәбен Тамара гына белә иде.

Тышта чалт аяз җылы көн, институт хезмәткәрләре себерке, көрәк тотып ишегалдына чыккан: Октябрь бәйрәменә хәзерлек бара иде.

## Аулак өйме, культура сараемы?

Октябрь бәйрәменә дип, колхозда культура сараен өлгертеп яталар. Яңа штатлар бирелде: ул баянист штатымы дисең, массовикмы дисең... Сөембикә директор булды. Кайтарттылар затлы урындыклар,

гаҗәеп матур пәрдәләр һәм — оркестр! Көмеш трубалар, зур барабаннар. Килде шәһәрдән бер үзешчән композитор, өйрәтә башлады егетләрне трубада уйнарга. Үзе туктаган арада егетләргә гел бер темага сөйли:

— Минем давление, аракы эчәргә ярамый, — ди.

Егетләр яшь, кайсы тугызда, кайсы унда укый, кайсы сигездән соң комбайнга утырган, эчүнең әле нәрсә икәнен дә белмиләр. Давлениенең — шулай ук. Үпкәләрен бераз ял иттергәч, иреннәрен юешләп яңадан трубага өрә башлыйлар. Ярты сәгать чамасы өргәч, композитор туктата, төзәтмәләр кертә, киңәш бирә һәм авыр сулап:

— Менә ике ел була, авызга грамм аракы кергәне юк. Миңа эчәргә ярамый, давление, — ди.

Шулай да үз эшен яратып эшли, егетләрне музыка серләренә төшендерә.

Яңа культура сараенда морҗа-фәлән юк, котельныйдан кайнар су белән җылытасы. Аңа мич ягучы итеп председатель үз этисен куйды. Хезмәт хакы зур түгел, күбрәк төнлә эшлисе булганга, авылда моңа сүз әйтүче булмады.

Ленарның исә максат икенче иде. Әтисе, Фәхрислам, котчыккыч искелек тарафдары. Бай яши, ләкин баеган саен зарлана. Һәр яңалыкның бер начар ягын таба. Анынча, хәзерге бодай кумәче — чын күмәч түгел, хуш исе юк, чөнки төрле нәсел бодай белән куша-куша, галимнәр ризыкның тәмен бетерделәр. Әмерхан бәрәңге бетте, аның урынына ниндидер мәгънәсез лорх сорты гына калды, тәме шәп түгел. Элеккеге «йортавай» сарыклар урынына шулай ук әллә ниткән яңа нәселләр чыгардылар, сарык итенең хәзер бер ләззәте юк. Кая ул элеккеге хуш исле күпереп пешкән арыш ипиләре! Шәһәр кибетләрендә дә хәзер нибары бер сорт — арлауский ипи генә ашарлык...

Олайган саен Фәхрисламдагы бу сыйфат арта, көчәя барды. Колхоз буенча бөтен тармакта фән һәм техника яңалыклары кертеп йөргән бер вакытта үз әтисенең мондый позициясе, әлбәттә, председатель өчен кыен хәл иде.

Культура сараена эшкә билгеләнүе әнә шул каткан фикерен бераз җебетү, яңалык кертү өчен иде. Ташкүмерен озын тимер таяк белән бутап, дөрләтеп җибәргәч, Фәхрислам сарайның оркестрантлар бүлмәсенә керә дә, стенага сөялеп, чүгәләп утыра һәм дәшмичә генә күзәтә. Йөзендә бераз гына мыскыллы караш. Бу караш аның йөзендә утызынчы еллардан бирле катып калган караш. Һәр яңалыкка шулай ярым мыскыл белән карый ул, дәшми. Әйе, утыз дүртенче елдан бирле. Фәхрисламның башка чыккан елы иде, авыл башына, каралтыкурасыз ялгыз өй торгызып. Колхоз көтүеннән бер бозау югалды. Көтүче — Фәхрислам. Явызлардан берәү яман хәбәр тараткан: бозау түшкәсен Фәхрисламның өй астыннан эзләргә дип. Авылга, тарихында беренче булып, этле милиция килде. Авыл дөрт итте, бу хәлне күргәннәре юк иде, халык хәтта кыр эшенә дә чыкмады, озын телле, таңкәле каеш кигән этнең идарәдән чыкканын көтеп сабан туйга җыелгандай урамга бөялде. Этле милиционер исә ике пунәтәй белән идарәдән кичке якта гына чыкты, инде көтү кайткан иде.

Халык тынсыз калды. Озын телле, бозау кадәрле овчарка урамга чыгуга, иснәнеп, як-якка тартыла башлады. Милиционер пунәтәйләрдән Фәхрисламның өен сорады. Авыл башындагы ялгыз өй идарә янынннан ук күренә иде. Аннан этне шул якка алып киттеләр. Авыл бетте, кырыйдагы ялгыз өйгә борылгач, эт тә борылды, чинап-чинап йортка керергә ыргылды. Фәхрислам исә тәрәзә пыяласына битен терәп йөзенә бер төрле елмаю чыгарып тик торды. Овчарка әйләндеәйләнде дә чыгып китте. Тик икенче көнне генә уҗым басуының уртасында козгыннар өереннән шикләнеп барган малайлар әлеге бозауның

тоякларын, колхоз клеймасы тагылган колаклы башын күрделәр. Әйләнә-тирәдә уҗым тапталган, кара балчык чыккан, йоннар, тире кисәкләре чәчелгән иде. Дөньяда бүрегә дә яшәргә кирәк бит... Тәрәзә пыяласына битен терәп карап торгандагы елмаю Фәхрисламның йөзеннән шуннан соң инде китмәде.

Хәзер дә шул: дәшми, елмая. Андый кеше хәтәр була. Нәрсә уйлый ул? Бригадирлыктан да хәйлә белән котылды кебек ул. Малаен шакшатырды. Районнан вәкил килгән вакыт, силос кампаниясе иде. Фәхрислам, яңарган ярасын дәвалап, больницадан кайткан гына иде. Идарәгә чакырдылар.

— Бригаданы кабул ит, эшнең кызу вакыты, — диделәр.

Фәхрисламны халык ярата иде. Туры, гадел сүзе өчен. Югыйсә, колхозның иң авыр елларында башка бригадирлар халыкка булмастайны вәгъдә итеп харап булалар иде. Эшкә әйткәндә:

— Давай, давай, быел хезмәт көненә кило ярымнан да ким булмый,— дип, җәй буе сөйләнәләр дә, көз көне өч йөз грамм белән калгач, берничә айга шып булалар. Аннан язга таба тагын кило ярым...

Фәхрислам алай булмады.

— Сезгә, — дип әйтә иде ул кешене эшкә кушканда, — күпме икмәк тиясен мин алдан әйтә алмыйм. Ну инде колхоз үзебезнеке, гел болай булмас, рәтенә бер сыгарлар. Хөкүмәт рәтләми калмас. Эсләми яту ярап бетмәс.

— Ну, шушының теле! Эшләмәс җиреңнән эшләрсең,— диләр.

— Дөресен әйтә бит. Шул дөрес сүзе хакына гына тыңлыйсың инде...

Колхоз авырдан барды. Ничектер төп мәсьәлә белән шөгыльләнелми иде. Иген уңышын күтәрергә диләр, ашлама юк. Җирне яхшы эшкәртергә диләр, машина җитми. Яңа сорт орлыклар юк. Таләпләр генә бар. Силос хәзерләргә кирәк, вакыт көтми. Ә менә шундый уттай эш өстендә районга бөтен активистларны җыялар да «Тел белеме мәсьәләләре» дигән зур киңәшмә уздыралар, көне буе ниндидер бер галимне сүгәләр. Фәхрислам да арттагы рәтләрнең берсендә утыра, башы җитми. Тукта, нинди тел мәсьәләсе әле? Силоска тотынган гына идек бит. Җәйнең бөтен бер көне әрәм була бит. Нинди тел? Булган телгә, әлеге үзебез сөйләшә торган телләргә — русчасына, татарчасына ни булган? Әле шушы телләр белән рәхәтләнеп сөйләшәбез бит. Фәхрисламның бит әле бер-ике авазы бөтенләй дә юк...

Шулай авыр еллар кичелде. Бер-ике ел Фәхрислам эчте. Кешенекен түгел, үзенекен, һәр кич алҗып эштән кайтышлый кибеткә кереп салып чыга иде. Ленар ул чакта армиядә, семьяда аны тыярлык ачуланырлык кеше — Сабира җиңги генә иде. Кибеттән кайтканда ул өенә бәрәңге бакчасы аркылы гына керә. Кайвакыт хатыны кибеттән аны алып кайтырга дип каршы чыккан була. Аны күрүгә Фәхрислам тыкрыкка борыла һәм әйләнеп кайта.

— Теге Геббельс өйдә түгелме минем? — дип, күршеләреннән сорый да тиз генә йортка кереп ята һәм шундук йокыга китә.

Авыр иде. Еллар узды, колхоз тормышы белән дә ныклап кызыксындылар. Күп үзгәрешләр керде — машиналар, ашламалар кайтты, яңача планлаштыру, яңача исәпләү керде. Фәхрисламның әтисе Һидиятулла карт әйтә иде:

— Исәп кирәк, хисап кирәк, уникe пот арпа онына ничат (ничә ат) кирәк?

Колхоз исәп-хисапка, машинага, ашламага корылды. Инде бу катлаулы техника шартларында Фәхрисламның башы чуалып китте. Улы белән әллә ничә тапкыр сөйләште:

— Миннән булмый, икенче кеше тап, — диде.

Тегесе һаман риза булмады.

— Син халыкны беләсең, күпме генә машина кайтса да, колхозны машина үзе түгел, колхозчы күтәрәчәк, — диде. — Мин дә яңа кеше, бригадирны да яңаны куйсак, без кая барып чыгарбыз.

Малай хакы дип моңарчы эшләде. Инде хәзер котылу өчен уңай сәбәп килеп чыкты — авырып алу.

— Бригаданы кабул ит,— диде район вәкиле,— эшнең кызу вакыты, ир кешегә мондый вакытта авырып йөрү оят.

Вәкил погонлы, фуражкалы кеше иде — районның милиция начальнигы. Фәхрислам дипломатиягә күчте.

— Сту син, иптәс палнамусы, бездән булмый ул хәзергә колхозда зитәксе булу...

— Бүген үк кабул ит, иртәгә уракка төшәбез.

— Булмый, әйтәм бит...

— Ни өчен булмый? Моңарчы эшләдең бит.

— Моңарчы булды инде.

— Ә хәзер ник булмый? Инде бит колхозчының тамагы тук, эшкә әйтеп йөрисе юк, оештырасы гына.

— Менә какраз сунысы булмый.

— Ник?

— Сту син, иптәс капитан, булмый ул аның тиклем техника белән командовать итү...

Фәхрисламны һаман кыстылар. Ул актык чарасына кереште.

— Безнең,— диде ул үзе турында,— аракы эсеп ми сергән. Безнең грамыт белән колхозны алга алып барып булмый хәзер. Толковый бригадир кирәк. Безнең ми сергән. Әнә, бик кыссагыз, бригадир ярдәмчесе булып калам...— Ул шулай бригадир ярдәмчесе булып калды.

Фәхрислам — күпне күргән, аңына барысын сеңдереп яшәгән кеше. Артык крестьянча, артык авылча ул. Җирдән аерып берәр разъездга, поселокка күчереп утыртсаң, бер атна эчендә үләр сыман ул.

Егет вакытта мул йөрде, шәп йөрде. Егерменче еллар — нэпманнар, сату-алу, базарлар чоры, авылның барыр юлын эзләгән, крестьян миенең уйлаудан башы каткан чор. Ленин җир бирде, крестьян атлы, сыерлы булды. Гөрләтеп иген игә башлады. Әмма хезмәт авыр, бик авыр иде. Машина кертергә кирәк иде. Алга таба ничек булыр?

Бу вакытта Фәхрислам җиткән егет иде. Каз өмәләре, аулак өйләр. РККАга (армиягә алынуны ул вакытта РККАга алыну дип сөйләшәләр иде) авылдан нибары ике егет алдылар, ул вакытта армиягә алыну бәхете бөтен кешегә дә эләкми иде — шуның берсе Фәхрислам. Авыл аларны көзен ике ай чамасы кунак итте. Ул аулак өйләр... Хәзер, мәсәлән, Фәхрисламның ишеткәне дә, укыганы да бар — язган була кайбер галимнәр: имеш, аулак өй татар халкының артталыгыннан, наданлыгыннан булган. Имеш, аулак өйдә төрле бозыклыклар эшләгәннәр. Юк, дөрес түгел. Җир сөргән, иген иккән егетләр-кызларда нинди бозыклык булсын? Дөрес, яшьлек шаярулары, мутлыклары, кайчакта хаталары да булгандыр. Әмма бит хатаны клубка танцыга йөргәндә дә ясыйлар. Я әйтеп кара син, теге вакытта аулак өйгә йөргән Фәхрислам бүген клубка барып таңгача «кәҗә сугып» утырган бер егеттән начаррак булган дип? Әллә кызларның әхлагы начаррак идеме? Кызларга ул вакытта кырыс хөкем бар иде. Авылда, мәсәлән, фәлән кыз белән фәлән егет фәлән нәрсә кылганнар дип сөйләп тормыйлар иде. Алай вакланмыйлар иде. Тик бер-ике сүз белән генә гомуми хөкем чыгарыла иде. «Минҗамалның эштие суынган». Бетте. Шуның белән тәмам. «Эшти» нәрсә ул? «Щи» дигән сүзме? Шайтан белсен. Әмма шул хөкемне ишетмәс өчен кыз бала үзен бик нык саклый иде. Шаярмагыз сез Фәхрисламнар заманындагы кызлар белән. Дөрес, хәзерге кебек тәрбия җитмәгәндер, хәзерге кызлар кебек тәмле ашап, затлы кием киеп йөрмәгәннәрдер алар. Күбесенең табигать биргән тән

тиресе тиешенчә тулып киерелә дә алмагандыр. Ул вакытта пальтоның артына, түбән ягына мамыктан бераз гына өстәмә мендәр куеп йөрүчеләр була иде. Күкрәк турысына да өстәмәләр куела иде. Ни хәл итәсең? Адәм баласының яшь чакта матур буласы килә. Олайгач матур да, бай да буласы килә. Картайгач матур да, бай да, акыл иясе дә булып күренәсе килә...

Ул уеннар... Хәзер шәһәрдән әллә ниткән сикерүле бию өйрәнеп кайталар. Я ул бию түгел, я йөгерү түгел... Аулак өйдәге уеннар начар идемени? Тәңкә салыш уйныйсың.

— Тәңкә кемдә? Тәңкә кемдә? — дип кызларның уч төбенә «чап» итеп суккан буласың. Яраткан кызыңның шул вакытта озак кына итеп кулын тотып торасың. Аннан күгәрчен туйдыру. Уенда отылган егет белән кызга «күгәрчен туйдырырга» дип җәза бирәләр. Халык аның «җәза» дигәнен дә ямьсез сүз итеп аңламый, шуңа күрә сүзен үк үзгәртеп «яза» дип әйтәләр. «Яза» үтәлә: егет белән кыз бер шырпының ике башыннан да кабалар да әкрен-әкрен генә теш белән әчкә алып араны кыскарталар. Егетнең дә, кызның да болай итеп «күгәрчен ашатканда» башлары әйләнә, аяк астындагы идән каядыр төшеп китә, тын кысыла, йөрәк дөп-дөп килә, рәхәт, бик рәхәт була. Я нәрсәсе начар, нәрсәсе әхлаксызлык моның?

Аулак өйгә кай чакта яшьлекләрен сагынып, өлкән ирләр килеп чыга. Күбрәге — салган баштан. Аларны мәзәк өчен генә кертәләр, тиз чыгып китүләрен өмет итеп сүзләрен тыңлыйлар. Берчак шулай кызмача көе аулак өйгә Галләмгали агай килеп кергән иде. Егерме тугызынчы еллармы икән? Һәрхәлдә, Фәхрислам РККАга киткәнче иде. Картлачны тиз озатканнар. Караңгы урамнан кайтып килешли Фәхрисламны очратты. Карлыккан тавыш белән тегенең җилкәсенә кулын куеп җырлады:

Түбән очка төшкән идем
Аулак өйләр бар диеп, Фәхрислам.
Тышка урын җәеп бирделәр
Өйдә урын тар диеп, Фәхрислам.

Фәхрислам да аннан котылу ягын карады. Кич йөрергә чыккан өлкән кеше, гомумән, яшьлеккә комачау итүдән башкага ярамый. Хет авылда, хет шәһәрдә булсын. Бераздан Галләмгали агайның тузган тавышы ерактан ишетелде.

Су буенда вак таллык,
Вак таллыкта вак бал-лык.
Вак балыкның мае юк —
Бездә кызларның җае юк...

...Оркестрда шушы колхоз өчен заказ белән язылган яңа көй өйрәнәләр. Фәхрислам бүлмә тактасына сөялеп утырган да тыңлый. Хәзер яңа мода китте... Һәр район көйгә заказ бирә. Аннан колхозлар үз көйләрен тудыра башладылар. Килә шагыйрь, килә композитор. Суела сарык, әллә күпме тавык. Һәм җыр туа. Ул җырда менә мондыйрак өр яңа сүзләр була: бу колхозның кызлары бик уңганнар икән, болар шуның өстенә бик чибәрләр дә икән, боларның даны күрше тирәгә таралган икән. Тагын, боларда кичләр зәңгәр икән, хисләр көчле икән. Һәм башкалар... Өр яңа сүзләр.

Оркестр тырышып-тырышып яңа көй өйрәнә. Фәхрислам тыңлый. Әйдә, ярар, һәркемнең үз яшьлеге була. Хәзерге яшьләр әнә оркестр яраталар, танцы яраталар, бильярд уйныйлар. Уйнасыннар, әдәпле, культуралы булып үссеннәр... Без риза, без — каршы түгел. Гомер — яшьләрнеке.

Культура сарае, шулай да, Фәхрисламга бер ягы белән бик ошады: аның бер бүлмәсендә Бөек Ватан сугышы чорына кагылышлы документлар туплый башладылар. Сөембикәнең әйтүенә караганда, монда «Алар Ватан өчен сугыштылар» дигән зур витрина оештырылырга тиеш иде. «Ватан сугышы чорында безнең колхоз» исемле бер музей сыман бүлек тә буласы, имеш. Музей һәм витрина язга — тугызынчы майга ачылырга планлаштырылды.

Китте документ җыю, хатлар, фоторәсемнәр, солдат киемнәре... Музейга көн саен нәрсә дә булса өстәлә торды. Музейга иң актив әйбер җыючыларның берсе — Фәхрислам иде. Фәхрислам бигрәк тә сугышта үлеп калган энесе Зиннәткә кагылышлы документлар, хатлар туплады. Зиннәт — тын гына, шыпырт кына егет, сугыш вакытында бөтен авылны таңга калдырды: командованиедән аны мактап өч тапкыр хат килде, аның батырлыгы турында язылган фронт газетасыннан өзекләр килде. Зиннәтнең һәлак булыр алдыннан гына җибәргән соңгы фоторәсемен авылда кулдан-кулга йөрттеләр: аның күкрәгендә ике Дан ордены бар иде. Галләмгали агай — белемле кеше — сугыш беткәч сөйләп йөрде:

— Тагын берсен эләктерсә, Геройга тиң буласы булган. Дан орденының өчесен дә таккан егетләрне күрдем мин: урамнан барганда офицерлар үзләре честь биреп калалар. Шаярма син. Солдат ордены ул...

Зиннәткә кагылышлы күп әйбер җыелды. Зиннәт утыз алтынчы елларда Ташкент, Кәттә Курган тирәләрендә акча эшләп йөрде. Кизил якларына да килеп чыкты. Һәр ай саен йортка хаты килеп торды. Хатны бик мәгънәле, төгәл яза иде. Сугыштан язган кыска хатлары белән бергә, Кизил, Ташкент якларыннан язган бер-ике хаты музейга китерелде. Дөрес, язган хатлары эчтәлеге, стиле ягыннан бер-берсеннән күп аерылмыйлар иде.

«Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле газиз атам белән газиз анам, энем Шәйдулла белән сеңлем Саимә сезгә үземнең яшь йөрәгемнән кайнап чыккан сәламнәремне иртән искән таң җилләре аша җибәреп сезгә тазалык, тынычлык теләп калучы улыгыз һәм абыегыз Зиннәт дип белерсез. Янә Фәхрислам абый семьясының барчасына аермаенча күп сәлам. Янә Вәлиулла абзыйларның барчасына аермаенча күп сәлам. Янә Галләмгали абыйларның барчасына аермаенча күп сәлам. Янә Мәтәли абзыйларның барчасына аермаенча күп сәлам. Янә...

...Сәлам соңында сүзләргә күчәм. Мин исән-сау, ул тарафларда сезне дә исән-саудыр дип беләм. Май числасының унберендә язган хатыгызны егермесендә алып укып бит шат булдым.

Монда тормыш ярыйсы гына, арыш оныының поты ун-унике сум, кайбер атналарда тугыз сумга да алырга була дип сөйлиләр. Бодай оны унбиш-уналты сумнар тирәсе. Кибетләрдә чәй-шикәр бар, йөзенче, меңенче [1] чәйләрне дә бер ярты көн чират торсаң, алырга була. Шушы көннәрдә генә сезгә посылка салдым: алты такта йөзенче чәй, ике кило алма каклы конфет, әтигә бер пар шахтер галошы, әнигә бер пар кызыл эчле галош, Шәйдуллага полсукно чалбар, Саимәгә бер пар пәнски [2] оек. Чәй-конфетны аз-маз күчтәнәч итеп күрше-тирәгә, мине

[1] Элегрәк такта чәй шулай номерлап аталып йөри иде.

[2] Казан арты сөйләме. Портта бәйләгән оектан аермалы буларак, фабрика оегын шулай дип атаганнар.

сораганнарга, яхшы сүз белән искә алганнарга биргәләрсез. Үзем, исән булсам, каты сука өсләренә кайтып җитәрмен, инде исән йөреп кайтсам, колхозда гына эшләмәкче булам, дөньяны күрмәдем түгел, күрдем...»

Зиннәт өйләнмәгән иде, шул көе сугышка китеп барды да бетте. Ә менә аның дусы Ибрай өйләнгән иде, бер ел хатын белән торып калды. Ибрайның үзе киткәндә бер айлык малае калды — Ибрай да бетте. Фәхрислам аның хатларын эзләтте. Хатлар сакланмаган иде. Авыл бетереп эзләп, Ибрайның бер фоторәсемен таптылар. Саргаеп беткән кәгазьдә иптәш егете белән Ибрай иде. Кара калын костюмнан (ул чорда авылда «фәлән егет кәчтүм-чалбар алган» дигән зур хәбәр йөри иде), күн итеген сыдырган, балакларын шул сырлы итекләргә тутырган. Һәр икесе дөп-дөрес итеп, туры гына итеп калын кепкалар кигәннәр, Ибрай ак күлмәкнең киң якасын мул итеп пиджак өстенә чыгарган. Ике егет елмаешып бер-берсенең кулларын кысканнар да фотообъективка караганнар. Карточканың артына: «1940 ел, воянкаматка каралырга барган җирдән төшелде, уникенче апрель» дип язылган. Һәм аска болай дип тә өстәлгән иде: «Гаеп итмәгез, начар төшелде».

Культура сараеның түрдәге бүлмәсендә Фәхрислам боларны озак карап утырды. Узган гомер, бу авылда яшәгән егетләр берәм-берәм күз алдыннан кичтеләр. Авыр уйлар баш миен томалады. Өенә кайтып урынына яткач озак вакытлар күзен йокы алмады. Ни өчен болай килеп чыкты соң әле бу? Авыл тулы тап-таза ирләр, егетләр иде — менә шулар хәзер юк. Адәм баласы шуның өчен яшимени? Ана үзенең баласын шуның өчен — бомба, снаряд астында туракланcын, янсын, батсын, асылсын, атылсын өчен үстерәмени? Фәхрислам аңлап бетерми: хәзер телефон заманы, дәүләт башлыклары нигә бер-берсенә чылтыратып сөйләшмиләр икән? Мәсәлән, болай дип:

— Әссәләме галәйкем! Бу мин әле. Ни хәлдә яшисең? Хатының, бала-чагаларың исәнме? Явым-төшемнәр ничек? Әле печәнгә төшмисезме? Арыш серкә очырдымы? Карале, кардәш, без болай итик әле. Әрмиләрне таратыйк. Сугышмыйк моннан соң. Син дә тыныч йокла, мин дә...

Тегесе җавап бирә:

— Вәгалайкем әссәләм. Әле бүген үзем дә чылтыратырмын дип тора идем. Исәнлек-саулык. Яңгырлар булды. Ие. Бик. Яхшы. Печәнгә бүген-иртәгә дип торабыз. Арыш та серкәнең соңгысын очырды. Ие, бер ун көннән өлгерер дә. Көннәр кызу торса. Ә-ә... Әрмияләрне әллә кайчан таратасы иде. Нигә сугышып торырга. Ие. Әдәм каны коярга, нәрсәгә хаҗәт ул. Килештек. Мин хәзер күрше мәмләкәткә хәбәр итәм.

Таң атканчы Фәхрислам бөтен президентлар, патшалар, премьерлар белән шулай сөйләшеп чыкты. Ә таң алдыннан...

Әллә ниткән йомыш белән генә урманчылыкка барган иде Фәхрислам. Соңга калынды. Кич булды, ай калыкты. Камыл басуыннан туры ярып авылга кайтырга чыкты. Бөтен дөнья — аяк астындагы камыл, бераз читтәгерәк карабодай басуы ай нурына коена иде. Камыл басуы — сары алтын, карабодай басуы — ак көмеш диңгезе булган. Авылга кадәр ике чакрым юл иде. Менә Фәхрислам кемнәрнеңдер мыдыр-мыдыр сөйләшкәнен ишетте. Горизонт артыннан бик озын ике адәм күренде. Котчыккыч озыннар, пожарный сарайның каланчасы биеклеге булыр. Әһә, бу аларның күләгәсе икән. Менә алар Фәхрислам янына килеп тә җиттеләр.

— Нихәл, абый! Әйбәт яшисеңме?

Зиннәт икән.

— Нихәл, Фәхрислам абый? Дәү карт булабызмы?

Монысы Ибрай икән.

Киттеләр. Авылга таба бергәләп, салмак атлап өч ир китте. Күбрәк тегеләр сөйләште.

— Ибруш! Хәтерлисеңме, утыз өченче елнымы икән, шушы басуда каты сукада вакытта...

— Хәтерләмәскә соң. Тульке утыз икедә ул, ялгышма. Ну, үзебез дә инде. Шундый кигәвенле вакытта көн үзәгендә ат янына ятып йокларга.

— Ие. Мин уянмасам син сука тимере арасында беткән идең инде.

Фәхрисламга бер сорау бирмиләр. Авылга килеп җитәрәк адымнарын кызулаттылар.

— Бергәләп йөрибезме? — диде Зиннәт.

— Шту син, аерылмыйбыз. Әйдә башта безгә.

Зират башындагы арт урамга чыктылар. Авыл тып-тын. Кайбер тәрәзәләрдә генә ут җемелди. Ибрайның йорты хәзер яңа икән. Ул бераз гына нигезен танымый торды. Ут яктысы мулрак төшкән бер тәрәзә артына килеп бастылар һәм күзәтә башладылар.

Ибрай хатынын таныды. Зиһникамал картайган икән. Яшь вакытта таза бәдәнле кыз иде. Кулында эш уйнап тора иде. Тукта, ничә ел күрешмәгән? Егерме биштән узганмы? Картайган. Башын бәйләп куйган. Димәк, баш авыртуы белән җәфалана. Тегесе кем? Табак-савыт юып йөри. Таза, яшь хатын. Бәлки килендер? Малай кайда? Әнә идәнгә сузылып яткан. Кемдер зарлана, кемнедер ачуланалар. Ят тавыш. Киленнекедер.

— Көн дә — көн дә эчеп кайтмаса! Аракы зәхмәте тигәндер, аракы зәхмәте. Электрик булдым диген дә, кешегә кер дә эч, кер дә эч. Туйдым, билләһи! Минем бәхетсезлегемә дип бер исерек үскән икән. Туйдым. Бер кабар җирем калмады...

Зиһникамал дәшми генә нәрсәдер бәйләп утыра.

— Әйдә, сезнекеләргә, — диде Ибрай, авыр сулап.

Киттеләр. Зиннәт төп нигезне тиз таныды. Тәрәзә каршында янтаеп үскән шомырт бар иде, малай вакытта шуның ботагына менсәң йорт эче күренә иде. Шомырт юанайган. Зиннәт тиз генә шунда менде, өй эченә күз салды. Фәхрислам белән Ибрай нигездә басып, тәрәзә пыяласына борыннарын терәделәр.

Стенада зурайтылган портретлар. Һидиятулла абзый! Я алла! Костюм, галстуктан. Гомерендә күргән әйберләре түгел. Монысы кем? Зиннәт ич! Зурайтылган, бизәлгән. Ә-ә, теге вакытта. Сталинград янында партбилетка дип төшерелгән иде.

Йортта сөйләшәләр. Кечкенә энесе Шәйдулла икән. Тегесе хатыныдыр. Тукта, кем турында?

— Зиннәт абыйның биографиясен сорап район газетасыннан шалтыраттылар. Җиңү көненә материал бирәбез диләр. Бала вакытыннан алып сугышка киткәнче ниләр күргән, кайларда эшләгән.

Монысы хатын-кыз тавышы. Әйе, чибәр генә бер хатын өстәл янында китаплар белән мәшгуль. Шәйдулла диванга кырын яткан. Ахрысы, радио тыңлый. Бер сүз дә дәшми.

— Я, киттекме?

Зиннәт кәкре карт шомырт кәүсәсеннән җиңелчә генә шуып төште. Ибрай — этисе йортына, Зиннәт — абыйсы йортына бару турында телгә дә алмадылар. Фәхрислам белән дә сөйләшмиләр.

Туп-туры кырга, килгән якларына чыгып киттеләр. Фәхрислам да алар белән атлады. Үргә менеп җиттеләр. Авылда инде утлар сүнгән,

идарә янындагы баганадан радио тавышы да ишетелми, дөнья тын иде. Туктадылар. Авыл ягына борылдылар. Көнчыгыш ягы кып-кызыл иде. Талгын гына җил исте, авыл аркылы узган бу җил сыер абзарының җанга якын, күңелне кузгатырлык исен — бала чак исен алып килде. Офык ягындагы кызыллык әллә нинди нечкә озын, экияттәге кылыч сыман кара болыт кисәге белән урталай ярылган: күрәсең, кичтән явып бетми калган бер болыт кисәге көн яктылыгында үзенә кая барыр урын тапмый иде.

Зиннәт шинелен бөтереп төрде, камыт ясап җилкәсенә салды.

— Я, ярый, — диде ул, Ибрайга карап, — кояш чыкканчы мин тегендә булырга тиеш. Анда, курган өстендәге обелискта, списокта торам мин. Иртән анда халык килә башлый. Соңга калырга ярамый.

— Миңа да иртән сигездә частьтә буласы, — диде Ибрай. — Анда ротада иртәнге тикшерү вакытында һәр көнне минем исемне әйтәләр.

— Хуш. Син кай якка? Миңа — көньяк-көнбатышка.

— Миңа бераз төньяккарак. Калинин ягына.

— Тагын кайчан кайтабыз?

— Ә-ә... Исән булсак, бер кайтырбыз әле...

Көнчыгыш тагы да ныграк кызарды, талгын җил тагын бер тапкыр исеп куйды, авылда кемдер «Беларусь»ен кабызды, урам башындагы баганада электр утын сүндерделәр.

Егетләр эре-эре атлап китеп бардылар, киткән саен аларның гәүдәләре озыная иде.

Көнчыгыш җиле аларның артыннан куа китте...

...— Йокымны йокы итмәдең. Әллә эчеп кайткан инде, оятсыз? — диде Сабира җиңги караватыннан торганда Фәхрисламга. — Үкерү дисеңме, теш шыгырдату дисеңме. Бүген дә шулай клубта озак утырасыңмы? Төн уртасында кайтасыңмы?

Фәхрислам байтак дәшмичә торды.

— Ә, бер кайтырбыз әле, — диде аннары, авыр сулап.

## Мәтәли агайның оныгы

Һич тә уйламаганда, һичкем көтмәгәндә Мәтәли агайның оныгы Хәбибрахман тотты да унны бетерде. Укыр дип, югыйсә, беркем дә башына да китерми иде. Ун ел буе, югыйсә, өчледән югары билгене бөтенләй күрмәде. Моңа гаҗәпләнеп бетерә алмадылар, авылда бер вакыт хәбәр таралды: Хәбибрахман, имеш, югары уку йортына китә икән. Монысына, әлбәттә, ышанмадылар, шаяру дип кабул иттеләр. Идарәдә инде трактористлар курсына җибәрергә дип, һич булмаса, ферма мөдиренә ярдәмче итәргә дип чамалап торалар иде. Әмма июльнең егермеләре тирәсендә Хәбибрахман фанер чемоданын сул җилкәсенә салып, чыннан да, тимер юл станциясенә таба чыгып китте.

Ә нигә гаҗәпләнергә?

Нигә әле Хәбибрахманга югары уку йортына кермәскә? Ул кемнән ким? Нәрсә, югары уку йорты ул әллә гел бишкә укыганнар өчен генәме? Ә шундыйлар очрамыймыни: беренче класстан алып унынчыга кадәр гел бишкә укый. Баксаң, бер фәнне дә яратмый икән ул. Аның төп максаты — институтка керү икән. Керә дә, тәмамлый да ул аны. Анда да гел биш. Баксаң — эгоист икән ул, коллективтан аерылган индивидуалист икән. Һәр ялтыраган алтын түгел икән әле.

Шулай булгач, Хәбибрахманга нигә институтка кермәскә? Бәлки, өчлегә генә укыса да, кечкенәдән гыйлемгә мәхәббәте зур булгандыр аның. Ә ул әтисез үсте, сугыш чыккач, алар әнисенең төп йортына — бабай йортына кайттылар.

Аның бабасын авылда Мәтәли карт дип йөртәләр иде. Картның чын исеме элек Мөхәммәтгали булган. Ләкин бу исем шул кадәр ерак күмелеп калган ки, моны хәтта Мәтәли карт үзе дә оныткан. Яр буеннан качып-посып аның бәрәңге бакчасына килеп чыккан казларга Мәтәли карттан рәхим-шәфкать булмады. Ул аларга юан имән таягын ыргыта, имгәнеп калган казны тотып, муенын борып ташлый, аның бакчасына таба тезелеп менеп барган үрдәк бәбкәләрен чалгы белән кыра. Берәр сарык бәтие көтүдән адашып аның бакчасы тирәсенә килеп чыкса — бетте диген. Мәтәли карт аны тота, бәтинең үз тиресе төсле кыл алып, аның аяк сеңерен рәхимсез рәвештә кыл белән буып куя. Бәти аксап кайтып китә, хуҗасы аксауның сәбәбен белми. Бераздан бәти, аягы шешеп, үлә. Тиресен тунаганда гына хуҗа кешенең пәкесе теге кылга барып төртелә. Бер дә шикләнмичә: «Мәтәли дуңгызның эше бу», дип хөкем чыгарыла.

Ләкин Мәтәли бик дини карт иде. Һәр көнне ул икенде, ахшам намазларын укып барды. Шәригать, намаз укыган җирдә сурәт-фәлән булмасын, намазлык тирәсендә хәрәкәт булмасын, дип өйрәтте. Хәзер стенада нәрсә генә юк соң! Шуңа күрә Мәтәли карт намазны ишегалдында яшел чирәм өстендә укый. Монда сурәт тә, хәрәкәт тә юк. Тик менә Мәтәли картның калын, коры тавыш белән яңгыратып намазны башлавы була — аның ике яшьлек оныгы — ыштансыз Хәбибрахман намазлык өстенә үрмәләп килеп керә. Һәм шуннан соң намаз менә болайрак бара:

— Әгузы билләһи минәш шәйтан ирражим. Бисмилләһи... Гафифә! Алыгыз әле моннан Хәбибрахманны, намазымны бүлдерте бит чукынып киткере! Бисмилләһи рәхман әррәхим. Әшһәдә ән ла илаһа... Гафифә! Колагыңа таш керде мәллә! Алыгыз бу көчекне моннан. Әшһәдә ән лә илаһа илла аллаһы мөхәммәде рәсүлулла. Хәбибрахман! Син (фәлән дә фәсмәтән) китәсеңме, юкмы намазлыктан? Чык дим намазлыктан, зинадан туган нәрсә!

Бу — һәр кичне шулай дәвам итә. Кайвакыт Хәбибрахман намазлыкны юешләп тә ала. Мәтәли картның бу вакытта Хәбибрахманның аяк сеңерен буарга кызыгудан тавышы калтырый, намаз онытыла.

Мәтәли карт — авылда үзен иң дини, иң тәкъва кеше дип исәпли иде. Әйе, иде! Чөнки ул инде күптән «агачлыкка кайтып» китте. Ә Хәбибрахман үсте, югарыга үрләде. Әле аның яшисе бар, бабасы, атасы күрмәгәннәрне күрәсе бар.

Хәбибрахманны белемгә гашыйк итүче кеше — беренче курста, беренче сентябрь көнне беренче лекцияне укыган карт галим булды. Карт галим, күрәсең, паралич кичергән, муены бер якка авышып катып калган иде, кереп кафедра янына басты да башын читкә борган килеш сөйләп китте. Тел галиме икән.

— Анда,— диде,— әдәбиятчылардан бер хыялый бар, сезнең башыгызны шул бутап бетергәнче, мин сезгә кайбер киңәшләр бирим әле. Сөяк өчен җелек ни дәрәҗәдә булса, кеше өчен дә белем шул дәрәҗәдә: кимекнең матурлыгы — җелек; кешенең матурлыгы — акыл. Белемсез кеше — җелексез сөяк кебек буш нәрсә. Җелексез кимеккә кул сузмыйлар. Белүче белеме белән югары күтәрелде, белемсезлек кешене түбән чиктерде. Кешелек дөньясының акылы, эпохабызның даһие Владимир Ильич «әгәр мин аз белүемне беләм икән, мин күбрәк белергә тырышачакмын» дигән...

Хәбибрахманнар группасындагы студентлар әсәрешкәннәр, лекцияне язып барырга да онытып тыңлыйлар иде. Кызганычка каршы, карт галим шул елны пенсиягә китте.

Хәзер Хәбибрахман — авылдагы иң могтәбәр егетләрнең берсе. Чөнки ул Ленардан алда югары белем алып чыкты, Мараттан алда

кандидат булды. Бер авылдан ике кандидат — аз түгел. Ә Хәбибрахман — шуның беренчесе. Ләкин Хәбибрахманның кандидатлык юлы җиңел булмады. Аның кандидатлыгына авылда комачаулый торган факторлар бар иде. Авыл халкына нәрсә? Ул — гади халык. Аңа кандидат ни, академик ни? Алар, яратып, үз итеп һаман да әле Хәбибрахман дип дәшәләр. Я инде, ачуым килмәгәе! Хәбибрахман исемле фән кандидаты буламыни? Шәһәрдә бит инде әллә кайчан ул Хәбиб Фәһмиевич дип мәшһүр. Ә монда кайтса:

— Мәтәли картның Хәбибрахманы кайткан!

— Фәһметдин малае кайткан! — диләр.

Хәбибрахман авыл халкының мокытлыгына шактый ук рәнҗи. Мокытлар! Исем кушканнар, әмма татар халкының киләчәген күрмәгәннәр. Ә бит ата-баба бу исемне инде Совет заманында кушкан. Хәбибрахман, имеш! Я, уйлап карагыз инде, менә, әйтик, бервакыт шушы егет академик булды, ди. Академиклар сайлау бюллетенендә язылган:

— Хәбибрахман Фәһметдин улы Мөхәммәтгалиев.

Мондый бюллетеньгә, әлбәттә, шундук кара шар[1] салалар. Шул булдымы исем, шул булдымы академик?

Шулай да, академиклыкка әле ерак, хәзергә Хәбиб Фәһмиевич дигән исем астында шәһәрдә ярыйсы гына яшәп яту...

Шәһәрдәге юл да авыр, бик авыр булды Хәбибкә. «Авыллык» аңа гел комачау итеп торды. Укырга кергәннең беренче атнасында ук ул зур оятка калды. Бөтен факультетка. Ярый инде түзде, анда да шул «авыллыгы» белән генә түзде. Башка шартларда үскән кеше булса, шул көнне үк шәһәрне ташлап чыгып китәр иде. Ә эш болай булган иде: укуның беренче атнасында ук сәламәтлек пунктында боларга комиссия ясадылар. Пунктның ишегенә язып куелган иде: иртәгә сәгать сигезгә лабораториягә анализ өчен фәлән-фәлән нәрсәләр тапшырырга дип. Хәбиб шунда кычкырып янды: иртәгесен ул «Спартак» ботинкаларыннан бушаган зур бер кәгазь тартма һәм маринованный томаттан бушаган литр ярымлы банка белән лабораториягә килде. Шырпы тартмалары һәм майонез банкалары арасында аныкылар, әлбәттә, контейнер һәм домна миче булып күренделәр.

Группа ул көнне ни рәтләп лекция тыңлый алмады, ни вакытында ашап-эчә алмады.

Инде ул вакыйга онытылды. Дөньяда азмы әйберләр шулай яңа хәлләр, яңа вакыйгалар белән күмелеп бара. Бишенче курска җиткәчме икән, Хәбиб бер егетлек эшләп карады: бер кафеда официант булып эшләүче яшь хатын белән танышты. Хатын чибәр, каны уйнап тора иде. Хәбиб каушаудан нәрсә ашаганын, нәрсә эчкәнен белмәде, алма согына тоз салып болгатты, тагын әллә ниләр бутап бетерде. Чөнки теге хатын сүз арасында үзенең бер квартирада ялгыз яшәгәнен, иренең бик каты эчүче булганын һәм эчә-эчә кешелектән чыккач, каядыр Себер ягына китеп барганын, инде рәсми рәвештә аерылышканнарын сөйләде. Ул арада Хәбиб кыюланып китеп тегенең адресын да сорады. Хатынга нәрсә? Өстәл өстендәге кәгазь салфеткага дүрт-биш сүз язды да китте: «Набережная, 4, кв. 9. Сигездән соң».

Хәбибнең кичкә кадәр башы шаулады, колаклары чыңлады, берөзлексез тамак төбе кипте, тыны сикерде. Кичке җидедә исә ул инде гастрономда иде: бер шешә «Волжское», өч йөз грамм карамель алды да Набережнаяга таба юл тотты.

Иртәгесен кафеда теге хатын, имеш, Хәбибнең группадаш кызларыннан берсенә болай дигән:

[1] Тавыш биргәндә «каршы» тавышны галимнәр дөньясында «кара шар салу» дип йөртәләр.

— Егетегезгә әйтегез: коньяктан түбәнне эчмибез, шоколадтан түбәнне ашамыйбыз...

Ах, бу авыллык!

Нинди зур хисләр, нинди бөек өметләр белән барган иде Хәбиб ул кичне Набережная урамына!

Шуннан соң Хәбиб чит-ят уйларны ташлап гыйлем урләренә таба юл алды... Аның җитәкчесе, илле яшьләрендәге доцент, бичара, хәмерне начар нәрсә дип әйтергә йөрәге җитүчеләрдән түгел иде.

Дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, дипломын бишкә яклагач, аны аспирантурага тәкъдим иттеләр. Җәй үтеп беренче октябрь җиткәндә Хәбиб инде зур китапханәнең «гыйльми хезмәткәрләр өчен» дип язылган уку залында китап дөньясына чумып утыра иде. Баштарак «аспирант» дигән хикмәтле исемгә ул ияләнә алмады, бу исемгә үзенең шәхесен туры китерә алмыйча җәфаланды. Атна-унбиш көн үткәч әкренләп рольгә керде, бер тапкыр авылга да кайтып килде. Әнисе аның шәһәрдә калуын зур фаҗига буларак кабул итте. Дөресен генә әйткәндә, бу — малайсыз калу дигән сүз иде. Хәбиб «Татар телендә тагылмаларның кайбер мәсьәләләренә карата» дигән теманы диссертация итеп эшләп чыгуның дөньякүләм әһәмиятен, күпме генә тырышмасын, үзенең әнисенә аңлата алмады. Ана елады да елады. Абзар-кураның рәте киткән, өй искергән, базның таш стеналары җимерелә башлаган иде. Мәтәли карт дәшмәде — ул инде үзенең яше буенча бөтен әйбергә дә битараф карый башлау чорына килеп кергән иде.

Хәбибрахман, шулай итеп, Мәтәли онытьг булудан, үзенең озын исеменнән азат булып Хәбиблек юлына, галимлек юлына сәфәр китте.

Уку залында ул шәп утырды. Урта кул укучы булып гомер буе исемлек ахырында йөрүе өчен дә, Мәтәли оныгы булып йөрүе өчен дә реванш алырга булды ул. Аның өстәлендә тел гыйлеменә караган китаплардан тыш Эйнштейн, Фейербах, Ландау, Монтень, Плутарх, Ибсен әсәрләре, Бетховен, Наполеон, Гарибальди турында монографияләр була иде. Үз темасы артык авыр түгел, эш гөрләп барды. Тик җитәкчесенең генә тормышы кителде; хатыны озак срокка больницага керде. Гомер буе хатын тарафыннан кадердә генә яшәгән галим, бичара, сабый бала хәлендә калды. Үз-үзенә ашарга әзерләү турында уйларга да ярамый иде: остаз дигәнебез газ плитәсен дә кабыза белми, хәтта ваннага су да җибәрә белми икән.

Хатыны больницадан чыкканчы дип, ул аспирантлар яши торган тулай торакка күчте. Анда ашханә, буфет эшли, атна саен урын-җирне алыштыралар, техничкаларга акча түләсәң, киемеңне юып, үтүкләп бирәләр иде.

Ул, дүртенче кеше булып, Хәбибләр бүлмәсенә керде. Бер яктан карaганда Хәбибнең диссертациясе өчен җитәкче белән бергә яшәү файдалы да булып чыкты. Җитәкче сабый баладай бер катлы, ярдәмчел кеше иде. Ул Хәбибнең дөньяга чыгачак мәкаләләрен әзерләште, диссертацияне ашыктырды, куалап торды. Авылдан, буразна арасыннан килгән Хәбиб аның тирәсендә культуралы итеп, милли телдә сөйләшергә тырышты. Матур җөмлә төзеп, вәкарь белән сөйләшергә өйрәнде. Холодильникны суыткыч, пепельницаны көллек, хоккейны кәшәкә уены, клюшканы кәшәкә таягы дип кенә сөйләште. Бераздан телевизорны да кулланмас булды: аның исеме — «еракттан күрсәткеч»кә әйләнде.

Җитәкчесе, дөрес, алай ук сөйләшми иде. Хәер, хоккей, холодильник, телевизорлар белән ул гомумән бу дөньяда алыш-биреш итми иде. Үз фәнен белә, студентлар аны ярата, хатын-кыз артыннан чапмый, имтиханда гадел, үз хатынын чын күңелдән кызгана, кайбер көннәрне күзләре кызарганчы хатынын кызганып елый иде. Тик бер генә йом-

шак ягы бар бичараның: «капкалый». Әнә шул йомшак ягының нәтиҗәсеме, соңгы вакытта галимнең сөйләме дә үзгәрде. Лекцияләрне газап белән, үзен дә, студентны да җәфалап сөйли башлады. Шәп кенә күтәреп җөмлә башлый да ахырын йота. Өр-яңа фикер әйтәме дисәң, аны әйтми калдыра, берөзлексез күзлек алмаштыра. Конспекттан карарга бер күзлек, студентларга карарга — икенчесе.

— Монда без нәрсә күрәбез? Монда без (тавыш күтәрелә) күрәбез (тавыш төшә, сүз йотыла) уыт.... Ни өчен (күтәренке) шулай? Чөнки (төшенке) уы-ыт... Димәк, уы-т... димәк... уы-ыт... димәк...

Доцентның әнә шул йомшак ягы булуга карамастан, эш мәсьәләсендә ул үз намусына бер дә тап төшерми иде. Аның бу «йомшак ягын» файдаланырга теләүчеләр, гадәттә, шактый мәзәк хәлләргә калалар иде.

Бишенче курсның шомарган гына бер егете шулай харап булды. Дүшәмбе көн иртән группалары әлеге доцентка имтихан бирәсе иде, шома егет бу имтиханнан бик курка иде. Шуңа күрә доцент янына ул якшәмбе көн кичке якта бер шешә кыстырып килде. Аспирантлар кайсы ялга, кайсы командировкага китеп барган вакыт иде. Шуңа күрә шома студент белән доцент иркенләп утырдылар. Студент тагын ике мәртәбә кибеткә барып килде, доцент акчасы янына аның стипендиясе дә кушылды.

Дүшәмбе көн иртән доцент кәефсез иде, шулай да билге кую мәсьәләсендә гадел булды. Шома егет тә зачеткасын биреп, әзерләнмичә генә тегене-моны сөйләп, бишле эләктерергә уйлаган иде, барып чыкмады. Доцент аңа салкын кан белән генә «неуд»[1] куйды.

— Ә? — диде шома егет, зачеткасын тотып. — Ә?

— Материалны белмисең, — диде доцент. — Менә шуңа күрә «неуд».

— Ничек инде, ә? Бу ничек алай була? — ди-ди шома егет бөтәрләнде.

— Кем әзер, чыгыгыз җавап бирергә, — диде доцент, чират көтеп утырган студентларга карап.

Шома егет шуннан соң ике тәүлек буе хурланып та, үкенеп тә елап йөргән диделәр.

Доцентның тагын бер гадәте бар иде: аз гына, фәлән тиен генә булса да кеше исәбеннән акча тотылган икән, хезмәт хакы алгач ул шуларны таратып йөри, бирәчәген калдырмый иде.

Хәбибне ул тәмам кеше итте. Хәбиб уңышлы гына диссертация яклады.

Хәбиб зур кеше булды. Күзлек киде, баш түбәсеннән чәче коелды, яхшы мех кырыйлы, плюш түбәле бүрек киеп җибәрде, галимнәрнең шундый бүрек кенә кияргә тиешлеген ул белә иде, асты киңәйгән портфель алды, бу портфельгә бик күп китап-кәгазь, берничә шешә кефир сыя иде. Озак та үтмичә, Хәбибкә яңа йорттан өч бүлмәле квартира да бирделәр, бу вакытта инде ул өйләнгән, бер баласы бар иде. Хәбиб акрынлап авыл белән элемтәне өзде, шәһәрләшә башлады. Дусишләре күбәйде. Дуслары үз коллегалары арасыннан түгел иде, алай модасы юк икәнен ул яхшы белә иде. Дуслар төрле булырга тиеш. Җәмгыять алдында абруй казанасың килсә, дусларың үз профессияңнән бөтенләй ерак кешеләрдән булсын. Хәбибнең дуслары — кайсы юрист, кайсы геолог, кайсы врач. Шәһәр кешесе һәм аның да интеллигенты булу өчен тагынниләр кирәк? Хәбиб боларны яттан белә иде.

---

[1] Неуд — неудовлетворительно (канәгатьләнерлек түгел, ягъни начар).

Беренче шарт. Үзеңнең чыккан җиреңне, авылдан икәнлегеңне онытасы. Мәҗлесләрдә, компанияләрдә моны телгә аласы түгел.

Икенче шарт. Кунак чакырганда дус-иш белән нәсел-нәсәпне аралаштырасы түгел. Нәсел-нәсәпне аерым җыярга, алар белән авылча утырсаң да ярый.

Өченче шарт. Яшь вакыттагы фотоальбомнарны юк итәсе. Килгән кунак альбом-фәлән карый икән, «һи-и, аны актарган кеше дә юк, карточкага төшкән дә юк» дип, ис китмичә генә альбомны бирәсе. Ләкин альбом шәһәр рәсеменнән — хатын белән синең ЗАГСтан чыккач төшкән рәсемеңнән башлансын. Шуңарчыгы авыл рәсемнәрен юк итәсе.

Дүртенче шарт. Шәһәр интеллигенты эчемлек төрләрен бик яхшы белергә тиеш. Авылда, югыйсә, ике генә төрле сүз бар: ак аракы, кызыл аракы. Интеллигент сухое, полусухое, крепленое кебек сүзләрнең мәгънәсен яхшы аңларга тиеш.

Бишенче шарт. Мәҗлестә һәр вакыт бер сюрпризың булырга тиеш. Гадәттә, ул командировкадан алып кайткан, бу шәһәрдә күренми торган бәрәр затлы эчемлек.

Алтынчы шарт. Стенада яки сервант өстендә чит илдә вакытыңда үз кулың белән диңгез төбеннән-фәләннән, базардан алган бәрәр кабырчык яки статуэтка торырга тиеш.

Җиденче шарт. Үз хатының турында «минем хатын» дип мокытланып сөйләшәсе түгел, «фәлән ханым» дип әйтәсе.

Сигезенче шарт. Балаларың чит тел мәктәбендә, рәсем һәм спорт мәктәбендә укысын, моннан тыш музыкальныйга йөрсен.

Тугызынчы шарт. Дача, көймәң, машинага чиратың булсын. Машинаның үзе булу шарт түгел.

Унынчы шарт. Фәлән районда фәлән колхозның председателе синең җан дусың булсын (үз авылыңнан түгел). Ул председатель шәһәргә килгәндә сиңа түшкәсе белән ит, центнеры белән кәбестә, кисмәге белән бал алып килә, ә син шул яхшылыгына җавап итеп җәй көне семьяң белән төялеп аңа кунакка кайтып киләсең һәм кышын бу турыда иптәшләр арасында сөйлисең.

Хәбиб акрынлап әнә шул программаны тормышка ашырырга керешә. Алар квартирасында булган мәҗлесләрдә сүз-әңгәмә менә болайрак бара, ләкин һич тә шуннан да түбән түгел.

— Русановның хатыны француженка була бит. Әйе. Ә үзе гомере буе Яңа җир утравын өйрәнә. Сәяхәттә. Ә тегесе — Джульетта.

— Радж Капурның студиясен нәрсә дип белдегез аны? Аның бит гел мелодрама. Менә соңгы фильмын карагыз әле...

— Фордның төп конторасында, беләсеңме, ничә кеше эшли? Менә мин...

— Юк, минемчә, Григның зениты — «Сольвейг» җыры. Ә бит «Пер Гюнт» әсәре, болай карагаңда..

Дөрес, шундый мәҗлесләрдә бәхәс бик эчкәре кергәч, кайвакытта Хәбибнең гап-гади Хәбибрахман булып үз авылларына кайтасы, әнисе, картайган бабасы белән келәт янында тавык үләне өстендә киндер ашъяулык җәеп катык катып токмачлы аш ашыйсы килә. Ах, утырырга иде, мәсәлән, шулай сөйләшеп:

— Сарыкларны быел мулрак калдырмыйча булмас. Люцерна чапкан өчен процентны да алсак, ул курмыларны кая куеп бетерербез?

— Иртәгә люцернаның эшен бетереп кайтсагыз, мунча ягып чабынырга кирәк булыр, улым. Килен белән мин бүген мунчаны карап куярмын...

Кайвакыт Хәбиб мәҗлестә шулай онытылып китә, аның йөрәге сулыгып-сулыгып ала. Авыр, сагышлы бу дөнья!

Шундый мәҗлесләрнең берсендә кунаклар сигарет кабызып балконга чыктылар. Әңгәмә кызды, япон транзисторларыннан француз артисты Жак Габенның соңгы роленә күчтеләр. Берсе кичә генә Америка күргәзмәсендә булган икән, күргәзмәдәге ЭВМ машинасының режимын сөйли башлады.

Шул вакыт урамда, балконнан аста, әллә ниткән йөрәк өзгеч газиз, җанга якын бер тавыш ишетелде. Баксаң, йортның дворнигы Кәрам (йортта аны Кирилл дип йөртәләр) кунакларын озата икән.

Нейлон күлмәгенең җиңен сызганган, кыска чәчле, юан беләкле тәбәнәк бер кеше урталай өзәрлек итеп тальянын тарта. Аның янында икенчесе — шулай ук таза, чәчен кырдырып алдырган бер йомры кеше җан-фәрманга кычкырып җырлый иде.

Ал да бәйли фаберик,
Гөл дә бәйли фаберик.
Сатып алган кайгым түгел,
Яшь йөрәгем, сабыр ит.

Хәбибнең шул вакытта кычкырып елыйсы, барысын ташлап чыгып йөгерәсе, әлеге йомры башның түгәрәк җилкәсенә кулын куеп кушылып җырлыйсы килде. Ләкин бу уйларыннан аны хатыны бүлдерде.

— Шампанскийларыңның барысы да холодильниктамы? Җылысын китереп хур булмыйк тагын,— диде.

Ә йортның теге башыннан йомрының карлыккан тавышы ишетелә иде:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ибырай.
Ал кулыңа гармуныңны,
Игырай да игырай...

Кайвакытта Хәбибнең әнисе Гафифә җиңги малаена кунакка килә, Хәбиб ул вакытта әнисе малае була да кала. Аны театрга алып бара, хәтта балет күрсәтә. Кайвакытта шулай да була: Хәбибнең төзүчеләр институтын тәмамлаган югары белемле хатыны балет спектакле вакытында йокымсырап китә, ә Гафифә җиңги урынында тынып утыра алмый, берөзлексез катнаша, сораша.

— Карале, Хәбибрахман, теге шөкәтсезнең шушы матур кызда өмете бармыни инде?

— Үл-ләм, бетәм, тегеңә чәнчергә маташа түгелме соң ул, биегән булып?

Өйгә кайткач та чәй янында Гафифә җиңги балет спектакле тәэсиреннән әле чыга алмый.

— Теге кыяфәтсезне әйтәм әле: шаталтрестлыкта йөрде-йөрде дә нинди матур кызны харап итте бит. Ничек җаена китереп биилләр бит ә? Кара, теге кыз үләр алдыннан нишләп беттеләр! Кыҗыкыян-дупыян [1] киләләр бит...

....Гафифә җиңги әнә шулай малайсыз калуына әкренләп күнде. Баштарак ул гел малаем кайтыр, шушы нигездә тормыш корыр дип өмет иткән иде. Ләкин малай өч бүлмәле квартира алгач, бу өмете киселде. Ана бит: өй туена бер бөтен каклаган каз алып килде дә чын күңелдән улына изге теләк теләде.

— Яңа өегез к о р т л ы булсын, ш а р т л ы к л а р [2] белән гомер кичерергә насыйп булсын,— диде.

[1] Казан арты сөйләше. Кайнашу, исерекләр кебек (допьяна) ыгы-зыгы килү.
[2] Казан арты диалекты.

Дога укый белми иде, бит сыпырган булды да эчтән изге теләк теләде. Бергә төп нигездә — авылда яшисе килгән иде, югыйсә.

Бик, бик авыр көннәр кичергән иде ул кечкенә Хәбибрахман белән бергәләп... Хәбибрахманны ул аңлый алмады: ничек итеп үз теләгең белән үз нигезеңне ташлап китәргә кирәк? Менә, мәсәлән, Гафифә җиңгидән ул хәл булмый. Ул — егерме дүрт көнлек санаторийны ташлап кайткан кеше.

Ә Хәбибрахман үз теләге белән — егерме дүрт көнгә түгел, мәңгегә — шәһәрдә калды. Моны аңларга Гафифә җиңгинең белем дә, грамыт та җитми иде...

## Тик бер генә коймак...

Хәбиб байтак үзгәрде хәзер.

Баштарак аңа кыен иде: шәһәрчә булам дип, авылга кайткач, ял күрми иде. Элек ипигә май ягып, гади итеп кенә ашыйлар иде, май яккан ипи кинәт кенә бутербродка әйләнгән. Гафифә җиңги моны бутап әллә нинди сүз әйтеп ташлады бервакыт. Элек утырып аш ашыйлар иде дә, чәй эчкәч торып китеп баралар иде. Хәзер әллә каян «второй» дигән сүз чыккан. Гафифә җиңги монысына да күнмәде.

— Әйдә, үзебезчә генә яшәгез, бизли-бизли[1] шәһәрчә ашап булмый авылда,— дип, ул яңа системаны кабул итмәде.

Бу — элегрәк шулай иде. Хәзер Хәбиб ялга ел саен кайта, ел саен җәй уртасында я семья белән, я улы белән кайта. Соңгы бер-ике елда, мәсәлән, гел улы белән кайта. Ул авылны сагына. Авылга кайткач, үзе яшүсмер чакта ат җигеп көлтә керткән юлларга улын алып чыга, фермаларны, ат абзарларын күрсәтеп йөри. Кесәләренә ипи кисәкләре тутырып чыгалар да, утардагы кырыкмыш тайларны Хәбибнең улы шул ипи кисәкләре белән сыйлый. Тайның кара төкле иреннәре аның кечкенә учларын кытыклый. Аннары алар, колхозның элеккерәк елларда бөтен эшче көчләре җыелып кырга таралыр алдыннан сбруй ала, арба майлый торган лапасларында йөриләр. Ул лапаслар инде хәрабә хәленә килгән, алар янында кирпечтән салып шифер белән капланган зурзур гаражлар.

Июльнең соңгы көннәре рәхәт тә, монсу да була. Бакчаларда бәрәңге ап-ак чәчәктә, шомыртлар каралган, кура җиләкләре чук-чук булып утырган чак ул. Кичләрен куе булып чык төшә, кичке һава печән исе белән тула, абзар кырыйларында «пош-пош» килеп сыер ял итә, беренче әтәчләргә кадәр чикерткәләр чырылдый...

Беркөнне ат абзарларын карап кайтышлый аның улы урамда уйнап калды. Шәһәрдән кайткан кунак бала авылда кадерле була. Кайсы өйгә керсә дә, аңа якты чырай бирәләр, пешкән йомырка, җиләк белән кунак итәләр. Уйнап йөри торгач, малай ачык капкадан күрше Фәхрислам агайларга кереп киткән. Моны Хәбибкә малаен җитәкләп керткәч, Сабира җиңги үзе сөйләде. Ул коймак пешергән дә, картын чәй эчереп утыра икән. Малай тубын күтәреп аларга килеп кергән, тәрәзә төпләрендәге гөлләрне, гөл төбендәге күгәрчен йомыркаларының буш кабыкларын карап йөргән. Өйгә таралган коймак исе, ахрысы, аның борынын кытыклагандыр, бераздан ул өстәл тирәсендә әйләнгәләп йөри башлаган. Ләкин... сабыйның коймак ашыйсы килү мөмкинлеген Сабира җиңги исенә алмаган. Малай (шәһәр баласы кыюрак була бит) тубын кочаклап өстәл астына кереп качкан. Аның юкка чык-

[1] «Везде» сүзеннән кергән булса кирәк.

канын да сизмәгәннәр. Тик Сабира җиңги мич алдыннан чыжылдатып тәлинкә белән коймак алып килгәндә малай өстәлгә җәйгән ашъяулык астыннан үрелеп аның аягыннан чеметкән. Сабира җиңги сискәнеп киткән һәм, өстәл астында күзен елтыратып утырган сабыйны күреп, хәйран калган. Аннары аңа бер коймак биргән. Малайны җитәкләп кергән Сабира җиңги, баскыч төбендә кет-кет көлеп, Хәбибкә шуны сөйләде. Хәбиб исә аны ныклап тыңлый алмады. Бу вакытта дәһшәтле сугыш елларының бер иртәсе аның күз алдына килеп басты.

...Әнисе аны көн саен караңгыда уята иде. Тәрәзә пыялалары ватык, алар урынына карындык ямау куелган. Тәрәзә астыннан су китеп утыра, рамга сыланган кәгазь купкан, тыштагы буранга зыңгылдап, өйгә суык кертә. Бөгәрләнеп ятудан аның тезләре сызлый, шулай да бер дә торасы килми.

— Улым, улым, тор, тор, ут кына алдырып бир,— ди әнисе.

Бу — һәр көнне шулай. Малай торып утыра, йокы аралаш күзләрен уа. Әнисе аның кулына ут чыгара торган чакматашны тоттыра. Малай караңгыда чакматаш өстенә яндырылган кара мамык куя. Үң кулына авыр игәү сыныгы ала. Чак-чок... Сәкегә очкыннар оча. Мамык кабынмый. Тагын чак-чок. Кулыннан ычкынып киткән игәү кисәге караңгы өйдә каядыр шалтырап барып төшә. Әнисе аны үрмәләп эзләп таба. Яңадан шул ук очкыннар. Мамыкка шул очкыннарның берсе эләксә, әнисе дә, малай да аңа шатланып өрәләр. Борынга әче мамык төтене керә, алар өрәләр дә өрәләр. Аннары әнисе учак алдына кичтән җыеп куйган йомшак юкә күмерен алып килә, утны шуңа үрләтә. Әнисе хәзер салкын идәнне шыгырдатып ачып, өй астыннан орлыкка дип калдырган бәрәңгене санап алыр. Алар салкыннан йолдызланып яталар, кырыйдагылары инде өши дә башлаган... Әнисе ул бәрәңгедән шулпа пешерер, ә шуңа кадәр малай әле бераз йоклап алыр... Ләкин чакматаш һәр вакытта да алай кабынмый. Күп вакыт игәү белән бәрәбәрә караңгыда мамыкның көеге коела һәм ул чакта инде ут алындыру турында уйларга да ярамый. Андый көнне әнисе морҗа буеннан кружка кадәр генә саплы чүлмәкне ала да:

— Бар, улым, берәрсеннән утлы күмер алып чык,— ди.

Малай, киенеп, өй кыегыннан тигезләп өйгән кар дәрьясына чыгып баса. Салкын. Йолдызлар үзара сөйләшкәндәй җемелдиләр. Кемнең тәрәзәсендә ут бар? Кемнең морҗасыннан төтен чыга? Шуны карыйсың да чүлмәгеңне тотып китәсең. Ишектән керәсең, дәшмичә генә чүлмәгеңне сузасың. Хуҗа хатын синең чүлмәгеңә бер-ике күмер сала, дәшмичә генә чыгып китәсең. Ахрысы, моның өчен рәхмәт тә әйтелми иде. Хәтердә шулай калган. Сугыш елларында, кышкы караңгы салкын иртәләрдә, Хәбибрахман күршеләрдән шактый күмер ташыды. Рәхмәт төшсен аларга, шул вакытта күмер генә түгел, үзләренең йөрәк җылыларын да биргәннәр икән. Кайвакыт чүлмәк, тимер кружка белән аларга да керәләр иде. Ләкин учакта ут булган иртәләрдә Хәбибрахман әле йоклый иде, һәм моны ул бары тик әнисе сөйләгән буенча гына белә.

Әнә шул йөзләгән иртәләрнең берсе Хәбибнең хәтерендә аеруча нык сакланган. Ул көнне игәү кисәге белән ялгыш бармагына китереп бәргән иде. Мамыкның көеге коелды да, ул чүлмәкне тотып кар тавы өстенә чыгып басты. Бары тик Сабира җиңгиләрнең генә уты бар һәм чалт аяз иртәнге һавада аларның морҗасыннан куе төтен күккә аша иде. Малай каты карны шыгырдатып шунда таба атлады. Үзәккә үтәрлек суык. Тамак ач. Җитмәсә, төне буе төшендә катык белән кәрәз кебек ипи ашады. Шуңа күрәдерме, хәзер өзелеп-өзелеп ашыйсы килә. Сабира җиңгиләрнең өенә якынлашканда морҗадан чыккан төтен белән аның борынына гаҗәп хикмәтле ис бәрелде. Бу исне аның сугыш

башланганнан бирле сизгәне юк иде. Малай адымнарын ешайтты. Сабира жиңги һәр вакыт шулай иртүк миченә яга.

Ишекне ачып килеп керүгә, теге ис Хәбибрахманның борынына гына түгел, күзләренә дә бәрелде. Җылы, чиста өй. Матчага унлы лампа эленгән, өй эче балкып тора. Сабира жиңги мич каршында коймак пешерә икән. Ленар да урыныннан торган, мичтән төшкән кызу каршында ап-ак оекбашлар өстеннән таза, озын куныччлы киез итекләр киеп маташа. Майда пешкән коймак исе Хәбибрахманның тынын буды. Чүлмәкне сузганда ул Сабира жиңгинең мич алдындагы эсселектән кызарган йөзен күрде, аның үзеннән дә майлы коймакның хуш исе аңкып тора иде. Шуннан ары малай берни дә сизмәде дә, күрмәде дә. Аның күзен куе яшь басты — бу елау яше түгел, бик нык ашыйсы килгәндә шулай күз яшьләнә. Малайда ут кайгысы калмады. Ул күзләрен йомды һәм ишек янында катып калды. Бу вакытта малай бер генә нәрсә турында уйлый алды: шулай да нинди бәхетле ул! Әгәр игәвен бармагына бәрмәгән булса, бу көнне күрер идемени? Бәхет дигәнең бер ачылса хикмәт бит ул. Менә һич тә уйламаганда хәзер аның авызына бер коймак килеп керәчәк. Ул авызга керер, Хәбибрахман аны чәйнәп тормас. Ул анда эреп китәргә тиеш. Хәзер аңа бик рәхәт булачак. Әйбер пешергәндә балаларга авыз иттерү авыл хатыннарының бик әйбәт бер гадәте инде ул. Тукта, болай эшләргә кирәк: бер коймак бирсә — яртысын әнисенә алып чыгарга. Ул берни белми ут көтеп утыра, ә син аның кулына майлы коймак кисәге тоттырасың. Бәлки икене үк бирер?

«Мә, энем, утырып аша»,— дип, икене бирсә, берсен кабып йотасың да икенчесен өйгә алып йөгерәсең.

...Кулына җылы чүлмәк сабы килеп кергәч кенә малай күзләрен ачты. Өстәл өстендә тәлинкә белән майлы коймак утыра. Сабира жиңги авыр ишеген «дык» итеп ачып аны озатып калды. Малай кар тавына чыгып басты. Әлеге татлы хыяллары салкын йолдызларга таба менеп киткәндәй күккә очтылар.

Хәбибрахманга тик бер генә, бер генә коймак кирәк иде шул чакта...

...Эдикны җитәкләп кергән Сабира жиңгигә Хәбиб шәһәр күчтәнәче итеп лимоннар, кыйммәтле конфетлар, йомшак батоннар биреп чыгарды.

## Алда — иркен кырлар...

Диссертация яклау процессында профессор Хәсбиевнең болгатып йөргәнен белгәч, Маратның үз эшеннән кинәт кенә күңеле кайтты. Шәһәргә моның өчен килмәгән иде ул: моны дусларына да әйтте. Ләкин дуслары, моннан берничә ел элек яклау процессын узган галимнәр, аны тынычландырдылар:

— Яклаудан соң була торган хәл, гадәттәге депрессия,— диделәр.

Инде кандидатлык дипломы да килде, ләкин депрессия узмады. Бераздан ул үзенең перспектив планы буенча яңа тема раслатты һәм шуның буенча эш башлады. Теманы эшләү өчен база итеп үз районын алды, район оешмаларында, Авыл хуҗалыгы министрлыгында боларын да рәсми рәвештә хәл итте. Бер группа галимнәр, инженерлар белән алар яңа типтагы кош фабрикасы салырга планлаштырганнар иде. Проект яхшы дип табылды, аны гамәлгә ашырасы гына калды. Проект раслануга ул бер аспирант белән районга китү ягын карады. Профессор Хәсбиев тә моңа риза булды: соңгы вакытта җыелыш саен ул:

«Бездә кадрлар җитештерелмәгән, без — картларга алмаш юк»,— дип речь сөйли башлаган иде. Берәүләр, беркатлылар, профессорның бу реченнән соң, гадәттә, андагы үз-үзен тәнкыйть итү сәләтенә, принципиальлеккә сокланалар иде. Тик Марат һәм аның дусларыннан булган ике-өч галим генә моның төбен аңлыйлар иде: кадрлар җитешмәгән, димәк, профессорга алмаш юк. Алмаш юк, димәк, әле син үз урыныңда утыра бирәсең. Моны аңлаган галимнәр дә шактый кыен хәлдә иде. Дәшмәсәң — эшкә зыян килә, дәшсәң —«минем урынга кызыга» дип, Хәсбиевнең хәбәр таратачагы көн кебек ачык иде. Шуңа күрә һәр намуслы галим үз темасына чумды...

Профессор исә үзенең утыз ел буе эшләгән күпьеллык үләннәр темасы буенча монография чыгарып ята иде.

Марат барысын да калдырып районга китте. Берничә көн буе авыл хуҗалыгы идарәсендә, партия райкомында очрашып сөйләшүләрдән, киңәшүләрдән соң ул үз авылына кайтырга чыкты. Бер ай чамасы вакыт авылда яшәргә, авыл һавасы суларга мөмкин булачак иде.

Хәзер шәһәр белән аны Тамара гына бәйләп тора иде. Тамара авыр аерылышты: хәсрәтле күзләре белән аңа тутырып карады да кайнар учларына Маратның бирчәйгән калын кулларын алды. Аннан, як-ягына каранып, кулларын кесәсенә тыкты.

— Дөньяда синең булганың, яшәгәнең өчен рәхмәт!— дип пышылдады ул.— Әниләремнең үзем белән бергә укыган трест начальнигына бирәселәре килә. Ул егет безгә килеп йөри. Беренче хатынын аерган. Кичә егерме дүрт сумлык коньяк алып килгән. Эчертмәкче булды. Ә мин төне буе йоклый алмадым. Беләсеңме, нинди төш күрдем? Кухняда икәнмен, дим. Озак итеп кояш батканын карап тордым. Бөтен дөнья кып-кызыл иде. Кинәт шунда кояш убылып горизонт артына төшеп китте. Бөтен дөньяны караңгылык басты. Ходаем, куркып уянуымны күрсәң...

Вокзал янында сүзсез генә, күз карашы белән генә аерылыштылар.

...Районнан китешли станция буфетында поезд көтеп Марат озак утырды. Бүген колхозга кайтып җителсә, бәлки Тамара да онытылыр иде. Бигрәк интеллигент, бигрәк яклаучысыз күренә инде бу. Марат кебек практик булмаган егет белән ничек яшәр ул?

Поезд китәргә ярты сәгать вакыт бар әле — Марат вакыт уздыру өчен парикмахерскийга керде. Аның шәһәр кешесе икәнен сизеп, мастер хатын тиз генә идәндәге чәчләрне себереп алды, бер уңайдан үзенең дә прическасын төзәтте һәм Маратка урын тәкъдим итте.

— Поезд көтәсе булмаса, шәһәр кешесе безгә керми инде,— дип, Маратның тезләре арасына килеп керде дә, ак простынялар белән бутады. Ләкин береэдан, Маратның одеколон сиптертмәячәген белгәч, аны бөтенләй онытты, маникен белән эш иткәндәй, сүзсез генә кырды, промкомбинат шоферы белән генә ара-тирә уен-көлке сөйләшкәләп алды.

...Марат Вәлиевич — бөтен институтка мәшһүр буйдак егет. Буйдак дигәнне шәһәр кызлары аңлап та бетермиләр хәзер. Холостяк — вәссәлам. Бу инде сугыш елларындагы ипи карточкасы кебек. Фәннәр кандидаты бул да, шуның өстенә өйләнмәгән бул. Табигать биргән тазалыгың, буең-сының да булсын. Ул бик үзенчәлекле киенә: галстук такмый, һәр вакыт муены иркендә йөри. Соры костюм аның киң, калын арка-җилкәләренә килешә. Кыска гына чәч йөртә. Сәгать, йөзек такмый. Таза, ышанычлы кыяфәт. Эшче кеше тышкы кыяфәтеннән моның интеллигент икәнен белә, ә интеллигент — моның буразнадан чыккан табигать баласы икәнлеген тоя, хулиган — бу егеткә сүз катмаска кирәклеген сизә.

Кыяфәт — визит карточкасы. Бу дөньяда кыяфәт я бар, я юк. Аны костюм гына бирми. Марат бик сирәк кенә, кунакта гына эчә, әмма аның исергәнен күргән кеше юк әле. Ник өйләнми ул? Әллә берәр авыруы бармы? Институт кызлары баш ваталар. Тик бер Тамара гына баш ватмый: Марат — сау-сәламәт егет. Ләкин өйләнү мәсьәләсендә ашыкмый. Тәвәккәллегә җитми. Тамара анысын да белә. Һәм киләчәктә инициативаны үз кулына алмакчы була. Хәзерге заманда гаеп ителми ул... Дөрес, Маратның бер кыз белән романы булып алды. Ләкин моның уңышсыз очланасын Тамара алдан ук белде. Кайбер хатын-кызларга табигать йөз иргә җитәрлек алдан күрү сыйфатын биргән. Әйе, Марат ул кызны яратты, йөрәк серләрен бары тик шуңа гына ачты. Армиядә вакытта өч ел буе хат алыштылар, күпмедер вәгъдәләр бирештеләр. Шул кыз аны, тартып дигәндәй, институтка китерде. Югыйсә, Марат авыл хуҗалыгы техникумы җиткән дип исәпли иде. Шул кыз аны аспирантурага калырга димләде, мәсьәләне тизләтеште. Марат тәмамлаганда, ул институтта гыйльми секретарь булып эшли иде. Ләкин беркемгә дә аңлашылмаган сәбәп буенча, бу кызый көннәрдән бер көнне өч көнгә ял алды. Өч көн ял... Моның нигә икәнен дөньяда кем белми? Өч көнлек ял бервакытта да гадәти хәл өчен алынмый. Кызый кияүгә чыккан һәм бик шәп чыккан иде. Кияү — Мараттан күп чибәр, дулкынланып торган кара чәчле, һәр вакыт көләч йөзле, каратут битле, киң җилкәле егет,— яңа гына докторлык диссертациясен яклаган кафедра мөдире иде. Марат бу вакытта инде аспирантурада иде, секретарь белән бер ел буе сөйләшмәделәр. Бервакыт Марат аларны парлап театрда күрде. «Букет», чыннан да, шәп иде. Елмайганда кияүнең алгы рәттәге бер алтын теше елтырап китеп аңа көләчлек өсти, шуның өстенә кияү компаниядә үзен бик итәгатьле, культуралы тота. Рольләрен уйнап бетереп, беренче антрактта ук буфетка лимонад эчәргә кергән, әле быел гына сәхнәгә менгән ике артистны чиратларыннан чыгарып, үз өстәленә китереп утыртты да «ә» дигәнче ике шешә әрмән коньягы, шоколад-фәлән, минераль сулар күтәреп килде. Теге артистлар да таушалган берлекләрен кире кесәләренә тыктылар. Марат күрше өстәлдә «Рислинг» эчеп утырды, кәләш исә аңа бер тапкыр да күтәрелеп карамады. Әйтерсең ул аны үз гомерендә бер тапкыр да күрмәгән...

Аннан соң Марат күпне күрде, күп семьялар белән аралашты. Әйбәт семья — Ибраһимов семьясы бар иде, ул семья да кителде, Ибраһимов хәзер ялгыз. Фәннән бушаган вакытларында хатыны кабере янына бара, Златоустка мрамор ташына заказ бирде, шуны китертеп, шуңа язулар яздыртып йөри. Үзенең тормышындагы төп максатына — докторлык диссертациясе яклау моментына җиткәндә генә сөйгән хатынының үлем түшәгенә егылуын һәм шул көнне үлүен ул әле дә булса аңлап бетерми, диалектикадагы бөтен очраклылыклар турында уйланып баш вата.

Ә яшьрәкләр арасында төрлесе бар иде. Марат күп йөрде, күп аралашты. Баштарак кызык иде. Һәр шимбә, якшәмбе — кем дә булса кунак җыя. Төрлесен күрде. Өйләнгән иптәшләреннән барысының да өендә булды, барысы да аны якын иттеләр. Гыйбрәт тә байтак булды. Бер танышы бар, мәсәлән, Марат аларда өч-дүрт тапкыр кунакта булды. Ире дә, хатыны да ашыга-ашыга диссертация язалар. Ире кукуруза, хатыны тарих буенча. Ләкин сөйләшеп утыргалый торгач бер нәрсә аңлашылды: болар һич тә ире кукурузга, хатыны җәмгыятьнең көзгесе булган изге фән — тарихка гашыйк булудан гыйлем нигезенең ташларын кимерергә тотынмаганнар икән. Баксаң — хатынының курсташы кетмәгәндә университетка аспирантурага килеп кергән икән. Шуннан әлеге хатынның төп йокысы качкан: ничек инде, бергә биш ел укыган курсташ кызы галим була да, бу — гади бер музей хез-

мәткәре булып кала! Болай булмас, болай ярамас! Һәм теләгенә ирешә. Һәм бары тик шул теләгенә ирешкәннән соң гына ире белән халык алдына чыга — театрга, спорт сараена йөри башлый. Ләкин тынычлык озакка бармый: үзәк урамнарның берсендә очрашып, теге курсташы белән тигезгә-тигез килеп сөйләшеп торганда, курсташ кызый моны үтерерлек хәбәр әйтә: тегенең ире дә аспирант икән һәм бик һәйбәт җитәкчедән бик һәйбәт тема алып, шундый хикмәтле диссертация яза икән...

Фән дөньясында көнләшү — коточкыч афәт. Көнләшү фән-гыйлем дөньясына талантсызлар, җаһилләр, талымсызлар, әрсезләрне җибәреп тора. Ә алар исә фән-гыйлем дөньясында фаворитлар тудыралар. Корт анасы ясаган кебек, җаһилләр үзләренә курчак патша ясыйлар. Халыкка, ватанга хезмәт итүне онытып, гыйлем дөньясындагы әнә шул курчак патшага табына башлыйлар. Үзләре дә шундый курчак булу турында хыялланалар. «Мин фәлән иптәш янында булдым, ул миңа фәлән дип әйтте»,— дип сөйләнәләр, йомыш тапкан булып, дәрәҗәле ишекләр тирәсен таптыйлар. «Әле менә фәлән иптәшкә кабул ителдем, ул чакырткан...» Алар базар күгәрчене кебек әрсез булалар, китапханәдә утырасы урынга, дәрәҗәле кешеләр белән танышу юлларын эзлиләр...

Ибраһимов гыйльми советта чыгыш ясаганда бервакыт андыйлар адресына болай дип әйтте:

— Галимнәрнең яхшысы — җитәкчеләрне борчымас, җитәкчеләрнең юньлесе — галимнәргә комачау итмәс...

Ибраһимов җае чыкканда Маратка да әйтә килде.

— Намус турында фәлсәфә сату аны саклауга караганда шактый җиңел,— дип сөйләде ул.— Менә син авыр юл үткән кеше: техникум, солдат хезмәте, колхозда эш, институтта аспирантура. Сиңа авыр булачак: фән дөньясына ел саен күпмедер күләмдә тәти егетләр, тәти кызлар кереп тора. Алар талымсыз, аларга тема гына бир, аларга кандидатлык дипломы гына булсын. Намуслы галим ул турыда уйларга тиеш түгел. Әгәр син халык хуҗалыгы өчен файдалы тикшеренү алып барасың икән — синең намусың шул. Галим кем ул? Галим — әнә Воробьевлар, Миропольскийлар. Киң күңеллелеккә шулардан үрнәк аласы бар. Хезмәт сөючәнлектән, намустан тыш, беләсеңме, тагын кешене нәрсә галим итә? Безнең җәмгыятьтәме? Белмисеңме? Галимнең — мин рус галимнәрен истә тотам — башка, азчылык милләт халыкларына, шуларның культурасына, тарихына, гореф-гадәтләренә мөнәсәбәте. Әгәр галим казакъны, татарны, латышны яратмый икән, әгәр мари, чуваш, мордвага ихтирам белән карамый икән, лабораториясендә ник шунда яңа планеталар ачмый — аның бәясе юк. Галим кем ул? Галим — әнә аталы-уллы Арбузовлар, Камайлар. Үз эшләренең фанатиклары...

Кафедрада бер ассистент бар. Яшь, сәләтле егет. Кулында ут уйный. Хатыны артистка, Янавыл ягыннан. Квартиралары әйбәт, ашауэчү якларын көздән хәл итеп куялар. Балконында ящик белән ит, кипкән балык, подвалларында бәрәңге, кисмәк белән тозлы кәбестә, кыяр, помидор. Болар башкалар кебек базарда вакыт уздырмыйлар. Ләкин егет кәефсез йөри. Ябык, борчулы. Алдан сөйләшү буенча, Марат эш белән бер көн аларның өенә барды. Кич иде, артистканың ял көне икән, халаттан гына йөри — чибәр! Күзләре ялт та йолт килә, ул көлеп җибәрсә — көмеш, мәрҗән коелгандай була. Ире кителмәгән мәшәкать белән чыгып киткән икән, авылдан бер туганы килгән булган да, вокзалда шуны озатып йөри. Соң гына кайтты, Марат аны көтеп артистка белән кофе эчеп утырды. Озатып куйганда ассистент кызыксынды: син ничәдә килгән идең? Син килгәндә хатын нишли иде? Өйдә башка кеше юк идеме? Син барында ишеккә берәр кеше килмәдеме?

Телефоннан да шалтыратмадылармы? Синең белән нинди темага сөйләште?

Ахырдан зарланып алды: «Ике ел инде я командировкага чыга алмыйм, я әти-әни янына кайта алмыйм»,— диде. Чишелеп китеп әйтә куйды:

— И-и, слушай, ничекләр итеп анын бер үзен ышанып калдырып китәсең, үзең уйлап кара,— диде.

Әйе, уйлап карарлык иде хәлләр, чыннан да. Менә шуларны күрә торып, Марат ничек үзе теләп өйләнсен соң инде?

Шәһәр семьялары арасында төрле кызык хәлләр була. Болары да Маратның күзенә ташланмый калмады. Бер дусы, мәсәлән, интеллигент семьясында шулай булырга тиеш дип, гел хатын-кыз эшен эшли. Өенә кайтуга кухняга уза да, алъяпкыч ябып, и тотына пешерергә, и тотына. Үзе гел бабайларны сүгә.

— Безнең бабайларны татарлык изгән, татарлык харап иткән. Алар кыргый халык булганнар. Алар хатын-кызга кол итеп караганнар,— ди. Үзе бу коллыктан хатынын коткарыр өчен бөтен чараларны күргән. Хатыны чалбар, платформа киеп кенә киногa йөри — иренә карата ул шул кадәр гадел, караган фильмның эчтәлеген беткәнче сөйләп бара. Институтта бергә укыган курсташлары белән кафега китә, анда булган хәлләрне дә сөйли. Язга чыккач, теге хатын үз коллективы белән палаткалар алып Аккош күленә, мари урманына походка китә, куныплар кайта. Ә ире шат, бәхетле.

— Безнең бабайларны татарлык изгән, татарлык харап иткән,— ди. — Алар кыргый халык булганнар. Алар хатын-кызга кол итеп караганнар.

Марат өйләнү турында күп уйланды. Кирәк иде, өйләнеп, нигез корып, бала үстерергә, табигать законын үтәргә — җирдә нәсел дә калдырырга кирәк иде. Һәрбер буйдакка хас булганча, ул күп уйланды. Аспирантлар, буйдак укытучылар, өлкән курс студентлары белән бер бинада яшиләр иде. Марат өлкән курс кызларын яхшы белә: алар җитди, эшлекле булалар. Авыл кызлары, биш ел буе шәһәрдә яшәүләренә карамастан, һаман крестьянча була беләләр. Аларның форточкадан кышкы җилгә чыгарып элгән итләре, караватт астында бәрәңгеләре, тәрәзә арасында каймаклары була. Болар кафега аена бер мәртәбә генә баралар: стипендия алган көнне генә. Әмма авылдан чыкканнарының да төрлесе бар — киләләр кунак булып институтның тулай торагына. Инде! Бер семестр эчендә киемне, кашны-керфекне үзгәртеп бетерү дисеңме, яңа гадәтләр дисеңме! Авылдан килгән кыз элеккеге авыл елларын кайтарып ала, куып җитә һәм узып китә! Шәһәр урамында, кино-театрда гадәттән тыш киенгән берәр кызый күрсәгез, моны туптуры авыл кызы дип белегез. Үзенең бизәнүе, кием-салымы белән ул шәһәр кызларына чакыру ташлый: менә, ди, күрегез мине, мин авылныкы гына булсам да, сезне узып киттем, минем бер дә сездән ким җирем юк, әле артыграк та...

Болары да ярый, әмма бер төрлесе бар — әдәбият дөньясында кайнашалар — шигырь язалар. Бер шигыре басылып чыктымы — ул кыз бала бетте инде. Егет кеше түзә. Бер түгел, ике-өч шигыре чыккач та түзә, тик уйчанланып кына китә. Әмма авылдан килгән кыз баланың газета-журналда бер шигыре басылса... Марат шундый кызлар компаниясендә утырган иде бер вакыт. Шигыре басылган студентка инде лекциянең теләгәненә генә йөри. Инде кафедра укытучылары белән исәнләшми, деканны мыскыл итеп сөйләп йөри. Инде ул чалбардан башка нәрсә кими, сигарет тарта. Инде ул иптәш кызлары китапханәдә семинарга әзерләнеп утырганда, өлкәнрәк бер шагыйрь белән кафеда фужер тотып утыру ягын чамалый. Тәҗрибәле шагыйрь аңа «ун

да тугыз, җиде дә сигез» дигән булып шигырь ритмикасын сөйли, бу кыз белән шушыннан да аулаграк урында утыру мөмкинлеге булмаганга эчтән сызлана, ә кызый фужер эчендәге һава куыкларының берәмберәм сүнгәнен карап дәшмичә утыра... Күңелдә исә шигырь туа, образлар туа: тәүге мәхәббәт («беренче» дисәң шагыйрьләрчә булмый), тәүге ашкыну...

Юк, Маратлар институтында кызлар эшчәнрәк, житдирәк. Алар хуҗа булырга — эшнең, җирнең хуҗасы булырга укыйлар. Хәтта авылча итеп яши дә беләләр. Аспирантлар, буйдак укытучылар яшәгән тулай торакка, гадәттә, соңгы курс кызларын урнаштыралар. Тәртипле, эшчән кызлар. Аспирантлар, төнгә ач калсалар, шулар янына кереп ашыйлар. Боларда запас һәр вакыт була. Марат та алар бүлмәсендә сөтле чәй эчкәли иде.

Буйдаклар бүлмәсендә китап күп була. Төннәрен китап исенә борын кибә. Һава җитми. Ә китаплар сулый. Моны бары тик диссертация язган кешеләр генә белә. Әйе, китапларга да кислород кирәк. Буйдакларның шифоньерында юасы кием-салым күп була. Мунча мунчаласы, сабын, вакса, кипкән күмәч, алма, сосиски исе була. Шуңа күрә буйдаклар бүлмәсенең тәрәзәсе бер дә ябылмый. Марат бу бүлмәгә ныклап ияләнә алмады. Камыл басуларын, урман полосаларын, авылның көзге яңгырда үтә алмаслык колеяләр белән изелгән урамнарын сагынды.

Лекцияләр, практик дәресләрне яратса да, Марат имтихан алырга яратмый иде. Имтихан алу — студентның гына түгел, укытучының да сыналуы. Монда зачеткасын тотып синең каршыңа керүче студентлар шактый төрле була. Имтиханда гадел билге кую өчен башта алдында утырган кешенең эчке дөньясын чамаларга кирәк. Менә бер егет кереп утырды. Тыныч, ышаныч белән сөйли. Төп материалны бу егет яхшы белә. Дөрес, ул фәлән-фәлән академикларның фәлән-фәлән монографияләрен бутый әле. Әмма көлсу туфраклы зоналарда кыска саламлы бодай үстерүнең агротехникасын сытып сөйләп бирә бу, схемалар төзеп, формулалар белән исбатлап сөйли. Моннан менә дигән экономист, агроном, председатель чыгар. Бу — җир кешесе, институтны ул дөрес сайлаган. Менә икенче берсе. Кыз бала. Билетын тоткан да каушыйкаушый сөйли. Битенә чыккан кызылы — уч төбе кадәр — күчеп йөри. Билетның беренче соравына җавап биргәндә ул кызыл тап ияк тирәсендә иде, икенчесенә күчкәндә ак кофта уентыгына кадәр төште дә кереп югалды. Бу кыз җир фәненнән көчле түгел. Әмма намуслы. Ныклап хәзерләнгән, материалны яхшы белә. Бу да, һичшиксез, әйбәт кадр булыр, бу — таланттан бигрәк, хезмәтчәнлек белән алдырыр. Каушама, сеңел, зинһар каушама, Марат Вәлиевич сиңа күңелдән бишле куйды инде. Әйбәт җавап биргән студентка бишле куйганда шатлыгыннан укытучы үзе дә каушый. Бәхетле минут бу. Әмма шунысы авыр, синең алда кеше газаплана. Ник алай? Чыга өченчесе — ну! Бармагында кыйммәтле таш куелган йөзек, керфекләр, күз кабаклары зәңгәргә буялган, кызыл иреннәре чатнап беткән (димәк, узган төнне имтиханга әзерләнеп әрәм итмәгән бу), материалны белми, әмма артык кайгырмый да. Марат Вәлиевич белеп тора: институтка яратып килмәгән бу. Бу башта геолог, юрист, химик булырга хыялланган, әмма аларына керерлек хәзерлеге булмаган. Ә бу факультетта ул елны «недобор» булган иде, менә бит нинди кыз килеп эләккән. Бармый бу авылга, булмый бу агроном, яратмый бу җирне. Иң күбе — бишенче курска җиткәндә бер аспирантка кияүгә чыга да шәһәрдә кала бу. Иң хәтәре — бер карт буйдак профессорның өенә йөреп диплом эше яза да ахырдан аспирантурага керә бу. Бу — шундый студент, андыйларга «неуд» куеп булмый. Чөнки ул нәрсәдер белә. Өчле куярга да кул бармый, чөнки ул бик күп нәрсәне белми. Менә шулай Марат Вәлиевич

газапланып аны тыңлый. Тагы да хәтәре була: имтиханга юри иң соңгы булып керә. Белеп тора — укытучы белән ялгызга-ялгыз калып утырырга туры киләчәк. Ә инде Марат Вәлиевичны алай гына сынап караучылар булды. Бер гүзәл кызый шулай имтиханга иң соңгы булып керде. Җәйге кич иде, шомырт шау чәчәктә вакыт, гүзәл кыздан да шомыртмы, канәферме чәчәге исе бәрелеп тора иде. Керде, билет алганда ук буяулы керфекләрен наз белән сирпеп Маратка карады. Юбка дигәне — ташка үлчим — юк дәрәҗәсендә иде, матур аякларын янга чыгарып өстәл кырыена утырды. Үтә күренмәле зәңгәрсу кофтасы астында пөхтә, затлы тасмалар, эләктергеч-каптыргычлар сизелеп, күренеп үк тора иде. Кофтасының иң өске сәдәбе дә бик түбән тагылган икән. Кич иде, Марат арыган иде, шушы кыз исән-сау җавап биреп котылса, ведомостьны деканатка кертеп кайтып китәргә иде. Әмма, юк, җавап бирә алмый. Моның башында һич тә культуралы көтүлекләр мәсьәләсе түгел, билләһи, ул түгел! Әнә ул авыр зәңгәр керфекләрен сирпеп-сирпеп ала — Марат та адәм баласы бит! Ә үзе сөйләми, белми.

— Сезнең бер дә язганыгыз юкмыни, шуннан карап сөйләгез,— диде Марат кызга.— Нигә тик утырасыз?

— Бар минем язганым, Марат Вәлиевич,— диде кызый. Ул Маратка карап наз белән елмайды һәм бер бит кәгазь сузды. Анда нибары бер җөмлә иде: «Мин барысына да риза, мин инде школьница түгел».

Марат Вәлиевич шунда аны куып чыгарырга уйлаган иде — булдыра алмады. Торды, барып аудиториянең ишеген төбенә кадәр ачып куйды да өстәл янына килеп утырды. Гүзәллекнең шундый буш башка бирелгәненә ачынып, ул дәшмичә генә зачеткага «уд» куйды һәм, тиз генә ведомостьның эшен бетереп, кызыйга бирде.

— Деканатка илтеп тапшырыгыз, пожалуйста,— диде.

Ләкин бик сылу иде ул надан кыз, шайтан алгыры...

Ике тапкыр Марат Вәлиевич кабул итү имтиханнарында эшләде. Институт укытучысының иң авыр вакыты ул, август ае. Соңгы елларда яңа мода чыкты — һәр абитуриентның үзенә ияреп әти-әнисе, туган-тумачасы килә. Капрон эшләпә кигән мәктәп директорлары, кояшта кара янган район промкомбинат директорлары, сельпо председательләре, шәһәрдәге кибет мөдирләре үзләренең кадерле балаларын артларыннан ияртеп деканат, кабул итү комиссиясенең ишекләрен ачкалап, коридор буенча йөриләр, укытучыларның өенә киләләр, кайтуын сагалап торалар, телефоннан шалтыратып интектерәләр. Әллә ниткән вәгъдәләр бирәләр, кунакка чакыралар, әллә нәрсәләр табып китермәкче булалар. Кешегә каты бәрелеп булмый, син аларны тыңларга мәҗбүрсең. Кайберсенә ничек инде ярдәм итмисең? Институт укытучысы да кеше бит — менә аның каршында райондаш танышының малае утыра. Ә этисе коридорда йөри. Малай белми, икеле куй да чыгар. Әмма авыр хәл бу! Ләкин бит этисе күрше авылныкы гына, әйтик, Вәлиулла абзый белән бер чорда колхоз председателе булган кеше. Маратларның өендә ничәмә-ничә тапкыр булганы бар. Әнә шул кешенең улына гадел билге куеп кара син!..

Тагы да авыррак хәлләр була: бик якын танышың фәлән фәннән имтихан биргәндә малаена яки кызына күз-колак булырга куша. Тәҗрибәсез яңа укытучы үзенең дусына — имтихан алучыга әйтеп куя: шул кешегә күз-колак бул, ди. Тегесе шулай ук яшь: күз-колак була, әлефне таяк дип белмәгән бер эшлексезгә әйбәт билге куя. Ахырдан исә якын танышың юкка чыга. Ике-өч елдан соң очрый ул сиңа. Син инде, әлбәттә, тәге вакыттагы игътибарың өчен әлеге таныштан рәхмәт сүзләре өмет итәсең. Менә бит, якын танышымны миңа рәхмәт әйттерергә мәҗбүр иттем, дип алдан уңайсызланып утырасың. Ә ул...

— Минем кыз кергәндә ук гел бишкә бирде,— ди. — Декан үзе килеп эзләп табып аркасыннан сөйгән: «Молодец, сеңелем, сине беренче чиратта зачислять итәбез»,— дигән...

Марат беренче елларда боларын да күрде. Хәзер ул хәйләкәр: андый үтенеч белән килгән танышларын ахырынача тыңлый һәм елмаеп утыра: ярар, ярдәм итәрмен, ләкин үзләре тырышсыннар, ди. Һәм август аенда шәһәрдән чыгып китә. Я авылга ялга, я учхозга.

Ай-һай, бу мәсьәләдә актив кешеләр була. Марат Вәлиевич имтихан алган группада бер абитуриентка туры килде. Кыска итәктән, кызыл авызлы, очлы озын тырнаклы. Авыл хуҗалыгына моның ни чуртыма кирәге булсын. Кызый материалны белми иде, Марат салкын кан белән генә аңа икеле куйды. Тегенең исә бу икелегә сыңар керфеге дә селкенмәде, тыныч кына елмаеп чыгып китте. Ярты сәгать үттемеюкмы, имтихан бүлмәсенә профессор Хәсбиев йөгереп керде. Төсләре агарган, борын тишекләре киңәйгән иде.

— Сез ни эшләдегез, харап булабыз бит!— диде.— Бу кызның язмышы белән иптәш фәләнев үзе кызыксынган иде,— дип, тәэсирле бер шәхеснең фамилиясен атады. Зур фамилия Маратка әллә ни тәэсир итмәде, ләкин шул фамилия аркылы Хәсбиевнең ел саен Труцкавецка, Хостага баруы берәүгә дә сер түгел иде.

Ахырдан профессор Хәсбиев сөйләде (ул вакытта Хәсбиев әле Марат белән дус, сердәш иде). Наташа (теге озын тырнакның исеме шулай икән) аудиториядән чыгуга тәэсирле шәхескә телеграмма биргән: «Сочи, довостребования. Провалили прими меры». Тәэсирле кеше шул көнне үк самолет белән шәһәргә кайтып төшә, дусының квартирасына урнаша һәм телефон янына утыра. Наташа да шунда... Төн чыкканчы күп мәсьәләләр хәл ителә, иртәнге рейска кемдер авиабилет китереп бирә. Тәэсирле шәхеснең кайтып киткәнен семьясы да белми кала, иртәнге ашны әлеге шәхес үзенең өстәле янында, санаторийда ашый.

Беренче сентябрь көнне институт коридорында Наташа күренде. Марат аны таныды. Тик ул башка факультетка кергән икән. Матур трико, матур перчаткалар кигән, аягында кирза итекләр, иңенә матур итеп шәл салган, иреннәр кызыл, күзләре сөрмәле. Колхозга китәргә машина көтәләр иде. Менә сина Наташа! Тик бервакыт кына Марат шактый кызганыч картинаның шаһиты булды. Тәэсирле шәхесне Наташалар белән бик мавыгып маташканы өчен эшеннән чөйгәннәрен әйттеләр. Язның бер матур көнендә Марат урамда Хәбибне очратты да, Кабан күле буендагы кафега кереп утырдылар. Ишек янындагы иң дәрәҗәсез өстәлдә өч кеше утыра иде. Икесе шактый исерек, өченчесе болоньи курткадан, резин итекләрдән, әлегә аек иде. Официанткадан яшереп кенә өч сум алтмыш ике тиенлекне өстәл астында ачтылар, яшереп кенә эчтеләр. Болоньи курткалысы — урыныннан төшерелгән әлеге тәэсирле шәхес иде. Аның күзләре кызганыч караш белән Кабан күле өстенә, «Спартак» комбинатына юнәлгән иде. Кызык, Наташа белән хәзер очрашалармы икән? дип уйлап алды Марат шул чакта. Наташа әле дә аның тез башында утырамы икән?

Имтиханда эшләсәң — иң рәхәте Ибраһимов белән. Җаның тыныч. Ул икеле куйганда да тәмам ышандырып, аңлатып куя. Аның гаделлеге бөтен институтка мәгълүм. Аның янына тегенди-мондый үтенеч белән килүче юк та. Чөнки тышкы кыяфәте үк әйтеп тора: мин, ди, югары белемле совет интеллигенты. Мин — партия билеты йөртәм. Шуның өстенә әле мин — фронтовик. Протез аяк белән йөрим. Менә мин тормышыма юлны сыңар аяк белән ярдым. Яле, туганкай, ике аяк белән син ниләр эшләрсең икән?

Чыннан да, өлкән экзаменатор булып Ибраһимов кабул иткән группа иң гадел коллектив була. Ә соңгы кабул итү имтиханнарында

Марат шартлады. Анысы — бөтен биографиясенә җитәрлек. Дүрт ел буе армия хезмәтендә булды, нинди генә кыен хәлләрдә калмады. Армиядә иң авыр вазифа — сержант составыныкы. Солдатларга тәрбияче дә бул, өлкән офицерлар сиңнән канәгать тә калсыннар. Марат шул мәктәпне узган иде. Ә монда солдатлык чыдамлыгы аңа хыянәт итте.

Узган ел ул институт буенча кабул итү комиссиясе председателе иде. Аның янына көненә йөзләгән абитуриент, йөзләгән ата-ана керә. Барысының да хәле мөшкел, барысының да үтенече зур. Берәүләр авыру булганлыктан имтиханда дүртле алган, ә бишлесез — ышаныч кечкенә. Менә врач справкасы. Берәү институтка керә алмаган дигән данны күтәреп авылга кире кайта алмый. Теләсәгез нәрсә эшләгез. Тагын берсе физикадан икеле алган, ләкин ул имтихан кәгазенә өчле куюларын сорый. Ни өчен? Юк, ул барыбер инде документларын алып кайтып китә, тик менә институт ишеге төбендә аны иптәш кызы көтеп тора. Ул, әлбәттә, документны караячак...

....Марат каршына берет кигән яшь бер егет килеп басты. Беретында ике-өч значок. Кыска җиңле погонлы күлмәк кигән, погонлы плащын кулына салган. Азатлык армиясенең солдаты инде — койган да куйган. Тик погоннары гына хәрби түгел, ә болай фасон өчен генә.

— Я, тыңлыйм, — диде Марат.

— Миңа, ни, сочинениене кабат язарга рөхсәт итмәссезме икән?

— Ни өчен кабат язарга? Икеле алдыгызмы?

— Юк... мин... мине шпаргалка өчен куып чыгардылар.

— Рөхсәт итә алмыйм. Кайтыгыз, ныклап хәзерләнегез, киләсе елга шпаргалкасыз гына биреп керерсез.

Егет погонлы плащын кулдан-кулга алыштыра, борынын тарта, этенә.

— Рөхсәт итегез инде, абый, ә?

Бу газап ярты сәгать дәвам итә. Марат кыенсына, алҗый һәм аптырагач болай дип сорый:

— Я нәрсә инде ялынасыз? Сез яшь кеше, менә берәр ел эшләгез, киләсе елга тагын килерсез. Инде анысында акыллырак булырсыз.

Ләкин шул вакытта сүз көтелмәгән якка борыла.

— Абый, миңа быел һичшиксез берәр институтка керергә кирәк шул.

— Ә ни өчен быел гына? Сезгә бит әле унҗиде яшь кенә. Бер ел эшләп торыгыз.

— Укырга керә алмасам... мине армиягә алалар шул, абый.

Марат урыныннан сикереп тора. Гомердә булмаган хәл — калтырана башлый.

— Ә нигә, ике ел хезмәт итәрсез дә, кайткач керерсез.

Яшь егет оятсызларча елмая:

— Ике ел гомерне айт-двага әрәм итәргә дурак түгел шул мин, абый. Менә сез үзегез укыгансыз....

...Икенче көнне кабул итү комиссиясе председателе өстәле артында чандыр, нечкә билле, төксе генә бер ханым утыра иде. Марат Вәлиуллинны бер абитуриентны якалап институттан куып чыгарган өчен комиссия председательлегеннән алганнар, ә погонлы күлмәкле егетнең әти-әнисе эшне инде тиешле оешмаларга җиткергән иде.

...Бу авыл тирәсендә станцияләр әллә ничек моңсу була. Монда озак утырсаң, бөтен гомереңне иләктән уздырырга мөмкин. Марат монда яшь алмас иде. Ә менә теге матур аяклы кыз яшь. Әнә ничәнче тап-

кыр инде ул фонтаннан су алып кайта. Аның кадәр су кирәкми бит инде бер хуҗалыкка. Су китерү, күрәсең, аның бер рухи хаҗәтенә әйләнгән. Монда клуб юк, кино-танцы юк, кечке якта кая барасың? Ә матурлык бар, яшьлек бар. Менә ул яшьлек кичке якка таба дулый, кайный башлый. Ул кыз башта көзге янына килеп үзенең чәчен-битен карагандыр, аннан килешле аякларын... Ә әйләнә-тирәдә соры складлар, узучы юлчылар, мәсьәлә хәл итеп йөрүче тәэминат, сельпо, райпо, райтоп, сельхозснаб кешеләре. Бу матурлыкны кая куярга? Әнә шуңа күрә сәгатьтән бирле су ташый ул.

Кичке кояшның соңгы нурлары станциянең су башнясы артыннан төшеп, озын, шыксыз күләгәләр ясады. Диспетчер өзек-төтек тавыш белән поездга утыра башларга дип әмер бирде. Көнбагыш кабыклары белән чүпләнгән вагон баскычына менеп басуга, Марат күңеле белән шәһәрдән аерылды: алда иркен кырлар, кара балчыклы бормалы юллар, люцерна басулары, каен полосалары көтә иде. Анда — эш, анда — конкрет хәрәкәт, физик талчыгу, көч җыю, акылыңны эшкә җигеп сынау һәм бала чакны искә төшереп иҗади талпынулар көтә иде.

Кичке кояшның алтын нурына коенган су башнялары, пакгаузлар[1] күздән югалуга яшькелт болын һәм сары камыл басулары башланды...

## Гөлләр көзен саргаялар

Ибрай малаен авылда Ибруш малае дип йөртәләр. Ул үзе этисен белми. Этисе киткәндә кеше аерырлык түгел иде. Үсте, этисез дә үсеп, аякка басып була икән... Үсте, йорт-җир яңартты, этисен сагынмады, юксынмады, чөнки аны белми иде. Еллар узды — җир шары һаман әйләнә бит — Ибруш малаена да инде утызлар тулып килә иде, авылда карт егет булып йөрде. Эшкә карусыз булды, кыска сроклы курсларда укып электрик дигән исем алып кайтты, колхозга электр линиясе сузылгач, Ибруш малае бик кирәкле, дәрәҗәле кешегә әйләнде дә куйды. Кызлар белән йөрергә, клубта иһи-миһи килергә инде соң иде, кайсыдыр димләдеме, әллә юкмы, үзеннән байтак олы, чая Зәмзәмбикәгә — Галләмгали агайның кече кызына өйләнде. Егетнең дә яше узган булгач, авыл халкы бу вакыйганы әллә ни әвәләп тормады — тыныч кына яңа гаилә корылды.

...Тыныч кына... Анысын Ибруш малае үзе белә дә, Зәмзәмбикә белә. Зәмзәмбикә шаян кыз иде, иптәшләре арасында гомере буе уйнап сөйләшеп йөрде:

— Әй дим, бер вакыт табып кияүгә барып кайтасы бар иде.

Һәм барып та кайтты. Күчмә театрның авылга килгән көне иде, Галләмгали агайларга берничә артист куна төште. Арадан берсе — билет сатучысы — бакенбардлы, елтыр күзле чибәр егет иде. Эти-әнисенең ай-ваена карамыйча, Зәмзәмбикә бу егеткә ияреп китте. Һәм... өч көннән кайтып төште...

— Нихәл, тишек чиләк белән су ташып буламы? — диде егетләрнең бер явызы, Ибруш малае кыз алып кайткач.

Ибруш малае башта моны аңламады. Теге егет беткәнче явыз булып чыкты, кибет янында тагын бер көнне әйтә салды.

— Нихәл, суынган эшти(щи) эчеңә килешәме?

Сүзнең мәгънәсе шул көнне генә Ибруш малаеның миенә барып җитте. Һәм кибеткә йорт кирәге алырга килгән җирдән ул ике йөз

---

[1] Тимер юл станцияләрендә складлар.

грамм салып кайтты. Анарчы андый гадәте юк иде. Ә бит өйләнгәнгә нибары алты көн иде әле. Җиденче көнне ул тагын кибеткә керде. Кибеткә гармуннар кайткан иде, ирләр шул тирәдә әвәрә килде. Кайсыдыр тальян гармунны алып кычкыртып карады, кемдер Вараксин гармуныннан башка барысы да пүчтәк дип сөйләнде. Арадан берсе Ибруш малаена эндәште:

— Менә, Миңнулла, яңа гармун,. алып җибәр, — диде. Бер читтә чалгы, балталар карап яткан Фәхрислам шул вакыт елмайды да:

— Аның аккордеоны бар инде, — дип куйды.

Башка көнне, әйтик, моннан өч-дүрт көн генә элек әйтелгән булса, бу сүз гадәти бер сүз булып узып китә иде, әмма бүген ул Миңнулланың йөрәгенә кадалды. Үз гомерендә беренче тапкыр ул, күзләрен ямьсезләтеп, олы кешегә җикеренде:

— Я, син тик тор!

Шуннан йокы качты. Кечкенә өйдән Миңнулланың әнисе һәр төнне ишетеп ятты: һәр төн уртасында түр өйдә тавыш чыга. Никадәр тыңламаска тырышса да, тол солдатканың колагына керми калмады. Күрше авылда спектакль куйган көнне билет сатучы чибәр егет кияү мунчасы яктырган... Я, шуннан соң Миңнуллага ни дип яшәргә инде? Ә бит Зәмзәмбикәне матур тавышлы булганы өчен генә, имеш, сәхнәдә җырлатасылары булганга гына ияртеп алып киткәннәр, дип сөйләгәннәр иде башта.

Миңнулла каты эчте, соңга калып кайтты, тавышланды. Иртәгесен авыр баш белән сөйләшмичә генә чәй эчте, эшенә китте, көндез ашарга я кайтты, я кайтмады. Тиз исерә иде, исергәнен сизүгә өйгә торып чаба иде. Әнисеннән оялды. Бер төнне шактый соң кайтты, чолан ишегенә кирза итекләре белән типте, ишекнең биге суырылып чыгып очты. Өй алдына кергәч никельле караватны тартып аударды, эскәмиядәге су чиләген тибеп тәгәрәтте. Йортта тавыш купты. Киленгә ярдәмгә әнисе дә чыкты. Ләкин Миңнулла кеше танырлык дәрәҗәдә түгел иде. Әнисе барында Зәмзәмбикәгә ямьсез сүзләр әйтте.

— Фәлән итим, артист белән кияү мунчасы кергән себерке, — дип, тумбочка өстеннән кечкенә радиоалгычны күтәреп идәнгә бәрде. Аннары үкереп елап җибәрде дә түрдәге диванга барып ауды. Яман сүгенде. Әнисе дә, малайның холкыннан куркып калып, үзенең кечкенә өенә кереп бикләнде.

Миңнулла кәефсез уянды. Иртәнге чәйгә әнисе чыкмады. Зәмзәмбикә белән икесе сөйләшмичә генә чәй эчтеләр. Бу минутта алар икесе дә бик-бик бәхетсез иделәр.

— Әни минем исереп кайтканны белмәдеме кичә? — дип сорады Миңнулла. Бичара! Нишләсен инде ул? Зәмзәмбикә дә нишләсен инде? Егетләрнең матур сүзенә кем генә ышанмый. Ә бакенбардлы егет аңа ниләр генә әйтмәде! Матур җырлаган авыл кызының кайсысының гына артист буласы килми соң? Ә бит бакенбардлы егет аны бер айдан сәхнәгә чыгарам диде. Зәмзәмбикәнең үз гомерендә үзе турында мондый матур сүзләр ишеткәне булмады. Билет сатучы егет аның чәч толымнарын, керфекләрен, бит урталарын, тулы беләкләрен мактады. Шулай өч көн мактады да, штатта булмаган кешене йөртергә администратор рөхсәт итми, дип, Зәмзәмбикәне өенә озатты. Гастроль бетүгә кереп алырмын диде. Кермәде. Бераздан акча махинацияләре өчен аның эштән куылганлыгы ишетелде.

...Миңнулла бу гауганың мәгънәсез икәнлеген үзе дә аңлый, моның берничек тә, беркем дә исбат итә алмый торган эш икәнен белә иде. Я инде, нигә дуларга? Дөньяда иң актык серне бары тик хатын-кыз гына белә. Ирләргә андый мөмкинлек бирелмәгән. Миңнулла бервакыт шәһәр кибетендә касса янындагы җәнҗалны карап торган иде: бер хатын кассирның якасына ябышкан да селти.

— Бир ун сумымны! Бир! Рабучий классны ник талыйсың син, сволочь! — ди. Кассир да каушаган, каршы тора: — Алмадым, синеке кирәк түгел, сдачаны дөрес бирдем, — ди, үкереп елап ала.

Кем хаклы монда? Кем белсен аны. Миңнулла белән Зәмзәмбикәнең дә хәле әнә шулай, касса янындагы җәнҗал кебек.

Миңнулланың куллары алтын. Колхоздагы бөтен электр системасы аның карамагында. Эшенә ул зыян китерми, күпме түләүләре белән кызыксынмый. Көн дими, төн дими, куртка кесәсенә карга борыны белән отверкасын сала да чыгып китә. Колхозчыларның радиоалгычын, телевизорын рәтләп тору дисеңме, яңа кайткан суыткычны көйләп бирүме, телевизор антеннасы ясап бирүме — барысына да Миңнулла кирәк. Бер кешедән бер тиен акча алмый. Салып биргәнне эчми, эчкәндә дә кибеттән үз акчасына гына. Колхоз председателе Ленар ничә тапкыр җыелышта аны оялтып карады, үгетләде, әмма каты бәрелмәде. Җыелышларның берсендә аның турында сүз чыккач, Миңнулла кызмача хәлдә тел ачты:

— Үз акчама эчүдән ник тыясыз, демократия шул буламы? — диде.

...Ул көнне төнгә каршы яшенле яңгыр килде, Миңнулла төн уртасында, пыр туздырып юрган-мендәрен күтәреп, келәткә йокларга чыгып китте.

— Яман хатынны яшен сугучан була, минем әле яшисе килә, — диде.

Зәмзәмбикә тавышланмады, тешен кысып яшь түкте, ул инде бала көтә иде. Хатыны юанайган саен, Миңнулла эчүдән тыелырга тырышты. Тик бер генә тапкыр шактый кызып кайтып керде. Августның чык төшкән җылы бер киче иде, этисеннән калган Вараксин гармунын алды да урамга чыгып китте. Йөрәге кузгалган иде. Сәбәбе — яшь егет вакытындагы татлы бер истәлек иде.

...Кайдадыр, ерак якларда кибетче булып эшли торган Факиһә кайткан. Миңнулла аны көндез авыл урамында очратты. Факиһә тазарган, юанайган, затлы киенгән, алтын балдакларны мул кигән иде. Унбиш ел чамасы элек кенә алар бергә Миңнулла белән унынчыны тәмамлаганнар һәм укырга керү турында хыялланганнар иде. Аттестат алып кайткан көнне Факиһә кичен Миңнулла белән су буенда йөрде. Шул кичне Миңнулла үз гомерендә беренче тапкыр кыз баланың чәченнән башны әйләндерерлек хуш ис килгәнен тойды һәм теле тотлыгып калды. Үз гомерендә беренче тапкыр ул дерелдәп торган гәүдәле кызыйны күкрәгенә кысты, тегесе исә кайнар ирennәре белән моның тынын каплады.

Аннан алар аерылыштылар. Бераздан Миңнулла электриклар курсына, Факиһә сәүдә техникумына китте. Аны бетереп чыккач, Факиһәне Красноярск ягына эшкә җибәргәннәр, диделәр. Аннары шунда кияүгә чыккан, диделәр...

Инде менә шул гомердән бирле күрешмәгән Факиһә очрады. Үзгәргән, бик үзгәргән Факиһә. Шулай да урам уртасында кул бирешеп кыскача гына күрешеп алганда да Миңнулла яшьлегенә кире кайтты: Факиһә нәкъ теге елдагыча итеп елмаеп алды. Бер секундка гына аның күзләре дә нәкъ элеккечә итеп нур сибеп алдылар. Шул караш, шул нурлар Миңнулланың бәгырен телгәләде. Һәм кичен ул урам уртасыннан үз гомерендә беренче мәртәбә җырлап барды. Җыр запасы зур түгел иде, кызмача баштан ул гел бер җыр гына җырлый иде.

Гөлләр көзен саргаялар,
Ә син һаман яшь минем...

Бүген исә ул тагын бер җыр җырлады...

Урам уртасыннан гармун уйнап Миңнулла килә. Күктә тулган ай. Бөтен авыл көмеш нурга коена. Ай нуры астында Миңнулланың үз

кулы белән багана башларына борып куйган лампочкалары кечкенә саргылт нокта булып күренә. Миңнулланың йөрәге еш типте, тамагы карлыкты, Капка төбендә эскәмиядә беләкләрен кочаклап берәү утыра, ай нурында аның колакларында, беләк-бармакларында әллә ниләр ялтырап, җемелдәп тора иде. Бу — Факиһә, моннан күп еллар элек Миңнуллага бер бәхетле кич бүләк иткән Факиһә.

Ләкин Миңнулла аның янына бармады, туктамады. Факиһә — ир хатыны, Миңнулла — ата буласы кеше. Тик йөрәк түреннән чыккан тавыш белән генә, барган хутка бер җыр җырлап узды.

Тал бөреле, тал бөреле,
Тал бөреле була ул.
Җан яраткан, күңел тарткан
Яр бер генә була ул.

Факиһә, эскәмиядә утырган килеш, тыйлыга алмыйча елап калды. Хәер, Миңнулланың гармун тавышын ишетеп, аның кайсы урамда йөргәнен сизеп торган Зәмзәмбикә дә бу вакытта елый иде.

Үз капка төпләренә җиткәндә исә Миңнулла нәкъ элеккеге Миңнулла булды да калды. Гармунын җыйды, капкадан кергәндә экрен генә көйләде:

Гөлләр көзен саргаялар...

— Син! — дип, төксе итеп дәште ул өйгә кергәч Зәмзәмбикәгә. — Син! Син анда гастрольгә китеп, кияү мунчасы яктыртып...

Ләкин җөмләсен тәмамлый алмады. Зәмзәмбикә эчен уып диванда тәгәрәп ята, Миңнулланың әнисе йөгерә-кабалана, өйдә кыямәт иде.

— Бар, йөгер,— диде үз гомерендә бердәнбер малай тапкан тол солдатка кызмача улына. — Йөгер Ленарга. Машинасын сора. Тулгагына караганда малай булырга тиеш.

...Касмак башлы ямьсез кара малайга сугышта үлгән бабасының исемен бирделәр. Йортта Ибраһим барлыкка килде. Бәби туенда Миңнулла алты тапкыр үзе башлап җырлады.

Гөлләр көзен саргаялар,
Ә син һаман яшь минем.

Ленар бәби котлап идарә исеменнән аларга бер коляска, бер комплект юрган-мендәр җибәрткән иде.

Ибраһим моңарчы беркем дә хәл итә алмаган төп ике мәсьәләне хәл итте. Беренчесе: Миңнулла үзенең йөрәген талаган гастроль мунчасын онытты. Һәрхәлдә, күңел түренә бикләде. Бәлки бу хәбәр әле гайбәт кенә булгандыр. Зәмзәмбикә шулай ди бит. Әйе, бик ихтимал. Икенчесе: эштән кайтышлый кибеткә йөрүдән туктады.

Ләкин вак кабыргалы кара Ибраһим хәл итә алмаган бер мәсьәлә калды: мәҗлес-фәлән булганда, кәефләр хушланып киткәндә Миңнулланың җырлый торган җыры үзгәрмәде. Гөлләр һаман да көзен саргая килделәр... Тик инде бу җыр да елына ике-өч тапкыр гына җырлана иде...

## Бөтенләй икенче тормыш

Фәхрислам — сәнгать кешесе иде.

Гомер буе колхозның иң авыр эшендә булды, әмма сәнгатькә, сәхнәгә мәхәббәте аңа карап һич кенә дә кимемәде. Фәхрислам яшь иде әле ул вакытта — егерме бишенче еллар — алар сәхнәгә «Галиябану»ны куйдылар. Шул вакыйгадан соң Фәхрисламның тормышында зур

рухи байлык ачылды: дөньяда физик эштән, арып кайткач ятып йоклаудан тыш әле бөтенләй икенче бер тормыш, икенче дөнья бар икән. Ул — сәнгать.

Тормышта бик еш очрый торган хәл — бай рухлы бер иргә шактый ук ярлы җанлы бер хатын туры килә. Киресенчә булганнары шулай ук байтак. Фәхрисламнар тормышы беренче очракка туры килә иде. Сабира җиңги рухи яктан ярлы, йомык, саран булды. Колхоз эшен каты эшләде, өйгә кайткач казан асты тирәсендә, келәттә булды, әмма Фәхрисламны аңламады. Эчтән генә көнләште, сызды: хатын-кызның андые да була бит, яман көнләшә, әмма иренә сиздерми. Шулай, сиздерми-сиздерми, Сабира җиңги гомере буе бер теләк теләде: Фәхрислам картайсын иде тизрәк. Чәчләре коелсын, тешләре төшсен иде дә Сабира җиңгинең күзенә карап кына манный пешеп чыкканны көтеп утырсын иде, эштән кайткач.

— Безнең Фәхрислам бик картайды хәзер, бу елларда бик бетте,— дип, кеше арасында, бигрәк тә хатын-кыз арасында әйткәләргә ярата иде Сабира җиңги.

Сабира җиңги, өйләренә ничә керсәң дә, почмак якта була иде. Ни эшли ул анда? Моны беркем белми.

Авыл халкы бер-берсенә йомышка йөри. Шәһәрдә алай түгел. Авылда бер-береңнән ипи, он, май алып тору — хәтта күркәм гадәт. Шул йомышны үтәү-үтәмәү аркылы кешеләр бер-берсенә мөнәсәбәтләрне билгеләләр, ачыклыйлар. Йомыш — сүзсез аңлашу.

Сабира җиңгигә, әйтик, бер бала керә. Почмак яктан тавыш:

— Ни йомыш иде, лан?

Бала борынын тартып:

— Сабирәтти, ни, әни әйткәние, бер ярты кадак кына сары мае юк микән, алдагы атнада май язгач түләрмен дигәние...

Почмактан тавыш:

— Ы-ы... Югые шул, лан. Булса тотмасыем... Югые шул...

Бала чыгып китә. Ишегалдыннан капкага җитә. Шул вакыт чоланнан тавыш:

— Ни... лан, туктале... Кер әле. Тукта, менә монда әз генә бар икән, — дип, Сабирәтти яссы пычак белән мул гына кисеп бер түтәрәм майны баланың савытына сала.— Җае белән бер түләр әле, ашыкмасын. Ниме, сыерыгызның тояк арасы төзәлдеме инде? Тәтәләрең әле озак торамы? Утпыскылары бетмиме әле? Җиләк киптерәсезме?

Гомере буе шулай булды. Йомышны үтәде, әмма бер кат баш тарткач кына. Күрше-күлән моны белә иде һәм чыгып барганда ишегалдыннан капкага кадәр булган араны мөмкин кадәр акрынрак узалар иде...

Сабира җиңгинең саранлыгы Фәхрисламның йөрәген бик әрнетә иде. Саранлык дигән нәрсә фантазиягә бик бай була икән. Сабира җиңги кунак килгәндә эчемлек шешәсен алыштырырга остарды. Хәтта Ленар укып бетереп кайткач та, өенә зур кешеләр белән ашка кайтканда да бу нәрсә сизелде: арзанлы эчемлекне кибеттән үзе алып (Фәхрисламга ул акча тоттырмый иде), кыйммәтле эчемлектән бушаган шешәгә салып китереп, Ленарны кыен хәлдә калдырды. Егет вакытта Ленарның одеколонын да шулай кыйммәтле шешәгә бушатып куя иде. Әмма эчемлек мәсьәләсендә Сабира җиңги чын мәгънәсендә комбинатор булды. Сугыштан соңгы авыр еллар. Эчүчеләр күбәйде: утын — яртыга, печән — яртыга, бакча сукалау — яртыга... Ямьсез гадәтләр, ямьсез кешеләр барлыкка килде. Йөз грамм дигән яңа ямьсез сүз барлыкка килде. Сабира җиңги монда да әмәлен тапты. Эчемлекне үзе ясый иде. Өч төрле, өч дәрәҗәле итеп. Беренче дәрәҗәдәге

эчемлек өй астында, балчык нигездә саклана. Ул агач, шифер, түбә калае кебек әйберләрне хәл итәрдәй дәрәҗәдәге кешеләр кергәндә чыгарыла. Икенче дәрәҗәдәгесе трактор, автомашина кебек транспортны куллары белән тотып идарә итүче, беренче дәрәҗәдәге эчемлеккә лаек кешеләр табып биргән әйберне ишегалдына китереп куючыларга чыгарыла. Ниһаять, өченче дәрәҗәлесе — Фәхрисламга, бакча сукалаучыга, ат арбасына салып бирәр капчык онны кибеттән алып кайтып бирүче егеткә, Фәхрислам белән кара-каршы такта ышкылаган күршегә, чираттан ашарга кергән көтүчегә...

Саранлык... Дөньяда юмартлыкның чиге бар, әмма саранлыкның — юк. Юмартның фантазиясе бай түгел. Хәзинәдә ни бар, шуны бирә ул сиңа. Ләкин саранның фантазиясе... төпсез упкын. Сабира җиңгинең, бичара, тел-сөйләү манерасында да сизелә иде ул.

— Утыр, дип әйтерием инде, ашыга torгансыңдыр, — дип куя иде ул йомыш белән кергән күрше хатынга. — Самавар куяр идем инде, әчәсең килми торгандыр, — дип куя иде ул күрше авылдан йомыш белән килгән хатынга...

Сабира җиңгинең бер сандыгы бар иде: аның эчендә ни сакланганын шайтан үзе генә белә. Вакыт-вакыт, ялгыз калганда ул әлеге сандыгын актарырга ярата иде. Хатын-кызның бик бәхетле вакыты ул сандык актарган сәгатьләр! Бу вакытта аларга тимәгез, борчымагыз, бүлдермәгез... Яшь вакытындагы кулмәген, яулыгын, беренче баласының уч төбе хәтле генә баш киемен, кул аркасы кадәр генә күлмәген, ярты учка сыярлык бумази ыштанын саклый ул хатын-кыз. Боларны ул елына берәр тапкыр алып актара, кадерләп кенә карый, бу вакытта хатын-кыз — шагыйрь, композитор, бөек философ, бу вакытта саран — юмартка, куркак — батырга, явыз — юньлегә, ямьсез — матурга әйләнә. Сабира җиңгинең дә баласы булган иде. Ике генә ай яшәде ул кыз. Аның киемнәре әле дә саклана. Мәңгелек, йөрәк өзгеч булып. Әнә нәкъ шундый моментта килеп кергән иде Сабира җиңгигә килендәше Сөембикә. Сайлау участогындагы кабина ишегенә корырга чаршау сорап. Я, дөнья! Авылда сайлау кабиналарын утыз җиденче елның декабреннан бирле беләләр иде. Кемнәрдән генә нинди чаршаулар алынмады ничә еллар буенча! Инде белеп торалар иде: әнә теге иң күренә торган кабинага Бибиәсма җиңгинеке, әнә теге уртадан икенчесенә Гафифә җиңгинеке, әнә теге ишек кырыендагысына Камәр түтинең зур чәчәкле чаршавы әйбәт була. Алар шундый: сорамасаң, сайлауга ике-өч көн кала үзләре китереп бирәләр. Әмма Сабира түтинең чаршавын күргән кеше юк иде әле. Инде Сабира түти шундый хәйләкәр елмаю белән сандык төбеннән бер чаршау чыгарып тоттырды Сөембикәгә... Кара син аны хәйләкәрне. Бер сүз дәшми, үзе сынаулы елмая. Янәсе, күрдеңме? Менә, мин шулай... Сез, гомумән, мине белеп бетермисез. Мин — башка кеше... Әфлисун төсле эре-эре бизәкле затлы чаршаудан бераз гына нафталин, бераз гына скипидар исе килә иде. Әмма авылның мондый затлы чаршауны күргәне юк иде. Сайлаучылар гел шушы кабинага керделәр...

Бу, ахрысы, Сабира җиңги авырып китәсе елда иде.

...Фәхрислам аның белән һәр вакытта да аз сүзле булды. Тик аратирә генә әйткәләп куя иде:

— Син берәр сүз әйткәнче башта авыз эченнән генә әйтеп кара. Әйтергә ярыймы, юкмы. Яраса, аннан кычкырып әйтерсең...

Утызынчы елларда сәхнәдә кулакларга каршы җырлар җырлаганда Фәхрислам бик актив булды. Ничәмә-ничә спектакльдә катнашты, Сабира җиңги өендә эчтән көеп яtты. Эчтән көю аркасында Ленарга да ана җылысын бирә алмады. Малай гел кырыс тәрбия күрде. Хатын-кыз иреннән көнләштеме, юк инде, беренче чиратта, моның зыяны балага тия.

Ә Фәхрислам — үзе көтү көтте, кичләрен уку йортына йөрде. Ул вакытта уку йорты дигән сүз юк иде, аны ниндидер хикмәтле сүз «избач» дип йөртәләр иде. Хәтта районнан шунда эшләргә дип җибәрелгән бер ирне дә «избач абый» дип йөрттеләр, исемен белүче булмады. «Избач абый» Фәхрислам белән дус булды. Ә сәхнәдә ниләр генә куелмады, ниләр генә җырланмады! Фәхрислам камыл басуында сыер-бозау арасында көннәр буе репетиция ясый иде.

Уңда да ыштыр,
Сулда да ыштыр,
Чабата бавыңны кыстыр,
Сөйрә-ә-элеп йөрмәсен лә,
Сөйрә-ә-ә-леп йөрмәсен.

Монысы ярлыларны фәкыйрь тормыштан чыгарга чакырып җырлау.

Сезнең колхоз дигән нәрсәгездә
Туя икмәк ашап булырмы, шул,
Шундый матур сүзгә генә ышанып,
Аерым хуҗалыкны ташлап булырмы?

Монысын кулак җырлый. Фәхрислам кулак белән ярлы арасындагы дуэтта да җырлый иде.

Кайгырма ла, Сәрбиҗамал,
Баш сау булса, малның җаен
Үзебез табарбыз.
Барын тар-мар китерик тә,
Сатып-эчеп бетерик тә,
Читкә таярбыз.

Монысы кайсыдыр бер спектакльдән. Бу җырны Фәхрислам җырлый иде. Музыкасы Сәйдәшнеке дип йөртәләр иде. Ә Таҗи Гыйззәтнең «Акбаш вакыйгасы»? Төп роль Фәхрисламда иде... Ә аның көе? Ник, нигә ул көй юк хәзер? Ә бит кайчан гына әле ул әсәрне куйганга...

Акбашкаем, башмаккаем,
Тапмадыңмы, балакаем?
Ач бүрегә тәмле азык
Булган мәллә яшь малкаем?

Фәхрислам сәхнәдә җырлаганда, аста утыручы халык елый иде. Колхозны Фәхрислам эшләп кенә түгел, әнә шулай сәхнә белән дә төзеште. Кулаклар да тик ятмады. Фәхрисламнарның капкасын дегет белән буяп киттеләр, югыйсә, мондый йоланы начар даны чыккан кызларга карата гына кулланалар иде. Икенче бер вакыт Фәхрисламнар коймасына күмер белән яңалиф хәрефләрен сызгалап киткәннәр иде. Көтү куучы халык иртән бу сызмаларны оештырып укыды.

Уф, алла, дип әйтерсең, ди, үлгәч,
Китереп куярлар, ди, бер күмәч.
Аны да алып китәрләр, ди,
Колхоз иканеңне белгәч.

Колхоз бозавын Фәхрисламга сылтауны да шул кулаклар оештырган булып чыкты. Председатель Вәлиулла ахырдан Фәхрисламны чакырып болай диде:

— Дүрт аяклы ат та абына. Ялгышлык бездә. Көтүеңне әйбәт көттең, рәхмәттән башка сүзебез юк. Әмма тагы да җаваплы эшкә куймакчы булабыз сине. Җаткага утыр. Тәртипле, укуратный кеше кирәк.

Бер үзенә өч ат, бер машина. Үзе урганны үзе учмага салып бара торган машина кайтты. Көлтә бәйләүчеләргә күз-колак булырсың, хатын-кыз шулай ук синең командада...

Урак башлануга Фәхрисламның бер үзенә зур бер басу бирделәр. Атларны ул ярата иде, әмма хатын-кызны күмәк эшкә иләндерү җиңел булмады. Кая ул хәзер! Хәзерге хатын-кызлар белән тау күчерергә була. Ә аерым хуҗалык рухында тәрбияләнгән хатын-кызны күмәк эшләү тәртибенә өйрәткәнче күпме айлар, еллар китте. Ләкин Фәхрислам монда да сәнгать кешесе булуын файдаланды. Аның ишеткәне бар иде: имеш, урманда янгын чыкса, аннан котылу чарасы бер генә. Утны үзең төртәсең дә каршыга таба җибәрәсең. Фәхрислам иртән эш башлаганда ук аеруча үткен телле хатыннарга утны үзе сала торган булды. Югыйсә, юктан гына талашып китәләр. Җир буен адымлап бүләләр дә жатка салып киткән учмаларны көлтә итеп бәйләп торалар. Баш күтәрми эшли торгач, берсенең арасы кыскарып китә, икенчесенеке озыная. Кайвакыт бәхәс чыга.

Яшь килен Сабира — үз хатыны — бер көнне нәкъ шул мәсьәләдә председатель хатыны Бибиәсма җиңги белән талашты. Югыйсә, Фәхрисламга аны димләүче кеше Бибиәсма җиңги үзе иде.

— Кайда ике араң? Кайда ике араң? — дип кычкырды, нахак сүзне күтәрәсе килмичә Бибиәсма җиңги.

Кайвакытта ат сбруясын рәтләп, машина көйләп җир башында озак торыла. Шуннан файдаланып, хатын-кыз да бил төзәтеп ала, җыелышып дөнья хәлләрен сөйләшәләр. Җирнең икенче башына барып җиткәч, Фәхрислам машинаны тагын көйли. Бу баштагы хатыннардан берсе сорап куя:

— Теге башта Халидәләр нишләп тик торалар? — ди.

Фәхрислам машина канатлары арасында буталган булып болай гына әйтеп куя:

— Һи-и, аларны да әйтер идем инде. Синең гайбәтне саткан була...

— Нәрсә ди, нәрсә ди, әҗәткана?

— Ни ди... Бер көнне озак йоклап сыерыңны саумыйча көтүгә кугансыңмы, нимазар[1], ди...

— Ах, кәнтәй, мин аны нишләтәсен белермен. Мин аны...

Фәхрислам елмаеп кына дилбегә кага да китеп бара. Түбән башта аның янына Халидә килә.

— Миңкамал белән нәрсә серләштегез? Атлар туктатып? — дип, үзенең бәхетсезлегенә каршы сорап куя.

Фәхрислам тагын жатка канатлары арасына кереп чыга.

— Һи-и, аныкын беләсең инде. Һаман синең белән булышкан көне...

— Нәрсә, ди, нәрсә дигән була, сантый?

— Ни, ди... Табак-савытын өч көнгә бер генә юа, ничек итеп кайнанасына ярый икән бу алама, ди...

— Ах, сантый крич, сантый крич... Үз гәүдәсен генә үстерәп йөртсәче. Тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән бит аңа. Ну, әйтәм әле мин аңа бүген әбәткә утыргач...

Шулай ди-ди баш та күтәрмичә ачу белән эшлиләр.

Фәхрисламның сәхнә кешесе булуын һәм шулай булганга гына Сабира белән яшь алуын барысы да аңлыйлар иде. Халидә дә, Миңкамал да, Фәхрисламның артистлыгы аркасында инде бушанып беткәннәр, аларга кушылып башкалар да бушанганнар иде. Фәхрислам үз әченә

---

[1] Казан арты сөйләше. «Нәрсәләр», «нидер» мәгънәсендә.

генә елмаеп, аларның күмәк хезмәттә чистаруларына, аерым хуҗалык гайбәтләреннән азат була баруларына шатланып йөрде.

Ничек итсә итте, гомер узды. Фәхрислам әчтән генә үзенең гомере әрәм узганга ачынды, семья җылылыгы күрмәде. Хәер, Сабира белән бер кич кунгач та ул үзенең ялгышканын аңлады: хатында наз юк иде. Дөньяда иң бәхетсез ир кем? Назны белмәгән хатынга өйләнгән ир. Туйлар ясалган, расходлар күп тотылган иде. Икенче көнне, тотылган акчаны кызганып түгел, болай гына, Фәхрислам сәке кырына утырып әйтте:

—Да-а-а... Акчаны суга салдым...

Сабира, бичара, кинаяне аңламады. Самаварга чыра телеп яткан җиреннән олы якка чыкты да:

— Ник суга саласың аны, миңа бир, — диде.

— Вәт, ту-ты шул, сиңа бирдем инде мин,— диде Фәхрислам, төксе итеп...

...Бибиәсма җиңги үлем түшәгенә яткач, Фәхрислам, ничектер, йомыш белән аларга кергән иде.

— Син миңа рәнҗемисеңме, Фәхрислам, Сабираны мин димләгән идем бит сиңа, — диде Бибиәсма җиңги, хәлсез иреннәрен ялап.

Фәхрислам авыр сулады. Авыруның йөзенә карады, аның көннәре санаулы икәнлекне аңлады. Сүзнең турысын әйтергә изләнгән иде ул.

— Һи-и-и, зиңги заным,— диде ул.— Нинди ул рәнземәгән. Нинди ул... Гомерләрем генә әрәм узды бит. Андый зегет идеммени мин...

Бибиәсма түти моңа гаҗәпләнмәде.

...Сабира җиңги баеп, рәхәт тормышка чыккач кына авырып китте. Аш үтмәс булды. Бер кыш авырды. Кышы да әллә нинди туры килде, яз җиткәнче авылда әллә ничә мәет булды. Ни өчендер, гел хатын-кыз. Сабира җиңги һәр авыруга карата игътибарлы булды, хәлен белергә йөрде, мәет саклап төн кунды, карашты, юышты, озатышты. Әмма сәер генә гадәтен кеше сизми калды: һәр үлгән карчыкның калган даруларын (сәдәф даруларын) җыеп алып кайта да, нинди дару икәнен сорашып тормыйча, көненә өч сәдәф эчә иде. Ләкин берсе дә ярдәм итмәде... Ленар аны машинасына утыртып районга алып барды, иң зур докторларга күрсәтте. Аннан шәһәргә. Докторлар барысы да операция кирәк диделәр. Ләкин Сабира җиңги моңа риза булмады, газраил килгәнне көтәргә әзерләнде.

Фәхрислам исә аны күмеп кайткач сабый баладай үксеп-үксеп елады. Бергә гомер иткән, бергә тормыш корган кеше бит! Әйбәт, тырыш хатын иде бит! Караңгы чырайлы булды, саран булды, аз сүзле, уенкөлкесез булды, әмма — хатыны иде бит...

Хәер, исән чакта кадерен белмәгән, хатыннары үлгәч елаган ирләр бер Фәхрислам гына түгел.

...Ә тормыш алга таба барды. Кеше үлде дип дөньяда беркайчан да хәрәкәт тукталмый. Ленар әтисенең ялгыш юлга кереп китүеннән курыкты. Олайгач кына кинәт ялгыз калган ирләр, гадәттә, берәр хата эшләп ташлыйлар. Кайвакытта ул хата бөтен нәсел-нәсәбеңне хур итәрлек, гомергә онытылмаслык бер кара тап булып кала. Фәхрисламны әнә шундый хатадан саклау өчен Ленар ашыгыч чаралар күрде. Колхоз эшенә зыян китермичә генә, бер бригададан икенче бригадага узып барышлый гына төп йортка тукталды: Фәхрислам баскыч төбендә кояшта күңелсез генә җылынып утыра иде. Ленар өйдән дә бер әйләнеп чыкты: өй эчендә хатын-кыз булмаган йортларга гына хас морҗа, кирпеч исе таралган, гөл яфраклары саргайган, өй шыксыз иде.

Өстәл өстендә салкын, тузанлы ак самавар — нәкъ адәм баласыдай моңлы, ятим. Өй эче тулы колакка ишетелерлек яңгыравыклы хәсрәт. Сәгать тек-тек килә — бары да үз, бары да якын, әмма — дөнья китек...

Ленар бервакытта да андый күңелсез уй-хисләргә бирелмәде. Монда да ул тәвәккәл булды. Өйдән тиз генә чыгып китте дә әтисен машинага утыртты, колхозның моннан алты километр ераклыктагы бригадасына алып китте. Бригадада илле яшьләр чамасындагы бер тол хатын бар иде: ул хатын сарык карый, заманында шул кечкенә колхозның председателе, республика Верховный Советының депутаты булган кеше. Үзе идарә салып биргән җыйнак өйдә яши, эшкә булган, көләч йөзле, тәвәккәл иде. Ире эчкечелеккә бирелгән, моннан байтак еллар элек исерек килеш трактор чанасына кысылып үлгән иде. Хатын шуннан соң иргә чыгам дип әйтмәде, бөтен көчен-куәтен эшкә бирде, дәртен эштә сүндерде.

Әмма бүген, капка төбенә председатель машинасы килеп туктагач, ул хатын каушады: ишегалдына председательгә ияреп таза гәүдәле өлкән бер ир керде. Ирнең өстендә чиста, ләкин үтүкләнмәгән кызгылт шакмаклы күлмәк, аягында брезент чүәкләр иде. Бүген иртән генә кырган яңагы бер-ике җиреннән киселгән, кисекнең берсенә хәтта кечкенә генә гәзит кәгазе дә ябыштырылган иде.

...Сөйләшүләр ике сәгать дәвам итте һәм дуслык, эчкерсезлек шартларында үтте. Тагын бер атна узгач исә тол хатынның ишегалдына йөк машинасы килеп керде. Кабинадан чыгып, ашыга-ашыга машина бортларын ачып йөргән кеше — Фәхрислам иде.

Шулай итеп, ике нигезнең берсен саклау максаты белән берсен бетерделәр. Фәхрисламнар моржасыннан ул көнне сыек төтен үрләде.

— Нихәл, Фәхрислам абый, яшь кәләш белән килешеп буламы? — дип сорады бер көнне аның янынннан узганда Шәйдулла. Фәхрислам капка рәшәткәсенә сөялеп эчке яктан урамга карап тора иде. Сорауга җавап биргәнче, ул башта як-ягына каранды. Капка-койма тирәсендә кеше-кара юк иде.

— Һи-и, энекәш, — диде ул әллә каян, күкрәктән чыккан тавыш белән, — бөтенләй икенче тормыш, бөтенләй. Әйдә, чәйгә кер...

Аның йортында чыннан да бөтенләй икенче тормыш башланган иде.

Тагын берничә көннән авылда хәбәр таралды: Фәхрисламның сакаулыгы беткән иде.

## Мәк чәчәген өздем ялгыш кына...

Каз өмәсенә Хәбиб кайта алмады. Югыйсә, Гафифә җиңгинең унбер бала казы үскән иде. Яшьтәшләре, аның кебек солдаткалар, күптән инде колхоз пенсиясен алып тыныч кына яшиләр. Әмма Гафифә җиңги тавык фермасыннан китә алмады. Дөресен генә әйткәндә, Ленар да аның пенсиягә китүен теләми иде. Гафифә җиңги менә ничә еллар инде фермада тавык анасыдай хуҗа булып йөри: аның янында ничәмәничә кызлар эшләп чыкты. Кайсы кияүгә китте, кайсы укырга. Күпме кеше аның кул астында эшләп дан алдылар: күргәзмәгә путевка дисеңме, премияләр дисеңме, район газеталарында мактау дисеңме — барысы да Гафифә җиңгинең сүзсез генә, сабыр гына эшкә өйрәтүе, колхоз фермасына үз йортына караган кебек чын күңелдән каравы аркасында иде. Быел көз башында гына әле республиканың авыл хуҗалыгы алдынгыларын бүләкләгәндә газеталарда Гафифә җиңгинең дә

исеме күренде: аны «Почет билгесе» ордены белән бүләкләделәр. Ленар машинасына утыртып аны шәһәргә үзе алып барды, зур залга үзе алып керде, исеме чыккач аны зал түренә орден алырга үзе култыклап алып барды. Гафифә җиңгинең күзләрендә шул вакытта яшь күренде. Залның алгы коридорында аларны Хәбиб көтеп тора иде, ике машина белән Хәбибләрнең шәп квартирасына чәйгә кайттылар. Председатель машинасына утырып Гафифә җиңги авылга ук китеп тә барды. Октябрь бәйрәме алдыннан каз өмәсе ясыйбыз, өйдә ир заты булса күңелле була, дип улын чакырды. Әмма Хәбиб кайта алмады.

Ферма кызлары белән Гафифә җиңги көне буе каз йолыкты, каз коймагы пешерде, кичке ашка кызлар янына каз суючы Фәхрислам чакырылды. Тик, яшь хатын көнләшер дип куркып, Фәхрислам аш мәҗлесенә килмәде. Аш бүленеп беткәч кенә, көтә-көтә арыгач кына, Гафифә җиңгинең исенә төште: Фәхрисламны хатыны белән чакырырга кирәк булган икән. Яңа хатын, иренә хет җитмеш яшь булсын, көнләшмичә калмый. Һәм, аш бераз гына суынган булса да, Гафифә җиңги Фәхрисламны яшь хатыны белән алып килде. Гомерләрен колхоз эшендә уздырган ике хатын чрты тәлинкә аш ашаганчы җан дус булып киттеләр, уртак тел таптылар. Аш тәлинкәләрен җыеп алганда яшь хатын инде алдына алъяпкыч бәйләп Гафифә җиңгигә эшләшеп йөри иде. Фәхрислам да бу мәҗлестән канәгать, бик канәгать иде.

...Тик Хәбиб кенә кайтмады. Югыйсә, гармун белән утырырга иде бер. Авыл көенә рәхәтләнеп бер җырласын иде Хәбиб. Кызларга да күңелле булыр иде. Кайтмады...

Ләкин... дөнья бу. Хәбиб нәкъ шул сәгатьтә, нәкъ шул минутта җырлап утыра иде.

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Чүп үләне белән бута-дым...

И, булса була бәгыреңне телгәли торган көйләр. Моны иҗат иткән кешенең эче тулы моңдыр, сагыштыр, музыкадыр. Хәбибнең елыйсы килә. Юк, бу көйне ялгыз гына, теләсә кайда җырлап әрәм итәргә ярамый. Моны зур симфоник оркестр башкарырга тиеш. Кайчан, кайда? Мәсәлән, моны Тугызынчы май көнне — Хәбибләр буынының изге бәйрәме көнне, җиңүчеләр, тол хатыннар, Хәбиб кебек солдат уллары, кызлары, ятим карчыклар, аяксыз-кулсыз инвалидлар, сугыш ветераннарының изге бәйрәме көнне бөтен планетага эфирдан тапшырырга кирәк. Сүзсез генә. Чөнки сүзләре — гадәти. Ә моңы! Бу моңны космодромнан адәм баласы бөек батырлык эшләргә күккә күтәрелгәндә, бөек солдат — Ватан сугышы герое, полководецка җитмеш, сиксән тулган көндә, республиканың авыл хуҗалыгы алдынгыларын көзге эшләр тәмамлангач опера һәм балет театрына җыйганда уйнарга кирәк. Бу көйне вак-төяк урында әрәм итәргә ярамый. Мәҗлестә җырлар өчен башка көй дә бетмәгән. Бу көй, нигәдер, Хәбибкә әнисен искә төшерә. Менә шул көй моңы астында анның әнисе үзгәрә: битендәге җыерчыклары бетә, өстендәге тупас күк халат урынына аксыл-зәңгәр газ сыман киемнәр барлыкка килә, әнисе тавык фермасына бара торган әрекмәнле сукмактан салмак кына аерыла да, акрын гына югарыга күтәрелә. Күтәрелә, күтәрелә дә болытларга аша, ә эфирда музыка тирбәлә:

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына...

Хәбиб күзен ача. Ачса — ресторанның зур залы икән. Ачса — бу залда танышлар, таныш булмаганнар ризык-нигъмәтләр, эчемлекләр янында утыралар икән. Түрдә Хәбибләр кафедрасының бер егете икән.

Ә, әйе, бүген ул диссертация яклаган иде. Шул уңай белән утыз-кырыклап кунак җыелган икән. Әнә түрдә диссертант утыра, ул ябыгып, кечерәеп калган. Арыган, йончыган. Мөгаен, ул «Мәк чәчәге»нә хисләнмидер. Мөгаен, ул исәпләп утыра торгандыр: кырык кешегә уртача унар сумнан — дүрт йөз сум. Уникеләргә хәтле утырылса, димәк, официанткаларга, вахтерга, поварларга — һәр кайсына өстәмә рәвештә бишәр сум. Барлыгы дүрт йөз илле сум. Ә агай-эне шәп утыра. Барысына да күңелле. Тәк... Дүрт йөз илле сумның дүрт йөзен җизни түләсә, (җизни авылда колхоз экономисты, байлыгы зур, хатыны юаш, алар төп кредиторлар сыйфатында диссертантның уң ягында нык кыяфәт белән утыралар), илле сумын үз кесәмнән чыгарсам. Аннан бер биш ел эчендә җизни белән исәп-хисапны өзеп булса... Фу, шайтан, күңелсез уйлар...

Мондый уйлар бер Хәбибтә дә анда гына... Хәбибнең иртәдән бирле кәефе юк бүген. Кичә ул өендә кечкенә генә бунт күтәреп карады: авылга, әни янына, каз өмәсе уздырырга кайтам, диде. Атнаның бу яртысында лекцияләре дә юк иде. Әмма кандидатлык диссертациясе яклау хатының белән бәхәскә керү белән чагыштырганда бик кечкенә булып кала. Хатыны дулады: кешедән минем кай җирем ким, диде, ни өчен әнә фәләневнең хатыны банкетка барасы бар дип парикмахерскаяга торып йөгерде дә, ни өчен мин өйдә хезмәтче хатын булып ятарга тиеш? Эшемдә әле дә миннән көләләр: үзең доцент хатыны, үзеңнең нибары бер генә алтын балдагың бар. Үзең доцент хатыны, ә үзеңнең кримплен күлмәгең дә юк. Үзең доцент хатыны, үзең чәчеңне айга бер ясатсаң ясатасың, ясатмасаң юк. Үзең...

Хатын иртүк торып парикмахерскаяга йөгерде, Хәбиб исә шәһәргә чыгып китте. Кызык дөнья! Кем яклый? Нинди темага? Яклый алырмы? Темасы авырмы? Кирәклеме? Банкет уздырырлык акчаны каян ала? Ник кенә бер шундый сорау бирелсен. Хәер, сораулар бирелде бирелүен: сәгать ничәдә? Кайсы ресторанга? Фәләневләр, фәләневләр буламы? Алайса, фәләневнең хатыны теге күлмәген киеп тагын кан катырып утырыр инде, тозсыз... Алайса, фәләневнең хатыны авызын җәеп тагын бер җырлар инде...

Хәбиб кырпак төшкән коры, салкын урамнардан җәяү барды. Мондый көнне авылда шәптер! Колхозда инде эш беткәндер, терлек абзарыннан һавага җылы пар күтәреләдер, колхоз идарәсендә экономистлар, бухгалтерлар еллык исәп-хисапны чыгаралардыр, культура йортына күчмә театр, филармония килә торгандыр, әллә ниткән кызыклы кичәләр була торгандыр...

Хәбибнең күңеле тулды. Авылның иң матур вакыты — яз, имеш. Авылның иң матур чагы — җәй, имеш. Юк, алай түгел. Дөрес түгел. Менә аның иң матур чагы — көзен кырпак төшкән чак. Бу көннәрдә авыл бер яшькә картая. Яз буе, җәй буе ашыгып-ашыгып яши дә авыл, менә шушы октябрь ахырларында картларча тынып кала, уйчанлана. Әнә шул көннәрдә ул үзенең гомеренә бер яшьне өстәп куя. Ләкин иң күңеллесе — менә хәзер. Үләннәр аксыл бриллиант белән капланган, урманнар күкселләнгән, агач түбәләренә бозлы сары яфрак түшәлгән, кояш моңсу гына җылыта, сөрелгән җир өстендә бәрәңге сабагы гына калган, бөтен табигать акыл иясе, философка әйләнгән. Бу Ленар нинди бәхетле! Әнә шул матурлыкның бөтенесе — аныкы. Марат та ярты гомерен авылда уздыра. Аның эш көйле — семьясы юк. Ә менә Хәбибнең кәефе иртәдән үк начар булды бүген. Ул коры салкын урамнарда җәяү йөрде. Николай Ершов һәйкәле янында туктап торды. Революционер, үз гомерен Хәбибләр бәхете өчен биргән бу яшь-яшь егет ил язмышы хәл ителгән көннәрдә урам сугышларында баһадирларча көрәшеп гомерен биргән. Хәбиб өч бүлмәле иркен квартирада яшәсен өчен, аның хатыны иртән парикмахерскаяга йөгереп чибәрләнеп кайт-

сын өчен, бүгенге өстәлләрдә ризык мул булсын өчен яшьли көрәш утына ташланган, моңа аны намусы, вөҗданы этәргән. Хәзер ул, әй, син, Мәтәли оныгы Хәбиб, безнең кебек бөек идеаллар белән яшисеңме, көрәш утында янасыңмы, дип сорый сыман. Әллә син тук тормыш эчендә мещанлык сазлыгына баттыңмы, тыныч обыватель буларак гомер черетәсеңме? Безнең йөрәкләрнең ялкыны синдә бармы, ул ялкын дөрлиме дип әйтә сыман.

Әле генә ЗАГСтан чыккан яшьләр Муса Җәлил һәйкәле янында рәсемгә төшәләр. Кәләш ак күлмәктән, ак фатадан, егет кара костюмнан, муенына «күбәләк» таккан, кулларында чәчәкләр. Дус-ишләре читтә аларның пальтоларын тотып тора. Яшьләр үзләренең семья тормышын Муса һәйкәле яныннан башлыйлар. Сез аңлап, барысын да аңлап басып торасызмы анда? Сез беләсезме, бу бөркет тә сезнең кебек шулай бәхетле булырга, якты урамнарда кояш астында яшәргә хыялланган иде? Ул да сезнең кебек яшь иде бит! Сез беләсезме, Муса адәм балаларының бик сирәгенә генә туры килә торган авыр, сынаулы язмышка очрады. Сез беләсезме, аның геройлыгы секунд яки минут эше түгел, ә айлар, еллар буе әзерләнгән аңлы батырлык иде. Чәнечкеле тимер чыбыкларны өзгәләп күккә ашкан бу егетнең безнең барыбызның да бәхетендә өлеше бар икәнен беләсезме?

Диссертация яклау башланганчы Хәбиб әнә шулай урамда йөрде. Аннары... Аннары диссертантны котладылар, аның дус-ишләреннән берсе уч төбе хәтле генә кәгазь өләшеп йөрде. «Хөрмәтле дус! Сезне, фәлән ханым белән икегезне, бүген кич фәлән ресторанда булачак чәй мәҗлесенә чакырабыз». Чәй мәҗлесе... Моны яратучылар байтак. Гыйльми совет әгъзаларыннан бик күбесе моңа йөрми, аларның моңа вакытлары юк. Кәгазьне алалар, рәхмәт әйтәләр дә өйләренә кайтып китәләр. Ләкин банкет дигән мәҗлеснең даими халкы, яратучылары була. Болар — гадәттә, искереп беткән профессорлар, искереп беткән доцентлар. Боларның тостлар, дежур анекдотлар, дежур комплиментлар әзер. Әнә өстәлнең ишеккә караган башында түбәдән чәче коелган соры костюмлы доцент утыра. Бу — бер банкетны да калдырмый. Күп сөйләшми, тост әйтми. Әмма бер яман гадәте бар: банкетка килеп керүгә иске күн портфелен ача да өстәлдәге берәр шешәне шунда шудыра. Өстәлдә җитмәсә, аның чарасын барыбер күрәләр ич. Әнә тагын берсе, анысының һәр вакыт ботинка үкчәләре кыеклап ашалган булыр. Бер банкетны да калдырмый, әмма грамм да эчми. Нарзан гына сорап утыра. Менә тәртип буенча тостлар китте. Болар инде күп ишетелгән, искергән кушы, төче җөмләләр. Башта «ихтирамга лаек, иң зур галим, остаз, аксакал оппонент исәнлеге өчен». Аннан шулай ук «иң мәшһүр галим, кешегә ярдәмчел, фәннең флагманы, яшьләрне үстерүче, хезмәтләре (мәсәлән, бер мәкаләсенең аннотациясе) хәтта чит илләрдә дә мәгълүм булган галим, остаз, аксакал, балалар атасы, үз хатынының менә дигән ире — икенче оппонент саулыгы өчен». Аннан — яшь булса да зур кыюлык белән гыйлемнең олы юлына атлаган диссертант саулыгы өчен. Аннан «бу диссертацияне язуда ул ялгыз булмаган. Аның янында һәр вакыт, иң авыр минутларда да аңа терәк булган, бу эшкә аны рухландырган, көч-куәт биргән, яшь, принцесса кебек гүзәл, матурлыгы белән шәһәрдә дан алган ханым истәлеге өчен». (Бу тостны әйткәндә әлеге ханым боларның барысына да ышана, тик ире генә тормышның әллә ниткән ямьсез бер моментын хәтерләп ала: «Бетмәде инде шушы диссертация дигәнең дә! Гомеремне череттең инде! Ичмаса, кеше ирләре төсле заводка кереп эшләсәң, аена ике йөз тәңкә акча кереп барыр иде!»)

Алдагы тост — түрдә әдәп белән генә утырган, пенсиягә чыкмыйча иза чиктергән бер кафедра мөдире исәнлеге өчен. Чөнки ул әлеге дис-

сертацияне яклаганда матур чыгыш ясаган. Диссертант мәҗлескә аны алып килүгә бик ялынып кына ирешә алган, әнә ул галим елмаеп кына әдәп саклап утыра.

Менә түрдә утыручылар арасыннан берсе сүз алды. Күптәнге, шомарган галим. Тел галиме. Кызган.

— Мин дәген сезнең каршыгызда берничә фикер әйтмәкче булам әле. Кушылырсыгызмы-юкмы, бусысы үзегезнең эшегез: шулай да кайбер замечаниеләр ясыйсым килә. (Галим ялтыраган башын өстәлдәге салфетка белән сөртеп алды.) Менәтерәк, тел галимнәре арасында Алтай теориясе һәм угро-фин теориясе яши. Менә мин үзем Ашхабадта конференциядә вакытта...

Чәч ясаткан, кримплен күлмәк, алтын йөзек кигән кырык яшьлек доцент хатыннарының, әлбәттә, боларны тыңлыйсы килмәде, музыка башланды. Һәркем үз хатынына гадәттән тыш нәзакәт белән карады. Болконскийларча гына сак хәрәкәт белән һәркем бары тик үз хатынын гына танцыга чакырды. Хәбиб тә шулай эшләде. Бигрәк, бу — абруй эше, кеше алдында үз семьяңның бөтенлеген, бәхетлелеген демонстрацияләү эше иде.

Елмаеп кына бисең, ә күңелне төрле уйлар били. Фән өчен иң куркыныч кеше — искергән галим. Искергән доцент, тагы да хәтәррәге — искергән профессор. Юк, физик картайган мәгънәсендә түгел. Була шундыйлар — институт этажларыннан чак-чак менәләр, этаж араларындагы белдерүләрне озаклап укыган булалар, витриналарны карап торалар — бу инде уку да, карау да түгел, бу — тын беткәнне кешегә сиздермәс өчен. Этаж араларындагы витриналар бик файдалы. Әмма үз этажына менеп җиткәч, ул галим яшәрә дә кала, үзенең авыруы турында беркемгә берни әйтми, андый галим тирәсендә яшьләр бөтерелеп йөри, ул галим эчкерсез ихтирам белән чолганып яши.

Була шундыйлар, әле ул үзе алтмышта гына, әмма июнь аеның эссе бер көнендә, студенткалар инде тән мәйданының өчтән бер өлешен генә күлмәк белән каплап йөргән, чәчәкләр, дипломнар, обходный листлар, пляжлар заманында — әнә шул галим коридорда күренә, үзе белән ул котып салкынлыгы алып килә. Менә ул кабинетына кереп утыра, өстәл астыннан аның микропор аслы калын ботинкасы, чалбар балагы эченнән ак җылы ыштан балаклары күренә... Юк, билләһи, юк! Бу кеше яшьләргә дә, фәнгә дә җитәкче була алмый, чөнки бу инде, хәтта үз гәүдәсенең дә, үз тормышының да хуҗасы, җитәкчесе түгел. Ә фән үсеш-яшьлекне сөя, яшьләрне ярата. Шулардан башка тәрәккый, хәят юк, булуы да мөмкин түгел. Андый искергән кеше яшьләргә ярдәм итми генә түгел, ул үзе алардан көнләшә, аяк чала, ваклана.

Маратның бер очрашканда Хәбибкә сөйләгәне бар. Диссертациясен яклар алдыннан Маратка берәү әйткән:

— Син, энекәш, — дигән, — бу арада бераз гына гадирәк киенеп йөр.

Тегесе аңламаган.

— Ни өчен? Нигә?

— Аның хикмәте бар,— дигән теге галим.— Синең җитәкчең,— дигән,— яшьләрдән көнләшә торган кеше, шуңа күрә яклаулар узганчы бу финский костюмыңны да, югославский плащыңны да, ленинградский баш киемеңне дә кимичәрәк тор. Беткәнмени сиңа суконный базар киоскыларында бәясе төшерелгән пиджаклар?..

Әйе, галим — бөек җанлы, гуманлы булырга тиеш. Марат шул вакытта сөйләп утырган иде: шундый үлчәгеч прибор булсын иде, дигән иде ул, фән юлына керергә теләүчедән кан анализы алгандай анализ

аласың. Була бит әле врачлар кулында кәгазь: лейкоцитлар, РОЭ, гемоглобин. Менә фәнгә кергәндә дә өч анализ ясатырга иде. 1) Талант; 2) кешедән көнләшмәү; 3) башка галимнең уңышына шатлана белү. Менә шул шартларның берсе туры килмәсә дә, ул кешене фән дөньясына аяк бастырмаска...

Ләкин Марат үзе, ни өчендер, институттан китте. Районда аны райбашкарма комитеты председателенең урынбасары итеп сайладылар. Хәзер ул — район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы. Үз кулында агрономнар, зоотехниклар группасы, баш архитектор-инженер, энтомолог бар. Нигә районга китте икән ул? Хәсбиев аркасында түгелдер бит? Имеш, борынгы акыл ияләреннән берәү әйткән ди: «Начар галимнәр сугару каналына төшкән таш кебек: суны үзе дә сеңдерми, кырга да җибәрми». Әйе, фән өчен иң куркынычы — иске галим.

Егетләр, кызлар барысы да бер төсле аттестат алып урта мәктәп тәмамлыйлар. Ул вакытта алар арасында аерма зур булмый. Әмма фән юлына кереп киткәч, алар арасында аерма бик зурая. Берәү яңа сорт бодай чыгара, икенче берәү океан төбеннән яңа нефть ятмалары таба, өченче берәү шул ятмаларның запасын билгели, прогноз төзи, дүртенче берәү Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәренең сюжет үзенчәлеген тикшерә... Карыйсың, болар яңадан тигезләшәләр: барысының да кулында бер үк төсле диплом катыргылары. Барысы да фән кандидатлары...

Шуларны уйлап биегән кешедән нинди мәгънә бар инде? Музыка туктаган икән, Хәбиб әле һаман да әйләнмәкче. Тик аның һәр вакыт аек, бөек практик хатыны гына бу халәттән чыгарды. Банкетның икенче өлеше башланган икән. Диссертантны «адаштыру процессы» башланды. Ул процесс, гадәттә, банкетның икенче өлешендә була. Монда инде кәефләр хушланган, банкетта катнашучылар белән мөнәсәбәтләр ачыкланган була. «Адаштыру процессы»н, гадәттә, искергән галимнәр башлый. Алар диссертантны «олы юлга» чыгуы белән котлыйлар, андый шәп диссертациянең моңарчы әле булмавы турында кат-кат искәртәләр. Ахыр чиктә бичара диссертант моңа ышана. Хәбибнең тәҗрибә зур: аның мәҗлесендә дә шулай дигәннәр иде. Банкетның иртәгесен Хәбиб юри урамга чыгып йөрде. Кичә сөйләнгән сүзләр чын булса, бүген урамда халык бары тик Хәбибнең диссертациясе турында гына сөйләргә тиеш иде. Хәбиб күп кибетләргә кереп йөрде, трамвай тукталышларында басып торды. Бөтен темага сөйләшәләр: кичәге хоккей, Киссинджерның Токиога килүе, кримплен, рижский гарнитур турында... Әмма Хәбиб турында ләм-мим. Дөнья бу. Объектив нәрсә ул тормыш. Хәбиб беренче китабы чыккач та шулай җир шары бермәлгә әйләнүдән туктап калыр дип хыяллана язган иде. Әйе... Беренче китап. Башта Хәбиб аны укып ятты. Беренче биттән соңгысына кадәр укыды да, аннан кире якка. Аннан битенә куеп ятты. Беренче китапның буявы исе! Андый исерткеч дөньяда юк! Имеш, бик шәп кальвадослар, джиннар, вискилар, «Камю»лар була! Юк, беренче китаптан килгән типография буявының исе янында болар буш сүзләр генә! Бераздан Хәбиб, утын сүндереп, ул китапны мендәр астына тыкты да йокыга талды. Талды... Әйтергә генә ансат! Йокларсың бар! Төнөнә әллә ничә мәртәбә ул аны мендәр астыннан тартып чыгарды, сыпырды, китап кәгазенең җанга рәхәт бирә торган кыштырдавын ишетте...

Иртәгесен ул тагын шулай халык күп булган урыннарда йөрде. Юк, юк... Ә бит анда да Хәбибне әлеге тамада-галим саташтырган иде.

— Синең, — диде, — бу китабың тюркологиядә зур ачыш. Моның турында Мәскәүдә генә түгел, чит илләрдә язып чыгачаклар. Америкада!

Хәбиб әнә шунда саташып калган иде. Ләкин айныды. Дөнья айнытты. Тормыш үзе, гомумән, тәрбияче бит. Хыяллан, ләкин чама белән генә, дип тормыш адәм баласына гел тукып тора. Ә яклау көнне? Телестудиядән килеп Хәбибнең дус егете рәсемнәр төшереп киткән иде. Алдагы җомгада «Кичке Казан» программасында бирәбез, диде. Җомга көнне бөтен эшләрен ташлап, хатыны белән «Кичке Казан»ны карадылар. Креслоларын рәттән куеп, журнал өстәленә хәтта бер шешә «Твиши» куеп.

— Менә! Менә! Хәзер, — ди-ди дулкынланды Хәбиб.

— Әнә! Әнә! Хәзер, — ди-ди каушады аның хатыны. Ул хәтта кайнар учы белән Хәбибнең кытыршы яңагыннан сыпырып алды. Яратып. Булачак моментның рәхәтен алдан тоеп.

Әмма... Тормыш кайвакытта рәхимсез... «Кичке Казан» программасы бетте, диктор егет хисләнеп Казанкада бозның калынлыгын, Минзәләдә һава басымын, Казанның Вахитов районында чагыштырмача дымлылык процентларын сөйли иде — программа бетеп маташа икән... Хәбиб белән хатыны, бер-берсенә карарга оялып, «Кара йөзләр» повестендагы Закир белән Галимә сыман утыралар иде. Алай гынамы? Хәбибнең хатыны шул айда гына тагын бер тилпенеп алды: Сигезенче мартка аның исеменә рәхмәт белдереләсе икән, исемлеккә тәкъдим ителгән дип сөйләгәннәр иде. Март кичәсе өчен ул махсус күлмәк тектерде, ул кичә алдыннан ике-өч көн Хәбиб белән хәтта рәтләп сөйләшә дә алмады, дулкынланды. Ул көнне иртән сәгать биштә парикмахерскаяга чират алды, катып бетте... Ә приказ укыганда аның исеме чыкмады. Шунда ул өенә кайткач кухнясына узды да, ишеген япты һәм... ирләрчә явыз, әшәке итеп татарча бер сүгенде. Ә нинди семьядан! Кайда, каян ишеткән ул мондый сүзләрне. Ул бит әле юньләп татарча да белми. Хәер, болар барысы да файдага китте. Хәзер алар — аеклар. Аларны алдый алмассың. Әнә шуңа күрә алар бик тигез ритм белән икәүләп тыныч кына җырлап утыралар.

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына...

*Ахыры киләсе санда.*

## Фәнис Яруллин

### Замана портреты

Зур адымлы, киң җилкәле,
Көр күңелле замана —
Ияртеп безне артыннан
Ашкынып алга бара.

Туктамый үрләр күреп тә,
Туктамый чүлләр күреп.
Ул бара үле җирләргә
Җан өреп, гөлләр сибеп.

Ул бара дошманын җиңгән
Әкият батыры кебек:
Җанында аның — олылык,
Күңеле тулы — көрлек.

Гел биеккә, гел матурга
Илтә аның юллары:
Бер кулында Кояш аның,
Бер кулында Җир шары.

### Яшьлектә

Урманнарга кереп бер кычкырдым,
Түзә алмый йөрәк ярсуга.
Кәләш кебек көяз ак каеннар
Баш ияр күк иде барсы да.

Җавап көттем каеннарга карап,
Горур башым тотып югары.
Ә тавышым яфракларга бәрелеп,
Ешкынга ук кереп югалды.

Аваз салдым тагы да ярсыбрак:
— Ишетегез, таулар, үзәннәр.
Бүлешергә минем хисләремне
Ашыгыгыз, сылу, гүзәлләр!..

Ак каеннар, гүзәл ак каеннар
Көлде шунда карап күземә.
Кабул ителмәгән гыйшкым кебек
Тавышым гына кайтты үземә.

## Диңгез

Җанымны тетрәттең, диңгез,
Күрдем дә калдым телсез:
Кара инде, моңа кадәр
Ничек торганмын синсез.

Мин сиңа кирәкме? Белмим.
Син миңа кирәк икән.
Син диңгез генә дә түгел,
Син олы йөрәк икән.

Ярсыйсың, хисләнәсең дә,
Буласың дулкын-дулкын.
Арыйсың, сүреләсең дә
Каласың тагын тып-тын.

Дәһшәтле дә, шәфкатьле дә,
Моңсу да, ягымлы да.
Мин әле аңлап бетмәдем
Синең бар ягыңны да.

Сөйләмәде дулкыннарың
Төптә ниләр барлыгын.
Ә бит синең өстә түгел,
Бик тирәндә байлыгың.

Ярый инде, үпкәләмим,
Серле булып гел яшә:
Иксез-чиксез диңгезгә дә
Тыйнак булу килешә.

## Учак

Гомер учагында көннәр яна,
Күккә үрли ялкын телләре.
Сүндерергә теләп ялкыннарын
Елый-елый исә җилләре.

Чыга давыл, куба зилзиләләр,
Бозлы тамчы коела көзләрен.
Учак һаман өскә үрелеп карый,
Челт-челт йомып елтыр күзләрен.

Кайчагында арыган юлчы-мазар
Ял итәргә монда туктала, —
Кирәк икән җылына таңга кадәр,
Кирәк икән үзенә ут ала.

Ә берәүләр үзе җылынгачтын
Таптый аны, изә — түз генә.
Андый чакта үләннәргә посып
Калса кала күмер — куз гына.

...Көннәремне ягам җәлләмичә,
Кимемәсен аның ялкыны.
Шул учакның яктылыгы бәлки
Күренер әле еллар аркылы.

## Ак чәчәк

*Нурсөягә*

Син гөлләр булсаң әгәр дә,
Ак чәчәк атар идең.

**Х. Туфан**

Күңелең — ак чәчәкле болын,
Мин җыям чәчәкләрен —
Сайлап кына, җайлап кына
Иң матур, иң шәпләрен, —
Күңелең чәчәкләрен.

Атлый барам, якынаям
Болыннарың түренә.
Барган саен ак чәчәкләр
Күбрәк булып күренә
Күңелләрең түрендә.

Әйтче, әгәр сер булмаса,
Әйтче шуны, чибәрем:
Ак чәчәкле болыннарга
Нигә мине җибәрдең?
Әйтче шуны, чибәрем.

Ярый да, мин болыннарда
Бер кош булсам, тынмасам.
Сары күбәләкләр булып
Ак чәчәккә кунмасам,
Син сыгылып сынмасаң.

## Сагышларым

Сагышларым бирдем җилләргә,
Алып кит дип ерак илләргә —
Канатлары җилнең сыгылды,
Сагышларым җиргә
Таралашып җилдә
Сары чәчәк булып коелды.

Сагышларым салдым суларга,
Адашсын дип ерак юлларда —
Елга туктап калды ярсудан.
Сагышларым бар да
Утырып калды ярда
Ташулардан калган боз сыман.

Сагышларым аттым яшенгә,
Яндыр дидем, җиргә төшермә.
Яшен сүнде күкләр йөзендә —
Синнән башка беркем
Күтәрә алмый диеп,
Сагышларым кайтты үземә.

## Марсель Галиев

# КҮҢЕЛЕҢӘ ҮЗЕҢ ШАҺИТ

хикәя



Тын инештә — пар ат шәүләсе. Яллары суда салмак кына агып барган ак болытларга тигән. Атлар, иртәнге табигатькә матурлык өстәп, бербересенең муенына сарылып иркәләнәләр. Су буйларын калын тавыш яңгыратып узды:

— Чакматай!

Тауларга бәрелә-сугыла тирбәлгән кайтавазга хуҗасын искәреп алган атның дәртле кешнәве килеп кушылды. Атка никадәр якын бу исемне әйтүче калын тавыш. Менә ничә еллар инде ишетә килә ул аны: «Чакматай».

Зур яшьтә булганы өчен түгел, ә калын җилкәле, озын буйлы, көчле булганы өчен Өлкән Сәгыйрь дип йөртәләр Чакматайның хуҗасын. Аның кыргый таштан кыеп ясалган шикелле тупас йөз рәвеше, эчке бер көч тантанасын чагылдырып, ирләрчә матурлык биреп, гәүдә төзелешенә чат килешеп тора. Салынып торган куе каш күләгәсеннән төбәлгән күзләре түбә астында утырган карлыгачлар кебек җитез, хәрәкәтчән, ә текәлебрәк карасаң, аларда нииндидер моңсулык күрәсең...

Өлкән Сагыйрь вак адымнар белән юырттырып килеп җиткән атның бөдрә ялын икенче якка авыштырып куюга, атның тәне буйлап рәхәт бер дулкын йөгереп үтте. Өлкән Сәгыйрь ямьшәйгән эшләпәсен салып ат сыртына куйды да тир бөртекләре җемелдәп торган такыр башын сөртте. «Картая, картая»,— дип уйлады ул Чакматайга карап.— Бүген сабан туенда чабышка бармасын сизә микән?.. Син миңа үпкәләмә инде, малкай... Беренче килә алмады, димәсеннәр. Сизәм бит, алдыралмаячаксың быел. Җиңелмичә кит син бәйгедән».

Өлкән Сагыйрь тыштан караганда караңгы чырайлы, төмсә күренсә дә, аның эчке табигатендә беркатлы самимилек ята. Мал-туарны яратуы да бәлки аның шул табигатенә бәйледер. Ничә еллар инде ат караучы булып эшләү дәверендә алар телен ул күзләреннән укып белә. Атка авызлык кидерми. Нинди кулга эләккәнен дилбегә кагышыннан ук сизмимени ат дигәнең...

Өлкән Сәгыйрь атын ипләп кенә йөгәнләде дә аңа үзенә генә хас осталык белән сикереп атланды. Бүген сабан туена Чакматайны ул үзе алып бара. Нәкъ көрәшкә чыккандагыча: бераз кыршылган чалбарын, терсәк турылары сыпыла башлаган күлмәген кигән.

Бәйрәмчә киенгән халык — мотоциклысы, машинасы, җәяүлесе — бөтенесе бер якка — атауга, Эстәрле буасы буена агыла. Арадан кайберләре Өлкән Сәгыйрьгә сүз кушып кала:

— Чакматайны быел чабышка җибәрмисеңмени?

Өлкән Сәгыйрь мыгырданып кына үтеп китә. «Үзем турында сорамыйлар. Көрәшмәс дип уйлыйлар, ахры. Илле яшь чикмени әле ул, җенен чыгарып көрәшәм әле мин... Карап карарбыз менә...»

Малае Шаһинур, хәрби хезмәт срогын тутырып, әле кичә генә кайтып төште аның.

Өлкән Сәгыйрь ишегалды себереп йөри иде. Күрше хатын урам як коймасыннан үрелеп карады да, мәгънәле генә итеп:

— Сәгыйрь, малаең кайткан бит,— диде.

Өлкән Сәгыйрь сискәнеп китте. Кайтарып бер сүз дә дәшмәде. Себеркесен баскыч култыксасына сөяде дә өенә кереп китте. Өй эче аңа бу минутта аерата шыксыз булып күренде. Кием шкафыннан ул яхшыга кия торган күлмәген, костюм-чалбарын алып киде. Костюмының эчке кесәсенә бер шешә «әчкелтем» шудырды да, ишеген дә бикләп тормыйча, урамга чыкты. Кайткан, дип уйлады Өлкән Сәгыйрь. Бер килергә тиеш иде инде бу көн. Әгәр, кодрәтеннән килсә, бу көнне бераз кичектереп тә торыр иде ул. Көтү, күрешүне өмет иткән билгесез уйлар ләззәтеннән нәүмиз булмас өчен кичектерер иде.

«Җитте, бүген үк күзгә-күз карап сөйләшергә кирәк,— диде Өлкән Сәгыйрь үз-үзенә.— Ирләрчә аңлашырга вакыт җиткәндер... Ә ул аңлармы соң? Әти дип эндәшерме? Хәер, миңа барыбер түгелмени. Яшәлгән кадәр яшәлмәс... Язмыш һәр вакыт уңайга гына сыйпап тормый...»

Тыкрык буендагы ихатаның җил капкасын ачып, Өлкән Сәгыйрь бермәлгә тукталып калды. Чирәмле ишегалдында аналы-уллы икәү: ак сөлгесен иңенә салган Һәдия һәм билдән чишенеп ташлаган, иелә төшеп юынып торган улы Шаһинур. Капка тавышына икесе дә борылып карадылар. Шаһинур тураеп басты, әнисенең иңеннән сөлгене алды да кулларын сөртә башлады. Өлкән Сәгыйрь нәкъ үзенә охшап үскән, ирләрчә төс кергән улына таба түгел, гүя үткәненә, үзенең яшьлегенә таба атлый иде. Аның якын итеп, үз итеп эндәшәсе, улын кочаклап аласы килде. Әмма тыелып калды. Үсеп җиткәнче улы аңа беркайчан да «әти» дип әйтмәде, хәрби хезмәткә киткәндә дә Өлкән Сәгыйрь белән хушлашмыйча гына китеп барды. Шуннан туган рәнҗү, еллар буена сакланып, Өлкән Сәгыйрьнең бәгырен тырный, сызландыра иде. Кайту хәбәрен ишетүгә, алдын-артын уйлап тормастан, аның янына килеп җитте. «Ата итсә, үзе килеп күренсен иде». Ләкин капканы ябып кире борылырга соң иде инде.

Улының «әти» сүзен читләтеп кенә исәнләшүеннән йөрәге тырналып куйса да, улының кызара төшеп күзләрен читкә яшерүеннән ата күңелендә нindидер өмет уянды.

Өйгә керделәр. Өстәлдә, ашыгыч кына әзерләнгән нигъмәтләр арасына чыгып утырган теге әчкелтем «шайтан суы» гына әңгәмә сүрешен бер җепкә бәйли алмады.

Улының кайту шатлыгын күңеленә сыйдырып һәм моңа әле ышанып та бетә алмаган Һәдия, күбрәк табындагы ризыкларны искәртеп, кыстау белән мавыкты.

Бераздан Шаһинур, өстәл янынннан торып: «Авылны бер әйләнеп кайтыйм әле, унөч ел күрмәгән кебек булдым»,— дип чыгарга рөхсәт сорады. Һәдия сөенеч һәм соклану тулы күзләре белән улын озатып калды. Улы чыгып киткәч, Өлкән Сәгыйрь кечкенә рюмканы күтәреп куйды да бермәл чыраен сытып торды. Аның ишелеп төшкән кашлары, киерелгән канатлар кебек, кинәт өскә чөелделәр. Йөзе яктырып китте.

— Коеп куйган мин бит, билләһи! Күзләре генә синеке, Һәдия.

Күңеленнән уйларын барлагандай сүзсез генә утырганнан соң, Һәдия:

— Ниһаять, кайтты,— диде.— Әле ярый, моңарчы син булдың. Бу хуҗалыкны ничек тернәкләндермәк кирәк. Ир-атсыз йорт — терәксез йорт дигәннәр бит.

— Үссен, бер аңлашырбыз, дигән идек...

Өлкән Сәгыйрьнең калын тавышы кунаклыйсы урынын эзләгән кош шикелле, тын бүлмәдә талпынып торды да, авырттырып, Һәдиянең күңеленә барып тиде. Шул авыртудан бушанырга теләгәндәй, Һәдия тирән итеп сулап куйды:

— Бала, бала дип, үзең турында онытасың икән шул. Аның өчен яшисең, ә ул үсеп җитә дә, үз көнен үзе күрә башлый. Бер хатында әйткән иде: — Әни, теге вакытлар өчен рәнҗемә инде, бергә торырга уйласагыз, бер каршылыгым да юк,— дип...

— Соң?

— Соң шул, Сәгыйрь. Ни аерым, ни бергә булмадык дигәндәй...

— Иртәгә үләргә җыенган кебек сөйләшмик әле. Гомер...

— Үтте инде.

— Картаймыйк ла ул хәтле, Һәдия! Бу куллар, бу беләкләр әле үз көчендә.— Өлкән Сәгыйрь, җыелган бөтен сагыш-исәбен сыгып чыгарырга теләгәндәй, йонлач учларын шытырдатып йомды.— Әнә, көзгегә кара, син дә бит әле кызларга алыштыргысыз.

Өлкән Сәгыйрьнең сүз иркенә бирелеп, Һәдия, үзе дә сизмәстән, стенадагы көзгегә ялт итеп карап алды. Моңсулык пәрдәсе аша, күзләрендә күптән сүнгән ялкынның кинәт кабынуыннан бит очларына кызыллык сирпелде. Ләкин бераздан яшьлек чалымнары яңадан сүреләсүрәнләнә төште.

— Юатышмыйк, Сәгыйрь.

— Ике йортны бер итеп йөрү туйдырды бит, Һәдия. Хатын-кыз җылысы булмагач, өйнең коты бармыни аның. Кайтып керәсе дә килми.

— Шаһинур кайтты дип, мин сиңа аркамны куймам. Йөрешербез. Хәлемнән килгәнчә ярдәмем булыр...

— Син һаман шулай дисең...

Өлкән Сәгыйрь ярты сүздә бүленеп калды. Бу турыда тел күтәрдеңме, Һәдиянең йөзенә күләгә төшә, кырыслана, өзеп кенә бер нәтиҗәгә дә килә алмый иде ул. «Бүген улы кайту шатлыгыннан тәэсирләнгән күңелен нигә дип кузгатам әле,— дип уйлап куйды Өлкән Сәгыйрь.— Моңарчы, дөньяның бирмешенә шөкер кылып, өметне алдагыга күчерә торып гомер кичерелгән бит. Алда көн бар. Чиялэнгән төенне капылт кына чишеп буламы...»

«Тәкъдир шулай язгандыр инде», дип уйлады Һәдия. Бүген аның иценнән ниндидер авыр йөк төшкәндәй булды. Ниһаять, улы үсеп җитте. Ул аның яшәү өмете дә, иң якын иптәше дә бит. Шуңа багышланган гомер агышын һич кенә дә үзгәртәсе килми иде ананың. Улы үсә барган саен Һәдия никахсыз ирен күңеленнән читкәрәк тибәрә килде. Яраттымы ул аны? Бу сорауга өздереп кенә җавап та бирә алмас иде. Шул ук вакытта Өлкән Сәгыйрьне янәшәсендә итеп тоймаса, дөньясының да бер ягы китек булыр сыман иде. Янә-

шәсендә... тик бергә түгел. Өлкән Сәгыйрьнең холкы ягыннан күндәм-юашлыгы Һәдияне бераз сәерсендерә һәм бер яктан ошый да кебек. Әмма каты холыклы, дуамалрак булса, Һәдия күптән инде аның теләгенә буйсыныр да иде... Хәер, алай булыр иде микән? Бергә тормауның сәбәбен кемдер каршында үзен аклау дип уйламый микән ул?..

Көн кичкә авышып бара. Тәрәзә төбендәге гөлләр кояш баешына таба борылганнар.

Өлкән Сәгыйрь өметсез сүлпәнлек белән өстәл яныннан торды да папирос кабызып бакчага чыкты. Алмагач төбендәге үзе ясаган урындыкка утырды. Гадәттә, аның усал йөзе, калын гәүдәсе күңелендәге самимилекне яшерә, кешегә белгертми тора иде. Артык нечкәреп киткән чакларында Өлкән Сәгыйрь ялгызы калырга тырыша, хисләренә иркенлек бирә иде.

Бөҗраланып күтәрелгән тәмәке төтене алмагач ботаклары арасыннан югарыга үрле дә таралып юкка чыга. Өлкән Сәгыйрь инде чәчәге коелып, төймәләнеп килгән алмаларга карады. Өстә, ике алмагач ботаклары бергә кушылган урында, бер үрмәкүч тигез, пөхтә итеп челтәр үрә иде. Нәни генә бөҗәкнең шулай матур итеп ятьмә коруы Өлкән Сәгыйрьнең ачуын кузгатты. Ул җирдә яткан таякны алды да, селтәнеп, нәфис ятьмәне сыдырып төшерде. Елкылдап торган пәрәвез җебе тоныкланып, сүнеп калды.

«Соң инде, Сәгыйрь»... Һәдиянең сүзе аның колак төбендә каткат яңгырагандай булды.

«Соң икәнен үзем дә беләм. Бер уйласаң, болай да мең шөкер. Хыянәт итмәдең. Ярдәмеңнән ташламадың. Бергә дә түгел, аерым да... Сүзләреңдә хаклык бар шул. Иңләнелгән ялгызлыкка да, тик... гомер ахырында дуадак каз шикелле калмаска иде. Бәхетсезлек чыккан йортка бәхет иңмәскә дигәндер инде»...

Ишегалдында йөргән Һәдиянең кызыл парчалы яулыгы бакча коймасы аша күренеп китте. Теге вакытта да яулыгын нәкъ шулай чөеп бәйләгән иде бит ул. Ә күзләре... Кайчан иде соң әле ул?..

Ярый әле, үткәнең бар. Хәтер сау. Үткәнеңә кайтып юанырга була.

Йөрәгенең еш-еш тибә башлавы аңа шул чакларның кайтавазын ишеттергәндәй булды.

...Даң! Даң! Даң!

Тимерчелектән яңгыраган бу гайрәтле аваз, сугыш бетүен, тыныч тормыш башлануын хәбәр иткәндәй, бөтен авылга таралды. Кайдадыр зур шәһәрләрдә фанфаралар уйнагандыр, куанычлы нотыклар сөйләнгәндер, тостлар күтәрелгәндер. Ә монда — Таллы Бүләк авылында — сугыш бетүгә гомум тантана тимерче сандалыннан яңгыраган аваз булды.

Даң! Даң! Даң!

Су буендагы таллар, бу хәбәрне алкышлагандай, каргалар көтүен дәррәү күккә чөйделәр. Алачыкка таба бала-чагалар, алар артыннан — олылар йөгереште.

Төтен белән ысланып, корымланып беткән алачыкның ике ишеге дә төбенә кадәр каерып ачылган. Эчтә ут яна. Сандал кырыенда — билдән чишенеп ташлаган, аякларын аерып баскан мәһабәт гәүдәле Өлкән Сәгыйрь. Алагаем селтәнә, авыр кувалда тимерне изә... Очкыннар чәчри... Яшәүне раслап, дәрт биреп, утлы аваз яңгырый.

Менә Өлкән Сәгыйрь ямкигә кыстырган тимерне сулы чиләккә батырды һәм аннары бу бөркеп инде зәңгәрләнә барган тимерне ишек төбенә алып ыргытты. Җыелган халык бердәм чигенеп куйды.

Өлкән Сәгыйрь, маңгаендагы тирен сөртә-сөртә, ишек төбенә чыгып басты. Европаны гизеп кайткан кырык бишле итек табаны ас-

тында тузанлы, иске күмерләр шыкырдап уалды. Кулына биниһая зур кувалда тоткан баһадир иргә карап торган халык, ниһаять, телгә килде.

Менә шунда инде Өлкән Сәгыйрь маңгаена төшереп чөелгән ак яулык астыннан яндырып караган ялкынлы күзләрне искәреп алды...

Өлкән Сәгыйрь үткән хатирәләр хозурында бакчадан чыкты да, өйгә кереп Һәдия белән саубуллашып та тормыйча, тыкрык буйлап су буена төшеп китте.

Кояш урман өстенә иңеп бара. Үзәндә — тышаулы атлар. Еракта-еракта менә-менә агып китәр төсле күренгән зәңгәр гөмбәзле таулар. Киңлек... Өлкән Сәгыйрьнең йөрәге кысылып куйды. Вакыт һәм чиксезлекне җанына сыйдыра алмау һәм гомернең чикләнгән икәнлеген белү тойгысыннан йөрәкнең көчсезләнеп үзен сиздерүе иде бу. «Үткән гомергә шушы тугайлар шаһит бит. Кемдер йөз, мең ел элек шушы тугайларга карап нәкъ минем төсле уйланып торгандыр». Күңелендә пыскып кына уяна барган сагышны яшисе килү, мәңге шулай дөньяның хуҗасы булу, сабыйларча гадел һәм акыл җитмәс табигатьнең аерылгысыз җаны булу теләге күмеп китте. Кешеләр ике канатлы, күрәсең: берсе белән ул үткәненә, икенчесе белән киләчәгенә таяна.

Тыелгысыз гайрәт, тыныч тормышта кинәнеп яшәү хисе белән ашкынып кайткан Өлкән Сәгыйрьне сугышка кадәр ике ел бергә торган хатыны вокзалда каршы ала алмады. Авыру хатынын ул район шифаханәсеннән ат белән үзе алып кайтты. Өлкән Сәгыйрь эчтән сүнеп өметсезләнеп калса да, тыштан берни дә сиздермәде. Элеккечә яши бирде, әмма тимерче алачыгы янында җанына ут салган әлеге ялкынлы кара күзләр аны алгысыта, яшерен өмет биреп яшәүгә өнди, ләззәтле газаплый иде.

Кайда да булса мәхәббәт, ярату кебек сүзләр ишетергә туры килсә, аның мәгънәсенә бары тик әнә шул ялкынлы кара күзләр аша гына төшенә иде Өлкән Сәгыйрь.

Күңелендә йөрткән яшерен тойгы шулай беркемгә дә ачылмыйча калыр да иде бәлки, әгәр очраклы бер хәл булмаса...

Ул чакта да нәкъ шушындый җәйге көн иде бугай. Өлкән Сәгыйрь ул вакытта бригадир булып эшли иде. Җигүдәге атлар һәм үгезләрнең көрәеп килгән чагы. Авыр елларда да үз көче саклап калынган айгырны җигеп, арбага тәпи баскан килеш кенә, Өлкән Сәгыйрьнең кырларны иңләп кайтып килеше иде.

Шулай урманга җитеп килгәндә, юл уртасында туктап калган җигүле үгезне, аның тирәсенә җыелган хатын-кызларны күреп, Өлкән Сәгыйрь дилбегәне кагыбрак куйды. Атны килгән шәпкә кырт кына туктатты да арбасыннан сикереп төште. Хатыннар аны шаулашып каршы алдылар.

— Сәгыйрь туган, җилкәң белән күтәреп булса да кузгат әле шушы чукынчыкны!

— Үгезләр көрәйдә хәзер, хатыннарга махы бирмиләр.

— Ир кешене тыңламасмы, ичмасам.

— Арагызда бер ир бар бит инде,— диде Өлкән Сәгыйрь, шарлатан Гыймай Заһитына ымлап.

— Чалбар киеп кенә ир булсаң икән ул...

Бусын Һәдия әйтте. Аның йөгерек карашы Өлкән Сәгыйрьнең җанын сыйпап үткәндәй булды.

Өлкән Сәгыйрь үгезнең сбруйларын, камыт бавын барлап чыкты.

— Я, утырышыгыз!— диде дә, сыдырырга ук ниятләп булса кирәк, чыбыркысын өскә күтәрде һәм... нидер уйлап, тыелып калды.

Чыбыркылауның ни файдасы булсын, үгез бер кирелэнсә, болай гына тыңлатырмын димә. Пошаманга калган Өлкән Сәгыйрьгә карап, хатын-кызларның да теләнә куәт килде.

— Әй, синнән дә булмады...

— Үзең җигелеп кайтырыең, ичмасам.

Болар алдында Өлкән Сәгыйрьнең үз горурлыгын җуясы килмәде. Келт итеп, кемнәндер ишеткән бер хәйлә исенә төште. «Болай кул кушырып торып булмый бит инде, сынап карарга кирәк», дип уйлады ул.

— Ашыкмагыз, хәзер,— диде дә, коры-сары җыеп, юл читендә бәләкәй генә учак тергезде. Аптырап калган хатыннар тынып калдылар, берничәсе арбадан ук сикереп төште.

Бераздан Өлкән Сәгыйрь Һадияне үз янына чакырып алды.

— Нәрсәгә тагын.

— Менә учакны сүндерә тор, аягыңда күн итек икән. Ә сез утыра башлагыз, — диде Өлкән Сәгыйрь, арба янәшәсендәге ике хатынга борылып. Ә үзе, таякның кисәүле башын уттан алды да йөгереп килеп үгезнең койрык астына тидереп алды.

— Нык тотыныгыз!!

Өлкән Сәгыйрь хәтта әйтеп өлгергәнче үк, үгез җир иңрәтеп дәррәү алдырып та китте. Хатыннарның чыр-чу килүе, көпчәкләр дыңгырдавы — барысы бергә кушылды.

Шул чак Өлкән Сәгыйрьнең үз аты да кузгалып китте. Борылып караса... Арбада Һадия, дилбегә кага-кага, атны куалапмы-куалый иде. Өлкән Сәгыйрь бермәлгә аптырап калды. «Шаяртумы, әллә чынлапмы?»

— Авызлыкламаган, дулатасың бит, юләр!

Өлкән Сәгыйрь шулай кычкырып олау артыннан йөгерә башлады.

Һадия, дилбегәне уңга тартып, атны авыл ягына борырга тели, әмма ат, аның саен тискәреләнеп, урманга таба чаба иде. Бераздан ул атны тыңлата алмасына ышанды һәм инде туктатырга да исәбе юк иде шикелле... Өлкән Сәгыйрь куып җитәм дигәндә генә Һадия дилбегәне бушатып ала, иркенлек тойган ат яңадан алдырып китә.

— Туктат дим, Һадия!

— Туктатты ди! — Һадиянең йөзе бер усаллана, Өлкән Сәгыйрьнең алпан-тилпән йөгерүен күреп бер көләчләнә иде.

— Бетәсең бит Һә...дия, ду...лый хә...зер.

Урман авызына килеп керүгә ат, сулгарак алдырып, юл читендәге каенга арбаның арт күчәрен ордырды да туктап калды. Янтая башлаган арбадан Һадия кычкырып сикереп төште. Бераздан мышнап Өлкән Сәгыйрь үзе дә килеп җитте. Юка күлмәгенең күкрәк турылары манма булып тәненә ябышкан. Өлкән Сәгыйрь кәпәчен салып арбага ыргытты да керпе энәсе кебек каты чәчләрен сыпырып куйды.

— Болай ук усалдырсың дип уйламаган идем.

— Нигә дип аерып калдырдың?.. Хатыннар нәрсәгә юрамас...

— Кем уйлаган аны чаптырып китәр дип.

— Уйламадың, имеш... Утлы кисәүдән үлгән үгезең дә сикереп торыр.

Өлкән Сәгыйрь арбаны, артын күтәреп, турылап куйды.

— Утыр, әйдә!

— Утырмыйм. Әзмәвер кебек адәм белән...

— Күтәреп утыртканны көтәсеңме әллә?

Һадия аңа сөзеп кенә карады да арба читенә килеп утырды.

— Кардон аша кайтырбыз. Яшелчә бакчасына сугыласым бар.

— Яңгыр яварга тора бит, — диде Һадия.

— Тоз түгел, эремәбез.

Урман эче сизелерлек караңгылана башлады. Каеннарның ябалдашларына тияр-тимәс күкле-яшелле болытлар кайнаша. Күңелгә шом салып, давыл кузгаткан яфраклар шикелле, каргалар көтүе очып узды. Берәм-сәрәм төшкән яңгыр тамчысыннан яфраклар шыбырдаша башлады.

— Кожан бар иде, каядыр, — дип, Өлкән Сәгыйрь печән астыннан изелеп беткән кожанын тартып чыгарды да, каккалап, шуны Һәдиянең иңенә япты. Кулы Һәдиянең ачык муенына, кайнар беләгенә кагылып китте. Һәдия кинәт читкә тартылды.

— Эчкәрәк менеп утыр, аякларыңны агачка сыдырттырырсың — диде өлкән Сәгыйрь йомшак кына.

Еракта күк күкрәде. Тонык гөрелте агач башларын тирбәтеп узды да урман киңлегендә йотылып калды. Кыюсыз гына башланган яңгыр шәбәеп, бөтен урманны оеткыч шауга күмде. Өлкән Сәгыйрь атны, изри башлаган юлдан читкә борып, чикләвек куагы астына кертеп туктатты. Күкрәү авазлары отыры якыная, баш очында гына ишетелә башлады.

— Янәшәдә генә каен, яшен сукмагае,— дип, Һәдия, кожанын ачып, Өлкән Сәгыйрьгә карады.

— Синең белән бергә үлсәң дә ярый,— диде Өлкән Сәгыйрь. Кинәт, бер көйгә генә оеп яуган яңгыр шавын күмеп. баш очында чытырдап күк ярылды. Күз камаштыргыч яктылык, абагалар төбенә кадәр үтеп, тирә-юньне ялмап алды. Һәдия сискәнеп Өлкән Сәгыйрьгә totынды. Кожаны иңеннән шуып төште. Искәрмәстән Өлкән Сәгыйрьнең куенына кергән хатынның тәне, җил кагылып сискәндергән су өсте кебек, сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде.

Һәдия...

Күк белән урман кушылып, тоташ су томаны эчендә калды. Аннары... яфрактан-яфракка күчеп арырак киткән соңгы тамчылар, пәрәвез җебе шикелле сузылып төшкән кояш нурлары... яфракларга сыенган тамчыларның сак кына җилдән шыбырдап коелуы, өзәңгеләрен зеңгелдәтеп атның кешнәп куюы — һәммәсе урман кочагына җан кертеп, тереклекне яңгыр иләслегеннән үз хәленә кайтарды...

— Әгәр көләргә уйласаң!..

— Минем йөрәк менә шушы йодрык кебек кысылган.

— Кеше күзенә ничек күренермен?

— Ә нигә яшерергә, белсеннәр. Малай кирәк миңа, Һәдия, малай. Җил-яңгыр тидерми, күрәшче итеп үстерәчәкмен мин аны. Шундый нарасыйның авызын бөрә-бөрә елавын бер күрәсем килә. Үзең күреп торасың бит, юк ул бездә. Карт анамны күтәреп йөрткән кебек, хатынымны урыннан-урынга күчерәм...

— Мин гаепле, Сәгыйрь. Әмма сине алачык янында күргәннән бирле әллә нишләдем. Кыяфәтең дә, югыйсә, ташка үлчим. Эчеңдә җенең бардыр синең... Син миннән көлмә, Сәгыйрь. — Һәдия таралып төшкән юеш чәчләре белән Өлкән Сәгыйрьнең күкрәгенә сыенды. — Мин әле наз дигән нәрсәне юньләп белмәгән дә бит. Азат белән биш кенә ай яшәп калдык. «Көт, кайтырмын», дип китте дә... кайтмавы белән рәнҗетте ул мине. Беләм, сугыш гаепле...

Һәдия читкәрәк тартылды, иренен тешләп тынып калды. Гүя ул, үзе дә сизмәстән, упкын аша чыкты да, хәзер инде кире борылырга теләп, ярда басып тора. Ә артка юл юк... Язмышың белән килешергә һәм алга атларгамы? Ә анда нәрсә көтә? Билгесез уйлар әзәрлекләвенә түзә алмыйча, ул гасабиланып кычкырып җибәрде һәм, кулларын йодрыклап, Өлкән Сәгыйрьнең күкрәген төя башлады:

— Нишләдем мин, нишләдем?!

Аннары, шунда ук йодрыкларын язып һәм үксеп, арбадагы печәнгә йөзтүбән капланды.

Икенче җәйдә, алмалар өлгереп килгән чакта, Һәдия малай тапты. Кап-кара кашлы, бөдрәләнеп торган кара чәчле сабый Өлкән Сәгыйрьнең зур учларында нәни кошчык кебек иде. Ул аны сак кына тотып ишекле-түрле йөренде. Сабыйның томанлы күзләренә карап нидер сөйләргә итенде. Әмма, бала телендә нәзакәтле итеп сөйләшә белмәгәнлектән, аның сүзләре бик тупас килеп чыга иде. Елый башлагач, чарасыз калып, баланы Һәдиягә тоттырды.

Бераз ябыга төшкән Һәдия шатлыклы да, сагышлы да иде бу минутларда. Бала — бәхет. Әмма бу бәхет Һәдиягә күпме йокысыз төннәр, икеләнү-сызланулар, кешеләрдән ишеткән авыр сүзләр аша килде. Бәхетле мин, дип, кешеләр күзенә туры карый алмагач, тулы буламыни ул бәхет...

Ул төн Өлкән Сәгыйрьнең күңеленә мәңге онытылмаслык булып уелып калган. Менә ул тып-тын урам буйлап атлый. Тәрәзәләрдән төшкән утлар агач яфраклары арасыннан йолдызлар булып җемелди. Күктә авылның таҗы булып Киек каз юлы сузылган...

Ишек тавышына түшәктә яткан хатыны Кәшифә әкрен генә борылып карады.

— Кайттыңмы?

Өлкән Сәгыйрьнең бер генә төнне дә кайтмый калганы булмады. Кәшифә һәрчак ярдәмгә мохтаҗ иде. Тездән бозлы су ярып торф чыгарганда тигән салкын үзенекен иткән, аяклары йөрми иде аның. Больницадан алып киткәндә Өлкән Сәгыйрьгә врач: «Хәле кыен, үпкәсенең дә ярты ягы гына сулый,» — диде. Өлкән Сәгыйрь Кәшифәне бик бирелеп карады. Үзе белсә дә, хәтта ашка тоз салу кебек вак кына нәрсәләрне дә Кәшифә белән киңәшләшмичә эшләмәде.

— Ике бәхетсезлек бергә килмәсен. Мин инде үлемгә йөз тоткан. Теләгән кешеңне сайла, — дигән иде Кәшифә аңа.

Авылда сернең изүе ачык. Уйлаган уең кешеләргә кайчакта үзең әйткәнче үк барып ирешә. Хәл белешергә кергәләп йөргән күрше-күләннән Кәшифә авыл хәлләрен һичшиксез белеп торгандыр «Теләгән кешеңне сайла» дигән сүз шуңа ишарә иде. Малай туу вакыйгасын Өлкән Сәгыйрь ачыктан-ачык әйтергә булды. Иң элек ул бакчадан алмалар җыеп алып керде.

— Кайсы алмагачныкы? — диде Кәшифә. — Баз кырыендагысы былтыр көз чәчәк аткан иде. Анысы ничек соң?

— Алмаланмады.

Дөньясы кечерәеп, шушы бүлмә белән генә чикләнгәнгә күрәдер, Кәшифә әллә ничек, үткен итеп, йөрәккә туры карый белә иде. Бу караштан сакланып, Өлкән Сәгыйрь байтак кына сөйләшеп утырды. Төп сүзгә сабырлык белән, сак кына барып җитәргә иде исәбе. Кинәт кенә аларның карашлары кисеште. Катгый бер мәгънәне таләп иткән бу караш әсирлегендә Өлкән Сәгыйрь кинәт югалып калды.

Кәшифә, кулын юрган астыннан алып ястык буйлап шудырып китерде дә караватның салкын тимерен кысты.

— Малаймы?..

Өлкән Сәгыйрь гаҗәпләнүдән сүзен әйтә алмыйча торды.

— Малай, — дип, үзе үк җавап бирде Кәшифә. — Минем төш рас килә ул.

Өлкән Сәгыйрьнең күңеле тулды. «Эх, Кәшифә, яратмаслык кешемени соң син...»

— Сиңа кызару килешми, Сәгыйрь... Нәзберәк булмасын, синең кебек эре сөякле булсын. Шундый нәсел калдыр... Кешеләр вагая кебек хәзер...

Өлкән Сәгыйрь, онытылып, Кәшифәнең ябык гәүдәсен кочып алды. Нindидер җылы сүз әйтәсе, аны юатасы килде. Әмма сүзләре киң күкрәгә эчендә йотылып калды.

Кәшифә буылып-буылып ютәлләргә керешге. Өлкән Сәгыйрь аны сак кына торгызып утыртты да термостан кайнар чәй агызып бирде. Тынычланып урынга яткач, Кәшифә:

— Китмәскә килгән чир җан сорый, ди. Ә син, Сәгыйрь, барысы өчен дә үч итеп яшә. Минем өчен дә, — диде. — Бала күрү шатлыгы насыйп түгел иде бит миңа.

Ул төнне икесе дә бик озак йокыга китә алмый яттылар. Кинәт исеп куйган җилдән тәрәзәгә агач ботакларының тиеп-тиеп китүе ишетелеп торды. Икесе дә үз уйларына чумган һәм бер-берләренең уйларын беләләр, бер генә сүз әйтсәләр дә, йөрәкләрендә мәңге күмелеп калачак моң-сагышка кагылырлар, бер-берләренә рәнҗү салырлар кебек иде алар бу төндә.

Көз якынлашкан саен Кәшифә дә, яфраклар белән бергә, күзгә күренеп саргая-сула барды. Тәмам өзлегеп китте. Үз-үзен белештермичә саташкан чакта кырыенда утырган Өлкән Сәгыйрьнең кулына чытырдап ябыша иде.

Әйтерсең Өлкән Сәгыйрьне үзе белән каядыр дәшә, төшендә үзен дә сәламәт итеп күреп, узган бәхетле көннәрендә аның белән бергә озаккарак калырга тели иде.

Бер таңны Кәшифә карлыккан тавыш белән иренә эндәште. Өлкән Сәгыйрь, ятагыннан кузгалып, Кәшифә кырына килеп утырды. Кәшифәнең йөзенә сәламәт алсулык йөгергән иде. Коргаксыган кулын иренең беләгенә куйды да:

— Әллә нигә куркыныч, — диде ул. Бик озак тын ятканнан соң ят тавыш белән сүзен дәвам итте. — Син ишетмәгәнсеңдер, күршенең әте төне буе улап чыкты. Бер ай инде шулай... Этләр үлем исен алдан сизенәләр, ди. Син юатма, Сәгыйрь, тыңлап кына тор. Сүзләрем санаулы гына калды...

Бүген төш күрдем. Әни, мәрхүмә, ап-ак күлмәктән, текә яр читенә баскан да мине үзенә чакыра, «кил, кызым, кил», ди. Мин йөгерәм, баскан саен җир убыла. Үзем һаман йөгерәм... аяк астыннан җир китә бара, китә бара... Шуннан соң әни үрелде дә озын куллары белән мине күтәреп алды... Әнә, бу тәрәзәгә тиеп торган алмагач ботагында бер генә яфрак калган... ач әле тәрәзәне... ул хәзер өзелер. Җил очыртып кертмәсме? Юатма, Сәгыйрь. Алай димә. Мин сиңа рәнҗемим. Соңгы үтенечемне тыңла: улыңны алып килеп күрсәт... Һәдия дә килсен...

Өлкән Сәгыйрь никадәр генә әйтеп караса да, Һәдия өйгә керергә яхшысынмады, баскыч төбендә торып калды. Өлкән Сәгыйрь баланы биләвеннән чишеп караватка салгач, Кәшифә авыр йокыдан уянган шикелле күзләрен ачты. Хәлсез кулы белән баланың чәчләрен, битен сыйпады. Йөзенә нур йөгерде. Аның кипкән иреннәре сизелер-сизелмәс кенә елмая иде.

— Сиңа охшаган икән...— Кәшифәнең күз яшьләре сулып калган яңаклары буйлап агып төште дә мендәргә тамды. Бу минутта ни кылырга белми торган Өлкән Сәгыйрь күзләрен читкә борды. Бусагада ни алга атларга, ни артка чигенергә белмичә, икеләнеп, Һәдия басып тора иде.

Кинәт бала кычкырып елап җибәрде. Һәдиягә менә хәзер кемдер баласын тартып алыр да ул тагын япа-ялгыз торып калыр кебек тоелды. Һәм ул йөгереп килеп баланы кулларына алды. Баланың кайнар яшьләрен күкрәгендә тоюы аны бу шомлы тойгыдан айнытып җибәрде. Һәдия авыруның ятагы кырына килеп тезләнде.

— Кичер, зинһар, Кәшифә, мин синең алда зур гөнаһлы,— диде.

Кәшифә, күзләрен йомып, бик озак тын гына ятты. Бераздан, күзләрен ачып, түшәмдәге билгесез бер ноктага төбәлде дә:

— Соңгы сүзне ул әйтер,— диде.

Балага ышыкланырга, сыенырга теләгәндәй, Һәдия аны кысыбрак тотты. Сабыйның җылы тәне, зур ачылган күзләре тормыштагы ялгыш-гөнаһларны юа алырдай бер өстен көч булып тоелды аңа.

Кәшифә актык сулышына кадәр шул ноктадан күзен алмады һәм башка бер сүз дә әйтмәде.

Кәшифә үлгәннән соң Өлкән Сәгыйрь үз эченә бикләнеп калды. Күбрәк атлары янында булырга тырышты. Алар янында ул онытыла, үзен иркенрәк хис итә иде.

Һәдия дә салкынаеп, кырысланып китте. Ике араны уртак өмет — сабый гына бәйли иде.

Кәшифәнең әрнүле карашы Өлкән Сәгыйрьне торган саен ныграк эзәрлекли, һич кенә дә күз алдыннан китми иде. Ул карашны тымызык көзге көннәрдә җанны кысып җиргә иелгән болытлы күк йөзеннән дә, таң беленеп килгән тәрәзәдән дә, төмсәләнеп калган су өстеннән дә күреп сискәнеп китә иде Өлкән Сәгыйрь. Кешенең сүзсез, әрнүле соңгы карашы гомер буе шулай эзәрлекли, җавап бирүне көтә микәнни?.. «Кем иде соң «ул»? Һәдияме? Өлкән Сәгыйрь үземе? Баламы?

Баланың беренче тапкыр атлап китүе, әле әнисенә, әле әтисенә килеп сыенуы ике араны якынайта төште. Ләкин Һәдия Өлкән Сәгыйрь йортына күчеп килергә теләмәде. Үз өе була торып, йортка кергән исеме алып Һәдияләргә күчеп килергә Өлкән Сәгыйрь дә яхшысынмады.

— Читкә чыгып китик, Һәдия. Гелгә түгел. Малай үсеп җиткәч, әйләнеп кайтырбыз,— диде Өлкән Сәгыйрь, бер карарга килеп.

Һәдия, төрле сәбәпләр табып, өзеп кенә җавап бирүдән тайчынып килде һәм беркөнне:

— Элгәре үзең барып төплән, аннары күз күрер,— диде.

Өлкән Сәгыйрь Казагыстан якларына барып урнашкач һәм торак урынын җайлагач та, Һәдия анда күчеп китүне һаман кичектерә торды.

Битараф вакыт — кешеләрнең икеләнү-борчуларына карыймыни ул — үз җаена уза бирә.

Өлкән Сәгыйрь, инде тәмам өметен өзеп, туган якларына кайтырга җыенып йөргәндә, бәлагә тарып аягын имгәтте. Шифаханәдән язган хатларында бу турыда ул үзе бер сүз дә кузгатмады. Савыгып чыккач та, әле ныгып җитмәгән аягы белән, авылга аксап кайтып керәсе килмәде. Сабан туйлары булыр, беткән икән бу, димәсеннәр...

Кайту, Һәдия белән бер-берсен бүлә-бүлә сөйләшеп утыру — баш очында торган язмышның ни кыласын сиземләмәгән бу бәхетле минутта... ишекне бәреп ачып, җиде яшьлек Шаһинур кайтып керде. Өйдә чит кеше барына да игътибар итмәстән, ул:

— Әни, мин уйнаштан туганмыни!? Малайлар шулай дип үртиләр. Минем әтием юк икән, син алдагансың!— дип кычкырып елап җибәрде. Һәдия агарынып китте, күлмәк итәге белән улының борынын сөртте дә:

— Алар белми әйтәләр, улым. Әнә бит әтиең кайтты. Сиңа бүләкләр җибәреп торган әтиең шул бит инде,— диде. Малай төксе генә карап алды:

— Алдашмагыз! Минем әтием юк! Чыгып китсен ул безнең өйдән!

Туктаусыз үчеклəп торган язмышын каһəрлəп, үз өенең инде бүтəн ачмаска дип кадаклаган тəрəзə такталарын кубарганда ул, əллə кире Һадиягə кайтыргамы, дип, икелəнеп тормады. Малаена түгел, кешелəргə рəнҗегəн иде ул. Соңыннан ат караучы булып эшли башлавы да кешелəрдəн читтə булырга телəвеннəн иде. Җаны тарыккан, эче пошкан көннəрдə ул эч серен яраткан атына сөйли торган булып китте. «Берни дə аңламыйсың бит син, малкай. Шуның белəн бəхетлесең дə. Кешелəрнең менə акылы да, теле дə бар. Əмма бер-берсенə яраша алмыйлар». Атның күзлəреннəн ул: «Ə син үзең тормышта бер дə ялгышмадыңмы, беркемне дə рəнҗетмəдеңме?» дигəн сорауны шəйлəгəндəй була. Лəкин бу четерекле сорауга җавап бирүне һаман алдагыга калдыра иде.

Ə ул «алдагысы» дигəне нəкъ менə бүген, Шаһинурның кайтып төшкəн көне түгел микəн? Анык нəтиҗə бəлки аның белəн күзгə-күз карап сөйлəшкəндə үзеннəн-үзе туар. Шул уй белəн Өлкəн Сəгыйрь эңгер төшү белəн Һадиянең өй турысына килде. Түр тəрəзəдəге пəрдə читеннəн улын күреп алды. Солдат киеменнəн. Клубка чыгарга җыенадыр. Шул мəлдə моннан күп еллар элек йөрəгендə уелып калган тавыш яңадан кабатлангандай булды: «Чыгып китсен ул безнең өйдəн, чыгып китсен!»

Өлкəн Сəгыйрь өйгə керергə яхшысынмады. «Иртəгə сабан туе, кайтып бераз ял итим булмаса»,— дип, кире үз йортына таба борылды.

Сабан туе. Елга бер генə килə торган, кайгыларны оныттыра, шатлыкларны уртаклаштыра торган бəйрəм. Бу көндə кешелəрнең йөзлəре нурлана, күңеллəре киң ачыла.

Өлкəн Сəгыйрь өчен көтеп алына торган бəйрəм ул. Менə шунда инде ул бар дөньясын онытып тантана итə.

Элегрəк авыл халкы арасында шундый риваятьлəр йөри иде. Имеш, Өлкəн Сəгыйрь яшь чагында ике потлы герне өй түбəсе аша чөеп уйный торган булган. Арт тəгəрмəченнəн тотса, тройка урыныннан кузгала алмаган. Бу хакта үз алдында сөйлəсəлəр, Өлкəн Сəгыйрьнең ирен читендə канəгать елмаю саркып китə, вакыйганың никадəр дөреслеген тəфсиллəп тормый, булгандыр инде, дип кенə куя иде.

Өлкəн Сəгыйрь Эстəрле буена килеп җиткəндə, мəйданда көрəш башланган иде инде. Көрəшчелəр арасында улын күргəч, ул гаҗəплəнмəде. Сизенгəн иде. Кичə күрешкəндə үк кул кысышыннан аның көчен чамалап алды.

Кай арада диген... Хəрби хезмəткə киткəнче үсмерлəр белəн көрəшеп йөргəн малай... Хəтерендə əле, бер елны җиңүче калып мəйданнан чыккач, кешелəрне үртəп тəм табарга яратучан шарлатан Гыймай Заһиты Өлкəн Сəгыйрьнең куш аю кебек сузылып яткан шəүлəсе өстенə килеп басты да:

— Бик масайма, теге малаең ике-өч елдан күрсəтер əле күрмəгəнеңне! — дип, сары тешлəрен ыржайтып көлə башлады. Өлкəн Сəгыйрь каш астыннан гына карап торды да Гыймай Заһитының бил каешыннан элəктереп алды һəм, аны күтəреп килеш, буа ярына таба юнəлде.

— Сəгыйрь абзыкаем, җибəр, яңа кəчтүмем...

Гыймай Заһитының соңгы сүзләре су чәпелдәве астында күмелеп калды. «Бата күрмәсен тагын», дип, Өлкән Сәгыйрь ярдан үрелеп карады да, сәгать таккан кулын өскә күтәреп, корбанының йөзеп килүен күргәч, тынычланып, зиреклек астындагы кибеткә китеп барды.

...Иң актыкта батыр исемен дәгъвалаучылар — аталы-уллы Өлкән Сәгыйрь һәм Шаһинур чыгып баскач, мәйдан кысыла төште. Мәйдан уртасына чыгып басу Өлкән Сәгыйрь өчен һәр вакыт дулкынландыргыч минутлар иде. Бусы инде соңгысы булачак. Көч мәңгегә бирелми икән шул кешегә. Соңгы көрәштә, ни генә булмасын, һич бернинди ташламасыз җиңеп китәргә тели иде Өлкән Сәгыйрь. Сөлгегә үрелгәндә улына каш астыннан гына күз төшереп алды. Менә бил алышу башланды. Өлкән Сәгыйрь улының тимер кебек каты мускулларын беренче талпынышта ук тойды. Гадәттә, тын алырга ирек бирмичә, билне кысып китереп, чиста гына сала иде бит ул. Ә Шаһинур алай гына бирешерлек күренми. Җиңенә кызыл бәйләгән, күгәрчен канатына охшаган мыеклы карт, көрәшчеләр бер-берсен каерып алып күтәргәндә, җиңел генә читкә тайпыла. Куллары белән тезенә таянып һәр икәвесен дикъкать белән күзәтә.

Алгы рәттә Һәдия басып тора, улының ак күлмәген беләгенә салган. Өлкән Сәгыйрь Шаһинурның тирләгән җилкәсенә ияген терәде, сөлгеләр шыгырдап тартылды.

— Кулыңны касыкка терәмә, искечә алдырасың, Сәгыйрь туган! — Бу сүзләрне әлеге картларның берсе әйтте.

Яңадан тотыштылар. Мәйдан хәлиткеч нәтиҗәне көтеп түземсезләнә. Өлкән Сәгыйрь җәгәре кими баруын сизә, ниндидер яшерен үч аның көчен буа сыман иде.

Менә ул ахырга кадәр саклап килгән хәйләле алымына кереште. Шаһинурның биленнән кысып алып, инде күтәрим генә дигәндә, эчтән газаплы ыңгырашып куйды. Ләкин бу кызганыч аваз тышка чыга алмады, бавы өзелгән кое чиләге кебек, киредән күкрәгенә төшеп китте. Шаһинур моны бөтен йөрәге белән тойды. Беразга хәл алырга дипме, сөлгесен бушатты. Шул чак Өлкән Сәгыйрь аны кысып алып күтәрде һәм... беркайчан да җиргә аркасы белән төшүне белмәгән, җиңүченең кайнар тыны битенә бөркелүен тоймаган Өлкән Сәгыйрь гәрселдәп төшкән Шаһинурны җәһәтлек белән җиргә кысты. Шул минутта ул эчендә еллар буе газаплап тартылып килгән җепнең кинәт кенә өзелүен тойгандай булды. Усал көчен тезгенли алмавын, хаксыз җиңүен тойган хәлдә, авырлык белән генә күтәрелде.

Мәйдан, өнсез калып, беразга тынып торды. Аннан кинәт уянып киткәндәй, ду килеп кайный башлады.

— Яшә, Сәгыйрь абзый!

— Вәт чиста салды, ичмасам.

«Юләр баш, бөтенләй чыкмаска иде миңа, карт кешегә ни калган. Улым белән кирәкми иде»... дип өзгәләнде Өлкән Сәгыйрь. Үзен котларга килгән кешеләрне этеп җибәрде дә Шаһинурның беләгеннән тотты.

— Болай булмый, улым. Яңадан...

— Кирәкми, әти...

Өлкән Сәгыйрьне өстәл янына чакырдылар.

— Телевизорны җилкәңә сал, Сәгыйрь абзый, фотога алабыз үзеңне.

— Ветеран көрәшче!

Кирәкми иде аңа телевизор. Башы әйләнә, йөрәге сикерә иде Өлкән Сәгыйрьнең, уйлары кайный иде. «Әти» диде түгелме?.. Күпме

гомерләр көткән кадерле сүзне шау-шулы гавам арасына төшереп ватты түгелме соң?..

Улының тавышын күңелендә саклап, бер ялгызы калгач, кабат тыңларга һәм рәнҗергәме, сөенергәме иккәнлеген тәгаен ачыкларга теләү аны мәйданнан читкә алып чыгып китте.

Атын җитәкләп, тау итәгендәге чаукалыкка кереп барганда, «Әткәй!» дип кычкырган тавышны яңадан ишеткәндәй булды. Ләкин артына борылып карамады. «Соңгы сүзне ул әйтер», дип пышылдады аңа күңел тавышы.

Таудан караганда мәйдан чәчәкле түбәтәй кебек кечерәеп күренә. Әнә түбәтәй сүтелде — халык дулкыны юлга таба агыла башлады. Ерактан тузан болыты кузгатып, томырылып атлар килә иде. Алдан, сөлек кебек сузылып чапкан ат халык арасына килеп кергәндә, Чакматай, колакларын шомырайтып, башын күтәрде, тартылып куйды, әллә нинди тетрәндергеч тавыш белән кешнәп җибәрде. Өлкән Сәгыйрь тезгенне кыскартыбрак тотты да йөгәннең сагалдырыгына ак сөлгесен бәйләп куйды. Сөлгенең җилфердәп алуы, йөзенә рәхәт дулкын булып кагылып китүе атның элекке хатирәләрен уятып җибәрде, күрәсең. Чакматай кешнәп аягүрә басты һәм кинәт алга ыргылды. Сөрлегеп киткән Өлкән Сәгыйрь ирексездән тезгенне ычкындырып җибәрде. Ирек яулаган ат килгән юлдан кире чабып китте...

Өлкән Сәгыйрь, тау битенә утырып, кесәсеннән тәмәке чыгарды. Сыңар гына шырпысы калган икән. Аны да җил өреп сүндерде. Өлкән Сәгыйрь авыр сулап урыныннан торды һәм ут алырга дип, гармун, җыр тавышлары ишетелеп торган мәйданга таба төшеп китте.

## Эдуард Мостафин

### Беренче яшен кебек

Күк йөзендә камчы-камчы
Яшеннәр уйнаклаша.
Җаясеннән очкан уктай,
Тай чаба үрләр аша.

Яшеннәрме шушы тайның
Көч биргән йөрәгенә.
Яңгыр җиле тотам-тотам
Ялларын үрә генә.

Янса яна, ыргыла тай,
Ак күбек — күкрәгендә.
...Тормышка атыла тайлар
Күкләре күкрәгендә.

●

Җылы яңгыр бөртекләре
өлгергән игеннәрдә.
Сабыр итегез, болытлар:
башаклар иелгәннәр.
Учларыма сеңеп калды
сары тамчылар исе,
күкләргә карап борчылам,
изүләремне чишеп.

●

Кичәгене сагынабыз
Яшәсәк тә үзебез бүген.
Бүген алда юлым ята,
Баш очымда йөзә күгем.
Бүген җилләп язым килә,
Чәчәк ята яннарымда,
Бүген менә акыл белән
Дәрт көрәшә каннарымда.
Бар да бүген: көлү бүген,
Яшәү бүген, үлем бүген.
Тик бер бәла, ничек итеп
Кичәгене күмим бүген? —

Бүгенгедә — үткәннәрем:
Таңда калган ярчык кебек,
Я бер сөеп туймас кыздай,
Я иң явыз карчык кебек.

●

— Суларың тәмлеме? — Сорадым чишмәдән.
— Юк, кеше, төбемдә күпме ком, күпме ләм.

...Иренне тигездем —
Суында күпме тәм!

— Чишмәдәй сафмы син? — Сорадым чәчәктән.
— Юк, кеше, өстемдә җәйләрнең тузаны.

...Күзәттем:
Сокланды туктап һәр узганы.

— Чәчәктәй гүзәлсең! — Дәштем бер сылуга.
Яшьләре тәгәрәп төштеләр күзеннән...

...Әллә соң бу сафлык ояла үзеннән?

## Фәннур Сафин

### Иптәшләр!

Һәрбер сүзнең җаны, үз моңы бар.
Ә ничегрәк яңгырый: «ИПТӘШЛӘР»?! —
Төрле яктан, ялкын эчләреннән
дәшә безгә, дәшә җирдәшләр...

Гомерен ялкын итеп яшәгәннәр
үз күңленә һаман табар иш. —
Ипле кеше генә иптәшмени,
ярсу җаннар күбрәк яна ич?!

Бөек чорның — бөек төзелешнең
үрләренә менеп давылда,
без төзергә тиеш өр-яңаны,
гайрәтлерәк итеп тагын да!

Ул сүнмәслек, егылмаслык булсын
хаталарга безнең абынып.
Нәкъ безнең чор — мәңге яши торган
дастаннарда урын алырлык!..

Ә соң безнең эшләр кушыламы
шул дастанга — бөек моң-җырга? —
Без ул тиеш Тукай кебек туры,
Җәлил кебек батыр булырга!

## Разил Вәлиев

### Бәхет

Кыя ташка менеп шигырь яздым —
Бу шигырем бәхет турында.
Хозурланып тауда басып торам,
Болытларга башым орына.

Шундый якын миңа бар кешеләр,
Туган ягым кебек киң җиһан.
Ташлап киткән ярым кире кайтты —
Кулларына алсу гөл җыйган.

Иңнәренә шатлык йөге төяп,
Сизелми дә үтә ай, еллар...
Үзәннәрдә илләр сугышмыйлар —
Сугыш-сугыш уйный малайлар.

Уенчыклар тезеп шук малайлар
Мәйданнарда ясый парадлар...
Диңгезләре — язгы ташу суы,
Бата анда кәгазь кораблар.

Кичләр җитсә, кулга-кул тотышып,
Әйлән-бәйлән уйный дәүләтләр.
Бар кешеләр шундый киң күңелле,
Бар кешеләр шундый әйбәтләр...

Хозурланып тауда басып торам —
Болытларга башым орына.
Кыяларга менми аңламассың —
Бу шигырем бәхет турында.

●

Минем гомер гүя башланмаган,
Мин дөньяга гүя килмәгән...
Күкрәгемдә — әнкәм биргән йөрәк,
Иңнәремдә — әткәм күлмәге.

Шатлыгым да үземнеке түгел,
Үземнеке түгел кайгым да.
...Абыемның гомере кыска булган —
Бар хисләрен миңа калдырган.

Мин үткәннәр белән яшим әле...
Эзлим җирдә бабам бәхетен.
Ул менмәгән тауга мендем инде,
Ул үтмәгән озын юл үттем.

Үткәннәргә таба йөзне борып,
Күп таптармын әле бу җирне.
...Үземнекен түгел, язам әле
Шагыйрь язмый калган шигырьне.

●

— Сине эзләп мин тауларга мендем,
Аннан аштым күккә.
«Мин яратмыйм», имеш. Күрче менә —
Юкка синең үпкә:

Телисеңме, кара күк йөзендә
Булам янар йолдыз?..
Аңладыңмы инде сөюемне —
Күктә дә мин ялгыз.

Наз кирәксә, битләреңне сыйпап,
Җылы җилдәй исәм.
Хат язармын яшен уты белән:
«Мин, дип, яшим, исән».

Сүзләремә инде ышандыңмы,
Онытттыңмы үпкәң?

— Ышандым. Тик минем күңел инде
Башкаларда күптән.

## Урман

Ил урманы көн-төн шаулый.
Урманда без куак түгел.
Әйдә, түрдән узыйк әле, —
Без бит монда кунак түгел.

Сыйпап узыйк чәчәкләрне —
Алар олы урман яме.
Олысына, кечесенә
Бер үк җылы нур тияме?

Анда берәр сөрхәнтәе
Тимәгәнме кырмыскага?
Кечеләрне кимсетергә
Кайберәүләр, ай, оста ла.

Күрә калсаң андыйларны,
Йөзенә бәр, әйт турысын.
Каеннар да, мин ак, диеп,
Алгы рәткә чыкмый торсын.

Тыңлап торма: «Нарат яхшы,
Усак начар», дигәннәрне.

Һәр агачның үз урыны —
Күккә чөймә имәннәрне.

Урман булгач урын җитәр,
Имәнгә дә, үләнгә дә.
Аланнарда пешсен җиләк,
Гөмбә үссен күләгәдә.

Монысы карт, кирәксез дип,
Ташлап китә күрмә тагын.
Ыграк назла андыйларны,
Корыган булса, кис ботагын.

Үссен урман... Без дә бәлки
Инде нәни куак түгел? —
...Түргә атлыйк хуҗа булып,
Без бит җирдә кунак түгел.

## Гаепле

Барысына гаепледер, ахры,
Чал Иделнең яшел нараты.
Сине күрми узып китә идем...
Ул үзенә мине каратты.

Гаепледер бәлки кара төндә
Юл күрсәтеп торган якты ай.
Сукмак булып ул алдыма ятты,
Колагыма дәште: «Якынай!»

Гаепледер аннан яр буеның
Кочагыңдай җылы, мул комы.
Гаепледер тагын яңгыр, давыл,
Болыт, яшен, елга дулкыны.

Гаепледер бәлки урман җиле:
Көнләштереп, башта ул үпте...

Чыкмас идем Идел ярларына —
Үз йөрәгем, ахры, гаепле.

## Диңгез дулкыны

Тын култык, тын ярны калдырып,
Юл тотты диңгезгә дулкыннар...
Аларны сагынып ярларның
Йөрәге бик озак сулкылдар.

Шундый зур, шундый киң һәм иркен,
Куәтле һәм назлы ул диңгез.
Теләсәң, тын гына күккә бак,
Теләсәң, талганчы йөз дә йөз.

...Иярткән аларны үзенә
Диңгезнең ягымлы агымы...
Тик бераз баргач та иңнәргә
Усал җил куллары кагылды.

Калтырап, сискәнеп куйдылар
Дорфалык күрмәгән дулкыннар...
Әйттеләр: «Без — диңгез кунагы,
Тияргә нинди, — дип, — хакың бар?»

Ә җилләр шаркылдап көлделәр,
Ачынып кычкырды акчарлак.
Аңлады дулкыннар бик тиздән:
Җилләргә иярми юк чара.

Ә җилләр әйләнде давылга...
Диңгездә тоз исе, яшь исе.
Туктаусыз кабатлый дулкыннар:
«Бик килә яш-ши-се, яш-ши-се!»

Яр калган тарафка күз атып,
Борылды кирегә дулкыннар.
Ярларны тапканчы, йөрәкләр
Шашынып, авыртып сулкылдар.

Җил белән көрәшеп талдылар,
Күзләрдән тамчылар чәчрәде.
Кайттылар дулкыннар тын ярга.
...Агарган иде тик чәчләре.

●

Бертуктаусыз уйный, шаярасың...
Шатлыгыңны кемнәр уяткан!
Син бит башка, син гел уйчан идең.
...Ә беләмсең,
Бу җылы җил исә төньяктан.

Авыр кайгы баскан бүген сине,
Йөри идең элек гел актан.
Син бит башка. Син бит көләч идең.
Ә беләмсең,
Бу салкын җил исә көньяктан.

≈≈≈≈≈

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**СЕНТЯБРЬ, 1975 ЕЛ**

Кама автомобиль комплексы төзелешендә иң җаваплы, иң киеренке чор — җиһазларны монтажлау һәм ходка җибәрергә әзерлек башланды. Төзүчеләр һәм КамАЗ эшчеләре өчен «Даешь автомобиль!» лозунгысы көн тәртибенә килеп басты. Моны тормышка ашыру өчен барлык ресурслар мобилизацияләнә, гаять зур киеренкелек шартларында биш ел дәвамында иңгә-иң торып көрәшкән ике зур коллективның — төзүчеләрнең һәм җиһаз көйләүчеләрнең көчләре туплана.

КамАЗ ул — елына 150 мең йөк машиналары, 250 мең дизель двигательләре җитештерәчәк заводлар комплексы. Конвейердан минут ярым саен бер машина төшеп торачак.

Әзерләүләр производствосына аерым тукталу кирәк. Кою заводының куәте — елына 560 мең, тимерчелекнеке 300 мең тонна. Бу — 1974 елда бөтен автомобиль промышленносте җитештергән шушы төрдәге әйберләрнең өчтән бере һәм дүрттән бере кадәр.

Кама автомобиль заводлары комплексының техник проектын илебезнең иң зур предприятиеләре һәм проект оешмалары — И. А. Лихачев исемендәге Мәскәү заводы, Ярославль моторлар төзү заводы, «Гипродвигатель» институты, СССР Госстрое, СССР Энергетика министрлыгы, СССР Махсус төзелеш һәм монтаж министрлыгы, шулай ук башка министрлыклар, ведомстволар белән берлектә «Гипроавтопром» институты әзерләде. Техник проектны әзерләүгә барлыгы 62 оешма катнашты. Аерым производство объектларын проектлаштыруны чит ил фирмалары «Свинделл-Дресслер» (АКШ) — кою заводы проектының технологик һәм махсус өлешләрен, «Рено» (Франция) — двигательләр заводы проектын, кабиналарны эретеп ябыштыру һәм буяу эшләрен «Либхерр» (Германия Федератив Республикасы) — тизлекне үзгәртү тартмаларын җитештерү проектын һәм җиһазлар җитештерү буенча контрактлар белән бәйле башка фирмалар башкарды. Производствоны әзерләүгә бу тармактагы барлык зур предприятиеләр һәм институтлар: ГАЗ, ВАЗ, ЗИЛ, ЯМЗ, МАЗ, КрАЗ, УралАЗ, УНИПТИмаш (Ульяновск) һәм башкалар тартылды.

Күп кенә совет белгечләре чит ил фирмаларында проектлар өстендә эшләүгә турыдан-туры катнашты. Үз чиратында Мәскәүгә проектларны башкаручы һәм җиһазларны тәэмин итүче чит ил фирмаларының вәкилләре килде.

КамАЗны төзүнең үзенә хас үзенчәлекләре бар. Эш менә нәрсәдә: заводлар комплексын салу, аны проектлаштыру һәм автомобильләрнең конструкциясен өзерләү бер үк вакытта башкарылды. Бу исә заказчының, проект төзүчеләрнең һәм генподрядчыларның төгәл һәм бердәм эшләвен таләп итте. Автомобильдә бер генә деталь үзгәрсә дә, барлык җиһазлар технологиясен, төзелештәге фундаментларны, металл конструкцияләрен һ. б. ларны яңабаштан үзгәртергә туры килде. Ә бу эшләр гаять зур масштабта барган төзелеш шартларында башкарылды. Төзү-монтаж эшләренең күләме тәүлеккә миллион сумлыктан да артып китте. Әмма кыенлыклар һәм чыгымнар берни белән дә чагыштыргысыз отыш — вакыт отышы бирде. Әгәр автомобильләрнең әзер конструкциясен һәм комплекс проектын көтеп торсаң, КамАЗ биш-алты ел эчендә түгел, шактый озаграк төзелер иде. «КамАЗ» техник

яктан да, экономик яктан да, машиналар җитештерү эшләрен оештыру ягыннан да дөнья автомобиль төзү практикасының таләпләренә җавап бирә. Уңышлы тәмамланган сынаулар конструкцияләрнең ныклыгын, әйбәт сыйфатлы булуын ачык күрсәтте. Сынау үткән барлык машиналар производствога тәкъдим ителде.

КамАЗны эксплуатацияләүнең илебез халык хуҗалыгындагы эффектлылыгы елына 700 миллион сумнан артыграк булачак, миллионнарча тонна бензин янга калачак, хәзерге көндә «ЗИЛ-130» тибындагы автомобильләрне йөртүче шоферлар саны 30 меңгә кыскарачак. Исәпләү күрсәткәнчә, Кама автомобиль комплексын төзүгә тотылган чыгымнар биш ел чамасы вакыт эчендә капланырга тиеш.

**«Огонек» журналы, Мәскәү.**

«КамАЗ-1974» (Ленинград документаль фильмнар студиясе) — төзелештә бер ел дәвамында эшләнгән эшләр турындагы фильм. Аның «Төзелеш хроникасы» дигән икенче бер исеме дә бар. Әмма ул — эшләрнең барышын, объектларның сафка басуын, министрлык вәкилләренең төзелешкә килүләрен һәм башка фактларның гади теркәлеше генә түгел. Фильм авторларының максаты — хәзерге заман төзелешенең үзенчәлекләрен, замандашларыбызның тормыш ритмын тамашачының күз алдына китереп бастырырлык итеп чагылдыру. Алар фильмда күрсәтелгән вакыйгаларга үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерергә, күп санлы фикерләрне һәм образларны гомумиләштерергә омтылалар.

КамАЗ турындагы фильмнар үзәгендә — кеше. Ә төзелештә кешеләр күп төрле. Менә бер кыз. Аның өчен КамАЗ — бөтенесе дә: яшьлеге дә, аның беренче гражданлык омтылышы да, шәхси тормышы да, бәхете дә, туачак балалары да. Менә инженер. Авыр эш көненнән соң ул арыган. Аның өчен төзелеш — күптән сайланган тормыш юлы: шау-шулы оперативкалар, субподрядчылар белән бәхәсләр, авраллар, объектның сафка басуы вакытында кичергән матур хисләр...

Бу — хезмәт һәм үзеңә якын кешеләргә укыган шигырьләр турындагы фильм. Бу — йөк машинасының беренче үрнәге һәм яңаның туу мизгелен тою өчен бер генә минутка шул машина кабинасына кереп утырган чибәр кыз турындагы фильм.

**«Агитатор блокноты», Казан.**

«Автозаводстрой»ның диспетчерлык пунктында бүген диспетчер Люда Руденко һәм оператор Анисья Исаковна дежур торалар. Люданың КамАЗга килүенә инде дүрт ел, ә Анисья Исаковнаның — өч. Люда Тимертаудан килгән, анда ул тегүче булган. Анисья Исаковна Курган тирәсендәге бер шәһәрчектә унтугыз ел китапханәдә эшләгән. 1971 елда «Автозаводстрой»ның ул вакыттагы начальнигы Владислав Александрович Фоменко Чаллыга килүчеләр турында болай дигән иде: «Кадрлар!» «Кадрлар! Тегүчеләр. Тукучылар. Прораб — элекке очучы. Баш диспетчер — пароход капитаны»...

Ул көннәрне Люда да ачык хәтерли. Беренче тапкыр дежур торып кайткач, кычкырып елаган иде: «Леша, кая алып килдең син мине?! Мин — тегүче. Кычкырып сөйләшергә өйрәнмәгән. Тракторны бульдозердан аера белмим. Рацияне, гомумән, беренче күрүем. Кнопкаларны басам, ычкындырам, ә мине ишетмиләр, үзем дә берни ишетмим...»

Хәзер инде ул үз эшенә өйрәнгән. Механизмнарның теләсә кайсын бер-береннән аера белә. Башта ул ире белән шоферлар тулай торагында яшәде. Рация белән эш итәргә дә, хәтта кычкырып сөйләшергә дә өйрәнде. Иң мөһиме: диспетчерга зарур булган сыйфатларны үзләштерде. «Автозаводстрой»дагы ун төзү-монтаж идарәләренә караган барлык төзү хуҗалыклары хәзер аның күз алдында: кемгә ком, кемгә вак таш яки бетон, кемгә бүтән нәрсә кирәк — ул бик тиз белеп ала. Люда Руденко белән Анисья Исаковна «Автозаводстрой»дагы иң яхшы диспетчерлар. «Автозаводстрой»ның хәзерге начальнигы Гостев мондый приказ игълан итте: «Бер сменага ике мең кубометр бетон кабул иткән диспетчерларны йөз сум премия белән бүләкләргә». Әлегә бу премиягә Люда белән Анисья Исаковна гына лаек.

**«Новый мир» журналы, Мәскәү.**

«Машина төзелеше» павильонында «Автотөзелеш технологиясе — 75» тематик күргәзмәсе оештырылды.

Автотөзелешнең куәтле үсеше, автомобильләрне күпләп чыгару һәм аларның сыйфатын яхшырту башлыча технологияне камилләштерүгә, заводларны техник җиһазлар белән тәэмин итүгә бәйле. Заводларда җитештерелә торган 420 дән артык исемдәге продукция хәзер Дәүләт сыйфат билгесе белән чыгарыла.

Без бүген йөк автомобильләренең соңгы модельләре турында сөйлибез.

«КамАЗ-5320» йөк автомобилен бик хаклы рәвештә поезд дип йөртәләр. Трассада бу великан күренгәч, җәяүлеләрнең дә, шоферларның да игътибары аңа юнәлә. Чыннан да, игътибарга лаек ул. Автопоездның тарту көче зур, ул куәтле дизель двигателе һәм камилләштерелгән трансмиссия, хәзерге заманның иң яңа җайланмалары белән тәэмин ителгән. Сигез цилиндрлы автомобильгә «ГКБ-8350» маркалы ике күчәрле, күп йөк сыйдырышлы прицеп тагылган. Шасси конструкциясе аңа төрле җайланмалар һәм агрегатлар урнаштырырга мөмкинлек бирә. «КамАЗ-5320», прицеп белән бергә, 16 тонна йөк күтәрә. Ул барлык төр юлларда халык хуҗалыгы йөкләрен йөртү өчен кулланылачак. «КамАЗ» машинасы илебезнең мөһим төзелешләрендә алыштыргысыз булачак.

**«На этой неделе». Бөтенсоюз халык хуҗалыгының информацион чыгарылышы, Мәскәү.**

КамАЗ — яшьләр төзелеше. Бирердә эшләүчеләрнең 30 меңнән артыграгы комсомол яшендә.

Төзүчеләрнең производство уңышлары, иҗтимагый активлыклары яшьләр арасында идея-тәрбия эшенең куелышына бәйле.

Яшь төзүчеләргә урта белем бирүне уңышлы тәмамлау өчен шартлар тудыру максаты белән комсомол оешмалары кичке һәм читтән торып уку мәктәпләрен шефлыкка алдылар. Алар укучыларның дәресләргә йөрешен, өлгерешен күзәтәләр. Укучыларга тулай торакларда урын беренче чиратта бирелә, укырга җайлы сменаларда эшләргә мөмкинлек тудырыла. Кагыйдә буларак, һәр тулай торакта өйгә бирелгән эшләрне эшләү, дәрес хәзерләү өчен махсус бүлмәләр булдырылган, алардагы китапханәләрдән дәреслекләр һәм әдәби китаплар алырга була. Комсомол комитетларының яшьләрнең укуын оештыру буенча эшчәнлеге шәһәр халык мәгарифе бүлеге белән берлектә төзелгән перспектив план нигезендә алып барыла.

Эре төзелеш оешмаларында, КамАЗның инде сафка баскан предприятиеләрендә кичке мәктәпләргә булышу комиссиясе төзелгән. Аларга администрация, җәмәгать оешмалары вәкилләре керә. Комиссияләр мәктәпләрне комплектлаштыру, контингентны саклау буенча практик эш алып баралар, эшче яшьләрнең уку барышын тикшереп торалар.

«Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең һәм завод комплексларының профсоюз оешмалары, төзү-монтаж идарәләре һәм предприятие җитәкчеләре белән берлектә, социаль үсеш планнарында һәм коллектив договорларда эшче яшьләрнең гомуми белем дәрәҗәләрен күтәрү чараларын үтәүгә зур игътибар бирәләр.

Төзелешнең профсоюз, комсомол оешмалары һәм шәһәрнең халык мәгарифе органнары ВЦСПС секретариаты, ВЛКСМ Үзәк Комитеты бюросы һәм СССР Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе «Һәр яшь эшчегә — урта белем» девизы белән игълан иткән Бөтенсоюз смотрына актив катнашалар.

КамАзда кичке һәм читтән торып уку мәктәпләрендә укучылар контингенты буенча халык хуҗалыгы планы һәр елны үтәлеп килә. 1971 — 1974 елларда 1350 яшь төзүче гомуми урта, 400 дән артык кеше сигезьеллык белем алды. 1974 елда урта мәктәп тәмамлаган 413 кешенең 90 ны югары уку йортларына һәм техникумнарга керде.

Кичке мәктәпләрдә укучыларның күпчелеге төзелеш мәйданнарындагы авыр эш көненнән соң парта артына утыра. Әйе, көзге һәм язгы яңгырлар астында, кышкы бураннарда ачык һавада эшләп кайткач, мәктәпкә барып дәресләр тыңлау җиңел түгел. Ләкин әгәр бу яшьләрдән «Күңелле итеп ял итәргә вакыт каламы

соң?» — дип сорасаң, укучыларның күбесе уңай җавап кайтарачак. Алар киноларга йөрилэр, кызыклы очрашуларга катнашалар. Яшь төзүчеләр атказанган спорт мастерлары — Н. Медведевны, гимнастка Л. Турищеваны, хоккейчылар В. Харламов, А. Мальцев, В. Шадрин һ. б. ларны алкышлап кабул иттеләр. Сабан туе бәйрәмендә КамАЗ яшьләре үзләре турында җыр язган композитор Әнвәр Бакировны бик яратып каршы алдылар.

Күп кенә укучылар тулай тораклардагы «Ассоль», «Ак ладья», «Подружка», «Ромашка» клубларына йөри.

«Кешеләр КамАЗ төзи, ә КамАЗ яңа кешеләрне тәрбияли» дигән сүз бирedә юкка гына киң таралмаган.

**«Народное образование» журналы, Мәскәү.**

СССРның халык артисты, профессор Натан Рахлин җитәкчелегендәге ТАССР дәүләт симфоник оркестрын КамАЗ төзүчеләре яхшы белә.

Бу коллектив Чаллы шәһәрендә күп тапкырлар булды һәм төзүчеләр арасында киң популярлык казанды...

Чираттагы очрашу 9—10 сентябрьдә булып узды. Оркестр «Энергетик» культура сараенда чыгыш ясады. Программада Чайковский, Глазунов, Лист, Бетховен, Римский-Корсаков әсәрләре бар иде. Оркестр А. Лупповның «КамАЗ яшьлеге» симфоник увертюрасын уңышлы башкарды. Бу әсәрдә яңалык пафосы, хезмәт героикасы яңгырый.

Тамашачылар ТАССРның атказанган артисты Гали Ильясовның совет һәм чит ил композиторлары җырларын башкаруын да яратып тыңладылар.

**«Советская Татария», Казан.**

Телевидение журналистларының бер төркеме төзелешнең киноелъязмасын алып бара, «Без КамАЗ төзибез», «Ярышта туган» исемле тапшырулар циклы әзерли.

Телевидение эшчеләр һәм автоград төзүчеләр өчен массовый трибуна булып әверелде.

КамАЗ төзелешенең уңышы һәр төзүченең партия карарларын тормышка ашыруда кертүгән практик өлешенә бәйле. Һәр көнне, һәр айда заданиеләрне яхшы сыйфат белән арттырып үтәргә дип, социалистик ярышка кушылган Сәлахов, Филимонов, Мавликов, Дерибизов, Сабирҗанов, Шатунов, Солтанов бригадалары нәкъ әнә шуны истә тотып эш итәләр. Алар башлангычы телеэкранда киң пропагандалана.

**«Телевидение, радиовещание» журналы, Мәскәү.**

Шишкинның Алабуга янындагы нарат урманын сурәтләгән картинасы һәм Чаллы шәһәренең киң проспектлары. Киң Кама елгасы һәм автомобиль төзүчеләр шәһәре тирәсендәге кырлар. Әле яңа гына салынган бу шәһәрнең кешеләре гаҗәеп яшь, заводлары гаять зур — алар цехлар белән генә түгел, автомат линияләр, конвейерлар, яңа станоклар белән җиһазландырылган бөтен бер заводлар комплексы. Шәһәрнең күренешендә дә, халкында да безнең совет җәмгыяте тормышында соңгы ун ел эчендә барлыкка килгән яңалык үрентеләре төсмерләнә.

Бу шәһәрдә һәр нәрсәгә исең китә, һәр нәрсә сине дулкынландыра, йөз меңнәрчә кешеләрне хезмәткә һәм иҗатка рухландыра.

— Кама буенда заводлар комплексын кору һәм яңа шәһәр салу — экономик һәм социаль эксперимент, — ди КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Беляев.— Әгәр мин, бирedә кешеләргә төзелеш технологиясе буенча да, социаль проблемалар өлкәсендә дә һәр адымда эксперимент ясарга, эзләнергә һәм яңа чишелеш табарга туры килә, дисәм, һич ялгыш булмас. Чаллыда, сиңа кечкенә генә эш тапшырылса да, аны башкарганда иҗат кешесе булмаска мөмкин түгел. Бу нәрсә, минемчә, төзелешкә катнашучыларның эшендә дә, үз-үзләрен тотышларында да үзенең эзен калдыра. Эшкә иҗади мөнәсәбәт — Чаллы кешеләренең йөзен әнә шул сыйфат билгели.

**«Огонек» журналы, Мәскәү.**

## Марсель Зарипов

# БАЛЫКЧЫЛАР



Туристик теплоходның тәгәл үтәлергә тиешле кырыс графигы Идел буйлап сәяхәт итүчеләрнең, белмим, күпмесен генә шулай канәгатьләндерә алыр икән?! Ул тукталыш ясый торган Углич, Горький, Казан, Ульяновск, Саратов шәһәрләре — Иделнең әле бары тик бер өлеше генә. Ә бит аның һәр кисәге, һәр карыш җире үзенчә кызыклы. Теплоход «күрмәмешкә салышып» узып киткән урыннарда да кешеләр яши. Һәркайсының үз шатлыгы, үз кайгысы, үз тормышы. Әнә шулар белән якыннан танышмый торып, теплоходтан карап узган җирләрне яхшы беләм дип әйтү — үз-үзеңне алдау гына ул.

Тольяттидан КамАЗга кадәр булган юлның яртысын узгач, әчкәреге бер утрауда балыкчылар артеле станын күреп, берничә көнгә шунда тукталырга карар иттек. Илебезнең балык җитештерүче төп елгасы буларак та Иделнең даны еракларга таралган. Инде шулай икән, ни өчен әле безгә Идел балыкчыларының эшләре һәм тормышлары белән танышып китү мөмкинлегеннән файдаланмаска?!

Мәрсин балыгы, кырпы, чөгә кебек балыклары белән һәрбер елга мактана алмый. Элек заманнарда патшалар өчен иң тәмле ризыкларны турыдан-туры Рыбинскидан һәм Камадагы Балык бистәсеннән җибәрелгән әнә шундый балыклардан әзерләгәннәр. Хәер, нигә ул төр балыкларга гына мәдхия укырга? Үз эшен яратып башкаручы оста пешекче әзерләгәндә, корбан, сыла, бәртәс, сазан, чуртан, алабуга кебек балыклар да табын түренә куелырлык ризык була алмыйлармыни?!

Әйдәгез, балыкчылар белән якыннан танышып узыйк. Станда бригаданы беренче булып, иркә, шаян тавыш белән сәламләп Малыш каршы ала. Төнге дежурга калган балыкчы иртәнге аш хәзерләү белән мәшгуль: учак өстендә чәй кайната, бөтен артельгә солянка пешерә, кичтән тозлап куйган сыла балыгын кыздыра.

Идел өстендә меңәрләгән моторлы көймәләр гөрли. Бу туктаусыз гөрелте эченнән Малыш үзләренекенең тавышын бик тиз танып ала. Аннан суга сикерә дә балыкчыларга таба йөзеп китә. Көн иртәнге аштан башлана. Артель өстәленә өйдән килгән төрле-төрле ашамлыклар куела. Чиләктәге чәйне зур-зур кружкаларга салып эчәләр. Кемнең нәрсә эшләячәге кичтән үк сөйләшенгән. Шуңа күрә өстәл янында сүз вак-төяк шаярулардан узмый. Әмма артель башлыгы Михаил Тенилинда шаяру кайгысы юк. Соңгы көннәрдә һавалар бозылып торды. Балык тирәнгә, төпкә китте. Ә аны тирәннән тотарга рөхсәт ителми. Бу — балыкның уылдык чәчәргә җыенган чоры.

Бүген көн кояшлы. Кырыс кыяфәтле Тенилин беренче булып чәен эчеп бетерде дә алдындагы ризыгын җыештыра башлады:

— Кузгалырга вакыт, егетләр, — диде ул аннары, башкаларга карап. — Көнне күрәсез, чалт аяз. Эшебез уң булырга тиеш.

Уртача буйлы, базык гәүдәле бригадирның көч-куәте күзгә бәрелеп тора. Менә ул, тамагын кырып, ике потлы моторны иңенә күтәрде дә яр буендагы көймәсе янына китте. Мин дә аңа ярдәм.

Җылым салынган җиргә без күз ачып йомганчы барып җиттек. Һәм ауны эләктереп көймәгә аркылы сала башладык. Ләкин эш без уйлаганча барып чыкмады. Бар көчебезгә тартсак та, җылымны сөйрәп чыгара алмый азапландык.

— Агач тамырына эләккән булса кирәк, — диде Тенилин. — Икенче баштан, агымга каршы тартып карарга кирәк.

Сүз уңаенда Тенилин җитәкчелегендәге артельнең балык тотуны ничек оештыруы турында әйтеп китү урынлы булыр. Гадәттә кайберәүләр җылымны башта көймә эченә җыялар һәм балыгын бушаткач, аны яңадан суга батыралар. Шулай итеп, ауга кергән балыкны бер тапкыр алу өчен ике эш башкарырга туры килә. Ә Тенилин балыкчыларының үз ысуллары бар. Җылымны алар, судан бөтенләй алып тормаслык итеп, баш-башыннан җиргә казыклар белән ныклап беркетәләр. Тотылган балыкны алу өчен җылымны көймәнең бер бортыннан җыя, ә икенче бортыннан шунда ук суга төшерә баралар. Ауны карау һәм кабат урнаштыру өчен вакыт бермә-бер азрык тотыла. Ике балыкчы көненә ким дигәндә ике чакрым озынлыктагы җылымны тикшереп, карап чыга.

Сүзсез-нисез генә эшлибез. Язгы салкын көннәрдән соң кояш көлеп караса да, Иделдә әле һаман җил. Көчле дулкыннар көймәне әрле-бирле айкый. Көймәгә утыруга, миңа ишкәк тоттырдылар. Көймә исә минем ихтыярыма һич кенә дә буйсынырга теләми, агым уңаена сөйри. Моны күреп, Тенилин көймә башыннан сикереп тора да пышылдап кына миңа ачулана:

— Уң ишкәгең белән җитезрәк, тирәнрәк алдыр! Өстән генә чупылдатып барма!

Аның бу ярсулы пышылдавыннан мин бөтенләй каушап калам. Ишкәкләр, үч иткәндәй, мине тыңламый гына бит: суны каерып ишәсе урында, ак күбекләрне як-якка чәчрәтеп, өскә калкып чыгалар. Тенилинның иптәше тиз генә борылып карый да, күзен кысып куя: борчылма, дускай, бирешмәбез, янәсе. Аннан соң яңадан ишкәгенә тотынып, көймәне кирәкле юнәлештә алып китә.

Шунысы гаҗәп: сине малайсытып тиргәп ташладылар, оялттылар. Ә күңелдә беркемгә карата да ачу һәм үпкә юк. Киресенчә, бригадирга ихтирамың тагын да арта, яныңда шундый тәҗрибәле өлкән кеше барлыгын тоеп кат-кат сөенәсең.

Балыкчыларның үз-үзләрен онытып, бирелеп эшләүләрен күзәткән хәлдә, кайчандыр алар турында ишеткәннәремне тагын бер тапкыр хәтердән кичерәм. Һәм менә шуны ачык аңлыйм: башка барлык эшләрдәге кебек үк, балыкчылар тормышында да һәр нәрсә барыннан да элек кешенең үзенә бәйле икән.

Тенилин җитәкчелек итә торган артельдә сигез кеше эшли. Дон, Агыйдел, Кама, Идел елгалары буйлап йөзәр чакрым үтсәң дә, моннан да бердәмрәк, моннан да бәхетлерәк бригаданы табуы кыендыр. Куйбышев диңгезенең югары өлешендә — Камада, Вятка, Зөя һәм башка елгаларда, шулай ук Чувашстан, Татарстан, Мари республикалары күлләрендә промысел алып баручы балыкчыларның Татарстан өлкәара трестында һәр кеше елына иллешәр центнер, ә Тенилин артелендә җитмешәр центнер балык тота. Тугызынчы бишьеллык планын да срогыннан ундүрт ай алда тәгәлләде.

Башлык буларак, Тенилинны артык кырыс кеше дип сөйлиләр. Ә төптәнрәк уйласаң, аңарда кырыслыкка караганда кешелеклелек күбрәк. Ул һәр вакыт, һәр урында башкаларга игелек кылу уе белән янып яши. Аның кырыс һәм таләпчән булуы исә балыкчыларда үз һөнәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләргә тырышуы белән аңлатыла. Башка һөнәр кешеләре турында ничек яратып, мактап сөйләсәләр, балыкчылар да шундый ук җылы сүзләргә лаек булырлык эш күрсәтергә тиешләр — Тенилин әнә шуны таләп итә. Бригадага килеп эшли башлагач шушы принципка буйсынучылар артельдә кала, ә аны кабул итә алмаучыларга балыкчылар гаиләсендә урын юк.

Тенилин үзе дә, аның якын дусты Михаил Пагольдин да гомер буена балыкчылар арасында. Уенын-чынын бергә кушып, Тенилин Пагольдиннан башка бер генә көн дә бригадир булып эшли алмый, диләр. Ләкин көтмәгәндә алар арасында шундый бер күңелсез хәл килеп чыга: Пагольдин артель куйган ауны башкаларга күрсәтмичә бушата һәм андагы балыкны таныш-белешләренә тарата. Тенилин моны бик авыр кичерә, ике арадагы дуслык чак кына өзелмичә кала.

Тәтеш — әллә ни зур шәһәр түгел. Урамда булсын, башка урында булсын, алар бер-берсе белән еш очрашалар. Әмма хәзер аларның дуслыклары элеккегә караганда да ныграк.

Тенилин артелендә әнә шундый тәртип. Аның бригадасына килеп эләктеңме, башбаштаклыгыңны оныт, «мин» дип түгел, «без» дип сөйләшергә өйрән!

Кайвакыт Иделдә шундый көчле давыллар куба, бригада станына барырга бернинди мөмкинлек булмый. Аңа юл тоткан көймәне дулкыннар кауры урынына уйната. Мондый көннәрдә авырлыкның башы станда калган дежурный өстенә төшә. Башкаларның биштәрләрендә калган барлык азык-төлекне үзенеке итеп ашаса да, аңа беркем дә сүз әйтми. Ләкин инде син бөтен артель тоткан балыкка кул сузма!

Бригадада тәртип каты. Ә шулай да Тенилинга барыбер киләләр. Монда артельдәге катгый таләпләрдән беркемнең дә зарланганын ишетмәссең. Балыкчылар арасында иң зур хөрмәт Тенилинга, аның иптәшләренә. Моннан берничә ел элек Тенилин Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Ә күптән түгел бригадага Мәскәүдән министрның союз ярышында җиңүләре белән котлап җибәргән телеграммасы килде.

Һәм, ниһаять, тагын бер нәрсәгә махсус тукталып үтәсе килә. Иң күп хезмәт хакы алучылар кемнәр? Шул ук тенилинчылар. Менә бухгалтерия статистикасы: Николай Шальнов бригадасында һәр кешегә уртача 36 шар центнер балык тотканнар һәм айлык эш хакы 86 шар сум туры килгән. Николай Марков һәм аның иптәшләре заводка һәркайсы 47 шәр центнер балык тапшырган. Аларның айлык эш хакы 107 шәр сум булган. Тенилин бригадасында һәр кеше башына [illegible]5 әр центнер балык тотылган. Хезмәт хакы — 148 әр сум. Өстәвенә Тенилин бригадасы һәр вакыт шулай уңышлы эшли — җәен дә, Иделне калын боз каплаган кыш көне дә...

Узган ел Виктор Сумараковны, яше чыгып, ялга озаталар. Андый очракларда, гадәтенчә, һәртөрле мактау сүзләре әйтелә, хәтта йөзәр сумлык транзистор бүләк итәләр, пенсиясен төп-төгәл 91 сум исәпләп чыгаралар. Ә менә шул киң җилкәле, базык гәүдәле пенсионер хәзер безнең белән көймәдә утыра, җылымнарны җыя һәм: «Әйдә, җитезрәк кыймылда!» — дип бригадирны да шелтәли. Ләкин аның бу сүзендә дә бригадирны ихтирам итү сизелә. Әйе, алар Тенилин җитәкчелегендә эшлиләр дә, аның кулына үз язмышларын да ышанып тапшыралар. Шул ук Виктор Сумараковка, әйтик, бригада җитәкләргә тәкъдим иткәннәр. «Юк, — дип җавап биргән ул, — мин

Михаил белән калам». Тенилинның өлкән абыйсы Дмитрийга да башта артель бирмәкче булганнар. Алмаган. Аның да җавабы кыска булган: «Михаил кул астында ышанычлырак».

Әйе, балыкчылар яхшы беләләр: бригада яки артель белән җитәкчелек итү өчен балыкны яхшы белү генә җитми. Монда иң әһәмиятлесе — холкыңның әйбәт булуы, талант һәм сәләт кирәк.

Әлбәттә, балык турында китаплардан да укырга мөмкин. Ләкин язган буенча гына балыкчы һөнәренә өйрәнү кыен... Менә шуның өчен дә Тенилин бригадасына тормыш баскычларын шактый таптаган балыкчылар да киләләр. Киләләр икән, димәк, бөтенләйгә! Хәер, нигә моңа гаҗәпләнергә? Кеше һәр вакыт кеше булып кала. Үз сәләтенә туры килердәй нинди дә булса эш һәркемгә дә бала чагыннан ук табылмый. Башта ул тегендә-монда сугылып карый. Әмма ничек кенә булмасын, шундый бер көн килеп җитә — аны Идел үзенә чакыра...

Җәтмәләр белән эшебезне ярты көндә бетерәбез һәм моторны яңадан кабызабыз. Тенилин белән Сумараков кулларыннан юеш бияләйләрен салалар. Алар шактый арыганнар. Бер-берсенә каршы утырганнар да папирос арты папирос тарталар.

Бүген уңышлы көн. Тенилинның кәефе шәп. Ярга чыгу белән ул элгечләргә ташлана һәм тагын бер комплект җәтмә ала.

— Әйдәгез, тагын берәрне куеп алыйк. Балык шулпасы пешеп чыкканчы өлгерәбез әле, — ди ул елмаеп.

Беләм, башкалар Тенилин белән бик үк риза түгел. Инде төшке аш вакыты җиткән. Ләкин җәтмәләр яңадан салына. Кире кайтышлый сайрак урынга борылабыз. Уылдык чәчү өчен оя куябыз... Яшькелт су өсте тулы уылдык. Димәк, оя балыкка ошый, уылдык чәчәргә ул шунда килә. Трест балыкчылары узган язда утыз мең урында шундый оя әзерләгәннәр.

— Начар хәзер балыкка,— ди Тенилин һәм ояны суга төшерә.— Уылдыкны бит ул су килгәндә чәчә. Озак та үтми, су чигә. Һәм ничаклы уылдык ярда кала. Өстәвенә, химия белән тагын күпме балыкны агулыйлар.

Белгән кеше авызыннан ишетәсем килә: Иделдә хәзер күпме балык бар икән? Вак балык көтүләрен күпләп үрчетүче махсус заводлар, питомникларның ярдәме тияме? Үрчемне башка елгаларга җибәрәләрме? Мисал өчен Иделнең түбәнге агымында төзелгән һәм хәзерге заман техникасы, тәҗрибәле белгечләр белән тәэмин ителгән Бюртюльский заводын алыйк. Анда һәр ел саен биш миллион чамасы яхшы токымлы балыклар — укборын, чөгә, кырпы үрчетелә.

— Ничегрәк,— дип сорыйм Тенилиннан,— Иделдә балык артамы? Сизелерлекме?

Тенилин кулын селтәде:

— Кая ди ул арту?! Балык тоту елдан-ел авырлаша. Хәзер бары тик вак балыклар гына тотабыз, ә яхшыларын ауларга ярамый, тыелган. Иделне бик нык агулыйлар. Шундый очраклар була: су өстендә кислота яки нефть калдыгы йөзеп йөри. Андый урыннарда җәтмә буп-буш чыга. Балык булса, аны тоту кыен эш түгел, ә менә аны үрчетүе авыррак.

Иделдә үзен иң бәхетле балыкчы санаган Тенилин да әнә шулай борчылгач, башкаларга нәрсә әйтергә кала? Ярга кайтып җиткәнче әле шактый вакыт бар. Шуңа күрә балыкчыларның үзләренә бик үк хас булмаган чигенеш ясарга телим.

Моннан ике ел элек миңа, «Советская Россия» газетасы редакциясе кушуы буенча, Идел буендагы шәһәрләрдә КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының махсус карары нигезендә Идел һәм Урал бассейннары елгаларының пычрануын булдырмау

өчен нәрсәләр эшләнүе белән кызыксынган бригада составында булырга туры килде.

Эшләнергә тиешле эшләрнең масштаблары гаять зур. Идел һәм Урал бассейннарына керә торган елгаларның ярларына 31 автономияле республика һәм өлкә урнашкан. Аларда йөзләрчә заводлар, фабрикалар, промыселлар эшли. Әлбәттә, аларның берсе дә сусыз яши һәм эшли алмый. Иделгә ел саен агып төшә торган ун миллион кубометр пычрак суның хәзергә бары тик яртысы гына чистартыла. Ә алда әйтеп бетергесез зур бурыч тора. 1980 елда Иделгә һәм Уралга алардан күпме алынган булса, шул ук күләмдә чиста су кайтарылырга тиеш. Тугызынчы бишьеллыкта гына да 546 чистарткыч объектлар төзү күздә тотылган иде. 37 шәһәр катлаулы комплекслар төзергә керешә. Ул комплекслар Иделнең суын тулыландыру өчен кирәкле булган барлык механик, химик, биологик ысуллардан файдалана башлаячаклар.

Елгаларыбызның киләчәге турында чын хуҗаларча кайгыртып, судан акыллы, сак файдалануны күрсәтүче мисалларны күп китерергә мөмкин. Һәркем өчен шатлыкны шундый бер мисал китерергә була. Мәскәү елгасында ташбаш, шыртлака, алабугалар яңадан чиертә башлады. Елганың суы чистарганлыгын һәм анда яшәргә мөмкинлек туганлыгын алар шунда ук сизеп алдылар. Ник шулай булмасын! Соңгы биш ел эчендә генә дә башкалабызда 750 чистарткыч корылмасы файдалануга тапшырылды, тагын 460 корылма төзелеп ята. Болар шатлыклы хәл, әлбәттә. Ләкин мактанырга, тынычланып калырга әле бик иртә.

Мин Казандагы «Теплоконтроль» заводында булдым. Бөтен илебезгә билгеле булган бу зур завод «югары культуралы хезмәт предприятиесе» дигән мактаулы исемне йөртә. Ул рәттән утыз тапкыр инде Бөтенсоюз социалистик ярышында квартал саен җиңүче булып килә. Ә менә елгага үзеннән агып төшә торган пычрак суларны чистартмый, шул килеш Иделгә түгә. Заводның директоры булдыклы, хуҗалыкчан, энергияле кеше. Мин аның күп төрле мәсьәләләр буенча төпле, нигезле итеп сөйләгәннәрен тыңларга яратам. Аның җитәкчелегендә эшләүче кешеләр — менә дигән хезмәт сөючән коллектив. Профсоюз оешмасы да бердәм һәм сугышчан. Шулай булуга да карамастан, бу завод Иделне һаман әле пычрата...

Ә моны социалистик ярыш шартларында Иделнең чисталыгын саклау турында бер сүз дә әйтелмәгән, дип расларга тырышучылар булды.

Күңелсез күренеш, әлбәттә. Кызганычка каршы, моңа охшашлы мисаллар аз түгел әле. Социалистик ярыш параграфларында Иделгә карата мәрхәмәтле булу хакында язылмагач, аны теләсә ничек пычратырга, агуларга ярыймы икәнни?

Тенилинның пошынуы балык турында гына түгел. Ул Иделне саклау, аны бездән соңгы буыннарга ата-бабаларыбыздан үзебез алгандагыга караганда аз гына булса да чистарак итеп калдыру турында борчыла.

Станга җитәр алдыннан тынып калдык. Үзара әңгәмә өзелде. Ярга чыгып, көймәбезне үз урынына куйдык. Башка көймәләр инде кайтканнар иде. Без дә учак янына әбәт ашарга ашыктык.

Ашка — балык шулпасы, тал ботакларына кидерелеп, чехоньнан кыздырылган шашлык. Аштан соң яңадан кичкә кадәр эш: тотылган балыкны, сортларга аерып, тартмаларга тутырабыз. Төн җитүгә, станда дежурный гына калдырыла. Бригада балыкны заводка алып китә. Моторлар тавышы акрынайганнан-акрыная. Ә көймәләр, кичке нурларда балкыган елга өстендә кара нокталарны хәтерләтеп, һаман ераклашканнан-ераклаша һәм бераздан күздән югала...

# ГАБДУЛЛА ШӘРӘФИГӘ 50 ЯШЬ

*«Сусыз дәрья», «Аккошлар кайтыр әле» исемле әйбәт повестьлары һәм матур-матур хикәяләре белән китап сөючеләргә яхшы таныш булган прозаик Габдулла Шәрәфигә (Шәрәфетдинов Габдулла Шәрәфетдин улы) 50 яшь тулды. Барлык татар язучылары, журнал редакциясе хезмәткәрләре, редколлегиясе членнары һәм күп санлы укучылар исеменнән без аны шушы зур бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз, иҗатында яңа уңышлар телибез һәм киләчәктә ул тагын да активрак иҗат итәр дип ышанабыз.*

*Г. Шәрәфи хәзер үз буыны — илле яшьлек замандашларыбыз хезмәтен һәм тормышын чагылдыруга багышланган яңа повесть яза. Укучыларыбызга аның шул әсәреннән өзек тәкъдим итәбез.*



## ҮҖӘТ



Авылга хәбәр таралды: яңа укытучылар килгән. Ирле-хатынлылар, имеш. Арурак бер төштән бүлмә кирәк, ди.

Кичкырын бу хәбәр Гарәфиләргә дә килеп керде. Почмак якта аш әзерләп йөргән Зиһнекамалның уйлары хәзер шулар тирәсендә чуала иде. «Шөкер, килгәннәр икән, төкле аяклары белән булсын. Югыйсә соң, бала-чага кайчаннан бирле өйдә утыра...»

Әйбәт кенә укып килгән балаларының кыш уртасыннан бүленеп калуы Зиһнекамалга инде тынгы бирми башлаган иде. Хәзер ул канәгать, күңеле тынычлана төште. Тик менә «Яңалиф» дигәннәре нидер, монысына аның зиһене җитми, шул бераз сагайта хатынны, шунысы шикләндерә. Яңабаштан тотынырлар микәнни?

Шиген басарга тырышып, Зиһнекамал иренә дәште:

— Атасы, балаларга яңа хәреф танытасылар икән. Яңалифчә диделәрме...

Асылмалы лампаны түбән үк төшереп, шуның яктысында камыт төзәтеп утырган Гарәфи тамак кырып кына куйды да тагын эшендә булды. Сүзгә саран кеше Гарәфи. Бик үк хаҗәте чыкмаса, көне буена да авызын ачмас. Әме — ә, җәме — җә аныкы. Кайчагында Зиһ-

некамал: «Ник дәшмисең, ичмасам, ник сөйләшмисең?» — дип талкый башласа гына: «Соң, ни дим, мин белгәннәр үзеңә дә мәгълүм», — дип, сары мыегы астыннан тип-тигез, ап-ак тешләрен балкытып ала да шуның белән бетә. Бу юлы исә, ничектер, бөтенләй үк сүзсез калмады, хатыны камыр җәеп, токмач кисеп өлгергәч кенә булса да, җавап кайтарды:

— Ник, Муса чабатасын үреп бетерде микәнни?

Бу аның гамәлдәге әлифбага ишарәсе булды бугай. Китапның бер битенә чабата ясап утыручы авыл агае төшерелеп, рәсем астына: «Муса чабата үрә» дип язылган иде. Күрәсең, шуны күздә тоткандыр.

Зиһнекамал ул-бу дәшмәде. Байтак вакыт узгач, иртәнге тамчыдай зарыктырып кына, Гарәфи тагын өстәп куйды:

— Яңа әлифтер инде.

Балалар югында, тынычрак чакта, җәелеп бер сөйләшәсе килгән Зиһнекамал, өмете акланмавын күреп, шактый ук сүрелә төшкән иде. Шуңа күрә аның тавышы да үпкәлерәк яңгырады:

— Әйтер идем, ичмасам... Шул булдымы җыеп утырган бер сүзең?!

— Шул.

Ләкин Зиһнекамалның болай гына калдырырга исәбе юк иде. Аның инде баядан бирле әйтергә җыенып та, әле җае чыкмаганга гына әйтмичә торган сүзе бар. Менә ул, кисеп бетергән токмачын ашка салып, казан астына йомычка өстәде дә, түр якка чыгып, иренең каршысына ук килеп утырды.

— Карале, атасы, әнеки җир кипмичә барыбер кайтмый, әллә теге мөгаллимнәрне үзебезгә генә кертәбезме? Тик тора ич кечкенә өй.

Гарәфинең бер түбә астында өч өе бар. Берсен аш өе, икенчесен ак өй дип йөртәләр. Өченчесен, шул ике өй арасына бүрәнәне урталай ярып кына салганын, кечкенә өй диләр. Анысында оныклары белән Гарәфинең анасы Зарифа карчык чуала. Кыш чыгарга ул, гадәттә, Казанда яшәүче улы белән кызы янына китә, алмаш-тилмәш шуларда тора. Ә авылга казлар бибеш чыгарып алдыннан, агачлар яфрак яра башлагач кына кайта. Ләкин аның, авылны сагындым әле дип, кыш уртасында да кайтып төшә торган гадәте бар. Карчык моны бигрәк тә Гарәфие килеп күренсә шулай итә. Ә Гарәфинең бүгенirtәгә калага барасы бар. Шуңа күрә ул хатынына кистереп кенә ни дип әйтергә дә белмәде:

— Тик тора дип...

Ирен ярым-ярты сүзләреннән дә аңларга өйрәнгән Зиһнекамал бу юлы да ялгышмады бугай.

— Кайтып төшсә дисеңме? Ак өйне җылытырбыз. Әнеки кайтмаса да ягарга дип тора идем әле мин аңа. Кызларнымы, малайларнымы шунда күчерергә кирәк. Үсәләр...

— Як соң... Күчер...

— И атасы, алай дип кенә булмый инде ул. Миңа гынамыни? Укучы өч балаң бар, дүртенчесе дә әнә букча даулый. Мөгаллимнәр тирәсендә күбрәк чуалсалар дим. Шәбрәк укырлар иде.

— Ник, болай да ярый ич... Укулары...

— Мәктәптәгесе инде аның мәктәптә. Укымышлы кешеләр күп белә ул...

Гарәфи башын күтәреп хатынына карады да, елмаеп:

— Синең шикелле икән, — дип куйды.

— Көлмәсәнә. Укыган кеше, ни әйтсәң дә, укыган кеше була. Балаларга йокмасмы дигән идем. Ис кермәсме үзләренә тизрәк.

Гарәфи уңайсызланыбрак калды. Саксызрак ычкындырды, ахрысы. Укытасы килә шул хатынның балаларны. Хәер, Гарәфи үзе дә

моңа каршы түгел. Гыйлемнең ни икәнен ул да яхшы белә. Әмма Зиһнекамал күк өтәләнеп тормый. Җире хәзер җитәрлек, мал-туар ишле, каралты-кура җитеш. Балалары да инде кул арасына керә башлады. Тагын ни кирәк авыл җирендә. Йөгерек кенә укый белсәләр, язу-сызуны алдырсалар, шул бик җиткән диебрәк карый Гарәфи. Аның өчен һөнәр өстенрәк, һөнәрле итәсе килә балаларын. Үзе шикелле. Ә үзе ул менә дигән балта остасы. Арба-чана дисәң, коя да куя. Бу яктан осталар авылда аннан башка да бар барын. Ә менә көпчәк ясау кулларыннан килми. Янәшә-тирәдә моны тик Гарәфи генә булдыра. Шуңа күрә, игенчелектән кала, төп килере дә аның әнә шул — соңгысы.

— Ярар,— диде Гарәфи, төзәтеп бетергән камытын читкәрәк куеп.— Дәшеп кара... Килсәләр. Синең бу корт иләңә.

— Корт иленә дип... Чорсыз балалар юк ич бездә. Килмәсәләр, үзләрендә калыр.

Әйтүен әйтте дә, тик үзләрендә генә калдырып бетерәсе килми иде шул Зиһнекамалның. Баягы сәбәпләрдән дә бигрәк, әле күңел түрендәрәк саклаган икенче бер нияте бар хатынның. Укытучылар аркылы Гарәфиен колхозга керергә күндерә алмаммы дип өметләнә. Инде ярты авыл кереп бетте, ә аның мыштымы һаман суза. Имеш, башында Канзафарлар токымы торсын да, шундый колхозга ни дип керсен әле ул Гарәфи. Бүтәннәргә яраган моңа гына ярамый. Үҗәт. Менә нинди гамьнәр бар Зиһнекамалның башында. Укытучылар өйдәш булса, алар белемле кешеләр, ничек тә аңлатырлар иде шул үҗәтенә.

Гарәфи бик яшьли ятим калды. Алты бала иде алар. Бер энесе дә дүрт сеңелесе. Иң олы дигәне Гарәфигә дә уникe генә яшь иде әле. Бәла ялгыз йөримени. Атасыннан соң күп тә үтми, карау җитмәгәнгәме, нindидер зәхмәт тиепме, атлары үлде. Өелешеп килгән бу хәсрәтләр басылырга өлгермәде, авылда ут чыгып, кышның бер төнендә, күршеләрендәге өч хуҗалык белән бергә, Гарәфиләр дә дөрләп яндылар. Элек-электән үк очын-очка чак кына ялгап килгән гаилә төпсез фәкыйрьлеккә чумды. Шундый ишле ояны кыш уртасында кем кертсен дә кем сыендырсын. Әниләре Зарифаның балаларын өй борынча таратасы килми иде. Шуңа күрә ул, авылдан читтәрәк булса да, җимерелергә торган җир идәнле пыста [1] йортка күчте.

Ничек кенә тартышмасын, фәкыйрьлек барыбер җиңде Зарифаны. Кемнәр аркылыдыр юллап, кече улын Казанның бер итек остасына малайлыкка бирде. Аннан кала бер кызын шулай ук калага бала багарга дип алып киттеләр. Ә Гарәфи, олы малай, өч сеңелесе белән анасы янында йорт тоткасы булып калды. Ләкин Зарифа өчен терәк булырлык җире юк иде шул әле малайның. Ә менә Канзафар бай тапты.

Шундый мал-мөлкәт арасында эш чыкмыйча калмас, тамагы булса да үтәр дип, беркөнне Зарифа, Гарәфине ияртеп, Канзафарларга китте. Капка келәләрен басуга, бозау чаклы кара бурзай, ишегалды буйлатып сузылган тимер чыбыктан бәен шудыра-шудыра, абалап өрергә тотынды.

Сагаеп кына керделәр. Кәшәвәй чанага җигеп, баскыч төбенә үк китереп туктаткан кара айгыр, муенын эткә таба борды да, авызлыгын чәйни-чәйни, тапкансың өрер кешеләр дигәндәй, башын чайкап куйды. Ул да түгел, баганаларын сырлап эшләгән болдырга Канзафар бай чыгып басты. Аягында чуар киез итек, өстендә кама тун, башында каракүл бүрек. Канзафар байның затлы тунын да, купшы бүреген дә белә иде Гарәфи. Ә менә алкалы-алкалы кызыл бизәкләр

[1] Русча «пустой» сүзеннән ясалган.

төшереп чуарланган ап-ак киез итеген беренче тапкыр күрүе. Каян күрсен ди, кәшәвәй чанасына утырып, һайт дигәнче узып китә бит ул авыл урамнарыннан.

Канзафар үзенә якынлашып килгән хатынга күз кырые белән генә карап алды да ялчысын дәште:

— Сабирҗан абый, кайда син?!

Лапас ягыннан тавыш ишетелде:

— Хәзер, хәзер...

Озак та үтми, мескен бүреген бастырып ук кигән, чикмән якасын күтәреп, билен кызыл пута белән буган Сабирҗан карт килеп чыкты. Аягында тула оек, чабата. Кулында чыбыркы.

— Кузгалдыкмы?

— Кузгалырбыз, ахры.

Канзафар, баскычтан төшеп, чанага утырам дигәндә, әле хәзер генә күргәндәй, Зарифага таба борылды.

— Нихәл, Зарифа, сау гына йөрисеңме?

— Шөкер әле, Канзафар. Вакытсызрак килдек бугай.

— Йомышың миңа идемени?

— Сиңа иде шул.

Зарифа артында посып торган Гарәфиен янгарак тартып чыгарды.

— Үзең беләсең инде безнең хәлне, Канзафар. Менә шушы малайга бирәр эш табылмасмы дигән идем.

— Хәлең билгеле дә бит. Җәй булса әле бер хәер иде. Ни кушасың аңа хәзер.

Шулай диде дә, тирән уйга чумгандай, кыска гына итеп кыркылган җирән сакалын бармак очлары белән капшарга тотынды. Канзафар, чыннан да, бөтенләй үк уйсыз түгел иде.

Зарифалар янгач, авыл халкы кулыннан килгәнчә аларга ярдәм итәргә тырышты. Кемдер бәрәңгесеннән, кемдер тары ишесеннән өлеш чыгарды. Ә беркөнне карындык тәрәзәле, капка-курасыз йорт янына үрәчәсез чанага җигелгән ат килеп туктады. Чана тавышына, яулыкчан гына килеш, ашыгып Зарифа чыкты. Килүче Канзафар байның ялчысы Сабирҗан карт иде. Ә чанада — аркылы-торкылы салынган ике капчык он. Моны күргәч, Зарифа нишләргә дә белмәде, чананың әле бер, әле икенче ягына чыгып, такмакларга кереште:

— Рәхмәтләр генә яусын инде бу Канзафарга, рәхмәтләр генә төшсен!..

Читтәрәк таптангалап торган Сабирҗан карт та, кулындагы дилбегәсен ат сыртына ташлап, чана янына килде һәм:

— Туктале син, Зарифа, алай ук өзелеп төшмә. Канзафар ул...— дип әйтәсе сүзен түгәрәкләп бетермичә туктап калды. Аннары: — Әйдә, күтәртәсеңме соң? — дип, өстә яткан капчык авызына тотынды...

Өйгә кергәч, аркасындагы капчыкны ишек янындагы бер култыкка шудырды да Сабирҗан карт авыр гына сулап куйды. Аннары, як-ягына карангалап, өй эченә күз йөртеп чыкты. Ярым караңгы кепкечкенә бу өйнең ләүкә кадәрле генә сәкесендә, бер-берсенә сыенышып, дүрт бала утыра. Идәнгә салам «палас» түшәлгән. Мич буенда — сулы кисмәк. Аның янында, аякларын аска бөкләп, мичнең акшарын ялый-ялый, бүрек хәтле генә кәҗә бәтие ята. Бер почмакта бәрәңгеле әрҗә. Шулар белән өй тулган.

— Алай,— дип куйды карт, сакалын учлап. Башка берни дә әйтмичә, икенче капчыкка дип йортка чыгып китте. Зарифа да аның артыннан атлады.

Сабирҗан карт киткәч, балалар, сәләмәләрен аралап, идәнгә сибелделәр һәм: «Әни хәзер кабартма пешерә!», «Әни коймак пеше-

рә!» дип, капчыклар тирәсендә сикерешергә тотындылар. Зарифа исә: «Чүгез, чү, салкын тидерәсез», дип, ялан аяклы балаларын сәкегә кире куып менгерде. Аннары, янып торган мичкә бер-ике пүлән өстәп: «Менә, мич кенә өлгерсен дә шишара пешерермен, бәрәңге тәгәрәтербез», дип, капчык янына килде. Чишеп җибәрсә... Бер балаларына, бер капчыкка карап катты да калды Зарифа. Ишектән элекке күршеләре Миңзифа килеп кергәндә дә әле шул ук хәлендә иде. Кerәкерешенә, такмаклый-такмаклый, Зарифа янына килде:

— И-и-и, ахирәт, баегансың икән. Сезгәдер дип уйлаган идем шул, күреп калган идем,— дип, капчык өстенә иелде. Тик шундук, борынын җыерып, кинәт туктап калды. Он күксегән иде. Укмашып, төерләнеп тора.

Бераздан Миңзифа тагын тотынды:

— Шул каруннан, шул тыңкыштан!.. Игелек күрәсеңме соң! Үрәчәсез чана белән җибәрткән бит тагын. Менә ул нинди, күрсеннәр, имеш. Имансыз!

Бу хәбәр бөтен авылга таралды. Сүктеләр Канзафарны, каргадылар. Бер намазны: «Ятимнәрне рәнҗеткәнсең»,— дип, мәчет картлары үзенә дә әйттеләр, оялтмакчы булдылар. Әмма оялтырсың Канзафарны! Икенче көнне шул ук Сабирҗан карт аркылы, бу юлы инде үрәчәле чанага салып, Зарифага бер пот он җибәртте.

Оялуын оялмаса да, күңеле бик үк тыныч түгел иде хәзер Канзафарның. Ни әйтсәң дә, шул авылда яши, ни булмас таниләр килеп чыкмас. Телдән төшү хәерлерәк.

Әле менә бер аягын чанага куйган килеш, сакалын капшый-капшый, шул турыда тагын бер кат уйлап алды Канзафар.

— Ярар,— диде ул аннары, Зарифага таба борылып.— Әш юк югын. Ятимнәр хакына дип кенә инде. Алай да чәй-шикәрлек түләнер. Шуннан арттырып булмас. Иртәгә килсен.

Дилбегәсен тотып кузлада утырган Сабирҗан карт моңсу гына итеп Зарифага карап куйды. Ләкин бу карашны хатын үзе күрмәде дә, сизмәде дә. Гозерен аяк астына салмауларына куана-куана, Гарәфиен җитәкләп капкадан чыгып китте.

Әгәр белгән булса... Белгән булса соң Зарифа...

Флүн Мусин

# ЕЛЛАР һӘМ ЮЛЛАР

Урал тауларының казакъ далаларына барып тоташкан көньяк итәге буйлап Уй дигән бер елга ага. Мәшһүр тау итәкләреннән башланган бу елга, юлында очраган кечерәк елгалар исәбенә тагын да зураеп, киңәеп ага торгач, бервакыт Тобол елгасына килеп җитә. Тоболдан аның сулары Иртышка, Иртыштан Обь елгасына һәм, ниһаять, диңгез киңлекләренә барып кушыла.

1916 елда Уйның урта бер җирендә утырган Троицк шәһәрендә дөньяга килгән Атилла Расихның тормыш һәм иҗат юлы да беркадәр шушы елганы хәтерләтә. Күп елгалар аша олы диңгезгә барып кушылган әлеге елга кебек, матур әдәбиятка, китапка тирән мәхәббәте күп төрле сикәлтәле юллар аша аны киң әдәбият мәйданына алып чыга.

Атилла Расих иҗат эше белән шактый иртә кызыксына башлый. Урта мәктәптә укыганда ул шигырьләр һәм мәктәп сәхнәсе өчен пьесалар яза. Шул елларда ук хәтта «Таулар итәгендә» дигән роман язарга да тотынып карый...

1928 елда Казанга күчеп килгәч, ул әдәби иҗат эше белән тагын да җитдирәк шөгыльләнә башлый. Шул елларда Мәскәүдә Муса Җәлил редакторлыгында чыккан «Октябрь баласы» журналында аның «Борылыш» исемле беренче хикәясе басыла. Бу — яшь авторны канатландырып җибәрә. Вахитов исемендәге заводның фабрика-завод өйрәнчеклеге мәктәбендә укыганда ул шундагы күп тиражлы «Вахитовчы» газетасы редакциясе каршында оештырылган әдәби түгәрәккә йөри. Түгәрәк утырышларында А. Алиш еш катнаша, кайчак алар янына Х. Туфан, И. Гази, М. Әмир кебек сәләтле яшь әдипләр килгәли.

Болар һәммәсе яшь эшче егетне әдәбиятка тагын да якынайталар, һәм ул әдәби иҗат эше белән торган саен ныграк кызыксына бара. 1934 елда «Чаян» журналында аның шактый зур күләмле «Касса янында» исемле хикәясе басылып чыга. Аннары бер-бер артлы «Таныш кеше», «Кызыл чүлмәк», «Карак» кебек хикәяләре дөнья күрә. Шул рәвешчә, А. Расих әдәбияттагы беренче адымнарын тормыштагы тискәре күренешләрне фаш итүче юмористик әсәрләр язудан башлый. Автор реаль чынбарлыктан шактый гыйбрәтле вакыйга һәм хәлләрне тотып ала һәм аларны уңышлы гына сәнгать чаралары ярдәмендә укучы күз алдына бастыра. Әлеге әсәрләр арасыннан проблематикасының әһәмияте һәм әдәби эшләнеше ягыннан «Кызыл чүлмәк» хикәясе аерылыбрак тора. Биредә автор шул чор кешесенең аңында яңа белән искенең катлаулы көрәшен чагылдырырлык эзлекле конфликт тудыра алган.

Җәйге төннәрнең берсендә «Беренче Май» колхозы члены Шәмсетдин абзый ишегалдындагы чокырдан алтын акчалар тутырылган кызыл чүлмәк таба. Шул чак аның күңелендә ике Шәмсетдин хасил була. Аларның берсе, акчаларны дәүләткә тапшырыйк, ди. Икенчесе каршы төшә. Шактый озакка сузылган бу тартыш икенче Шәмсетдиннең җиңелүе белән бетә. Башкача әйткәндә, герой аңындагы хосусый милекчелек карашлары җиңелеп кала.





Әгәр беренче хикәяләрендә автор башлыча юмор чараларыннан файдаланса, соңга таба инде ул сатирага да торган саен ешрак мөрәҗәгать итә. Бу яктан аның сугыштан соңгы елларда язылган «Каһәр төшкән тел» исемле сатирик хикәясе аеруча характерлы. Аны авторның сатира һәм юмор өлкәсендәге иң зур казанышы дип санарга мөмкин.

Әсәрнең идеясен һәм образларын ачу өчен язучы бик оста алым сайлаган. Ул «дилбегәне» персонажларның үзләренә тоттырган, алар үзләре турында үзләре сөйлиләр, үзләрен-үзләре фаш итәләр. Шул юл белән иң элек үзәк геройның — авылга эшкә китмәс өчен генә татар теле буенча аспирантурага кергән Хәбир Зәбировның гыйльми эшкә сәләтсез бер бәндә булуы ачыклана. Диссертациясе өчен материал җыю нияте белән Әлдермән авылына килгәч, Хәбир анда шундыйрак тагын берничә «тип» белән таныша. Аларның берсе — телгә беткән гайбәтче хатын Мәгъфрүз. Авылда Хәбиргә очраган икенче кеше — председатель Ярулланың да тормыштан аерылган, өстән күрсәтмәләр көтеп, әзергә хәзер булып яшәүче зат икәнлеге ачыклана. Персонажларның чын йөзен ачуда аларның сөйләм теле дә зур роль уйный. Автор геройларның сөйләмен индивидуальләштереп бирә. Тормышчан типларны сатирик осталык белән фаш итү ягыннан А. Расихның бу хикәясе ифрат уңышлы эшләнгән.

Язучының 30 нчы еллардагы иҗатына кабат әйләнеп кайтып, шуны әйтәсе килә: аның беренче хикәяләрендә тормышны һәм кешеләрне сурәтләүдә аерым кызыклы табышлар очраса да, авторны болар гына канәгатьләндерә алмый. Ул үзендә тагын да җитдирәк иҗатка көч барлыгын сизә, күләмле әсәрләр язу турында хыяллана.

Әмма аның бу хыялы тормышка ашмый кала. Бөек Ватан сугышы башлана. А. Расих аны Куйбышев шәһәрендә хәрби хезмәттә каршылый. Беренче көннәрдә үк ул фронтка җибәрелә һәм сугышның башыннан ахырына кадәр хәрәкәттәге армиядә була.

Сугыш А. Расих иҗатында да кискен борылыш тудыра. Башка татар язучылары кебек үк, ул да игътибарын фронт чынбарлыгына юнәлтә. Аның авыр сугыш елларында язылган әсәрләрендә шул чор прозасының гомум тенденцияләре шактый ачык гәүдәләнә.

Сугыш башлану белән әдәбият алдына, иң мөһим бурычларның берсе төсендә, социализм шартларында үскән кешенең характерын, югары мораль сыйфатларын һәм якты идеалларын сугыш ялкыны аша күрсәтү мәсьәләсе килеп басты. Дошман көтмәгәндә һәм хыянәтчел төстә илебезгә басып кергәч, совет кешесенең күңелендә аңа карата көчле нәфрәт ташкыны кузгалды, туган илгә мәхәббәт хисе искиткеч көчле бер төс алды. Сугышка багышлап язылган беренче әсәрләрдә үк менә шул уй-хисләр калку булып чагылды. Тормыш язучылардан оперативлык таләп итте. Нәтиҗәдә прозаның кыска хикәя жанры нык алга китте. Геройның дошманга чиксез нәфрәтен, туган илгә һәм тормышка бетмәс-төкәнмәс мәхәббәтен зур эмоциональ көч белән гәүдәләндерергә омтылу нәсер жанрының активлашуына китерде.

Тора-бара язучылар дәһшәтле чынбарлыкны ачыграк һәм конкретрак сурәтләүгә күчәләр, сугыштагы кешенең үзен тасвирлый башлыйлар. Хикәяләрдә солдат тормышының төрле-төрле яклары күтәрелә. Язучылар еш кына тыныч тормыш шартларында әллә ни күзгә ташланмаган гади кешенең сугыш кырында, хәлиткеч моментта үзен каһарман итеп танытуын күрсәтүгә басым ясыйлар. Г. Бәшировның «Сержант Хәйруллин» исемле хикәясендә, мәсәлән, нәкъ әнә шул проблема яктыртыла.

А. Расихның «Якташларым» хикәясендә исә әлеге проблема бераз башкарак планда хәл ителә. Яңа гына госпитальдә дәваланып чыккан офицерны күпчелеге татар сугышчыларыннан торган взводка командир итеп җибәрәләр. Якташлар янына туры килдем дип, ул башта бу хәбәрне шатланып каршылый. Үз күзе белән взводтагы хәл-

ләрне күргәч, бөтенләй аптырап кала. Яңа командирлары килгәндә солдатларның кайберләре «помидор бакчасында өлгергән помидор эзли, кайберәүләре салам ташый, кайсылары кояшта кызына». Солдатларның мондый «гражданский» кыланышлары «кадр армиядә хезмәт иткән» командирга акылга сыймаслык эш булып күренә. Шуның өстенә сугышчылар коралларын да рәтләп чистартмыйлар икән. Кыскасы, якташлары белән очрашу командир күңелендә шактый ямьсез тәэсир калдыра.

Бераздан шушы кешеләр белән ул сугышка керә. Һәм шунда хәрби тәртипкә иялэнеп бетә алмаган әлеге кешеләрнең хәлиткеч моментта зур батырлык һәм кыюлык күрсәтергә сәләтле булуларын күрә.

Совет кешесенең сугыш кырларында күрсәткән тиңдәшсез каһарманлыгын калкурак итеп күрсәтү максаты белән әдипләр әледән-әле разведчикларга мөрәҗәгать итәләр. Г. Әпсәләмов, И. Гази, М. Әмир, Г. Галиев, А. Әхмәт һәм башкаларның сугыш елларында язылган хикәяләрендә күп санлы разведчик образларын очратабыз. Шул ук нәрсә А. Расих иҗатында да күзгә ташлана. Аның «Дошман тылында», «Сагынылган мәхәббәт» кебек хикәяләрендә һәм «Бәхет орлыклары» исемле маҗаралы повестенда Фатих Ниязов, Ильяс Сабиров, Гәрәев шикелле кыю һәм тапкыр разведчиклар сурәтләнә.

Совет солдатының рухи дөньясы белән кызыксыну да елдан-ел көчәя бара. Геройның мәхәббәт хисләрен сурәтләүгә игътибар арта. Мәхәббәткә мөнәсәбәт сугышчының әхлак йөзен характерлый торган мөһим факторларның берсе итеп карала башлый. Бу мәсьәләне яктыртуда 20—30 нчы елларда язылган кайбер әсәрләр белән полемикага керү дә сизелә. Ачыграк әйтсәк, хәзер революцион аскетизм идеясе кискен рәвештә кире кагыла. Әдипләр совет кешесенең шушы дәһшәтле көннәрдә дә бай рухи тормыш, кызыклы уй-кичерешләр белән яшәвенә басым ясыйлар. Канлы сугыш геройларының интим хисләрен ярлыландырмый, бәлки тагын да көчәйтә, тирәнәйтә генә. Бу фикер А. Расихның «Сагынылган мәхәббәт» исемле хикәясендә аеруча ачык гәүдәләнә. Әсәрнең үзәк герое Ильяс Сабиров «мәхәббәт мәсьәләсендә моңа кадәр уңмаган бер кеше» була һәм үзен бу яктан бәхетсез саный. Менә бервакыт ротага Наилә исемле кыз килә. Аның белән очрашу геройның мәхәббәт хисләрен яңадан дөрләтеп җибәрә. «Фронтта мәхәббәт белән шөгыльләнеп булмый» дип йөргән Ильяс үзе шактый кыен хәлдә ала. Наилә белән утлар-сулар кичкәч, ул әлеге карашның ялгыш булуын аңлый. Геройның мәхәббәте, дәһшәтле көрәш сынавын үтеп, һәр төрле икеләнү-шикләнүләрне җиңеп чыга.

Сугыш елларында А. Расихка күп хәлләрне күреп, күп нәрсәләрне башыннан кичерергә туры килә. Табигый, язучы ул вакытта бар күргән-кичергәннәрен әдәби әсәр итеп язарга өлгерә алмый. Күп нәрсә әдипнең хәтер сандыгында кала бара. Әмма ул сугыштан соң да бу темага тотына алмый. Беренчедән, А. Расих фәнни эшкә бирелеп китә. 1950 елда аспирантура тәмамлап, кандидатлык диссертациясе яклый. Икенчедән, ул 30 нчы елларда ук хыялланган эшен тормышка ашырырга керешә. 1947 елда, үзенең яшьлек елларында күргәннәренә нигезләнеп, «Дустым Мансур» исемле роман яза башлый. Романның язылу тарихына тукталып, А. Расих болай ди: «Бу әсәр минем иҗат яшьлегемнең бер карлыгачы буларак кына түгел, бәлки үземә бик якын, күбесен күреп, хәтта үзем кичереп белгән хәлләр турындагы истәлек буларак та кадерле. Кайчандыр беренче бишьеллык чорында мин дә Карасу кебек бәләкәй бер шәһәрдән чыгып киттем, мин дә Мансурлар, Гарәфиләр кебек станок янына бастым». Билгеле, автор романда үз күргән-белгәннәрен сурәтләү белән генә чикләнми. Аның төп максаты — үз буыны «кичергән ялкынлы һәм михнәтле елларның җылысын, дәртен» хәзерге укучыларга җиткерү. Беренче бишьеллыклар заманының көрәш һәм хезмәт пафосын ачу дәвамында автор мөһим мәсьәләләр күтәрә. Барыннан да элек, ул социализм нигезләрен төзү чорында яңа кеше тәрбияләнүен күрсәтә. Мәгълүм ки, бу мәсьәлә безнең үткәндәге әдәбиятта, аерым алганда, 20—30 нчы еллар прозасында шактый киң яктыртыла. Мисал төсендә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар», Ш. Камалның «Матур туганда», Ф. Сәйфи-Казанлының «Өч нарат» романнарын, К. Нәҗминең «Якты сукмак» һәм «Кояшлы яңгыр», М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе» һәм «Агыйдел», Г. Толымбайның «Түбән Елгада» повестьларын күрсәтергә була. Социализм шартларында яңа кеше тәрбияләү мәсьәләсе бу әсәрләрдә башлыча авыл җирлегендә яктыртыла. А. Расих исә үткәндәге әдәбиятта рәтләп чагылыш тапмаган тормыш ма-

териалына мөрәҗәгать итә. Ф. Хөсни сүзләре белән әйтсәк, «Данлыклы беренче бишьеллык», «бөек борылыш елы» һәм ул елларда эшчеләр сыйныфына килеп кушылган күп санлы яшь эшчеләр турында татар әдәбиятында әллә ни зур байлык юк иде. «Дустым Мансур» романы әнә шул бушлыкны тутыра, безнең күз алдыбызга данлыклы үткән көннәребезне бастыра, шул ук вакытта игътибарны бүгенге бурычларга да туплый»[1].

Билгеле булганча, «Дустым Мансур» романында Карасу дигән кечерәк бер шәһәр янында авыл хуҗалыгы машиналары заводы салуга бәйле вакыйгалар, төрле җирләрдән шул төзелешкә килгән кешеләрнең тормышы, язмышы сурәтләнә. Алар арасында, табигый, үзәк персонаж — яшь егет Мансур образы аеруча күзгә ташлана. Авылдан төзелешкә килеп, квалификацияле эшчегә әверелгән бу егет үз чорының лаеклы улы, аңлы гражданины, тормышны үзгәртеп коручы булып җитлегә. Әсәрнең 1968 елда дөнья күргән икенче басмасында әлеге процесс тагын да нигезләбрәк һәм аныграк итеп күрсәтелә.

Беренче бишьеллыклар заманының төп пафосын, яңа тормыш төзүче кешеләрне, аларның фидакарь хезмәтен калку итеп сурәтләгәнгә күрә роман безнең көннәрдә дә актуаль яңгырый, хәзерге укучыларның да игътибарын җәлеп итә. Укучы хатлары әнә шул хакта сөйли. Байкал — Амур магистрале төзелешендә эшләүче комсомолец егет Яков Осипов, мәсәлән, бу романны укыгач, беренче бишьеллыклар рухын ачык тоюы, шул заман кешеләренең батырлыгына соклануы турында яза. Мин үзем дә 20 нче еллар эшче егете Мансур кебек булырга, безнең көннәрнең иң зур төзелеше БАМны төзүгә мөмкин кадәр зуррак өлеш кертергә телим, ди.

А. Расих — маҗаралы һәм фәнни-фантастик жанр өлкәсендә дә шактый күп эшләгән кеше. Аның дүрт маҗаралы повесте бар.

Билгеле булганча, совет әдәбиятында маҗаралы жанр һәр вакыт заман алга куйган мөһим бурычларны тормышка ашыру максатына хезмәт итте. А. Расих повестьлары да әнә шул яклары белән игътибарны җәлеп итәләр. Моны әдипнең башлангыч чор иҗатына караган «Бәхет орлыклары» повестенда ук күрергә мөмкин.

Әсәрнең язылу тарихы да шактый кызыклы. 1944 елда А. Расих «Фронт хакыйкате» газетасы редакциясендә эшләүче шагыйрь Ш. Мөдәррис белән очраша. Ш. Мөдәррис аны газета эшенә тартырга тели, сугышчыларның маҗаралы әсәрләрне яратып укуларын әйтә һәм аңардан фронт тормышыннан газета өчен берәр маҗаралы әсәр язуын үтенә. Әдип бу үтенечне бик теләп кабул итә һәм «Бәхет орлыклары» исемле бер хикәя яза башлый. Әмма иҗат дәвамында ул хикәядән повестька әйләнә. А. Расих аны 1945 елда Польшада тәмамлый.

«Бәхет орлыклары», Г. Кутуйның «Рөстәм маҗаралары»ннан кала, безнең прозада Бөек Ватан сугышы темасына багышланган икенче маҗаралы әсәр. Гәрчә бу ике повесть бер үк жанрга карасалар да, тормышны һәм геройларны сурәтләү алымы ягыннан алар бер-берсеннән шактый аерылалар. «Рөстәм маҗаралары»нда фантастика өстенлек ала. Укучы малай Рөстәм, күренми торган кешегә әверелеп, немецлар тылына китә һәм анда күп төрле батырлыклар эшләп йөри. А. Расих повесте исә реаль чынбарлыкка якынрак тора. Анда булуы бик тә ихтимал булган хәлләр турында сөйләнә. Автор тәҗрибәле разведчик Гәрәевнең һәм аның ярдәмчеләренең яңа сорт бодай уйлап тапкан карт агроном Федоровны немецлар кулыннан азат иткәндә күрсәткән батырлыкларын мавыктыргыч итеп тасвирлый. Ләкин ул моның белән генә канәгатьләнми, ә бәлки геройларның шәхесе белән дә якыннан кызыксына. Нәтиҗәдә без үзенчәлекле характер сыйфатларына ия булган тормышчан образлар белән очрашабыз. Әйтик, Гәрәев һәм аның юлдашы Гаяз Шәрипов кайчак легенда итеп сөйләрлек тапкырлык һәм батырлык үрнәкләре күрсәтсәләр дә, һич тә ниндидер гадәттән тыш шәхесләр түгел. Гаяз профессиясе белән тыныч тормыш кешесе, ул — агроном. Сугыш аны яраткан хезмәтеннән аера. Фронтка килгәч, ул бераздан партизан отрядына эләгә. Отрядта «хөрмәтле бер кешегә әверелгәнче», кичәге агрономга бик күп авырлыклар кичерергә туры килә. Гомумән, әдип тыныч тормыш кешеләренең сугыш кырында бөтенләй башка яктан ачылып китүләрен күрсәтергә ярата.

[1] «Совет Татарстаны» газетасы, 1955 ел, 16 декабрь саны.

Сугыштан соң язылган «Урланган хәзинә», «Хәвефле сынау» һәм «Сәхи бабай мажаралары» повестьлары шулай ук мажаралы һәм фәнни-фантастик жанрларны үстерүгә мәгълүм өлеш керттеләр.

А. Расихның сугыштан соңгы иҗатына гыйльми-педагогик эшчәнлеге сизелерлек эз сала. Елдан-ел көчәя барган бу йогынты язучы әсәрләрендә төрле формаларда чагыла. Барыннан да элек, әдипнең заман тормышы белән бәйләнеше ныгый, бу аңа чынбарлыкның актуаль мәсьәләләрен үз вакытында күреп алырга булыша. 50 нче елларда, мәсәлән, Казан ветеринария институтының доценты буларак А. Расихка терлекчелек мәсьәләләре буенча бик еш авылларда булырга туры килә. Әле берүзе, әле төрле комиссияләр составында ул республиканың байтак районнарын йөреп чыга. Районнарда йөргәндә, колхозларның экономик хәле белән беррәттән, ул колхозчыларның тормышы белән дә якыннан кызыксына, шул елларда авылда барган хәлләрне күзәтә. Бу әдипкә авылның илленче еллар уртасындагы киеренке тормышы һәм каршылыклы үсеше турында башка кайбер прозаикларга караганда нигезлерәк һәм тирәнрәк фикер йөртергә мөмкинлек бирә. А. Расихның «Ык суы буенда» исемле күләмле очеркы һәм «Язгы авазлар» романы шул хакта сөйли.

Бу әсәрләрдә язучы күбрәк терлекчелек өлкәсендә эшләүче кешеләр, терлекчелеккә караган актуаль мәсьәләләр белән кызыксына. «Ык суы буенда» исемле очеркында, мәсәлән, сөтчелек фермасында эшләүче яшьләрнең яңа, прогрессив хезмәт алымнары өчен көрәше тасвирлана. Алдынгы сыер савучы Мөкәррәмә, зоотехник Галимҗан һәм башкалар сыерларны карау һәм саву эшләрен фәнни нигезләргә салырга телиләр. Әмма аларның бу омтылышына колхоз председателе Кирам каршы чыга. Ник дигәндә, ул борчу-мәшәкатьсез, тыныч кына яшәргә тели, аның ниндидер яңа ысуллар белән баш катырасы килми. Бу бәрелештә, билгеле, яңалык тарафдарлары булган яшьләр җиңә.

«Ык суы буенда» очеркында күтәрелгән әлеге мәсьәлә А. Расихның «Язгы авазлар» романында тагын да киңрәк һәм тирәнрәк төстә яктыртыла.

Мәгълүм булганча, 60—70 нче еллар татар прозасында сугыш һәм сугыштан соңгы еллардагы авыл проблемасы шактый киң яңгыраш алды. Авыл тормышын сәнгатьчә сурәтләүдә ике тенденция күзгә ташлана. Беришә әдипләр игътибарларын шул чор авылындагы яшь буынның язмышын чагылдыруга юнәлдерәләр. Бу мәсьәлә белән башлыча балалык һәм яшьлек еллары шул чорга туры килгән прозаиклар, икенче төрле әйткәндә, хәзерге прозабызның урта һәм яшь буыннары вәкилләре кызыксына. Аларның әсәрләрендә шәхси тәҗрибәләрен, күргән-кичергәннәрен сурәтләү өстенлек ала, яшь герой белән автор арасында рухи якынлык көчәя. Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Баянов, М. Мәһдиев, В. Нуруллин, Ф. Мансуров һәм башкаларның повестьлары асылда әнә шул беренче агымны тәшкил итә.

Сугыштан соңгы авылны сурәтләүдәге икенче мөһим агымга «Язгы авазлар» романы белән А. Расих нигез сала. 1956 елда ук тәмамланып та, нибары 1963 елда гына дөнья күргән бу әсәр рус совет прозасының шул чордагы бер төркем әсәрләренә, әйтик, Ф. Абрамовның «Туганнар» («Братья и сестры»), Е. Мальцевның «һәр өйгә кер» («Войди в каждый дом»), В. Фоменконың «Җир хәтере» («Память земли») кебек романнарына якын тора. Әлеге әсәрләрдә авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек итү мәсьәләләре үзәккә куела һәм конфликтлар да төрле-төрле җитәкчелек стильләре арасында барган көрәшкә нигезләнә.

А. Расих романында төп конфликт «Яңа тормыш» колхозының председателе Ифрат Аллаһияров һәм зоотехник Солтан Фәхретдинов белән председатель урынбасары Баһави һәм райком секретаре Халиков арасында туа. Романда сурәтләнгән вакыйгалар барышында әлеге геройларның артель хуҗалыгын үстерүгә, аның белән җитәкчелек итүгә капма-каршы позицияләрдә торулары ачыла. Аллаһияров белән Фәхретдинов эшкә тотынганда «Яңа тормыш» колхозының, солдат Шакир әйтмешли, «аркалыгы шартлап өзелгән, чөелдерек бавы тегәрҗептәй генә калган» була. Иң аянычлысы шул, сугыштан соңгы елларда бер-бер артлы алышынып торган председательләрнең башбаштаклыгы, тормыштагы материаль кыенлыклар авыл халкының колхозга ышанычын киметә һәм, колхозны чынлап аякка бастыру өчен, яңа җитәкчеләргә күп нәрсәне яңабаштан карап чыгарга, мәсьәләгә яңача якын килергә туры килә. Һәм алар эшне кешеләрнең күңелен күтәрүдән, «эшләгәч, безнең колхоз да нидер бирә икән», ди-

гән ышаныч тудырудан башлыйлар, колхозчыларны материаль кызыксындыру принцибын алга куялар. Шушы нигездә әсәрдә принципиаль конфликт барлыкка килә. Бу конфликтта бигрәк тә Халиков кебек иске тип җитәкчеләрнең чын йөзе ачыла. Җитәкчелек эшен ул «югарыдан килгән директиваларны һич чигенүсез үтәүгә» кайтарып калдыра, җанлы оештыру-аңлату эшен исә үзенә буйсынган кешеләр өстеннән командалык итү, киңәшмәләрдә аларга «накачка» ясау белән алыштыра.

Халиковның шундый якларын фаш итү белән бергә, А. Расих герой алга сөргән принципларның тормыш законнарына каршы килүен күрсәтеп бара. Яңа иҗтимагый шартларда яңа төр җитәкчеләр белән очрашу Халиковның үзенә дә тәэсирсез калмый. Бу образда реаль тормыштан аерылган, «җилләрнең кайсы яктан искәнен аңларга да» теләмәгән консерватив җитәкченең тирән иҗтимагый һәм рухи драмасы чагыла.

Ифрат белән Солтан илленче еллар уртасындагы авылның реаль шартлары эчендә, шул шартлар белән органик бәйләнештә күрсәтеләләр. Әмма алар — тормыш шартларына буйсынып яшәүче пассив кешеләр түгел, бәлки ул шартларны үзгәртү, яңарту өчен кыю рәвештә көрәшеп яшәүче актив шәхесләр. Шулай итеп, биредә «иҗади герой» концепциясе күтәрелә, ягъни реаль тормышта яшәп, аны яхшырту өчен үзләре генә түгел, бәлки коллектив белән бергә киеренке һәм нәтиҗәле көрәш алып баручы геройлар күрсәтелә. Әлеге геройларның тормыштан аерылган, аның агымын тоймаган иске тип җитәкчеләр белән бәрелеше әсәрдәге конфликтның тормышчанлык көчен арттыра. Бу конфликт, тәнкыйтьче И. Нуруллин әйткәнчә, романда омтылышлы хәрәкәт барлыкка китерә, кешеләрдәге яхшы һәм яман якларның калкурак күренүенә ярдәм итә һәм нәтиҗәдә чынбарлыкның күп кенә закончалыкларын ачып бирә [1].

Сугыштан соңгы авыл тормышының төп иҗтимагый һәм социаль-әхлакый мәсьәләләрен күтәргән бу роман йөзендә 60 нчы еллар татар прозасы күп милләтле совет әдәбиятында авыл темасын яктыртудагы мөһим бер агымга килеп кушылды. А. Расих башлаган бу эш соңрак С. Рафиковның «Авыл иртәсе» һәм М. Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романнарында, Г. Ахуновның «Чикләвек төше», Ф. Хөснинең «Мәйдан», В. Нуруллинның «Күпер чыкканда», Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестьларында дәвам иттерелде һәм үстерелде.

Авторның үзе өчен бу романның төп әһәмияте шунда: ул әдип иҗатының 60 нчы елларда шактый җитлегә төшүе, аның заман чынбарлыгына тирәнрәк үтеп керүе, тормышны һәм шәхесне бөтен тулылыгында һәм катлаулылыгында чагылдыру юнәлешендә тагын да үсүе турында сөйли.

Бу юлда яңа бер адымны А. Расих үзенең «Ике буйдак» романында ясый. Әсәрдә, барыннан да элек, язучының конфликт төзү осталыгы камилләшә төшүен күрәбез. «Ике буйдак»та конфликт тагын да катлаулырак төс һәм полифоник яңгыраш ала, автор аны эзлеклерәк һәм нигезлерәк итеп үстерә. Әгәр «Язгы авазлар»да иҗтимагый һәм әхлакый конфликтлар әле бер-берсеннән аерылыбрак торсалар, монда инде алар үзара тыгыз үрелеп биреләләр. Бу хәл герой тормышының иҗтимагый һәм шәхси өлкәләрен органик бәйләнештә сурәтләргә мөмкинлек тудыра.

Озак еллар фән өлкәсендә күргән һәм кичергәннәренә нигезләнеп язылган бу роман, А. Расих иҗатының зур казанышы булу белән бергә, 60 нчы еллар прозасында барган мөһим идея-эстетик эзләнүләрне дә чагылдыра. Барыннан да элек, роман узган ун еллыкта прозабызның офыклары киңәя баруы турында сөйли. А. Расих татар укучысын шактый яңа бер дөньяга — фән дөньясына алып керә. Биредә тагын да әһәмиятлерәк икенче момент әдипнең бу дөньяны ничек сурәтләвенә карый. Бу уңайдан язучының герой хезмәтен белү мәсьәләсенә аеруча басым ясыйсы килә. Совет әдәбиятында хезмәт кешесенә, хезмәтне сәнгатьчә танып белүгә игътибар һәр вакыт зур булды. Геройның хезмәтен, «производствоны» яхшы белү язучыларга заман сулышын тирәнрәк тоярга, аның яңа проблемаларын һәм конфликтларын табарга булыша. Герой хезмәтен белү — ул барыннан да элек аның һөнәрен яхшы белү дигән сүз. Бу эшнең әдип өчен нихәтле әһәмиятле булуына тукталып, Л. Леонов болай яза: «Хәзерге язучыга герой профессиясен белмичә һич тә ярамый, чөнки профессия кешене эпоха белән бәйли торган чара ул... Геройның профессиясен өйрәнү... гомерен

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1964 ел, 1 сан, 144 бит.

хезмәттә үткәргән кеше рухының бөтен тирәнлекләренә үтеп керергә ярдәм итә... Кечкенә «профессиональ» деталь кайчак характерны бөтенләй башка яктылыкта күрсәтә ала» [1].

Фән-техника революциясе чорында хезмәтнең кеше тормышындагы роле тагын да үсә. Шуңа күрә әдәбиятта да герой хезмәтен, производствоны өйрәнүгә игътибар артканнан-арта. Хезмәт процессының тышкы ягын тасвирлаудан арына барып, язучылар производство мәсьәләләренә тирәнрәк үтеп керергә омтылалар. Һәм бу юнәлештәге эзләнүләр язучыларны кызыклы ачышларга китерә. Нәтиҗәдә элеккерәк елларда, технологик процесслар белән артыграк мавыгу сәбәпле, укучыларда шактый кире тәэсир калдырган «производство» темасы соңгы вакытта үзенә тулы хокук яулый. Партиянең XXV съездында хезмәт темасына багышланган иң яхшы әсәрләр хәзерге әдәбиятның мөһим казанышы дип бәяләнде.

Алтмышынчы еллар татар прозасының бу юнәлештәге эзләнүләре һәм ачышлары, безнеңчә, А. Расихның «Ике буйдак» романында аеруча ачык чагыла. Геройларның хезмәтен яхшы белү авторга яңалык белән искелек көрәшен үзгә планда, фәндәге төрле тенденцияләрнең һәм карашларның үзара бәрелеше төсендә гәүдәләндерергә ярдәм иткән. Роман белән танышканда, без бер-берсенә бәйле төстә барлыкка килгән берничә конфликт белән очрашабыз.

Башта конкрет фәнни проблемага бәйле рәвештә романның үзәк герое Рәхим Шәйхрамов белән кафедра мөдире профессор Филиппов арасында җитди конфликт туа.

Күңелен күптән биләгән фәнни проблеманы өйрәнү теләге белән Рәхим, берни белән исәпләшеп тормастан, шәһәргә күчеп килә һәм авырлык белән элек үзе укыган институтка гади лаборант булып эшкә урнаша. Биредә аны берсеннән-берсе зуррак яңа кыенлыклар көтә. Кафедра планында ул өйрәнергә теләгән проблема каралмаганлыктан, аңа тәҗрибәләрне эштән соң гына һәм берничнди ярдәмчесез үткәрергә туры килә. Монда да күп төрле комачаулар чыгып тора...

Әмма, берниндн кыенлыкларга да карамастан, Рәхим тәҗрибәләрен дәвам итә һәм «калкансыман бизләрнең эшчәнлеге белән карындагы микрофлора арасында бәйләнеш» барлыгын ача. Институтта әле яңарак кына эшли башлаган лаборантның бу ачышы кафедра сотрудникларында бөтенләй кире реакция тудыра. Чөнки бу ачышы белән ул кафедра мөдире профессор Филипповның гомер буе эшләгән хезмәтен юкка чыгара икән. Шул хәлләрдән соң фән даирәләрендә танылган галим һәм горур табигатьле кеше Филиппов институттан я мин, я Шәйхрамов китәргә тиеш дип, мәсьәләне кабыргасы белән куя. Рәхимгә, кафедрадагы фәнни эшен калдырып, учхозга ветеринар булып күчәргә туры килә.

Әмма ул көрәшне туктату турында уйлап та карамый. Киресенчә, бу хәлдән соң көрәш кискенләшә генә төшә. Әлеге көрәшнең драматик ягы шунда: Филиппов үз карашларының дөреслегенә һич тә шикләнми. Рәхимне исә ул төрле юллар белән фәндә дан казанырга омтылучы гади бер карьерист дип уйлый.

Менә шундый шартларда, зур принципиальлек һәм ихтыяр көче күрсәтеп, Рәхим ректордан үзенең эшен тикшерү өчен авторитетлы комиссия төзеттерә. Комиссия лаборантның хаклылыгын исбат итә һәм горур профессор үләр алдыннан Рәхимгә:

— Сез кайчандыр минем тарафтан ясалган методик хатаны тапкансыз, аны төзәтеп безнең кафедраның намусын саклап калгансыз. Рәхмәт сезгә,— ди.

Филиппов белән Шәйхрамов арасындагы конфликтны сурәтләү дәвамында әсәрдә икенче сюжет сызыгы барлыкка килә. Ул Рәхим белән доцент Заһид Сафичның үзара мөнәсәбәтләрен эченә ала. Башта дуслар булып очрашкан бу ике буйдак арасында бераздан төрле каршылыклар барлыкка килә. Профессор үлеп, Заһид Сафич вакытлыча кафедра мөдире итеп билгеләнгәч, ул каршылыклар җитди конфликт дәрәҗәсенә җитәләр. Автор бу хакта болай яза: «Моңа кадәр ике буйдак икесе ике юлдан баралар, берсе профессорның яшьлек юлын, ә икенчесе олыгайган көннәрдә сайлаган юлын дәвам итә. Менә хәзер бу юллар очрашты һәм, яшенле яңгыр буласын белгертеп, болытлар куера башлады».

---

[1] «Литература и современность». Рус теленнән тәрҗемә, җиденче җыентык. Мәскәү, 1967 ел, 367—368 битләр.

Кафедраның фәнни эшчәнлегенә, аның юнәлешенә һәм максатларына төрлечә карау нигезендә барлыкка килгән бу конфликт Шәйхрамов белән Филиппов арасындагы конфликттан бермә-бер киңрәк яңгыраш ала. Ягъни ул, гомумән, фәннең максатларына, фән кешеләренең үз хезмәтенә төрлечә карауларына нигезләнгән төп конфликтка әверелә. Рәхим фәнне тормыш белән тыгыз бәйләнештә үстерү, фәнни прогресс өчен көрәшә. Заһид Сафич исә тормыштан аерылган «саф теория»не алга сөрә. Алга таба геройларның бу карашлары аларның гомумән тормышка, яшәүнең максатына төрлечә караулары белән бәйләп аңлатыла. Алар тормышта төрле юллар сайлыйлар. Заһид Сафич «бер дә хәвеф-хәтәргә тармыйча, тыныч кына, сак кына» бара торган такыр юлны сайлый. Доценттан үрнәк алгандай, кафедраның күп кенә сотрудниклары да шундый юлга басалар. Алар, диссертация яклаудан инде күптән өмет өзеп, «мәшәкатьсез, тыныч» яшәргә тырышалар.

Рәхим исә «авыр көрәштән курыкмыйча һаман һөҗүмгә бара». Билгеле, бу авыр, мәшәкатьле юл булып чыга. Аңа кемнәр беләндер дошманлашырга, кемнәрнеңдер каһәрле сүзләрен, һәр төрле гайбәтләрен ишетергә туры килә. Ләкин Рәхим бернидән дә курыкмый. Чөнки, аныңча, бары тик шундый көрәш-бәрелешле юл гына чын бәхеткә алып килә. Максаты тормышчан булган кебек, Рәхимнең бәхет идеалы да тормышчан, конкрет. Шунлыктан ул киләчәккә кыю карап яши.

Бәхет турында Заһид Сафич та әледән-әле уйлана. Әмма ул дөньяда бәхет барлыгына ышанмый, аны гомер буе ашкынып та ирешеп булмый торган мираж итеп карый. Киләчәк аны үзенең билгесезлеге белән куркыта, шуңа күрә ул бүгенге көн белән, тыныч һәм хафасыз яшәү ягын карый.

Романның өченче әһәмиятле сюжет сызыгы мәхәббәт җирлегендә туа. Һәм ул Заһид Сафич, зоотехник кыз Мәдинә һәм Рәхимнең бер-берләренә шәхси мөнәсәбәтләре төсендә яктыртыла. Мәхәббәт линиясе романдагы ике төп конфликтка бәйле рәвештә формалаша һәм әлеге конфликтлар нигездә хәл ителгәч, ул алгы планга чыга. Бу яктан «Ике буйдак» беркадәр «Язгы авазлар»ны хәтерләтә. Чөнки, алдарак күренгәнчә, ул романда да конфликтлар һәм сюжет сызыклары шушы тәртиптәрәк бирелгәннәр иде. Әмма хәзер иҗтимагый һәм әхлакый конфликтлар, геройларның иҗтимагый һәм интим мөнәсәбәтләре, әйтелгәнчә, үзара тагын да тыгызрак үрелеп бирелә.

Романның байтак өлешендә Заһид Сафич белән Мәдинә арасындагы мөнәсәбәтләр яктыртыла. Баштарак бу ике кеше бер-берсенә якыная баралар. Заһид Сафич кызны ярата башлый кебек, Мәдинә дә кыен вакытта үзенә ярдәм кулы сузган доцентны хөрмәт итә һәм «бу хис, үсә төшкәндә, бәлки яратуга да әйләнеп китәр», дип уйлый. Әмма Заһид Сафич белән якыннанрак танышкан, аның күңелен һәм характерын ныграк аңлый төшкән саен Мәдинәнең аңа булган хөрмәте кими бара. Аның каравы, учхозда бергә эшләү, авырлыкларны бергә җиңү дәвамында Рәхим белән Мәдинә үзара якыная баралар, бу якынлык тора-бара көчле мәхәббәт хисенә әйләнә.

Заман герое, аның мораль-политик йөзе һәм тормышка мөнәсәбәте хакында «Ике буйдак» романында башлаган җитди сүзне А. Расих бераз башкарак планда «Каһарманнар юлы» романында дәвам итә. Әсәрнең төп проблемасы аның исемендә үк әйтелгән. Әйе, роман үзәгендә каһарманлык мәсьәләсе тора һәм автор үз игътибарын чын каһарманнар юлын тасвирлауга юнәлтә. Әмма әсәрдә сүз нинди каһарманнар турында бара соң? Әйтергә кирәк, баштарак әсәрнең максатын аңлап бетермәүчеләр дә булды. Роман «Казан утлары» журналында басыла башлагач, кайбер иптәшләр, аның исеменнән чыгып, әсәрдә сүз Беренче татар бригадасының гражданнар сугышы елларындагы сугышчан юлы турында барырга тиеш дип санадылар һәм, шул ноктадан карап, автор адресына тәнкыйть фикерләре дә әйтеп чыктылар.

Чынлыкта исә А. Расих башкарак максатны күздә тота. Ул тормыштагы олы иҗтимагый максатлары һәм идеаллары өчен кыю рәвештә көрәшеп яшәүче бүгенге каһарманнарның юлын тасвирларга алына. Әсәрдә каһарманлык турында җитди сүз бара, ул чын каһарманлыкны ялганнан аера белергә өйрәтә. Уйлап карасаң, каһарманлыкка төрле юллар белән ирешергә мөмкин икән. Әйтик, күпчелеге гади эшчеләрдән һәм крестьяннардан торган Беренче татар бригадасы сугышчылары, Идел буеннан Урта Азиягә кадәр гаять авыр, дәһшәтле көрәш юлы үтеп, күп кан коеп, халык азатлыгы өчен сугышларда тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп, каһарман исе-

менә лаек булалар. Ә менә Хәмзә Бакиров дигән бер бәндә бу исемгә башка юллар белән ирешмәкче. Гражданнар сугышы бетеп, күп еллар үткәч, татар бригадасы сугышчыларының күбесе үлгән булудан файдаланып, ул бригада тарихы турында матбугатта уйдырма «истәлекләр» чыгара башлый, аларда төрле юллар белән үзен «герой» итеп күрсәтергә тырыша.

Шушы типны, аның ялган каһарманлыгын фаш итү романның әһәмиятле сюжет сызыгын тәшкил итә. Бу эшкә яшь тарихчы Альфред һәм бригаданың исән калган сугышчыларыннан Хәбибрахман абзый алына. Алар бик мәкерле һәм тормышка оста җайлашкан әшәке тип белән очрашалар. Башка әсәрләрендәге кебек, биредә дә А. Расих тискәре персонажның психологиясен һәм яшәү принципларын ышандырырлык итеп ача. Шул ук вакытта әдипнең бу тип геройлар галереясының шактый төрле булуын да әйтергә кирәк. Әйтик, Бакиров инде Заһид Сафич кына түгел. Ул әлеге доцентка караганда күп мәртәбә активрак һәм сугышчанрак. Бу яктан Бакиров Ә. Еникинең «Рәшә» повестендагы Зөфәр Сабитовтан да уздыра кебек. Бакиров алдынгы совет кешесе булып күренергә, изге идеалларга ябышып яшәргә тырыша. Ул хәтта Хәбибрахман абзый аның чын йөзен ачкач та югалып калмый, куркып, куак артына посмый, бәлки үзенең җинаятьчел эшләрен аклау юлына баса. Һәм, беренче карашка, аклый да кебек. Үз сүзләренә караганда, истәлекләр язу эшенә, янәсе, ул изге ният белән, бригаданың хәзер инде онытыла башлаган героик юлын бүгенге буынга белдерү, аның турында язып та, сөйләп тә халыкка җиткерү теләге белән тотынган икән. Нигә башкалар күрсәткән батырлыкны үзенә үзләштерәсең, дип сорагач, Бакиров: «Тарихта батырлыкның кем тарафыннан ясалуы әһәмиятле түгел... эш... ысулда түгел, ә максатта» дигән фәлсәфә белән акланып калмакчы була. Хәбибрахман абзыйны болай да ышандыра алмагач, Бакиров тактиканы үзгәртергә мәҗбүр: «...Әгәр сез безнең арадагы конфликтны куертып йөрсәгез, ул бары бригада тарихын бетерүгә юнәлгән бер эш кенә булачак. Ул тарихтан бөтен кеше шүрли башлаячак, тарихчылар аңа кул селтәячәкләр. Ә бу килеш безнең узган шанлы юлыбыз үзенә билгеле бер гражданлык ала, ул тора-бара халкыбызның зур хәзинәсенә, үткәндәге мактаулы бер сәхифәсенә әвереләчәк», — ди ул. Шулайрак килеп чыга да. Хәбибрахман абзый Бакировны фаш итеп мәкалә китергәч, газетаның әдәби сотруднигы:

— Сез бик абруйлы, безнең газетка да күп язышкан бер кешегә каршы киләсез, — дип, аның мәкаләсен кире кайтара.

Шул рәвешчә, Беренче татар бригадасының тарихын язарга алынган геройларга зур кыенлыкларга очрарга туры килә. Шул авырлыкларны җиңеп чыгу һәм бригада турында дөреслекне раслау өчен Альфред белән Хәбибрахман абзыйдан зур ихтыяр көче һәм каһарманлык сорала. Аларның каһарманлыгы тормышта принципиаль булуда, иң кыен вакытларда да кешелек һәм гражданлык намусыңа тап төшерми яшәүдә чагыла. Бу яктан Альфред белән Хәбибрахман азый А. Расихның «Язгы авазлар»ындагы Солтан һәм Ифратка, «Ике буйдак»тагы Рәхимгә якын торалар. Образларны ачу чараларында да охшашлык сизелә. Һәр өч романда да уңай геройларның тормыш фәлсәфәсе, дөньяга карашлары һәм характер сыйфатлары тормышчан итеп сурәтләнгән тискәре персонажлар белән принципиаль конфликтларда ачыла.

А. Расихның геройны сурәтләүдәге тагын бер әһәмиятле сыйфаты персонаж характерын, аның рухи дөньясын каршылыклы уй-кичерешләр, эчке рухи конфликт аша чагылдырудан гыйбарәт. Аның әсәрләрендә билгеле бер иҗтимагый-рухи обстановкада тәрбияләнгән герой, башкарак бер атмосферага эләккәч, үз-үзе белән конфликтка керә һәм моңа кадәрге карашларының, яшәү принципларының ялгыш булуын аңлый.

«Каһарманнар юлы»ндагы Латифны алып карыйк. Трест управляющие урынбасары дәрәҗәсенә ирешеп, тормышы «билгеле бер көйгә салынган рәвештә тыныч һәм рәхәт» кенә аккан көннәрнең берсендә аңа Мюнхен шәһәреннән хат килеп төшә. Һәм бу хәл геройга аяз көндә яшен суккандай тәэсир итә. Чөнки хат күптән үлгән дип йөргән әтисеннән була. Баксаң, аның әтисе исән, Көнбатыш Германиядә яши икән. Бу хат аны бик нык куркуга сала. Чөнки Латиф әтисен моңа кадәр халык бәхете өчен көрәштә һәлак булган гражданнар сугышы герое дип санап йөри. Ә ул әнә гап-гади бер дезертир, икенче төрле әйткәндә, сатлык җан булып чыга.

Бу вакыйга Латифның тормышка карашларын сынау өчен җитди имтихан була. Шуннан язучы аның тормышка карашы формалашкан шартларны сурәтләүгә күчә. Бу яктан Латиф Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романындагы Хәсән Мортазинны беркадәр хәтерләтә. Аларның икесенең дә яшьлеге илдә сыйнфый көрәш кызган чорга туры килә һәм бу хәл геройларның иҗтимагый-рухи үсешенә мәгълүм эз сала. Мортазинны Г. Әпсәләмов «бөек, катлаулы чорның матурлыгы белән бергә, барлык каршылыкларын үзләренең биографияләрендә чагылдырган кешеләрнең берсе» итеп күрсәтә. Шушы ук фикерне Латифка карата да әйтергә мөмкин. Әлеге каты көрәшле елларда ул үзенә «дошманнан дошман, дустан дус туа» дигән фикерне сеңдерә һәм сыйнфыйлык мәсьәләсендә үтә сизгер һәм шәфкатьсез булып үсә, хәтта «сул-лык» чире белән дә авырый. Ә менә хәзер, Мюнхеннан хат алгач, аның ул карашлары җимерелеп, чәлпәрәмә килә. Күп уйланулардан соң ул үзенең ялгышын таныргa мәҗбүр була.

Заманның мөһим иҗтимагый-әхлакый мәсьәләләрен һәм конфликтларын яктырту белән бергә, А. Расих тарихи-революцион үткәнгә дә еш мөрәҗәгать итә. Биредә әдип үз игътибарын бу теманың үзенчәлекле һәм бик әһәмиятле бер тармагына — халыкның үткәндәге данлы улларына юнәлтә.

Гәрчә «Ямашев» романы бөтенләй башка чорга карaса да, аны А. Расихның алдарак тикшерелгән әсәрләреннән аерып карап булмый. Чөнки үзенең проблематикасы буенча бу роман «Язгы авазлар», «Ике буйдак» һәм «Каһарманнар юлы» белән тыгыз бәйләнгән һәм әдипнең идея-эстетик эзләнүләренең үзәк юлында тора. Әлеге романнардагы кебек үк, «Ямашев»та да заманның алдынгы героен эзләү үзәккә куела. Язучының, революциягә кадәрге тормыштан шундый геройны эзләп, Ямашев шәхесенә мөрәҗәгать итүе дә очраклы хәл түгел. Эш шунда, беренче татар большевигы Ямашев татар дөньясында массаларның марксистик-ленинчыл революцион хәрәкәте тудырган яңа тип геройның беренче үрнәкләреннән берсе була. Заманның алдынгы героен актив эзләгән Тукай бу хакыйкатьне шул чорда ук сиземләгән. «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» исемле шигырендә ул Ямашевны халыкка турылыклы хезмәт итүче гражданин һәм көрәшче итеп сурәтли. Ямашев шәхесенә тагын «Безнең көннәр» романында Г. Ибраһимов мөрәҗәгать итә. Ул аны әсәрнең үзәк геройларыннан булган большевик Зариф Булатовның прототибы итеп ала.

Әйтергә кирәк, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов әсәрләрендә без Хөсәен Ямашевның тарихи яктан тулы образын күрмибез. Әдипләр андый максатны алга куймаганнар да. Аларның нияте башкарак. Ачыграк әйтсәк, Тукай халык каһарманының поэтик гомумиләштерелгән образын гәүдәләндерүне максат итә. Ибраһимов профессиональ революционер образын тудырырга алына.

А. Расих романында исә Хөсәен Ямашев тормышын һәм эшчәнлеген яктыртуга башкачарак киленә. Әсәр хәзерге идея-эстетик таләпләрне искә алып язылган. Биредә геройның тарихи дөрес образын тудыру максат итеп куела һәм моның өчен автор күбрәк реаль фактларга нигезләнеп эш итәргә омтыла. Шунлыктан романда күбрәк реаль фактлар һәм реаль вакыйгалар турында сүз бара. Шуларга нигезләнеп, А. Расих геройның истә калырлык, тормышчан образын тудырырга тиеш була. Мондый эшне әдәби әсәрдә бары тик иҗади фантазия ярдәмендә генә башкарырга мөмкин. Менә ни өчен А. Расих романда иҗат фантазиясен актив эшләтергә тырыша. Бу нәрсә язучыга бигрәк тә аерым новеллаларда (роман аерым новеллалардан тора) Ямашевның эчке дөньясын, борчулы уй-кичерешләрен истә калырлык итеп бирергә булыша.

Әсәрнең күпчелек өлешендә исә автор башлыча үзәк геройның революцион эшчәнлеге белән кызыксына. һәм бу хакта хикәяләүне күбрәк вакыйгалылыкка нигезләнеп һәм рационалистик рухтарак, уй-хисләр төрлелегенә һәм тасвир чаралары муллылыгына артык омтылмыйча, биредә хәтта беркадәр саранлык күрсәтеп, кыскасы, документаль-публицистик пландарак алып бара.

Актив җәмәгать эшлеклесе булган Ямашев үз чорының төрле-төрле иҗтимагый катлаулары белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә. Алгы планда Ямашевның көрәштәшләре — революционерлар тора. Бу персонажларның күбесе — тарихи шәхесләр. Әсәр үзәгендә тормаганга күрә, бу геройларга Ямашевка булган кадәр игътибар бирелми. Автор аларны башлыча аерым штрихлар ярдәмендә генә күз алдына бастыра. Менә

«укымышлы кыяфәтле, эре сөякле» Саммер, «һәр вакыт тыныч, гадәтенчә, һәрбер сүзен үлчәп сөйли» торган Лозовский, «мәһабәт буйлы, яшь булса да чәче коелган киң маңгайлы, ачык йөзле» Кулеша, «тәптән юан, киң җилкәле» Табейкин һ. б.

«Ямашев» романында тарихи шәхесләрне сурәтләү белән бергә, автор үз фантазиясендә туган геройларны да күрсәтә. Әйтергә кирәк, бу очракта язучы үзен ничектер иркенрәк сизә һәм сәнгатьчәнрәк тасвирга омтыла. Әсәрдә бигрәк тә эшче хатын Тәгъзимә, авыл ярлысы Фәрхетдин һәм интеллигент Җәгъфәр образлары, аларның гыйбрәтле рухи эволюциясе ышандырырлык итеп бирелгән. Бу образлар аша автор Беренче рус революциясенең төрле иҗтимагый катлауларга ничек тәэсир итүен гәүдәләндерә. Шул ук вакытта бу персонажлар үзәк геройны ачу чарасы да булып торалар. Мәсәлән, реакция башлану белән революциядән ваз кичкән, куркак һәм җебегән интеллигент Җәгъфәр белән бәхәсләрдә Ямашевның идея һәм әхлакый яктан бик өстен торуы, аның революция идеалларына ахыргача турылыклы булып калуы үзгә бер көч белән гәүдәләндерелә.

А. Расих үзенең иҗат бәйрәмен Хөсәен Ямашевка багышланган дилогиянең икенче китабы белән каршылый. «Айлы төннәр» романында Ямашевның революцион эшчәнлегенең тагын да әһәмиятлерәк этабы — реакция елларында Оренбургта татар телендә большевистик «Урал» газетасын чыгаруы сурәтләнә. Саран гына детальләр һәм штрихлар ярдәмендә язучы геройның бу эшне нинди шартларда алып баруын күрсәтә. «Айлы төннәр»нең образлар галереясы «Ямашев»ныкы белән чагыштырганда чикләнгәнрәк. Аларның берничәсе белән укучы беренче китап буенча таныш. Шундыйлардан Фәрхетдин һәм Җәгъфәрнең реакция елларындагы иҗтимагый рухи эволюциясе шактый ачык төсмерләнә. Әгәр беренче китапта авылдан шәһәргә бәхет эзләп килгән ярлы егет Фәрхетдин 1905 елгы революцион вакыйгалар өермәсендә югалып калган булса, хәзер ул бераз акча эшләү нияте белән Оренбургка килеп чыга һәм биредә Ямашев һәм аның көрәштәшләре йогынтысында чын-чынлап революцион көрәшкә кушылып китә. Җәгъфәр исә һаман тормышта үз урынын таба алмый бәрелеп-сугылып йөри.

Тарихи шәхесләрдән яңа романда Г. Тукай белән Г. Коләхметовка чагыштырмача күбрәк урын бирелә. Берничә генә эпизодта автор аларның Ямашевка, аның эшчәнлегенә мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Әсәр, «Урал» газетасы полиция тарафыннан ябылгач, Тукайның көрәшне дәвам иттерү теләге белән Чиләбегә китеп барган Ямашев турындагы уйлары белән тәмамлана. Бары ике генә тапкыр очрашса да, шагыйрь аны гомерлек дустын озаткандай озатып кала: «Кешелекне алга алып баручылар, тәрәккый иттерүчеләр — шушы Хөсәеннәр бит инде», дип уйлана.

Заманның менә шундый әйдәп баручы актив геройларына һәм үзәк иҗтимагыйәхлакый конфликтларына йөз тотып, аларны реаль барлыгында һәм зур ышандыру көче белән гәүдәләндереп, А. Расих тормышның да һәм әдәбиятның да алгы сафында атлый.

**Флера Ганиева**

# ӘДИП ГОМЕРЕ

Язучының әдәбият тарихындагы урыны үз халкына калдырган иҗат мирасының зурлыгы һәм әһәмияте белән билгеләнә. Әдипнең гомере аның әсәрләрендә дәвам итә.

Мәсьәләгә шул яктан якын килгәндә, Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани — безнең мәдәният тарихында хөрмәтле урын алырга лаек шәхесләрнең берсе. Кыска гына иҗат гомерендә ул күп хикәяләр һәм сәхнә әсәрләре, зур-зур романнар язган. Замандашлары аны талантлы журналист, актив җәмәгать эшлеклесе һәм педагог буларак та яхшы белгәннәр. Ләкин бүгенге укучы гыйбрәтле һәм катлаулы иҗат юлы үткән бу әдип турында бик аз белә. Аның әсәрләре ныклап өйрәнелмәгән, тормыш юлы ачыкланып җитмәгән.

Дөрес, хәзер М. Галәү иҗаты белән кызыксыну артканнан-арта бара. Үзебездә һәм үзәк нәшриятларда бер-бер артлы аның әсәрләре басылып тора, тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә багышланган җитди мәкаләләр чыгып тора[1]. Соңгы елларда Мәскәү, Казан, Оренбург һәм Астрахань шәһәрләренең архивларында М. Галәүгә кагылышлы күп кенә яңа документлар табылды[2]. Шуларның һәммәсе әдипнең тормыш һәм иҗат юлын шактый тулы итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Мәхмүт Галәү 1886 елның сентябрь аенда хәзерге Татарстан АССРның Арча районы, Ташкичү авылында ярлы хәлфә семьясында туа.

Булачак язучының бала чагы шул авылда үтә. Ул крестьян тормышының бөтен авырлыгын, борчу-мәшәкатьләрен күреп, ярлы халыкның ачы язмышын татып үсә. Зурлар белән бергә кыр эшләренә йөри, крестьян малайларының күпчелеге кебек, урак ура, көтү көтә. Гомер юлының башлангыч адымнары, шул чакта кичергән шатлыклар-кайгылар аның күңеленә беренче бизәкләр, беренче тамгалар булып төшә. Әгәр Мәхмүт Галәү үз әсәрләрендә авыл табигатен, авыл халкының гореф-гадәтләрен, үен-бәйрәмнәрен, тормыш-көнкүрешен, авылдагы төрле социаль катлауларның холык-фигылен, психологиясен бөтен нечкәлекләренә кадәр зур осталык белән тасвирлый алган икән, монда бала чактагы беренче тәэсирләрнең дә роле зур була.

Унбер яшьтә Мәхмүт Казанга килә һәм шәһәр мәдрәсәләренең берсенә укырга керә. Биредәге тәртипсезлек, гаделсезлек яшь шәкерт өчен сыйнфый аңның беренче дәресләре була. Бай шәкертләргә самавар куеп, сабакларын өзерләшеп алты ел укыган дәвердә ул гыйлем дә ала, тормыш мәктәбен дә үтә. Мәдрәсәнең тузанлы, тынчу һавасы, күпчелек хәлфәләрнең һәм мәдрәсә җитәкчеләренең наданлыгы, артталыгы, шәкертләрнең яшьлеген туздырган, акылын томалаган искелек аның күңе-

---

[1] Г. Кашшаф. «Муть. Мухаджири» романнарының 1959 елгы басмасына кереш мәкалә; Р. Мустафин. Страницы жизни народной. «Дружба народов» журналы, 1959 ел, 10 сан; Ә. Фәйзи. Мәхмүт Галәү. «Әдипнең эрудициясе» исемле китап, 113—118 битләр һ. б.

[2] Болар арасыннан бигрәк тә Мәскәү шәһәр комитеты җибәргән анкета сорауларына җаваплар да зур игътибарга лаек (Әдәбият һәм сәнгать үзәк дәүләт архивы, 1651 фонд, 1 тасвирлама, 1 саклану берәмлеге, 21—22 битләр.



ләндә нәфрәт һәм ачу хисләре уята. Шул хис, М. Галәү иҗатының башыннан ахырына кадәр бер дә сүнмичә, көйдергеч ут булып бара.

1904 елда ул Астраханьга китә һәм шундагы татар мәктәпләренең берсендә балалар укыта башлый. Әмма укытучылык эшен озак дәвам итәргә ирек бирмиләр: балалар арасында атеистик карашлар таратканы өчен аны эшеннән куалар. Соңыннан, үз эшчәнлегенең шушы ягына тукталып, ул болай яза: «Инде динчелек мәсьәләсенә килсәк, минем һичбер вакытта динче булганым һәм динчеләргә ияргәнем юк. Киресенчә, яшүсмер чагымда ук мин ул заманда һәркем тарафыннан динсезлек белән танылган, шуның өчен укытучылыктан куылган, динсезлек таратуым өчен патша суды тарафыннан алты ай[га] крепостька хөкем ителгән кеше. Алай гына да түгел, татар муллаларының минем хакта: «Аңар сәлам бирмәскә, баласы туса, исем кушмаска, үлсә, мөселман каберлегенә күммәскә», дигән карарлары да бар» [1].

Астраханьда яшәгән елларда Мәхмүт Галәү революцион хәрәкәткә катнашып китә. Ул РСДРПның Астрахань татар группасында член булып тора, комитетның органы булган «Туп» журналын чыгаруда катнаша. Шул елларда Астрахань шәһәрендә актив революцион эш алып барган күренекле большевик Моратов (Зариф Садыйковның псевдонимы — Ф. Г.) белән бәйләнешкә керә, шәһәрнең татарлар яши торган бистәсендә агитация эшләре алып бара, забастовкалар оештыруда булыша, революцион эчтәлекле прокламация һәм листовкалар язышa [2].

Язучының бу чор эшчәнлеген турыдан-туры аның катнашы белән чыккан «Туп» журналы һәм анда басылган материаллар бик ачык чагылдыра.

Әдәби, сәяси, рәсемле көлкә «Туп» журналы 1907 елның 2 мартында чыга башлый. Демократик позициядә торган бу журнал җәмгыятьтә ул чактагы тигезсезлек һәм гаделсезлекне фаш итә, социаль һәм милли изүгә каршы чыга. «Туп ниләргә атачак?» дигән баш мәкаләдә журнал үзенең мәсләген һәм максатын бик ачык аңлата: «Туп» иң әүвәл хөкүмәтнең егылырга торган иске крепостена, бөтен кызганыч халыкны аяк аска салып изүче истибдад (деспотизм — Ф. Г.) үгезенә, иске тормыш бүркенә атылачактыр. Аннан соң бөтен тугрылыкка каршы төшүче, тәрки вә мәгариф дошманнары — хәзрәтләргә; хезмәттән качып, үзен суфи күрсәтеп, мәдрәсәдә ятучы надан карт хәлфәләргә; ике ботын югары күтәреп селеккәндә агызыннан бер әлиф төшмәслек, мулла белән байларга кул баглап һәм аларның кулын ялап, үз вөҗданнарене сатучы һәм иптәшләренең битләрен кызартучы шәкертләргә; үзләре унсигез сәгать йоклап, фәкыйрь эшче-крестьяннарның унсигез сәгать эшләгән көчләре белән җилкә калынайтучы уналты потлы байларга, унҗиде потлы помещикларга; халык өчен файдалы нәрсәләрне язарга өркүче татар мөхәррирләренә; череп-сасып беткән нәрсәләр белән халыкның башын авырттыручы җәмәгать рәисләренә... атылачактыр» [3].

Журналның популярлыгын арттыруда андагы материалларның үткен сатирик формада бирелүе дә зур роль уйный. «Туп»та басылган фельетон-мәкаләләрдә үк инде без М. Галәү иҗатына хас сатираның үзенчәлекле үрнәкләрен очратабыз. Сатира объекты, аңа хас алымнар, кыска, төгәл формалар (кара-каршы сөйләшү, төрле хәбәрләр, сүзлек, мәкаль-табышмак һ. б.) кыю әйтелгән фикерләргә тәңгәл килеп тора. Бу алымнарны язучы соңрак әдәби әсәрләрендә халыкның тапкырлыгын, рухи сыйфатларын, геройларның характерын ачу өчен файдалана.

[1] М. Галәү. «Ударниклар» идарәсенә ачык хат. «Ударниклар» журналы, 1932 ел, 9 сан.
[2] Астрахань дәүләт архивы, 286 фонд, I тасвирлама, 414 саклану берәмлеге, 471—489 битләр.
[3] «Туп» журналы, 1907 ел, 1 сан.

Билгеле, дини фанатизмга, реакциягә үтергеч һөҗүм ачкан «Туп» журналына иркенләп яшәргә ирек бирмиләр. Столыпин «галиҗәнабларыннан» килеп язылган мәкалә урнаштырган өчен, Астрахань вице-губернаторы тарафыннан журналның беренче санына ук арест салына. Шул ук вакытта Астрахань округ суды журналның редакторын ике айга төрмәгә ябарга дигән карар чыгара.

Бу карар көченә кергәнче, журналның тагын ике саны чыгып өлгерә. «Туп»ның өченче санына тагын арест салына һәм ул бөтенләйгә ябыла.

Әлеге вакыйгалардан соң М. Галәү охранка күзәтүе астына алына һәм, ахыр килеп, Оренбургка күчеп китәргә мәҗбүр була.

Бирегә килгәч, ул башта Кәримовлар һәм Хөсәеновлар типографиясендә наборщиклык һәм корректорлык хезмәтен башкара. 1909 елдан шул ук типографиянең китап кибетендә сатучы булып эшли. 1914 елда ул «Белек» исемендә нәшрият оештыра, үзе үк аның җитәкчесе була. М. Галәү Оренбургта да журналистлык һәм публицистик эшчәнлеген дәвам итә. 1908 елда басылган «Милләтчеләр», 1917 елда чыккан «Беренче мөселман съезды отчеты» дигән брошюралары, революциядән соң солтангалиевчелекне фаш итеп язган мәкаләләре аның әзлекле һәм дәвамлы рәвештә иҗтимагый мәсьәләләр белән кызыксынганлыгы турында сөйли.

Оренбургка күчеп килгәч, М. Галәү рус әдәбиятын ныклап өйрәнә башлый, рус классикларының аерым әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ул А. Пушкинның «Буран», Л. Толстойның «Хаҗи Морат» һәм «Крейсер сонатасы» исемле әсәрләрен, А. Пушкин һәм М. Лермонтовның күп кенә шигырьләрен тәрҗемә итә. Шул ук вакытта бу олы художникларның иҗаты аның өчен рухи азык та, илһам чыганагы да була.

1909 елда ул «Папалар вә муллалар яхут Ян Гус» дигән публицистик хезмәт тәрҗемә итә. Нәкъ шушы хезмәтне сайлап алуы да бик характерлы. Ян Гус — чех халкының патриот улы, милли азатлык хәрәкәтенең җитәкчесе. Озак еллар Прага университетының ректоры булып эшләгән прогрессив карашлы галим. Крестьяннарны һәм һөнәрчеләрне яклаганы һәм атеистик карашларыннан баш тартмаган өчен, урта гасырның иң зур еретикларыннан берсе буларак, утта яндырыла.

М. Галәүнең уку-укыту, мәгариф эше өлкәсендә башкарган хезмәтләре дә җитди игътибарга лаек. 1911 елда ул беренче сыйныф балалары өчен әдәбият буенча «Төрки уку» китабы бастырып чыгара. Шул ук елда аның икенче кисәге дә дөнья күрә. «Төрки уку» китабы балалар өчен язылган кыска хикәяләрдән тора. Җыентыкка кертелгән әсәрләр табигать күренешләре, кошлар-җәнлекләр дөньясы, балалар тормышы, өлкәннәрнең хезмәте, төрле һөнәрләр турында сөйли. М. Галәү балаларда тырышлык, югары әхлак сыйфатлары тәрбияләүне максат итеп куя, җиңел аңлаешлы, матур әдәби тел белән яза.

Оренбург шәһәрендә М. Галәү «Кармак» исемле тагын бер рәсемле көлке журналы оештырып җибәрә, үзе үк аның баш редакторы һәм төп язышучысы була. «Кармак» фанатик руханиларны, халык байлыгы белән кесә калынайтучы помещикларны, искелеккә ябышып яткан мөгаллимнәрне, кулларыннан бер файдалы эш килмәсә дә, буш сүз сөйләргә һәм ришвәт алырга остарып беткән «җәмәгать эшлеклеләрен» көн яктысына чыгара.

Журнал кармагына динчеләр эләккәндә сатира аеруча үткенәеп китә. Язучының хикәя һәм романнарындагы мулла-мәзиннәрне игътибар белән күзәткәндә, ул образларның яралгылары «Кармак»та басылган фельетоннардан ук килүен чамаларга мөмкин. Кайбер материаллар исә М. Галәүнең әдәби әсәрләренә шул килеш үк диярлек күчкән. Менә бер мисал: «Казан муллалары спирт, одеколон булмаганга корбан бәйрәме күңелсез үтте дип зарланганнар. Ярый әле, Печән базары әһелләре чүпрә ашап, лимонад эчеп исерүне уйлап тапканнар. Өстәвенә, корбанлык белән дә күңелсезлек килеп чыккан... 20 кеше җыелып, корбанга дип, сатып алалар бер сарыкны. Үзләре: «Бигрәк арык бит, кыямәт көнне безне ничек сыйрат күпереннән алып чыгар икән», дип сөйләнәләр. Шуны ишетеп, сарык бик куркуга төшә дә җанын туры китереп кача. Аны ике көн, ике төн куалар, ләкин ул тоттырмый, чөнки шулкадәр кешене гонаһларыннан коткара алмам да алла каршында оятлы булырмын дип курка» (1915 ел, 19—20 сан). Бу фельетон, соңыннан бераз үзгәртелеп «Мөселман ите» исемле сатирик хикәядә файдаланыла. Ярлылар тәненә сөлек булып ябыш-

кан мулла-мәзин образлары да романнарда кабат тергезеләләр. «Туп» журналыннан ук килә торган «сөлекләр» дигән эпитет «Болганчык еллар» романына бүлек исеме булып кереп китә.

«Кармак»тагы материаллар Мәхмүт Галәүнең эшчәнлеген һәм иҗатын тагын бер яктан ачып җибәрә. Журнал Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һәм Габдулла Тукайларны татар әдәбиятының иң зур фигуралары итеп саный. Күп мәсьәләләрдә бу әдипләр белән фикер, караш уртаклыгы күренә. Алар белән рухи уртаклык Галәүнең революциядән соңгы иҗатында да дәвам итә. Аның иҗатына аеруча Г. Тукайның тәэсире зур була. Аның шигырьләрен поэзиянең иң югары үрнәге итеп пропагандалау, мәктәп дәреслекләренә кертү, Г. Тукайга карата аеруча бер җылылык, шагыйрь язмышы өчен тирән әрнү белән язылган мәкаләләр — бу тәэсирнең ачык мисаллары.

Бөек Октябрь революциясен Мәхмүт Галәү Оренбургта каршылый. Революциянең беренче көннәреннән үк ул зур дәрт белән эшкә керешә, нәшрият эшләре һәм мәгариф өлкәсендә кирәкле белгеч булып танылa. Аңа тапшырылган эшләр дә шул турыда сөйли. 1919 елда ул Башкортстанда халык мәгарифенең кантон бүлегендә мәктәп секторы мөдире булып эшли. 1920 елда Оренбург губернасының мәгариф бүлегендә нәшрият эшләрен җитәкли. 1921 елда ПУРның «Восток» бүлегенә нәшрият начальнигы итеп билгеләнә. 1925 елда исә М. Галәүне Мәскәүдәге Үзәк нәшрият каршында наборщиклар мәктәбен оештырырга чакыралар, ахырдан ул бу мәктәпнең директоры була.

Бер үк вакытта язучының иҗтимагый эшчәнлеге дә активлашып китә. Башкалада яшәгән елларда ул язучыларның Мәскәү шәһәр комитеты члены, ревизия комиссиясе әгъзасы, Үзәк әдәби кабинетта консультант һәм «Коммунист» газетасы каршында әдәби тел түгәрәгенең җитәкчесе була. Гомеренең соңгы елларында СССР Язучылар союзы каршындагы тәнкыйть-библиография институтында эшли. Әдәби иҗат белән үрелеп барган киң диапазонлы мондый эшчәнлек Мәхмүт Галәүнең иҗат офыкларын киңәйтеп җибәрә, аңа тормыш сулышын тоеп яшәргә, дөньяга карашын үстерергә мөмкинлек бирә.

Мәхмүт Галәүнең матур әдәбият өлкәсендә актив эшчәнлеге 1920 еллардан башлана. Күп санлы очеркларында, хикәя-повестьларында язучы илдә барган үсешүзгәрешне чагылдырып барырга, яңа тормышның үткән белән бәйләнешен күрсәтергә омтыла.

Тормыш кына түгел, кешеләр дә яңара. Ләкин кешеләрнең аңын, психологиясен үзгәртү, аларны искелек сөременнән, гасырлар буе килгән гореф-гадәтләрдән арындыру гаять катлаулы һәм озак процесс булып чыга. М. Галәүнең игътибар үзәгендә менә шушы күзгә күренми торган, әмма корбаннар таләп иткән үзенчәлекле фронт була.

«Салам торханнар» (1926 ел) пьесасында татар интеллигенциясенең төрле катламнары күрсәтелә. Илдә зур вакыйгалар, кискен сыйнфый көрәш барган елларда интеллигенция вәкилләренең төрлесе төрле юлдан китә. Берәүләр үз язмышын ил, халык язмышы белән бәйли. Икенчеләре ачыктан-ачык Советка каршы көрәш юлына баса, чехка, Колчакка барып кушыла. Ләкин бер якка да кушылмыйча, битараф калырга тырышучылар да була. Хәлим Мансуров, мәсәлән, аклар белән китми, үзенең «милли, иҗтимагый» газетасы белән кызыллар ягында кала. Һәм шулай җиңел генә социалист булып китәргә уйлый. Ләкин аның «яңаруы», «социалист»лыгы җае чыкса-чыкмаса «милләт, мәнфәгать» дип авыз суы кортудан узмый. Әмма үзен милләт хадиме дип санаган бу кеше хәлиткеч вакыйгалар каршында каушап, аптырап кала. Гали аны гаепләп: «Салам торханнар! Гомерең буенча фәлсәфә сатып, һәркемне эшсезлектә, юлсызлыкта гаепләп йөр дә, нәүбәт үзеңә килгәч, чиген!» — ди.

Язучының 20—30 нчы елларда язылган хикәяләрендә яңа кеше проблемасы, искелек белән яңалык көрәше, шәһәр белән авыл мөнәсәбәтенә бәйле күп төрле мәсьәләләр күтәрелә. «Каяу» хикәясендә, мәсәлән, гади авыл карчыгының ничек итеп шәһәр тормышына, андагы яңалыкка күнегүе сурәтләнә. Улы белән килененең яңача, алласыз яшәүләре башта карчыкны тәмам хәвефкә төшерә, ул моны үз башына төшкән бер афәт итеп карый. «Ул тышкы күренеше белән яхшы ук картайган булса

да, әчке тормышы белән борынгы әнкәй иде. Әйтеп бетермәсә дә, безнең тормышны шактый ятсына, бик күп нәрсәбездән җирәнгән төсле тоела. Кайчагында базарда сатыла торган итләрне кем суйганлыгын да сорашып куя. Урамда йөргәндә, колбаса кибетләре яныннан узарга туры килсә, авыз-борынын каплап уза. Өйгә кайткач, урамда чагында урыс-марҗаларга кагылып киткән итәкләрен юып, киптереп тә йөргәли иде».

Ләкин яңа тормышның уңай якларын күргәч, үзенә дә, якыннарына да артык зыян тимәгәнлеккә ышангач, карчык акрынлап тынычлана. Өстәвенә, әби гаҗәп кызыксынучан, бик зиһенле бер кеше булып чыга. Ул'радионың ничек сөйләвен тикшерә, бер дә иренмичә аның антенналарына кадәр карап йөри. Яшьлегенә кире кайткандай, һәр яңага сокланып, канатланып яши башлый. Карчык бераз юмористик пландарак, ләкин автор тарафыннан зур симпатия белән сурәтләнә.

Яки менә «Күкеле сәгать» хикәясендәге Сиражи абзый белән Бану җиңгине алыйк. һәр көз, уңыш җыяр алдыннан, Бану җиңги: «Быел, насыйп булса, бер арба солының акчасын, аллага тапшырып, сәгать алырга багышларбыз инде, атасы», — дип сүз башлый. Сиражи абзый җайлап кына: «Ярый, вакыты җиткәч, күрербез әле, сәгать алырбызмы, сипарат булырмы?» — дип куя. Китәләр шуннан әләгешеп. Менә ничә еллар инде шул бәхәс чишелмәгән килеш сузылып килә.

Ниһаять, Бану җиңгинең хыялы тормышка аша. Ләкин күкеле сәгать, бөтен күрше-күләнне кызыктырып, бераз гына йөри дә, Бану җиңгинең нәкъ үзе төсле, көйсезләнә башлый. Ахырдан күп маҗаралар кичергән сәгатьнең тактасын Бану җиңги сөт чүлмәгенә капкач итеп йөртә башлый.

Мәхмүт Галәү эшчеләр тормышына да шактый еш мөрәҗәгать итә. Аның зур күләмле «Күпләрнең берсе» исемле хикәясе типография эшчеләре тормышына багышланган. Эшчеләрнең революциягә кадәрге хәле белән бүгенге көнкүреше оста чагыштырыла. Автор отышлы детальләр, төгәл буяулар таба алган. Билгеле, эшкә социалистик мөнәсәбәт тәрбияләү, иске тормыштан калган гадәтләрдән котылу җиңел генә бирелми. Үткән тормышның авырлыклары әле онытылмаган, аның сөреме, эшче кулына сеңгән тимер тузаны кебек, гел куңелне борчып, яңа гадәтләргә киртә булып тора. Ләкин коллективның көче зур, ул күпләрне, күпләрнең берсе булган Ризван абзыйны да уйланырга, үз тормышына яңача, аек күз белән карарга мәҗбүр итә.

«Төеннәр» җыентыгына тупланган хикәяләрдә дә җитди, актуаль мәсьәләләр күтәрелә. Хикәяләренең исемнәре үк аларда куелган проблеманы аңларга булыша. Гомумән, Мәхмүт Галәү әсәрләренә исем куюга гаять зур әһәмият бирә, аларда төп мәсьәлә, төп вакыйга гына түгел, шул мәсьәләләргә авторның мөнәсәбәте дә чагыла.

М. Галәүнең барлык әсәрләре диярлек тормышны тирәнтен өйрәнү нигезендә языла. Ул тормыштагы вакыйгалар белән даими төстә кызыксынып яши, еш кына зур төзелешләрдә, колхоз-совхозларда була [1].

Колхоз-совхозлар тормышы белән танышу нәтиҗәсендә, 1933 елда М. Галәү «Кабылсай» исемле роман яза. Романда революциядән соңгы авылда яңа тормыш төзү һәм шул юлдагы каршылыклар турында сүз бара. Әсәр үзенең мөселманлыгы, «гөнаһсызлыгы» белән горурланып гомер кичергән Туктамыш картның яңа төзелгән дуңгыз совхозына эшкә китеп баруын сурәтләүдән башлана. Каршылыклы хисләр кичерә Туктамыш. Бер яктан, ул дуңгызның мөселман өчен «харам» мал булуын яхшы белә. Бала чагында, күрше рус авылына баргач, дуңгыз баласы белән уйнаганы өчен кулын ут белән «чистартканнарын» да хәтерли. Ләкин шул ук Туктамыш революцияне күргән, гражданнар сугышында акгвардиячеләргә каршы сугышкан, колхоз төзүдә катнашкан кеше, аның улы һәм кызы — актив комсомоллар. Гаделлек, дөреслек мәсьәләсенә килгәндә ул менә дигән әйбәт кеше, гел колхоз дошманнары, динчеләргә каршы көрәшеп яши. Шулай да үз вөҗданы белән япа-ялгыз калганда анда мөселманлык «инсафлыгы» уяна, ул икеләнә башлый. «Кабылсай» совхозына үзе теләп эшкә китүе Туктамыш өчен зур сынау була. Ул укырга-язарга өйрәнә, барыннан да бигрәк сыйнфый дошманны танырга өйрәнә.

---

[1] 20—30 нчы еллар матбугатында М. Галәүнең Днепростройга, Мәскәүдәге метро төзелешенә багышланган мәкаләләре басыла. Колхоз төзелеше уңае белән татар-башкорт районнарында йөри һәм газеталарда очерклар бастыра.

«Кабылсай» совхозының директоры Идрис, рабочком председателе Федоров, агроном кыз Асия, зоотехник Фатыйх, студент-практикант Икбал, совхоз эшчеләре Гөлчирә, Вера яңа тормыш төзү өчен янып йөри торган, үзләрен аямый торган коммунистлар, комсомоллар итеп биреләләр. Совхозга килеп оялаган сыйнфый дошманнар — элекке управляющий Закир Ишмәтев, Колчак бандаларында сугышып йөргән Хафиз Дәуликамов, ат карагы Сөбханнар эшкә аяк чалалар, төрле корткычлыклар эшлиләр. Романда Мәхмүт Галәү зур осталык белән диннең кешеләр аңын томалап торучы сөрем генә түгел, ә революциягә, азатлыкка каршы көрәшүче актив көч икәнлеген күрсәтә.

Әсәр контрреволюция калдыкларының фаш ителүе, яңаның, яктылыкның җиңүе белән тәмамлана. Яңа җәмгыять рухи таза, үз киләчәкләренә ышанып караучы, тормышка хуҗа булып яшәүче кешеләр тәрбияли. Аларның көче — тормышның үзендә, һәр көн туып торган яңалыкта, хәрәкәттә. Халыкның элек-электән килгән рухи байлыгы, революциягә кадәр томаланып яткан, ләкин үзенә туктаусыз юл эзләгән таланты, сәләте революциядән соң тулы көченә үсеп китә, тормышны, кешеләрне үзгәртә, яңарта. «Кабылсай» романында гәүдәләнгән бу сыйфатлар Мәхмүт Галәүнең тарихи романнарында тагын да тулырак, киңрәк формаларда чагылалар.

Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» дилогиясе 20—30 нчы еллар татар әдәбиятына зур ачыш, яңалык булып керә. Автор бу әсәренә зур тормыш һәм иҗат юлы үтеп, максатлы рәвештә килә. Ул әлеге романнарны зур күләмле итеп планлаштыра һәм алар өстендә озак, җентекләп эшләргә уйлый. Мәхмүт Галәү тарихи романнарын «Канлы тамгалар» дигән гомуми исем белән дүрт том итеп язарга ниятли, һәр томның киңәйтелгән планын төзи, исемнәрен билгели. Беренче китапта революциягә кадәрге татар авылы, авыл һәм шәһәр халкының 1877 елгы ачлык фаҗигасен кичерү вакыйгалары үзәктә тора һәм ул «Ил тыныч чакта» дип исемләнә. Икенче китап 1897 елгы халык санын алу, шуңа бәйле рәвештә бунт күтәрү, Төркиягә күчеп китү вакыйгаларын тасвирлый һәм «Ил өреккәндә» дип атала. «Сабак» исемле өченче китап рус-япон сугышы һәм 1905 елгы Беренче рус революциясенә, «Өермәләр» исемле дүртенче том Октябрь революциясе вакыйгаларына багышланырга тиеш була. Шулай итеп, автор 1877 елдан 1917 елга кадәрге кырык ел эчендә булган тарихи вакыйгаларны иңләргә уйлый.

«Канлы тамгалар» әсәренең язмышы шактый катлаулы булып чыга. Беренчедән, аның баштагы ике кисәге генә язылып, әсәр тәмамланмаган хәлдә кала. Икенчедән, язылган өлешләре дә татарча басыла алмыйча кульязма хәлендә югалалар.

Мәхмүт Галәү эпопеяның беренче ике кисәген Мәскәүдә «Федерация» нәшриятында рус телендә бастыра. Нәшрият архивында шул кисәкләргә карата язылган эчке рецензияләр сакланган [1]. Ул рецензияләр М. Галәү әсәрләренең язмышына кагылышлы күп кенә нәрсәләрне ачыкларга мөмкинлек бирәләр.

Башта автор беренче һәм икенче кисәкләрне гомуми бер исем белән «Канлы тамгалар» дип атап йөрткән. Мәхмүд Максуд, Гомәр Гали һәм Шамил Усмановларның рецензияләрендә дә шушы исем кулланыла һәм рецензентлар тәрҗемә турында түгел, ә татар телендә язылган оригиналь әсәр турында сүз алып баралар. Ике томны берьюлы чыгару мөмкинлеге булмаган, күрәсең, автор әсәрне ике кисәккә бүлеп кабат эшли, һәм ул русчага тәрҗемә ителә. Беренче кисәк 1931 елда Гайшә Шәрипова тәрҗемәсендә «Муть» исеме белән басыла. Язучыны тәрҗемәнең сыйфаты канәгатьләндереп бетермәгән булса кирәк, 1933 елны ул аны кабат эшкәртеп, тулыландырып үз тәрҗемәсендә тәкъдим итә. Исемен дә «Тихий омут» дип үзгәртә. Романга («Тихий омут»ка) язылган рецензияләрдә бу яңа вариантның канәгатьләнерлек булуы әйтелә, автор белән договор төзергә тәкъдим ителә. Ләкин берничә рецензент әсәрне кабат бастыруга каршы киләләр һәм хәлиткеч сүзне «Федерация» нәшриятының милли серияләр редакциясенә калдыралар. Нинди сәбәпләр аркасындадыр әсәр икенче кат басылмый кала.

---

[1] Центральный государственный архив литературы и искусства. 625 фонд, I тасвирлама, 103 саклану берәмлеге, 42—62 битләр.

Икенче китап «Бунт» дигән исем белән йөргән. Муса Җәлилнең икенче томга язган рецензиясендә шушы исем кулланыла һәм әсәрнең татарча варианты турында сүз бара. Икенче томны да башта Гайшә Шәрипова тәрҗемә иткән була. Муса Җәлил үз рецензиясендә тәрҗемәнең сыйфатына да туктала: «Мин шулай ук бу романның Шәрипова тарафыннан эшләнгән тәрҗемәсен дә укыдым һәм оригинал белән чагыштырдым, ләкин тәрҗемә бөтенләй уңышсыз булып чыккан. Тәрҗемәче романның сәнгатьчә кыйммәтен һәм үзенчәлеген сакларга бөтенләй тырышмаган. Тәрҗемәченең теле тупас, әдәби түгел. Тәрҗемәче авторның әдәби үзенчәлеген аңламаган; үз эшенә җавапсыз караган. Бу тәрҗемәне кабул итәргә ярамый дип саныйм».

Муса Җәлил рецензиясе 1932 елның 15 ноябрендә язылган. Левин һәм Канатчаков рецензияләрендә инде (1933 ел, январь) «Мухаджиры» романы турында сөйләнә һәм 1934 елда әсәр М. Галәү тәрҗемәсендә шул исемдә басыла.

«Федерация» нәшрияты архивында сакланган рецензияләрне үзара чагыштырып карау кызыклы. Аларда төрле фикерләр һәм тәкъдимнәр, шул чор тәнкыйтенә хас уртак кимчелекләр дә очрый. Ләкин берничә мәсьәләдә фикерләр уртак. Иң беренче чиратта, тәнкыйтьчеләр романнарда тасвирланган үзенчәлекле материалга, әсәрнең тема һәм жанр ягыннан яңалыгына игътибәр итәләр.

Мәхмүд Максуд әсәрдәге материалның байлыгына, татар авылының төрле катламнарын чагылдырган типларның тормышчанлыгына аеруча басым ясый. Гомәр Гали дә авторның үзе сурәтли торган материалны яхшы белүен әйтә, жанр ягыннан романнарны социаль эпопея дип атый. Шул ук фикерне куәтләп, Ш. Усманов: «Роман укучының игътибарын җәлеп итә, җанлы вакыйгалар, типлар хәтергә уелып кала. Сыйнфый изү, ярлыларны коточкыч кимсетү картиналары да оста тасвирланган»,— ди. Рецензентлар М. Галәү әсәрләренең сәнгатьчә эшләнешенә, авторның осталыгына, бигрәк тә теленә югары бәя бирәләр. Муса Җәлил әдәби образларның реаль, җанлы һәм үзенчәлекле итеп тасвирланган булуына, әсәр теленең табигый һәм бай булуына аеруча нык игътибар итә.

Ә менә М. Галәү романнарының идея юнәлеше, авторның үзе сурәтли торган вакыйгаларга мөнәсәбәте мәсьәләсе рецензентлар арасында күп кенә бәхәсләр кузгата. М. Максуд, Г. Гали авылдагы сыйнфый катлаулар, эксплуатация оста һәм уңышлы күрсәтелсә дә, керәшен Максим образына авторның мөнәсәбәте ачык түгел диләр. Абдулла байга каршы торырлык уңай образның булмавы да әсәрнең житешсезлеге итеп карала. Бу мәсьәләләр хакында иң аек фикер әйтеп чыгучы кеше Муса Җәлил була. Ул автор стилендәге эпиклыкны битарафлык дип карауга, әсәрнең сыйнфыйлыгын, идеологик һәм политик нигезен образлар дөньясыннан аерып карауга кискен каршы чыга. Рецензент романнардагы тарихи моментларның дөрес позициядән торып бирелүен, хөкүмәт аппаратының бюрократик йөзе, крестьяннарны җәзалау күренешләренең социаль нигезе дөрес күрсәтелүен билгеләп үтә. Шамил Усманов та бу мәсьәләдә авторны һич икеләнүсез яклап чыга: «Идеологик ягына килгәндә, «Канлы тамгалар» — иң көчле революцион әсәрләрнең берсе, ул авылда барган сыйнфый көрәшне дөрес һәм нигезле итеп ачып бирә. Пролетариат әдәбияты бу әсәргә, һичшиксез, югары бәя бирер», — ди.

Чыннан да, аның бу сүзләре дөрес булып чыкты. М. Галәүнең татар халкының тарихын, тормыш-көнкүрешен җентекләп сурәтләгән, төрле катлауларның типик сыйфатларын, психологиясен зур ышандыру көче белән тасвирлаган романнары халык тарафыннан чиктән тыш җылы каршы алынды, югары бәя алды.

Бу романнарда халык тормышы ерак тарихтан алып, җентекләп тасвирлана. Моның белән М. Галәү конкрет максатны күздә тота: ул Октябрь революциясенә үсеп җиткән сыйнфый көрәш татар тормышының үз җирлегендә ничек туууын, иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләрнең кешеләр аңында, аларның психологиясендә ничек чагылуын күрсәтергә, шул катлаулы процесска анализ ясарга тели. Бу процессны динамик хәрәкәттә, вакыйгаларның үсеш тизлегендә генә сурәтләү мөмкин түгел, вакыйгаларны тудырган җирлекнең үзен тикшерергә һәм ералгы хәлендәге сәбәпләрен дә эзләп табарга кирәк. Шуңа күрә М. Галәү, зур түземлелеккә ия булган тикшеренүче кебек, вакыйгаларны ашыктырмыйча, табигый үсешендә — туу, үсү, җитлегү рәвешендә — сурәтли, аларның көндәлек, гадәтилек сыйфатына басым ясый. Революцион вакыйгаларны сурәтләүне төп максат итеп куйган хәлдә, язучы башта алар-

ның экспозициясен бирә: тарихның вакыт катламнарын күрсәтә, көч-куәт алып дәвылга әйләнәчәк вакыйганың тамырлары кайсы катламда булса, шуннан алып тасвирлый башлый. Беренче китапларда әсәрнең персонажлары да, вакыйгалар белән идарә иткән геройлар булудан бигрәк, тарихи чорны һәм җирлекне (вакыт һәм урынны) билгелиләр. Революциягә алар шартлар, вакыйгалар өлгергәч һәм үзләре дә шул дәрәҗәгә үсеп җиткәч кенә килеп кушыла алалар.

М. Галәү үз әсәрләренә материал итеп тарихны ала. Бу — язучыдан аеруча зур тәҗрибә һәм осталык сорый торган өлкә. Әсәр узган гасырның 80 нче елларындагы авыл тормышын тасвирлаудан башлана.

Казан артындагы Мәүлә Колы авылына солдаттан Миңлебай Сафасы кайтып килә. Сафаның үзе, аның семьясы белән таныштырганнан соң, автор укучы алдына берәмберәм авыл кешеләрен китереп куя башлый.

М. Галәү, алда әйтелгәнчә, ашыкмыйча, иркенләп сөйли, җентекләп тасвирлый. Мондый хикәяләү ул вакыттагы тормышның темпына, характерына да бик туры килә. Авыл халкы, патша һәм шәригать законнарына буйсынып, ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрне саклап, тыныч кына яши бирә. Әйтерсең бер көйгә салынган, билгеле бер темп, ритмга буйсынган бу тормышны берни дә үзгәртә алмаячак, ул гел шул бер көйгә агачак та агачак. Әсәрнең башында автор бер ел әйләнәсендәге авыл тормышын сурәтли. Яз җитә — иген чәчәләр, аннан соң җыен, сабан туйларын үткәрәләр. Җәй көне печән чабалар. Аннары уракка төшәләр, иген җыялар, көзге муллык белән тормышларын көйләп калырга тырышалар. Кышын — әвен сугу, йорттагы эшләр, аулак өйләр. Әйтерсең авыл бер дә үзгәрми. Ләкин бу — вакыйгаларга җирлек әзерләү, кешеләр, вакыт һәм урын белән таныштыру гына. Акрынлап хикәяләүнең тизлеге арта, мөнәсәбәтләр кискенләшә бара. Вакыйгалар да сиздерми генә җыелалар, куералар. Эчке хәрәкәт, зур вакыйгаларга әзерлек беренче күренешләрне тасвирлаганда ук башлана.

Авыл тормышы һәм аерым кешеләр белән таныштырганда ук көчле конфликтларга алып киләчәк мөнәсәбәтләргә, каршылыкларга ишарә ясап барыла яки аларның сәбәбе ачылып кала. Сюжет хәрәкәте дә, яшерелгән хәлдә, тамырлар буйлап бара. Вакыты җиткәч, ул ачыктан-ачык кабынып китәчәк, өскә калкып чыгачак.

Башта ике көч капма-каршы куела. Бер якта — табигать стихиясе, икенче якта — шушы чиксез стихия алдында торган халык. Халык кулыннан килгән чаралар белән ачлыкка каршы көрәшә, шул көрәш барышында халыкның төп сыйфатлары ачыла башлый.

Ачлык халык өстенә җиңә алмаслык бер афәт, фаҗига булып килә. Ачлыктан интеккән кешеләрнең кыяфәтләре дә ямьсез. Ләкин шушы фаҗигале елда халыкның рухи сыйфатлары, ныклыгы да сынала. Язучы менә шул сыйфатларны акрынлап өскә чыгара, рудадан металл койган кебек, олы бер образ — халык образын иҗат итә башлый.

Вакыйгаларның беренче дулкыны үтеп тә бетми, аңа тагын да көчлерәк булган икенчесе ялганып китә:

«1897 елның башы иде. Халык шау килде:

— Бөтен халыкны көчләп чукындырасылар, имеш...

— Чукындыру өчен бөтен мөселман халкының санын аласылар, имеш. Шул турыда приказ килгән икән, ди.

Баштарак колактан колакка гына сөйләнеп, озынколак хәбәре генә булып йөргән бу сүзләр төрле көчләүләр, җәбер-золымнар белән коты алынган татар крестьянын яшерен куркытып, астыртын шомландырса да, бара-бара өрескә чыкты».

Йөрәкләрендә уч ялкыны кайнаган халык, бу хәбәрнең асылына төшеп тә тормастан, бунт күтәрә. Бу юлы инде халык муллага да, староста белән куштаннарга да ышанмый. Беренче карашка бу бик сәер бер эш булып тоела. Чыннан да, «ассынкиссен, суйсын — без үз дигәнебездән кайтмыйбыз, ата-баба динен ташламыйбыз!» дип баш күтәргән халык ничек инде мулла сүзенә колак салмый?.. Ләкин шушы каршылыклы күренешнең эчке мәгънәсе, тирәндәрәк яткан катлаулырак сәбәбе, эчке бер пружинасы бар һәм автор ул сәбәпне күрсәтә дә: «Бу ярсу, бу чуалу йөз еллар буенча төрле җәбер-золым, азап һәм мәсхәрәлекләр күреп алҗыган, сугылган, таланган, тапталган, изелгән мужикның — крестьянның нәүбәттәге баш күтәрүе; ә сан

алу мәсьәләсе һәм ата-баба дине өчен куркыныч туу дигән сүз исә сылтау гына — коры салам өчен бер шырпы шикелле корал гына иде. Сан алу мәсьәләсе тукталып калса да, тулып ярылган азап чүлмәген яңадан бөтен хәлгә кайтару мөмкин булмаячак; гасырлар буенча җыйналып килеп тә, шушы сылтау белән генә дин буявына буылып тышка чыккан үч алу тойгыларын җиңү һичкемнең кулыннан килмәячәк иде».

Ләкин халык үзе конкрет кешеләрдән, күп төрле характерлардан тора. Шуңа күрә халык ачуы кабыну, үсү һәм сүрелү процессында бөтен катлаулыгында күрсәтелә. Үзенең чиксез нәфрәте белән, җиңеп булмаслык ачуы белән халык — бөек, матур. Шул ук вакытта имеш-мимешләрне, юк-барны чын дөреслек дип ышанып кабул итүе, аңсызлыгы белән ул көчсез дә.

Халык ачуы кайнап торган язгы ташкын кебек. Ә менә шул ташкынны билгеле бер юнәлешкә боручы, дөрес юлны күрсәтүче юк. Шуңа күрә максат та бик томанлы әле: «Кара халык һәммәсенә дә ышанды, барысыннан да шомланды. Котырынуы артты, ярсуы көчәйде. Бу яктан — шомланып курыкса, икенче яктан — әллә кемнәрдән, әллә нәрсәләрдән үчен алып рәхәтләнү теләге белән янып яши башлады».

Шул ук вакытта халык ачудан акны-караны аермаслык хәлгә килгән ерткыч толпа да түгел. Бик характерлы бер деталь. Тиешле вакыт җиткәч, билгеләнгән сан алучылар авылларга таралалар. Мәүлә Колыга солдатта чагында аз-маз язу-сызу өйрәнеп кайткан Гыйбад писарь килә. Таныш һәм үз кеше булгач, аңа берьюлы каты бәрелмиләр. «Үзең күз күргән кеше, яхшы ата баласы, болай балтага сап булып йөрүдән азрак оялыр идең!» дип, икенче килмәскә кушып, кайтарып җибәрәләр. Становой һәм стражникларның гәүдәләрен тураклап бетерсәләр дә, становойның кучеры булган урыска тимиләр. «Кайтып әйт, моннан болай безгә бу йомыш белән килеп йөрүче булмасын», дип әйтү белән чикләнәләр.

Халыкның дус-дошманны дингә карап түгел, ә сыйнфый күзлектән карап аеруы бояр утарын талау вакыйгасында тагын да ачыла төшә. «Сан алуга каршы баш күтәрүче татар авыллары гына булса да, бояр утарын таларга килүчеләр бик чуар иде. Анда рус, чирмеш, чуваш, ар һәм керәшеннәр дә күп булып, уртак дошманнан уртак малны алыр өчен барысы да килгәннәр иде».

Алпавыт утарын яндырган өчен дә, становойны үтергән өчен дә Мәүлә Колы авылы «үзенә тиешле» җәзаны тулысынча ала. Берәүне дә кызганмыйлар, берәүне дә якламыйлар. Ил йомышын үтәп, патшага прошение илтеп йөргән Әкрам карый белән Сафага да бертигез эләгә. Ничә еллар балаларын укыткан карыйны авыл куштаннары да, бертуган абыйсы Шәмси мулла да, кечкенәдән бергә уйнап үскән Сабирҗан мәзин дә якламый. Мәүлә Колы һәм башка авылларда бунт күтәрүчеләрне суктырып кына калмыйлар, һәр авылда халыкка өстәмә бәлаләр, газаплар тудырган «обжор командалары» урнаша. Ну «обжор командасыннан» ничек котылырга? Кемнән ярдәм, мәрхәмәт сорарга?.. Авыл халкы үз алдына килеп баскан бу мәсьәләне уртага салып үлчәп-тикшереп карый да, ниһаять, озак сүз көрәштерү, шаулашулардан соң уртак бер фикергә килгәндәй була:

«— Төркиягә күчеп китәргә кирәк! Шулай итеп, халыкның барлык теләк-омтылышлары бер максатка юнәлдерелде. Һәркемгә хәзер котылу юлы табылгандай булып, бәхетле тормыш якын һәм мөмкин булып тоелды».

Сабыры тулып ташкан, чарасы калмаган халык ташкыны авыр, газаплы юлны сайлый, ләкин бәхеткә илтә торган иң якын юл дип ышанып, зур өметләр белән сайлый. Яше-карты, олысы-кечесе шушы уртак хыял белән канатланып, юлга хәзерләнә башлый. Аларны бу кысыр хыялларыннан айнытырга сәләтле кеше табылмый. Хәер, Керпе Сәлим: «Анда да мондагы шикелле байлар, түрәләр бар ич... Җелегегезне суырырлар әле алар!» дип кисәтсә дә, йорт-җирләрен туздырып, бар әйберен сатып бетергән кешеләр аның сүзләренә колак салудан узган булалар.

Мөһаҗирләр авылдан чыгып китүгә газаплы юл башлана. Язучы шушы юлны һәр этабы, һәр туктаган шәһәрнең күренеше, андагы халыкның яшәү рәвеше белән бәйле рәвештә җентекләп тасвирлый бара. Мәүлә Колы кешеләренең чит ил паспортлары алуы, катлы-катлы рөхсәтләр белән, күп көннәр, озын юллар үткәннән соң гына үзләренә билгеләнгән җиргә барып урнашулары газаплы бер сәяхәт итеп тасвирлана. Төрек хөкүмәтенең идарә органнары, чиновникларның эш стиле, алдау-хәйләне үз-

ләренең төп кәсепләре итеп алган арадашчылар — барысы бергә коточкыч бер үрмәкүчне хәтерләтәләр.

Мәүлә Колыдан килгән крестьяннар, билгеләнгән җирләренә барып урнашкач, Төркиянең үз халкы да шушы үрмәкүч пәрәвезенә эләккән чебен хәлендә яшәгәнлекне күреп, тетрәп калалар.

Характерлы деталь: күчеп китү вакыйгаларына кадәр язучы Мәүлә Колы кешеләрен һәр урында «халык» дип йөртә. Ләкин шул халыкның бер төркеме, авылдан чыгып киткәннән соң, юлда никадәрле зур төркемнәр белән кушылып зурая барса да, аларга карата «халык» сүзе башка кулланылмый. Алар — «крестьяннар», «мөсафирлар», «мөһаҗирләр», «юлаучылар», «күчеп китүчеләр». Чөнки сүз туган иленнән аерылган кешеләр турында бара, ә халык үзенең туган җирендә, шундагы тарихы белән генә чын мәгънәсендә халык була ала. Мөһаҗирләрнең фаҗигасен автор нәкъ шушы мәгънәдә ача да.

М. Галәү үз романнарында халыкны кара, надан масса итеп түгел, ә тырыш, эшчән, түземле, ләкин сабыры тулып ташканда хәтәр көчкә әйләнә торган, ирекнехөрлекне яратучы актив көч итеп тә сурәтләргә омтыла. Халык, мул сулы елга кебек, яхшы тормышка, үзенең бәхетенә юл эзли. Бер урыннан буып куйсалар, икенче юл таба, ялгыша, җәфа чигә, ләкин өметен сүндерми.

Авырлыклар күргәндә дә матур сыйфатларын югалтмаган, бәхеткә, яхшы тормышка лаек шушы халык изелеп яши. Ул бу гаделсезлекнең сәбәпләрен аңларга тырыша һәм шул газаплы, ялгышулы эзләнүләр юлында аның аңы үсә, характеры формалаша. Язучы менә шушы катлаулы процессны художник буларак өйрәнә, сурәтли, зур идеяләр күтәрә. Массовый күренешләрдә халык сыйнфый дошманнары белән турыдан-туры бәрелешкә керә һәм үзенең максатын, омтылышларын да ачык итеп әйтә. Язучы халыкка теләктәш, аның көче, матурлыгы, олылыгына соклана.

Халык образы язучының эстетик карашларын чагылдыруда да зур роль уйный. Әсәрдә халык образы зур гомумиләштерү көче белән тасвирлана, аның сыйнфый эчтәлеге ачыла, аңа социаль-психологик анализ ясала.

Әсәрнең геройлары да үзенчәлекле сыйфатлары белән аерылып торалар, аларның һәркайсының үз йөзе, үз тормышы бар. Әлегә тормышның бөтен катлаулылыгын, гаделсезлекнең сәбәпләрен аңлап җиткермәгән Сафа саф күңелле, намуслы бер кеше итеп бирелә. Нинди генә эшкә тотынмасын, ул аны бөтен барлыгы белән, чын күңелдән бирелеп эшли. Аның бу сыйфаты Саҗидәгә булган мәхәббәтендә бик ачык чагыла. Ата-аналарының, туганнарының каршылыгы, гореф-гадәтләре дә киртә була алмый, гадәттә күндәм, юаш холыклы Сафа бу мәсьәләдә гаҗәп ныклык һәм каршылык күрсәтә. Иң авыр вакытларда да Саҗидәгә өйләнгәненә үкенми, аның үлемен иң зур югалту итеп кичерә. Сафа уйлап, ашыкмыйча эшләргә ярата. Ләкин бер инанган карарыннан чигенми. Характерының бу ягы алга таба зур вакыйгаларда ачылып китәргә тиеш булгандыр: үсеш, үзгәреш шул юнәлештә бара.

Саҗидә — автор тарафыннан бер соклану белән иҗат ителгән образ. «Әйтәсе дә юк — шомырт кара күз, өскә кайтарылып торган керфек, озын толым, зифа буй, алсу ирен, тезелеп торган ап-ак теш бик сирәк кызларда гына очрый... Өстәвенә тагын аның шаян холкы, яңгыравыклы тавышы, гомергә күңелгә күчеп кала торган сөйкемле, матур күз карашы да бар». Шушы матурлыгы янына аның уңганлыгы да килеп кушыла. Әтисе сырхаулабрак торса яки вакыты булмаса, йорттагы ирләр кулыннан гына килердәй авыр эшләрне Саҗидә эшли. Ул — әсәрдәге иң тулы, иң матур образ. Саҗидәнең тормышны яратуы, беркайчан да өметсезлеккә бирелмәве укучыны да сокландыра. Биш апасын калдырып, әтисенең киреләген җиңеп, гореф-гадәтләрне җимереп, Саҗидә яраткан кешесенә кияүгә чыга. Бу — аның беренче җиңүе була. Баласы булмаслыгын белгәч, ул башта гадәт буенча им-том чараларын үтәп карый. Берсенең дә файдасы тимәслегенә ышангач, күп үгетләүләрдән соң, ирен икенче мәртәбә өйләнергә күндерә. Көндәшен дә үзе сайлап ала һәм ялгышмый. Хатирә белән алар бөтен авылны таң калдырып, тату, дус яшиләр.

Бу ике образның бер-берен тулыландырып, баетып торулары әсәрдә гармония тудыра. Башка образлар да аларга тегe яки бу рәвештә килеп бәйләнәләр һәм бу гармонияне көчәйтәләр. Шул ук вакытта алар һәрберсе диярлек — гаять колоритлы, каршылыклы характерлар.

Мәнә Сәҗидәнең әтисе — Йосыф карт. Ул авылдашлары арасында аерылып торган бер кеше. «Ул ел саен ашлыкны күп чәчә, ашыкмыйча гына эшли, чәчүгә иң соңгы кеше булып чыга һәм чәчүне иң соңга калып бетерә иде. Уракны тиз ура, ләкин көлтәләре бик озак җыелмый ята. Басуда күзгә ягъгырларга калган көлтәләр булса, болар Йосыфныкы дип тәгаен әйтергә мөмкин иде. Урылмыйча ятып, терлекләр таптап бетергән ашлык та анык була иде». Ярганалып торган калын иреннәренә кәгазь яки яфрак ябыштырып йөри торган авыр сәякле бу карт шул ук вакытта гаҗәп кире беткән холыклы да. Шушы кирелеге аркасында аның биш кызы буй җитеп, кияүгә чыкмыйча картая. Беренче кызы үсеп җиткәч, төрле сәбәпләр табып яучыларны борып җибәрә. «Икенче кызына яучы килгәч тә, Йосыф аны апасыннан алда кияүгә бирергә теләми. Шулай итеп, аның өлкән кызлары картая, ә кечеләре үсә тора. Аннары инде алар йортына яучы да килмәс була».

Йосыф карт яшәү рәвеше, уй-фикере һәм психологиясе белән, беренче чиратта, крестьян булса, Керпе Сәлимнең «крестьянлыгы» җәй айларында Мәүлә Колыга кайтып, авыл читендәге өендә бераз вакыт торып китүдән узмый. «Ул бөтен тирә-юньдә иң яхшы такта яручылардан санала. Һәр елны көз җиткәч, Сәлим, озын пычкысын аркасына асып, авылдан читкә чыгып китә... Якын-тирәдә эш булмаса, Сәлим такта яру заводына барып яллана».

Такта яру заводында эшләүчеләр аны яраталар, үз итәләр. «Сәлим картны һәммәсе таныды. Шундук бер кузла өстеннән икенче кузлага таба: — Җәмәгать, Сәлим ага килгән! — дигән хуплау тавышлары тәгәрәде. — Исәнлек-саулык ничек, Сәлим ага? Аяклар күтәреп йөриме әле? — дип, төрле яктан хәл-әхвәл сораша башладылар».

Мәхмүт Галәү үзәккә бер семья язмышын куя, ләкин әсәр семья хроникасына әйләнми. Автор семья членнарын төрле катламнар белән аралаштыра һәм моның психологик җирлеген дә сурәтләп бара.

Сафа, Сәҗидәгә өйләнеп, башка чыккач, аның абыйсы Вафа белән юллары аерылып китә. Бер авылда торсалар да, алар чит кешеләр кебек, үзара аралашмыйча яшиләр, алай гына да түгел, алар арасында үтә алмаслык упкын хасил була. Бу «упкын» язучы тарафыннан алдан ук әзерләнеп килене.

Мәхмүт Галәү иң уңышлы алым итеп, Сафа һәм Вафаның аралашкан кешеләрен, аларның даирәсен тасвирлауны куллана. Сафалар аралаша торган семьялар — Йосыф карт, Керпе Сәлим семьясы — гадел, кешелекле, намуслы булулары белән аерылып торалар. Вафаның аралашкан даирәсе исә бөтенләй башка. Габдулла бай өендә дворник булып яшәгән чорда Вафаның эчке дөньясы бай өендәге атмосфера, андагы яшәү рәвеше фонында тасвирлана. Һәрчак йозакка бикләнеп тора торган капкалы, биек коймалы йортның эче гаҗәп катлаулы бер дөнья. Байдан алып йомышчы малайга кадәр барысы да бүре законы буенча яши. Һәрберсе бары тик үз файдасын гына кайгырта. Ачлык вакытында шәһәргә эшкә килгән Вафа бу «фәнне» бик тиз үзләштерә, хәтта хәйләдә байның үзеннән дә уздырып җибәрә...

Автор, бер урынга җыеп, куе буяулар белән тулы бер картинаны сурәтләп бирә, татар байларының тормышын, психологиясен бер төендә чишеп күрсәтә. Болар һәммәсе Мәхмүт Галәүнең байлар тормышын, аларның психологиясен яхшы белүе турында сөйли. Оренбург һәм Казан байлары, һичшиксез, аның фантазиясенә мул азык биргәннәр.

Әлеге күзәтүләрдән чыгып, «Канлы тамгалар» дилогиясе, аның автор иҗатында һәм әдәбият тарихында тоткан урыны турында түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин. Бу тарихи романны язу өчен, зур талант көченә ия булу өстенә, язучының татар халкының иҗтимагый һәм рухи тормышын да тирән белүе соралган. Андый белемне ул зур вакыйгаларда актив катнашу, тормышны, тарихны озак еллар буе махсус өйрәнү нәтиҗәсендә туплаган.

Дилогиядә автордан соңгы буын язучылар традиция итеп үстереп алып китәчәк күп кенә матур сыйфатлар очрый. Әсәр, бер семья тарихыннан башланып, халык язмышын хәл итә торган зур вакыйгаларны тасвирлауга кадәр үсә. Геройларның төрле социаль катлауларга хас психологияне чагылдырулары, татар халкы тормышында гасырлар буе килгән гореф-гадәтләрнең көчен, ролен һәм зур вакыйгаларда аларның үзгәрү процессын тасвирлау — роман-эпопея өчен зарури сыйфатлар.

М. Галәү, шул рәвешчә, татар әдәбиятына эпиклык һәм тарихилык сыйфатларын алып килә. Тарихилыкның әһәмиятле сыйфаты — чын, реаль вакыйгалар белән хыялның бәйләнеп бирелүе — шулай ук әсәрнең художниклык таланты белән тудырылган бөтен бер дөнья булуын күрсәтә.

Сюжет һәм композиция төзү остасы буларак та М. Галәү әдәбиятка яңалык алып килә. Әсәрдә сурәтләү объекты зур, катлаулы татар дөньясы, һәм ул язучының хыялы ярдәмендә тудырылган кеше язмышлары аша үткәрелеп тасвирлана. Вакыйга һәм геройларны бәйләп торган үзәк — Мәүлә Колы авылы. Автор бу авылга берничә тапкыр әйләнеп кайта, ләкин бу гади кабатлау гына түгел. Геройлар үсә, үзгәрә, вакыйгалар да югарырак дәрәҗәгә күтәрелә бара. Вакыйгаларның Төркия территориясенә кадәр барып җитүе дә әсәрнең географик киңәюе генә түгел, ә тарихи җирлекнең масштабы үсү булып та тора.

М. Галәү иҗатында зур һәм әһәмиятле проблемалар күтәрелүе аның дөньяга карашының киңлеге турында сөйли. Ул татар демократик әдәбиятының күркәм традицияләрен үстерүгә, иң матур үрнәкләрен пропагандалауга хезмәт итте. Мәгърифәтче буларак, агасы Шиһап Мәрҗанинең эшчәнлеген дәвам итте, иҗат осталыгына Г. Тукай, Ф. Әмирханнардан өйрәнде, бөтен гомерен татар әдәбиятын, культурасын үстерүгә багышлады.

Мәхмүт Галәүнең иҗат гомере революция аша уза, зур социаль үзгәрешләр чорына туры килә. Татар әдәбияты тарихында ул журналист, публицист, тәрҗемәче, күп санлы хикәяләр һәм пьесалар авторы, тарихи роман жанрына нигез салучыларның берсе буларак урын алды. Аның иҗаты — татар демократик әдәбиятын совет әдәбияты белән бәйләгән зур иҗат.

Ильтани Иляловa

# БУЫН НЫГЫТКАН БУЫН

Театрда аларны щепкинчылар дип йөртәләр, үзара нык берекkән тату бер семья итеп санйлар. Моннан унбиш ел элек Мәскәүдән Щепкин исемендәге училищены тәмамлаган, ә бүген Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында төп рольләрне башкарып, театрның актив иҗади көчләре булып исәпләнүче Ринат Таҗетдинов, Флера Хәмитова, Равил Шәрәфиев, Фирдәвес Әхтәмова, Наил Дунаев, Гөлсем Исәнгулова, Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Мәсгудә Хәйруллина, Рәшит Галиәкбәров барысы унау алар — сәхнә фидакарьләре...[1]

Минем күптән инде аларның барысы белән дә бергә очрашасым килеп йөри иде. Көннәрнең берендә бу теләгем тормышка ашты. Алдан килешенгән вакытка актерларның һәммәсе диярлек җыелып та беттеләр. Һәм менә шулай бердәм җыелулары, алар арасында ерактан ук күренеп торган үзара җылы бер мөнәсәбәт, берберсенә теләктәшлек — болар һәммәсе аларның тормышка, иҗатка уртак карашлар нигезендә берләшкән бер төркем кешеләре булуын күрсәтеп тора иде.

Мин, иң беренче чиратта, алар арасындагы шушындый бердәмлек һәм якынлыкның серен белергә теләдем.

— Күрәсең, бу безнең укытучыларыбыздан киләдер, — диделәр щепкинчылар. — Укытучыларыбыздан уңдык без. Михаил Николаевич Гладков — курс җитәкчебез, актерлык осталыгы буенча педагогыбыз — безнең өчен гади бер белгеч кенә түгел иде. Курсның илһамчысы, танылган һәм яраткан остазыбыз булып әверелде ул. Вакытын да, үзен дә жәлләмичә, безне актер итеп кенә түгел, ә иң элек кешеләр итеп тәрбияләргә тырышты...

Шулчак Гөлсем Исәнгулова белән Нәҗибә Ихсанова Гладковның васыять итеп әйткән сүзләрен искә төшерделәр. «Бер-берегезне какмаска. Рухи якынлыкны сакларга, бердәм булырга. Сәнгатьне бар нәрсәдән өстен күрергә...»

— Училищеда тәрбияләнүебез белән без чыннан да бәхетле,— дип, әңгәмәне дәвам иттерделәр Дунаев белән Әхтәмова.— Малый театр спектакльләрендә күмәк күренешләрдә катнашуыбыз әле дә истә, анда безне бик җылы каршылый торганнар иде. Театрның тәҗрибәле актерлары безгә коллегалары итеп карыйлар, сәхнә уены нигезләрен практик рәвештә үзләштерүдә төрлечә ярдәм итәләр иде.— Без барыбыз да авылдан чыккан, садә авыл балалары, — дип сөйләделәр алар. — Безнең аң-белем дәрәҗәбез дә, дөньяга карашларыбыз да, хыялларыбыз да бер төрле иде. Күрәсең, болар барысы да безнең арада туганлык хисе тудыргандыр. Без, асылда, чын оста кулына килеп эләккән үзле балчык кебек идек, ул безгә үзе теләгән форманы бирде. Бәлки бәхетебез дә шунда булгандыр. Әнә шулай итеп без изге теләкле, яхшы күңелле кешеләр җитәкчелегендә әзерлек үттек, алар безгә ышандылар, күңелебезгә изгелек, кешелеклелек, иптәшлек орлыклары сиптеләр...— Безнең тормышыбызда, татар театры мәйданына чыгуыбызда зур сәхнә остасы, гаҗәеп олы һәм саф күңелле кеше

[1] Башта алар егермедән артык иде. Берәүләр театрдан беренче елны ук китеп барды. Икенчеләре соңрак төрле сәбәпләр аркасында культураның башка өлкәләренә күчтеләр. Мәсәлән, Туфан Миңнуллин хәзер инде танылган драматург, Роберт Батуллин — драматург һәм прозаик, курчак театрында баш режиссер, Иркә Сакаева, Клара Газизова, Әхтәм Зарипов — телестудия хезмәткәрләре. Миргалим Харисов — «Социалистик Татарстан» газетасында бүлек мөдире, Хәмзә Арсланов — культура учреждениеләрендә административ эштә. Дамир Хәйруллин бик иртә вафат булды.— Авт. искәрмәсе.

Хәлил Әбҗәлилов ифрат та зур урын тота. Ул безне атабыз урынына багып үстергән кеше. Курска ул безне үзе сайлап алды, үзе Мәскәүгә алып барды һәм Гладков кулына тапшырды. Хәлил ага әледән-әле янибызга, училищега килә иде, матди яктан да ярдәм итүләрен үтенеп, республиканың җитәкче органнарына йөри иде. Укуны тәмамлагач, безне гадәттәгечә, төрле театрларга таратмыйча, туп-туры Академия театрына кабул иткәннәр икән, моның өчен дә без шактый дәрәҗәдә аңа бурычлы. Хәлил аганы без һәрчак үзебезнең янда итеп тоярга күнектек: театрга кайчан гына барсак та, ул безнең белән бергә булды. Кеше буларак та, актер итеп тә без аңа сөеп карый идек. Ләкин аның җылы канаты астында бик аз яшәп калдык...

— Ә хәтерлисезме, — ди Әзһәр Шакиров, — Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә без Хәлил аганың Хуҗа Насретдинны һәм «Ташкыннар»да Биктимер картны уйнавын чаршау артыннан таң калып күзәткән идек. Ул рольләр буй җитмәслек дәрәҗәдә югары осталык үрнәге буларак хәтеребезгә сеңеп калды.

Шулчак Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Мәсгудә Хәйруллина сүзгә кушылдылар. Алар театрның өлкән буын артистлары Гөлсем Камская, Мәрьям Сульва, Хәсәен Уразиков уенын карап сокланулары, алар тәҗрибәсен ничек үзләштерергә тырышулары хакында сөйләделәр. Әңгәмәбез кызганнан-кыза барды. Үз укытучылары һәм остазлары хакында шушындый ихлас мәхәббәт белән сөйләгән, аларның һәр сүзен, эшен кадерле бер хатирә итеп саклый белгән, васыятьләрен үтәү өчен бөтен көчләрен бирергә әзер торган шушы кешеләрне тыңлаганда мин әчке бер канәгатьлелек һәм рәхәтлек, горурлык хисе тоеп утырдым.

Әңгәмәбез вакытында тагын ике кешенең исеме кат-кат телгә алынды. Алар — училищеда биш ел уку дәверендә булачак артистларга татар әдәбияты һәм теленә мәхәббәт тәрбияләгән әдип һәм шагыйрь Әхмәт Фәйзи, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе режиссер Ширьяздан Сарымсаков. Ширьяздан ага Гладковтан эстафетаны кабул итеп ала һәм сәхнәгә яңа аяк басып килүче яшь актерларны тәрбияләүне дәвам иттерә, аларда үз-үзләренә ышаныч тудырырга тырыша. Щепкинчылар беренче айлардан ук спектакльләрдә уйный башлыйлар. Бу яктан аларның язмышы 1949 елда ГИТИС студиясен тәмамлаучылардан бәхетлерәк булып чыга.

Ул вакытта театрда егерме яшь тирәсендәге бер генә актер да булмый диярлек. 1961 елның көзендә инде (щепкинчылар үз туган көннәре итеп 1961 елның 20 августын, ягъни Академия театрына кабул ителгән көнне исәплиләр) яшь артисларның зур бер төркеме Аяз Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә» пьесасы буенча Габдулла Юсупов тарафыннан куелган спектакльдә уйный. һәм шуннан соң ук Ш. Сарымсаков аларны Шамил Шаһгалинең «Без аерылышмабыз» исемле әсәре буенча куелган спектакльдә уйнарга чакыра.

Алтмышынчы елларның беренче яртысында щепкинчылар Хәй Вахитның «Рәхим итегез», «Кайда соң син?», «Соңгы хат», «Туй алдыннан» кебек комедия һәм драмаларында бик күп роль башкарырга өлгерәләр.

Әңгәмә вакытында мин тагын шуны белергә теләдем: училищедагы актерлык осталыгына укыту методының театрда эшләгәндә аларга никадәр файдасы тигән? Укып кайтканнан соң тагын яңабаштан өйрәнергә, бөтенләй икенче нәрсәләрне үзләштерергә туры килмәгәнме?

«Юк, туры килмәде», диделәр. Аларны Щепкин исемендәге училищега, ягъни чынлыкта, Малый театр студиясенә укырга җибәрү иң дөрес адым булып чыккан. Русның бу атаклы театры белән татар театрының иҗат өслүбе, методлары бер-берсенә бик якын. һәр ике коллективта да тормыш хакыйкатен, сәхнәдә кешеләрнең хис-кичерешләрен реаль гәүдәләндерүгә ирешүне бар нәрсәдән өстен куялар. Бу турыда да алар үзләре болай сөйли:

— һәр иҗат эшегезне йөрәк кушканча башкарыгыз. Аның логик яктан нигезле, тәэсирле булуына ирешергә тырышыгыз, — ди торган иде М. Н. Гладков. — Остазның гадилек, табигыйлеккә омтылуы, эстетлыкны кабул итә алмавы кече яшьтән тир төмен белеп, авыл табигатендә тәрбияләнеп үскән без-яшьләрнең күңеленә хуш килә иде. Шуңлыктан, театрда эшли башлап, өлкән буын актерларның уенындагы табигыйлек, чынлык, ышандыру көчен күрү безне тетрәтте. һәм эш барышында режиссер Ширьяздан ага Сарымсаковның үзебез башкара торган рольнең эш-хәрәкәтен психологик як-



**Щепкин исемендәге училищены тәмамлап кайткан артистлардан Фирдәвес Әхтәмова, Наил Дунаев, Гөлсем Исәнгулова, Рәшит Галиәкбәров, Нәҗибә Ихсанова, театр белгече Ильтани Илялова, Равил Шәрәфиев, Ринат Таҗетдинов, Мәсгудә Хәйруллина, Әзһәр Шакиров.**

тан акланырлык, тамашачыны ышандырырлык итеп гәүдәләндерүне таләп итүе безгә нык аңлашыла, гүя уку процессының дәвамы булып тора иде... Шулай да ул елларда безне бер нәрсә бик аптырашта калдыра, хәтта куркыта да иде: ул — вакыт мәсьәләсе. Монда бөтен бер спектакльне әзерләү өчен бер-ике айдан артык вакыт бирелми, ә училищеда исә кечерәк кенә бер күренешне без ел буе әзерли торган идек. Аңлашыла ки, рольне шундый кыска срок эчендә өлгертүгә без әзер түгел идек. Баштарак берара өркеп калуыбыз, беренче рольләрнең тиешенчә шомарып җитмәве шуның аркасында булса кирәк. Без чынлап та өлгерә алмый идек.

...Академия театры алтмышынчы елларның беренче яртысында катлаулы чор кичерә. Режиссерлар алышына, ә театр исә бер урында таптана башлый. Ләкин щепкинчылар өчен бу кыенлыклар артык нык сизелмәде дияргә мөмкин. Алар күп уйныйлар һәм тамашачы белән һәр очрашу, сәхнәдә үткән һәр көн аларга яңа бер хис, канәгатьлелек тойгысы алып килә. Спектакльләрдә исә алар үз яшьтәшләрен, үз замандашларын уйныйлар. Үзләре өчен якын һәм аңлаешлы булган геройларны гәүдәләндерәләр.

Беренче башкарган рольләрендә үк щепкинчылар сәхнәдә үз-үзеңне табигый хис итүгә ирешү максатын куялар. Шул елларның театраль эстетикасы таләп иткәнчә, яшь актерлар сурәтләү чараларын бик саран кулланып, хисләрне эчкә яшереп, тотнаклы тыныч стильдә уйнарга тырышалар. Һәм шушындый стиль кайбер тип-персонажларны эчтән яктырып җибәрергә, кызыклы образлар тудырырга ярдәм дә итә. Мәсәлән, Нәкый Исәнбәтнең «Гөлҗамал»ында Равил Шәрәфиев башкарган Әкми, Хәй Вахитның «Соңгы хат» драмасы буенча куелган спектакльдә Фирдәвес Әхтәмова башкарган Розалия рольләре хәтергә сеңеп калган.

Театрда эшләгән биш-алты ел эчендә яшь актерлар һәрберсе берәр дистәгә якын роль башкаралар, барлык спектакльләрнең күмәк күренешләрендә катнашалар. Һәм менә алар билгеле күләмдә тәҗрибә туплаган, яңа сыйфат сикерешенә әзер башкаручылар булып җитешәләр. Нәкъ менә шул чакта язмыш аларга тагын бер тапкыр елмая. 1966 елда Татар дәүләт академия театрының режиссеры итеп Марсель Сәлимҗанов билгеләнә. Һәм бу юлы да Гладковның укыту методы Сәлимҗановның режиссерлык методы белән туры килә. Остазлары М. Н. Гладков үзенең шәкертләреннән һәр нәрсәне

төпченеп өйрәнүләрен, геройның эш-хәрәкәтләренә тәмам төшенеп бетүләрен таләп иткән. Гладков, бер үк эпизодны тәмам үзләштергәнгә кадәр, укучыларыннан чиксез кабатлата алган. Наил Дунаев, мәсәлән, бер минутлык бик кечкенә эпизодны ничек эшләүләре турында сөйләде. Чәчәк тотып бүлмәгә килеп керү күренешендә төгәл бер образны тапканчы, Гладков аны егермеләп тапкыр кабатларга мәҗбүр иткән. Укытучыны кирәген аңа башта ук та аңлатып бирә алган булыр иде, Дунаевка баш ватып, эзләнеп торасы да калмас иде. Әмма остазлары укучыларының мөстәкыйль рәвештә фикерли алуларына ирешергә теләгән.

Инде килеп, Академия театрында М. Сәлимҗанов җитәкчелегендә эшли башлагач та, яшь актерларга югалып калырга туры килми. Актерга, билгеле бер чикләр эчендә, үзе теләгәнчә уйнарга ирек бирүне яклаучы режиссерның эш стиле «щепкинчылар мәктәбе» принциплары белән бик туры килә. Сәлимҗанов сурәтләү чараларын сайлауда актерга тулы мөстәкыйльлек бирә, һәм бу хәл актерларга үз индивидуальлекләрен шактый тулы ачарга мөмкинлек тудыра.

Шушы еллар эчендә алар, эпизодик рольләрдән тыш, һәрберсе егерме-егерме бишәр роль уйнарга өлгерделәр. Бүгенге иҗат үрнәкләре белән чагыштырганда, беренче эшләренең байтагы беренче тәҗрибәләр, эскизлар булып кына калган инде. Әле күптән түгел, театр куйган спектакльләр буенча фикер алышу вакытында, щепкинчы актерларны «буын ныгыткан буын» дип атадылар.

Бу чыннан да шулай. Әгәр без бүген щепкинчы-артистлар тарафыннан соңгы ун ел эчендә тудырылган образларны хәтердә яңарта башласак, күз алдыбыздан бик күп сандагы реаль типлар: бер яктан, художникларның хыял көче белән сәхнәдә җанландырылган көчле ихтыярлы чын характерлар, кайнар йөрәкле көрәшчеләр, бу дөньяның гүзәллеген иҗат итүче гади хезмәт кешеләре, икенче яктан, үз кайгысын гына кайгыртып тормыш-яшәешкә үз кесәсе аша гына каручы мещаннар, туң йөрәкле эгоистлар галереясы узар иде.

Ринат Таҗетдиновның Эзоп, Кол Гали, Надыйр мәхдүм, Инсаф, Муса, Искәндәр, Чешковын искә төшерик. Яисә Гөлсем Исәнгулова башкаруындагы Назлыгөл, Энҗе, Люсяны хәтергә алыйк. Равил Шәрәфиевнең Альмавива, Рөстәм Әхмәтович, Искәндәр, Хаҗибәк, Исмәгыйл, Подхалюзинын күз алдына бастырыйк. Шушылар белән рәткә Наил Дунаевның Фигаро, Шамил Усманов, Шәмсетдинен, Фирдәвес Әхтәмованың Шәфәкъ, Розалия, Мәйсәрәсен, Әзһәр Шакиров башкарган Айдын, Анджело, Манагаров, Сәлим морзаны, Нәҗибә Ихсанова уйнаган Маһисәрвәр, Гөлчирә, Мәйсәрә, Сәрдия рольләрен, Флера Хәмитова иҗатында күренекле урын алган Сәрвәр, Мәйсәрә, Саҗидә, Анна Петровна образларын, Мәсгудә Хәйруллинаның Сәләхи, Керубино, Татьянасын китереп куйыйк.

Бик күп һәм төрле алар — щепкинчы актерларның иҗат җимешләре. Ул образларның яшәеш төбәкләре буйлап сәяхәткә чыксак, безгә илебез чикләре эчендә дә, ул чикләрнең тышкы ягында да бик күп җирләр һәм тарихи чорлар аша үтәргә, күп төрле халыкларның вәкилләре белән очрашырга туры килер иде. Әмма монысы ул кадәр гаҗәп нәрсә түгел. Үзенең җитмеш еллык юбилеен каршыларга әзерләнгән театрыбыз тарихының кайсы чорына әйләнеп карасак та, шундыйрак хәлне күрер идек. Щепкинчылар өлешенә тигән көмешнең (алтын дисәк тә хата булмас дип уйлыйм), театрга алар алып килгән рухи хәзинәнең кыйммәте башкада.

Чыннан да, режиссерлар белән берлектә, аларга иҗатташ булган хәлдә, ул буын актерлар театрыбыз сәнгатен нәрсә белән баеттылар, алар китергән яңалыкның мәгънәсе нидә?

Мондый сорауга җавап бирү өчен безгә щепкинчы актерлар тудырган образлар, уйнаган рольләрне бер яссылыктан, билгеле бер ноктадан торып күздән үткәрергә кирәк булачак. Әйтик, Ринат Таҗетдинов тарафыннан гәүдәләндерелгән тәвәккәл Ильяс та («Гүзәлем Әсәл»), кырыс максималист Чешков та («Чит кеше»), ирекке ыргылучы Эзоп та, ярсу йөрәкле гарип Надыйр мәхдүм дә («Сүнгән йолдызлар»), нечкә хисле Кол Гали дә актерның үзенең шәхес нуры белән өртелгән. Аларда ягымлы интеллигентлылык, лиризм кайнар эмоциональлек белән, кайнап торган тыелгысыз темперамент белән бергә кушыла. Ул да булмый, алар тышкы кырыслык, тотнаклылык белән алышына. Әнә шуңа күрә дә аның уены һәр вакыт игътибарны җәлеп итә, эчке мәгънәләргә байлыгы белән кызыклы була.

Равил Шәрәфиевнең исә иҗат үзенчәлеге бөтенләй башка. Алар барысы да форма үткенлеге, нечкә мәгънәләре белән күңелне тарта. Рольләре тышкы сурәте ягыннан бик төгәл эшләнгән була, графикадагы сызыклар кебек аерылып тора. Актер үзе уйнаган тискәре персонажлар өстеннән ачы һәм нечкә ирония белән көлә белә. Аның эксцентрик комедиячел таланты һаман калкурак ачыла бара. Кайбер рольләрендә Равил сирәк очрый торган (әйтик, Хуҗа Насретдин ролен башкарганда Х. Әбҗәлилов тарафыннан кулланылган) алымнан файдалана. Сүз монда рольдә берьюлы өч якның бердәмлеге хакында бара. Мәсәлән, К. Тинчуринның «Американ» комедиясендәге Искәндәр ролен алып карыйк. Эш шунда ки, совет студенты Искәндәр сәхнәдә икенче бер кеше булып «уйный», үзен кәләш эзләп Америкадан кайткан егет итеп күрсәтә. Әмма студентның да, «американың» егетнең дә артында бу икене елмаеп күзәтүче өченче зат — актер үзе басып торуы ачык сизелә. Башкаручының үз шәхесе ачыктан-ачык диярлек күренеп, персонажларның кылган гамәлләрен бәяләп торуы рольне көтелмәгәнчә бизи, аңа үзенә бер төрле колорит бирә. Шәрәфиев, щепкинчылар буынының барысы кебек үк, үзе сурәтләгән характерларның асылына төшеп җитә, аларның кылган гамәлләре, эш-хәрәкәтләренең сәбәпләрен ачып бирә белә. Щепкинчылар уенына хас бу сыйфат М. Байҗиевның «Дуэль» әсәре буенча куелган спектакльдә ачык күренде. Ул спектакльдә өч кенә кеше катнаша. Башкаручылар Гөлсем Исәнгулова (Назлыгөл), Ринат Таҗетдинов (Искәндәр), Наил Дунаев (Газиз) — өчесе дә бер үк училищены тәмамлаган актерлар.

Спектакльнең геройлары яшь кешеләр, безнең замандашларыбыз. Тышкы кыяфәтләре белән дә алар залда утыручы яшьтәшләреннән аерылып тормыйлар. Бер-кадәр өзек-төтегрәк сөйләшү манерлары, хәрәкәт һәм йөреш-торышларында үзләрен иркен хис итү, үз-үзләрен тотышларында, кием-салымнарындагы тышкы илтифатсызлык — бу сурәтләү чаралары, әлбәттә, актер уенының тышкы кабыгы гына — менә шулар артында, бер күренештән икенчесенә тирәнәя барып, спектакльнең эчке нерв җебе ачыла, замандашыбызга хас хис һәм фикерләр гәүдәләнә. Актерларның һәрберсе сәхнәдә төгәлләнгән характер тудыра. Аларның иҗат процессына хас булган әһәмиятле момент шунда ки, актерлар үзләре уйнаган геройның теге я бу гамәлен гаепләргә яки хупларга, берьюлы бәяләп куярга ашыкмыйлар, ә тамашачыга ул гамәлнең сәбәпләрен, алшартларын аңлатырга, персонажның эчке дөньясын, рухи тормышын хәрәкәткә китерүче моментларны эзлекле төстә ачып бирергә омтылалар.

Менә сәхнәдә яшь, чибәр Назлыгөл күренә. Тәненә сыланып торган кофта кигән. Уч төпләре белән балтыр итләренә сугып көлүе, биленә таянып тирә-юньгә кыю-кыю карашлар ташлавы белән ул җиңел холыклы хатын-кызны хәтерләтә. Ләкин бераздан, күзәтә төшкәч, бу вульгарлык, шамакайлыкның тышкы пәрдә генә булуын, эчке бер сагыш, җан газабын яшерү өчен битлек кенә икәнлеген абайлый башлыйсың. Спектакль барышында туктаусыз үсә килүче менә шушы икенче план тамашачыны мавыктырып тота да инде. Башта Назлыгөл Газиз алдында үзен дөньядан туйган ачулы, чәнечкеле телле хатын итеп күрсәтергә тырыша. Гөлсем Исәнгулова үз героинясының фикерләү логикасын оста күрсәтә белә. Ул бик яшь һәм тәҗрибәсез килеш Искәндәрнең тозагына эләккән, үзендә аның мәкерлелегенә каршы торырлык көч таба алмаган. Нәтиҗәдә кешеләргә ышанычын югалткан һәм «дөньясына төкереп» яши башлаган.

Чит кешеләр тормышын коткарганда һәлакәтле рентген дозасы алган Газизгә Назлыгөлне тормышның якты якларына ышандыру өчен шактый күп көч түгәргә туры килә. Һәм менә без героинябызда эчке үзгәреш башлануын тоябыз. Ахыр чиктә Назлыгөлнең күңел почмагында яшеренеп яткан сыйфатлары — рухи ныклык, кыюлык, тормышын яңабаштан башлый алырына ышаныч хисе өстен чыга. Спектакльнең буеннан-буена актрисаның уенында сурәтләү-гәүдәләндерү чаралары, гәүдә пластикасы эчке кичерешләр, эчке рухи хәрәкәт белән тулысынча ярашкан хәлдә, гармониядә яши.

Назлыгөл ролендә актрисага хас булган психологик тирәнлек, хәтта әйтер идем, үз эчке дөньясына чумып китү, хисләрне яшереп саклый алу, героинясының эчке халәтен нечкә сиземләү кебек сыйфатлар беренче тапкыр калку чагылыш тапты.

Спектакльдә Искәндәр ролен башкаручы Ринат Таҗетдинов та үз персонажының характерын җентекле тикшерә. Ул да образның бүгенге хәлен, бүгенге барлыгын гына түгел, ә аның үткән тормыш юлын, тайпылышлы сукмакларын күрсәтергә омтыла. Ни

өчен Искәндәр шушындый булып үскән, тормышның нинди ситуацияләре аның юлын чуалткан — актерны шушы мәсьәлә кызыксындыра.

Рольгә шушы рәвешчә якын килүдә актерның иҗат юнәлеше дә ачык чагыла. Кыска гына әйткәндә, бу — кешедә кешене эзләү, кеше психологиясенең эчке катламнарына үтеп кереп, аның асылын аңларга һәм аңлатырга омтылу. Тышкы тупаслыгы, эчкерлелек, намуссызлыгы, хәйләкәрлеге аша, кайчак, үткен психологик моментларда, Искәндәрдә башка бер шәхес күренеп китә. Искәндәрнең бөтенләй бүтән бер кеше булып үсәргә дә мөмкинлекләре булган икән. Ләкин Ринат Таҗетдинов үзенең героен аклау юлына басмый, ә кешедә кешелек намусын саклауның никадәр мөһим икәнлеген күрсәтә. Характерга тирән үтеп керергә, аның үз-үзен тотышы, кешелек сыйфатларының тамырларын күрсәтеп, тамашачы алдында гомумиләштерелгән типны гәүдәләндерүгә омтылышы Таҗетдиновны күркәм иҗади табышларга китерә.

Наил Дунаевка үз героен ничек тә булса аклауның кирәге дә юк иде. Аның Газизе— «җирдәге тормыш хакына» гомерен корбан итүче каһарман йөрәкле шәхес. Әмма актер шомарган штамплар белән мавыгып китмәгән, аның герое ясалма түгел. Актер Газизне кызгандырырга ашыкмый. Киресенчә, ул иронияга бай, үткен акыллы кеше булып күз алдына баса. Аның кешелек сыйфатлары, ягымлылыгы, олы күңеллелеге күзгә бәрелеп тормый. Кызгану хисе аңа карата тар һәм урынсыз нәрсә булып тоела.

Бу спектакль Г. Исәнгулова, Р. Таҗетдинов, Н. Дунаевка киләчәктәге эшләре өчен күп нәрсә бирде. Бергә укыган, рухи яктан бер-беренә якын кешеләр булгангамы, алар сәхнәдә, ничектер, эчтән чишелеп, иркенәеп уйнадылар. Шуңа күрә, эш стильләре, иҗат алымнары да анда аеруча ачык күренде. Татар театрының корифейларына хас булганча, алар кеше характерына тирән үтеп керү үрнәген бирделәр. Шул ук вакытта, аларның геройлары бер яки ике төс белән генә чагылмый, уен алымнары исә тагын да катлаулырак һәм мәгънәләргә баерак иде.

Бүгенге кешеләр (ә сәхнәдә — типлар) тышкы кыяфәтләре, үз-үзен тотышлары, килеш-килбәтләре һ. б. күп яклары белән бер-берсенә охшашлар, барысы да диярлек бер дәрәҗәдә гадиләр, культуралы һәм белемлеләр. Тышкы кыяфәте буенча гына галимне эшчедән, артистны инженердан аеруы ансат түгел. Сәхнәдә әнә Назлыны, Газиз белән Искәндәрне студентка да, врачка да, инженерга да охшатып була. Аларны Шекспир, Островский, Г. Камал геройлары белән буташтыра алмыйсың. Яңа шартлар, яңа чынбарлык персонажларының эчке асылын ачып бирүдә, кешелек сыйфатларын сурәтләүдә тагын да зуррак төгәллек, нечкәрәк буяулар куллануны таләп итә. Образны гәүдәләндерүдәге күп планлылык әнә шуның белән аңлатыла. Сәхнәдә тышкы билге-сызыклары бик үк ачыкланып җитмәгән, әмма төбендә күп кырлылык белән аерылып торган характерлар туу да яңа иҗади эзләнүләрнең бер нәтиҗәсе булып тора. Тирәлектәге шартлар үзгәрү белән сурәтләү чаралары да билгеле бер үзгәреш кичерә.

Бүгенге заман актерлары уенының (шул исәптән щепкинчыларыбызның да) мөһим сыйфатларыннан берсе — сәхнәдә фикер йөртә, уйлый белү сәләте. Бүгенге артист өчен интеллект — осталыкның иң төп күрсәткечләреннән берсе.

Иҗат юлын башлаганда Әзһәр Шакиров фикер куәтенә шул дәрәҗәдә инана иде ки, бөтен көчен үз героеның фикерләү сәләтен ачуга туплый, бу хәл хәтта аның персонажларының кул-аягын тышаулый, хәрәкәтчәнлекләрен киметә иде. Әмма вакытлар үтү белән актерның осталыгы үсә, таланты ачыла барды. Артистның фикерли белүенә һәр образга үз буяу-төсмерләрен таба белү өстәлде. Шакировның геройлары тыелгысыз стихияле көчкә ия. Мәсәлән, аның иҗат куәте белән тудырылган Айдын, яисә Надыйр мәхдүмне, «Шамил Усманов» спектакленнән Карибне искә төшерик. Күпчелек очракта бу хис ачыктан-ачык тышка бәреп чыкмыйча кала. Шул чак Шакировның геройлары көтелмәгән, әмма логик яктан акланган үзгәреш кичерәләр һәм бик тә йомшак күңелле, тартынучан, беркатлы кешеләргә әвереләләр. Болар актерның потенциаль мөмкинлекләре хакында сөйли.

Флера Хәмитова һәм Мәсгудә Хәйруллинаның иҗат индивидуальлекләре хакында да озак сөйләп булыр иде. Ф. Хәмитованың лирик табигатьле, саф күңелле мөлаем образлары бик күпләрне гашыйк итә. Тик шунысын да әйтеп китик, актрисаны озак еллар буе музыкаль спектакльләрдә бер пландарак уйнатып килделәр. Аның соңгы эшләреннән берсе — Анна Петровна («Әгәр ташлап китсәң») артистка талантының күп яклы булуына ышандыра. Тыштан шактый кырыс күренгән ул героиня күз алдына нык рухлы,

көчле характерлы кеше булып килеп баса. Спектакльне караганда, ирексездән, В. Вишневскийның «Оптимистик трагедия»сендәге комиссар, К. Треневның мәгълүм әсәрендәге Любовь Яровая кебек социаль героинялар күңелгә килә.

Мәсгуда Хәйруллинаның уен рәвеше бөтенләй башка. Аның башкаруында шаян малайлар да, җор телле хатын-кызлар да үзләре белән сәхнәгә ниндидер җиңелчә яктылык, бер нур, күтәренкелек алып киләләр.

Фирдәвес Әхтәмова белән Нәҗибә Ихсанованың уены, беренче карашка, бер-берсенә охшаш та кебек. Алар икесе дә сәхнәгә гүя яңа гына халык арасыннан, залдан күтәрелгәннәр, икесе дә гаять дәрәҗәдә табигыйлар, тормышчаннар. Тулысынча үз геройларына әверелгәннәр дә, бернинди көч һәм тырышлык сарыф итмичә, яшиләр. Бу яктан алар өлкән буын актерларын хәтерләтәләр. Әмма бу ике актриса бер-берсен кабатламый. Фирдәвес Әхтәмованың героинялары табигатьләре белән беркатлырак, басынкырак була. Нәҗибә Ихсанова башкарган рольләр исә тышкы яктан күбесенчә кырыс, кискенрәк гадәтле, катырак сүзле булалар. Ихсанованың үзсүзле Рокыясен («Чикләвек төше»), йорт эшләренә кереп баткан Сәрдиясен («Кан кардәшләре»), Әхтәмованың фидакарь җанлы Розалиясен («Соңгы хат»), акылга таман Мәйсәрәсен («Америкaн»), батыр рухлы Софьясын («Бер төн») хәтердә яңартыйк. Характерлары белән бик нык аерылып торуларына да карамастан, бу образлар кешенең рухи дөньясын, психологиясен дөрес күрсәтү, тормыш чынбарлыгын чагылдырулары белән игътибарга лаек.

...Әнә, бер буын актерлар арасында никадәр индивидуаль үзенчәлек, ничаклы төс һәм төсмерләр. Монда без интеллект сабырлыгын да, нечкә лиризмны, «каһкаһә берлән көлү» сыйфатларын да, героика, халыкчанлык, шаянлыкны да очратабыз. Һәр очракта алар персонаж характерының эчке логикасын ачу, шуны психологик нигезләү аша чагылалар.

Сүз дә юк, щепкинчы актерлар үз иҗатлары белән реалистик сәнгать традицияләрен дәвам иттерәләр. Һәм, чын иҗатчылар буларак, алга таба үстерәләр дә.

Элегрәк, өлкән буынның әйдәп баручы артистлары иҗатының нигезендә актерны тулысы белән роль эченә сеңдерү, роль белән тиңләштерү принцибы ята иде. Актер «үз-үзен, үз шәхесен, бөтен үзенчәлеген юкка чыгарырга, автор биргән затка әверелеп калырга тиеш», дип язды Щепкин. Актерларның яңа буыны уенында — әңгәмәбез вакытында алар үзләре дә шул хакта сөйләделәр — образ белән аны иҗат итүче тулысынча тәңгәл килми. Образның уй-фикерләре, хис-тойгылары белән яшәүләре өстенә алар, Б. Захава сүзләре белән әйтсәк, «образ кичергән уй-хисләр уңае белән дә фикерли һәм хис итәләр... Актерлык сәнгатенең законы актерның образга кушылуында, аңа тиңләшүендә түгел, ә үзара көрәшүче ике капма-каршы як — иҗатчы-актер һәм актер-образның диалектик бердәмлегендә» [1].

Бүген, училищены тәмамлауларына унбиш ел тулганда, щепкинчыларны без, һич арттырмыйча, зур сәхнә осталары рәтенә басып килүче өлгергән актерлар дип әйтә алабыз. Аларның гражданлык позицияләре, кешелек сыйфатлары моңа төпле нигез һәм ышаныч бирә. Чын шәхес кенә чын һәм олы художник-актер булырга мөмкин.

Әңгәмәбезнең ахырында мин щепкинчылардан:

— Бүген сезне театрда нәрсә борчый һәм уйландыра? — дип сорадым.

— Репертуар,— диделәр алар беравыздан.— Зур, җитди әсәрләрне уйныйсы килә, һәм классиканы... Чеховны, Шекспирны... Без күпмедер дәрәҗәдә үстек һәм аларның әсәрләрендә үзебезне сынап карарга әзер дип уйлыйбыз. Әгәр безне моңа кадәр башкарган һәм бер-берсен кабатлый торган рольләрдә генә уйнатып, гел берьяклы гына файдалансалар, киләчәк эшебездә штамп барлыкка килүе мөмкин. Без моңа бик борчылабыз. Әгәр театр җитәкчелеге, вакыты-вакыты белән, башка театрлардан да кызыклы режиссерлар чакыртса, бу бик файдалы булыр иде. Ул мәсьәләдә, әйтик, казакъ театры белән килешергә мөмкиндер. Бездә А. Мамбетов эшләп алыр, ә аларга М. Сәлимҗанов барып кайтыр иде. Мондый алышу файда гына бирәчәк.

Унынчы бишьеллык — сыйфат бишьеллыгы һәм без барлык спектакльләрдә дә үз эшебезнең иң югары таләпләргә җавап бирерлек булуын теләр идек.

Мин щепкинчы дусларыма яңа иҗат уңышлары, теләкләренең тормышка ашуын телрдем.

---

[1] Б. Захава. Актерлык һәм режиссерлык осталыгы. Мәскәү, 1969 ел, 37, 48 битләр.

Нурихан Фәттах

# ЕРАК ГАСЫРЛАР АВАЗЫ

## Кереш

Тел безнең бетмәс-төкәнмәс байлыгыбыз. Бу байлыкны берни белән бәяләп тә булмый, тулысынча колачлап та булмый. Туган телне иксез-чиксез диңгез белән дә, күктәге кояш белән дә, әкиятләрдәге серле сандык белән дә чагыштырып булыр иде. Ләкин минем хәзер аны борынгы хәрабәләр янына салынган яңа шәһәр белән чагыштырасым килә.

Археологларның эшен күз алдына китерик. Менә шәһәр чите. Курганнар, хәрабәләр... Таудай өелгән гасырлар тузанын сыпырып, археологлар җир астында калган тарих серләрен ачалар. Иплэп кенә, сак кына алар туфрак катламнарын алып ташлыйлар. Бер катлам артыннан икенче катлам алына, һәм балчык-ком арасыннан, көлкүмер арасыннан нииндидер чүлмәкләр, сынган кылыч, пычак, сөяк-санак һ. б. йортҗиһаз, тормыш-көнкүреш әйберләре килеп чыга. Шул әйберләрнең калдыклары буенча археологлар моннан йөз еллар, мең еллар элек яшәгән: шатланган-куанган, ярсыганкайгырган, кычкырып җырлаган һәм елаган кешеләрнең борынгы тормыш-яшәешләрен күз алдына китереп бастыралар.

Шул ук вакытта аларның аягы астында гына, ярларына чайпалып, тулып-артылып, көчле Идел агып ята, якында гына бүгенге шәһәрнең шау-шуы ишетелеп тора.

Җанлы халыкның җанлы теле дә менә шулай. Анда да үткән гасырлардан калган «курганнар», «хәрабәләр» бар, хәзерге заманның туктаусыз шау-шуы, гөрелтесе бар. Тик монда кечкенә бер аерманы да истән чыгарырга ярамый. Борынгы шәһәр калдыклары гадәттә бүгенге тормышта катнашмыйлар диярлек — алар күбесенчә музейларда, кабинетларда сакланалар. Телдәге «курганнар» исә һәр вакыт бүгенге тормыш белән яшиләр, һәм еш кына без аларның элекке заман таныклары булуы турында уйлап та карамыйбыз.

«Ерак гасырлар авазы» дип аталган бу язмаларда мин, кешенең борынгы аңкарашларын, борынгы тормышын чагылдырган һәм җанлы сөйләм телендә әлегәчә сакланып килгән кайбер сүзләрнең һәм сүз тезмәләренең «археологик» катламнарын ачып, төрки халыклар тарихына һәм этнографиясенә кагылышлы кайбер фикерләрем белән уртаклашмакчы булам.

## Нәрсә ул «аксөяк»?

Бүгенге телдә **аксөяк**нең мәгънәсе бик үк конкрет түгел сыман. Дөрес, югары катлам кешеләрен, ягъни аристократияне гадәттә аксөяк диләр. Ләкин аристократия генә аксөяк микән? Бу сүзне кулланганда, аксөяк кешенең кара эш, тупас эш эшләргә яратмаучы, тәмле ашарга яратучы булуы төсмерләнә кебек. Аннары ул ялкау да, эшлексез дә бугай әле. Югары дәрәҗәдәге бай кеше генә түгел, гап-гади бер әрәмтамак та кайчагында аксөяк булырга мөмкин.

Ни өчен аксөяк икән соң андый кешеләр? Бай, дәрәҗәле кешенең кулы-аягы «кара» кешенеке төсле тупас булмый дип уйлау нәтиҗәсен-

дә барлыкка килмәде микән бу аксөяк сүзе? Телдә, мәсәлән, шундыйрак карашны аңлаткан «хан кызы!», «хан малае!» дигән сүзләр сакланып калган ич. Ак, йомшак куллы, эш сөймәс кешеләргә бүген дә шулай мыскыллап (яисә шаяртып) әйтәләр ләбаса! Борынгы заманнарда аксөяк кешенең тәне генә түгел, сөякләре дә аграк була дип уйламадылар микән әле?!

Аксөякнең тышкы формасына гына игътибар итсәк, чыннан да без шундый нәтиҗәгә килер идек кебек. Ләкин безнең максат — тышкы форма алдында гына тукталып калу түгел, киресенчә, тышкы форма эченә яшеренгән тирән мәгънәне ачып бирү. Шуңа күрә без әлеге форманы — ягъни археологик «чүлмәк»нә ватарга тырышып карыйк. Моның өчен без шундый сорау куя алабыз: аксөяк кешенең кулы-аягы, хәтта сөякләре дә ак булгач, «кара» кешеләрнең куллары гына түгел, хәтта сөякләре дә кара булды микәнни? Дөресрәге, элекке кеше шулай дип уйлады микәнни? Беркайчан кеше сөяге күрмәгән кеше, әйтик, шулай дип уйласын да ди. Ләкин борынгы кешегә үлгән, үтерелгән кеше сөяген еш күрергә туры килгән һәм шунлыктан аны сөякнең нинди төстә булуын белмәгәндер дип уйлау нигезсез булыр иде.

Болай булгач, безгә икенче төрле юнәлештә фикер йөртеп карарга туры килә. Бәлки бу **аксөяк**нең төбендә бөтенләй башка төрле уй-фикерләр, башка төрле аң-карашлар ятадыр?

Аксөяк сүзе күрер күзгә бик гади тоелган **ак** белән **сөяк**тән «ясалган». Мәгълүм булганча, **ак** төсне аңлата. Ак ул **караның** капма-каршысы. Ләкин борынгы телдә **ак** төсне генә түгел, башка бик күп мәгънәләрне дә аңлаткан һәм, әлбәттә, бүгенге көндәгегә караганда активрак кулланылган. Акның төрле мәгънә аңлатуын без бүгенге телдәге кайбер сүз тезмәләре ярдәмендә дә исбат итә алабыз.

Мәсәлән, нәрсә ул **ак юл?** Бу сүзнең төп мәгънәсе «изге юл», «хәерле юл» була түгелме соң? Яисә **аккош, аксакал** дигән сүзләрне алыгыз. Аккош дигәндә ак төс тә күз алдына килә. Ләкин аккош дип аталган бу кошның карасы да була ләбаса! Шулай булгач, аккошның мәгънәсе **«ак төсле кош»**ка гына кайтып кала дип әйтеп булмый. Аксакал мәсьәләсендә дә шундый ук нәрсә күзгә ташлана. Аксакал дип элек хөрмәткә лаек булган, башлы, белдекле, дәрәҗәле, өлкән яшьтәге ир кешегә әйткәннәр. Бүгенге телдә дә аның төп мәгънәсе шундый, тик хәзер аның кулланылышы гына тарая төшкән. Монда да төс мәгънәсе дә бар — аксакал кешенең һичшиксез сакалы булырга һәм ул сакал ак (чал) булырга тиеш сыман тоела. Ләкин чынлыкта гел алай булгандыр дип әйтеп булмый. Аккошларның карасы да булган кебек, аксакалларның да сакалсызы яисә кара сакаллысы да булгандыр дип фараз кылу урынлырак тоела.

**Ак** тамыры катнашкан, ләкин төсне түгел, башка мәгънәләрне аңлаткан тагын бик күп сүзләрне һәм сүз тезмәләрен мисалга китереп булыр иде. Мәсәлән, **акбалык** (зур, яхшы балык), **агәби, акбабай, ак-түтәй** (өлкән, хөрмәтле әби, бабай, түтәй) һ. б.

Ак сүзе шулай ук **катык-сөт** мәгънәсендә дә кулланыла. Менә бу катык-сөткә киңрәк тукталасы килә. **Ак**ның катык-сөт мәгънәсе «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нә дә теркәлгән, ләкин аның ни рәвешчә, нинди формада катык-сөтне аңлатуына мисал китерелмәгән. Мин туып-үскән якта (Башкортстанның төньягында) катык-сөтне алай кистереп **ак** дип түгел, бәлки **сыер агы** дип әйтәләр. Һәм ул һәр вакытта да, һәр очракта да әйтелми. Катык-сөт бик кадерле вакытта гына аны шулай яратып сыер агы, сыер аккае диләр.

Сыер агының кайчандыр **туар агы** дигән тугanы да булган һәм туар агыннан русның **творогы** барлыкка килгән. Туар сүзе элек кайсыдыр кабилә телендә, күрәсең, хәзерге сыер мәгънәсендә йөргәндер дип әйтергә була. Бүгенге телдә **мал-туар** нигездә сыерны аңлата, **терлек** исә

күбрәк вак малга карата кулланыла. Телдә бик еш кулланыла торган **акча** сүзенең дә «ерак бабасы» менә шушы сыер агы яисә туар агы булырга тиеш дип әйтәсе килә.

XI гасырда яшәгән һәм иҗат иткән бөек галим Мәхмүд Кашгари үзенең атаклы сүзлегендә **агы** дигән сүз теркәп калдырган. Бу **агы**ның мәгънәсе: кыйммәтле әйберләр, хәзинә, бүләкләр була. Казан арты керәшеннәре әле бүгенге көндә дә бүләкне агы яисә ак дип әйтәләр. Ә менә кыйммәтле әйбер, хәзинә мәгънәсендәге **агы** бүгенге татар телендә юк бугай. Хәер, нигә ашыгырга?

Шулай итеп, борынгырак заманда М. Кашгари язып калдырган **агы** сүзе **сыер агы** яисә **туар агы** рәвешендә кулланылгандыр дип әйтә алабыз, чөнки ы тартым кушымчасы шуңа ишарәли. Борынгы күчмә халыкның төп байлыгы, төп хәзинәсе нәкъ менә шул **сыер агы** (туар агы) булуы бернинди шик тудырмый. Ләкин М. Кашгари заманында яисә аннан бераз элегрәк байлыкны, хәзинәне белдергән бу сүзнең **сыеры** да, **туары** да инде, күрәсең, кулланылмый башлаган булгандыр. Һәм сөт-катыкны гына аңлаткан бу сүз тезмәсеннән гомумән байлыкны, хәзинәне (алтын-көмешне, тирене, тукыманы һ. б.) белдергән яңа сүз аерылып чыккан.

Тик бу **агы**ның да гомере озын булмаган. Аны гарәп (?) сүзе **хәзинә** алыштырган. Шулай да хәзинәнең элгәресе дә бөтенләй үк эзсез югалмаган — агы сүзе **акча**да сакланып калган. Акча баштарак **агыча** формасында йөргәндер дип әйтергә була. Агы-ча ул бөтен байлыкның бер кисәген, өлешен аңлаткан һәм үзеннән элегрәк чорда кулланышта булган **ярмак** сүзен кысрыклап чыгарган.

Борынгы терлекченең сөт-катыгы гына түгел, сөт-катыкны бирүченең атамалары да тора-бара төп эчтәлекләрен үзгәртеп, икенче төрле мәгънәләрдә йөри башлаган. Мәсәлән, бүген бик күп телләрдә актив булган **товар** сүзе төркиләрнең **туар**ыннан үзгәргән. Шулай ук **мал** да, тулысынча ук булмаса да, «товарлашып» киткән (**кызыл мал** — тукыма). Мал сүзеннән русның **молоко**сы ясалган (мал-акы).

Күреп үткәнебезчә, ак сүзе бары төсне генә аңлатмый икән. Инде **сөяк** сүзен тикшереп карыйк. Сөякнең мәгънәсен искә төшереп тору кирәк микән? Юк, кирәкмәс, ахрысы. Сөяк сөяк инде ул. Ләкин «бай, көчле, изге.... сөяк» дип әйтсәк, берәр нәрсә аңлашылырмы соң? Әлегә берни аңлашылмас.

Бәлки сөяк сүзенең дә борынгы заманнарда бүтән төрлерәк мәгънәсе булгандыр? Әйе, булган икән шул. Сөяк элек **ыру** мәгънәсендә дә йөргән. Алтайлыларда (алтай-кежеләрдә), мәсәлән, бүген дә ул ыру мәгънәсендә кулланыла. Шулай ук татар телендәге «сөйкемсез сөяк»тә сөякнең ыру мәгънәсенә ишарәли.

Шулай итеп, борынгы төркиләр телендә **ак сөяк** сүзе көчле, изге, бай, дәрәҗәле һәм хөрмәткә лаек ыру дигәнне аңлаткан булып чыга. Сүзнең мәгънәсе ачыкланды, тик мәсьәлә барыбер ачыкланмады. Мәсьәләне ачыклау өчен безгә бераз гына тарихка күз ташлап алырга туры килә.

Мәгълүм булганча, дәүләтләр барлыкка килгәнче аерым ырулар, беркемгә буйсынмыйча, мөстәкыйль тормыш белән яшәгәннәр һәм еш кына үзара сугышып-ызгышып яшәгәннәр. Менә шундый ыруларның кайберләре, уңай шартлар туу белән, кинәт көчәеп киткәннәр һәм көчсезрәк, ярлырак күршеләрен басып алганнар, үзләренә буйсындырганнар. Шул рәвешчә **ырулар берләшмәсе, кабиләләр берләшмәсе,** аннан соңрак **дәүләтләр** барлыкка килгән. Башкаларны үзенә буйсындырган бай, көчле һәм күп санлы ырулар яңа оешкан берләшмәдә, әлбәттә, хакимлек ролен үтәгәннәр. Ханнар, каганнар күп очракта менә шундый ырулардан чыккан кешеләр булган. Яхшырак көтүлекләр алар (аксөяк ырулар) кулында булган һәм яуда талап алынган байлыкның

да күбрәк өлеше алар кулына эләккән. Башка ыру кешеләре өчен мондый ыру яисә ырулар, билгеле, изге, бай, көчле һәм хөрмәткә лаек ыру булып саналган.

Ибн Рустә (X гасыр) һәм Гардизи (XI гасыр) язмаларында Идел буе болгарларының өч өлештән (ырудан яисә кабиләдән) торуы турында әйтелә. Ыруларның (кабиләләрнең) берсе Берсула (Барыс иле), икенчесе — Эсигел (Ас иле), өченчесе — Болгар дип аталган. Моннан ике мең ике йөз еллар элек хәзерге Төньяк Кытай һәм Монголия территориясендә барлыкка килгән төрки дәүләт — «хунну» лар дәүләтендә дә атаклы ырулар өчәү булган. Болар: Хуянь (Куян), Лань (Болан?), Сөйбү (?) ырулары. Борынгы тарих язмаларында әйтелгәнчә, бу ырулар илдә иң атаклылардан саналганнар, һәм дәүләт башлыгы бары шул ыру кызларына гына өйләнгән. Илдәге хөкем-җәза эше тулысынча әлеге аксөяк ыру башлыклары кулында булган.

Гасырлар узу белән, бер дәүләтләр җимерелеп, алары урынына икенчеләр барлыкка килгән. Икенче дәүләтләрдә инде башкачарак тәртипләр, мөнәсәбәтләр урнашкан. Элекке аксөякләргә карата булган хөрмәт һәм курку тойгысы дошманлык һәм нәфрәт тойгысына әйләнгән. Шулай итеп, аксөяк сүзе тора-бара әүвәлге мәгънәсенә бөтенләй капма-каршы хис-тойгыларны, уй һәм карашларны аңлата башлаган. Шуңа күрә дә бүген без **аксөяк**не нигездә кире мәгънәдә кулланабыз да.

## Бүресе улый!

**Беренче сәяхәт. Беренче танышу.**

Кинәт кенә баеп киткән һәм гомумән зур уңышка, бәхеткә ирешкән кеше турында шулай **бүресе улый!** диләр. Нинди куркыныч — үзе бүре, үзе улый! Бүре генә дә түгел, **бүресе** бит әле! Әйтерсең байлыкка, уңышка ирешкән кеше үзенең абзары алдына бүре бәйләп куйган да... яисә уңышка ирешкән кешенең эченә бүре кереп утырган да сөенеченнән улапмы-улый!

Туктагыз әле, нинди бүре соң бу шулай да — чылбырга бәйләп куйган бүреме, әллә соң чыннан да кешенең эченә кереп оялаган бүреме? Телдә тагын **эчемдә көчекләр өрә башлады** дигән сүз дә бар. (Төрле лингвистик терминнарны онытып торып, кыскалык өчен биредә аңлы рәвештә «сүз» кулланыла). Бик ачыккан кеше «тупас» итеп: ачыктым, ашыйсым килә димичә, менә шулай читләтеп, эчемдә көчекләр өрә, ди.

Нәрсә бу — шигъри чагыштырулар гынамы, әллә, юкса, бу сүзләрнең дә төбендә борынгы заман кешеләренең реаль аң-карашлары яшеренеп ятамы? Моны дөрес аңлау өчен безгә хәзер этләрнең, бүреләрнең һәм шулай ук кыргый ата-бабаларыбызның кыскача «биографиясе» белән танышырга туры киләчәк.

Бик борынгы заманнарда кеше (дөресрәге, кыргый кеше) табигатьтәге барлык җанлы-җансызны изге дип уйлаган. Шуның нигезендә ул тауларга, елгаларга, күлләргә, агачларга, хайваннарга табынган. Иң әүвәл кеше агачларга һәм үсемлекләргә табына башлаган дип уйланыла. Мондый табыну хатын-кыз хакимлеге (матриархат) чорында киң таралган була. Хакимлек ирләр, ягъни аучылар кулына күчкәч, хайваннарга, кошларга, еланнарга табыну көчәеп китә. Борынгы кеше аңындагы мондый үзгәреш элекке «экономикадагы» үзгәрешләргә бәйле рәвештә аңлатыла. Матриархат чорында агач, үсемлек җимешләре, орлыклары белән туену өстенлек иткән булса, патриархат чорында инде ит белән туену, димәк, аучылык өстенлек итә башлый.

Яңа чор башлану белән генә кеше аңындагы элекке карашлар юкка чыкмый, әлбәттә. Яңалык белән искелек бик озак вакытлар бергә

яши. Без хәтта бүгенге көндә дә тирә-ягыбызда бик-бик ерак әбиләребезнең, бабаларыбызның агачка, үсемлекләргә табынуы турында сөйли торган мисалларны таба алабыз. Урта гасырда төрки савирларның аерым үсеп утырга зур имәнгә табынулары турында язма мәгълүматлар сакланып калган. Татар авылларына керер алдыннан юл буендагы агачларны әле бүген дә күрергә була. Болар — «изге» агачлар. Ялгызнарат, Чалманарат, Кушнарат, Өчимән, Кушимән кебек авыл исемнәре менә шул «изге» агачларны олылау нигезендә барлыкка килгәннәр.

Борынгы төркиләрнең агачларга, үсемлекләргә табынулары турында тагын күп кенә мисаллар китерергә мөмкин булыр иде, ләкин бу безне төп темадан читкә алып китәчәк. Шулай да татар хатын-кызларының борын-борыннан гөл, чәчәк үстерүгә хирыс булуларын, гомумән төркиләрнең чәчәкле, бизәкле кием-салым тукыма яратуларын искә алмый ярамас. Татар халкының бай орнаментында үсемлек мотивларының өстенлек итүе дә тикмәгә генә түгел. Аннары гөл, чәчәк үстерү йоласы да, аллы-гөлле тукымалар да, шулай ук кайбер үсемлекләр, чәчәкләр дә (мәсәлән, тюльпан, карабодай) Европа халыкларына гомумән төркиләрдән кергән дип исәпләнелә.

Үсемлекләр турында шуның белән җитеп торыр. Хәзер инде хайваннар дөньясына әйләнеп кайтыйк. Кыргый хайваннардан иң элек кеше **бүрене** кулга ияләштергән. Тирә-ягы төрле ерткычлар белән, куркыныч нәрсәләр белән тулы тормышта ул кешенең ышанычлы дустына, беренче ярдәмчесенә әверелгән.

Кулга ияләштерелгән бүре (яисә эт) кеше белән ауга йөргән, куркыныч килүен алдан аңа хәбәр иткән, кирәк булса, үзе югында аның куышын саклаган. Эт белән бергәләп кеше курыкмыйча бер урыннан икенче урынга күчә алган һәм әкренләп-әкренләп ерткыч хайваннарның мәңгелек биләмәләрен яулап алган. Нәтиҗәдә эт белән дуслашкан кешенең территориясе киңәйгән, аңы-карашы, теләк һәм омтылышлары үсә барган.

Менә шундый шартларда кыргый кешенең **эткә-бүрегә табына** башлавы һич тә гаҗәп түгел. Һәм ул табынган. Төрки халыкларның барысы да диярлек эткә-бүрегә табынганнар. Бу табыну төрле рәвештә булган. Бик борынгы заманнарда үлгән этне кеше кебек үк кадерләп күмә торган булганнар. Этнең, бүренең тешләре, тырнаклары төрле имтомда кулланылган. Тишеп җепкә тезелгән азау тешләрен кыргый кеше бөти итеп муенына тагып йөргән. Авыру балаларга ана эт сөтен имезгәннәр. Пычак сапларына, аелларга, төймәләргә, төрле коралларга, байракларга эт, бүре башы сурәтләре ясалган. Боларның барысы да кешене төрле яман күзләрдән, яман чирләрдән сакларга тиеш булган.

Борынгы кеше эткә-бүрегә табынып кына да калмаган, ул аны хәтта үзенең туганы, кан кардәше дип тә аңлаган. Кайбер аналар әле бүген дә үз балаларына ярату катыш ачуланып: **эттән туган!** диләр. Кыргый кешенең ышануынча, кеше — бүрегә, бүре кешегә әверелә алган. Татар әкиятләрендә убырлы карчык Гөлчәчәкне яисә анда таз малайны куа килгәндә бүрегә әйләнә. Явыз көчнең бүрегә әйләнүе, күрәсең, соңгырак гасырларда — безнең якларда ислам дине тамыр җәйгәч барлыкка килгәндер дип әйтергә була. Ә менә «Ак бүре» әкиятендә бүре, киресенчә, бик чибәр егеткә әверелеп, бәлагә тарыган яхшы кешеләргә ярдәм итә. Мәхмүд Кашгари сүзлегендә шундый бер мәкаль сакланып калган: XI гасыр кешеләре ир бала туса — **бүре туды,** кыз бала туса — **төлке туды** дип әйтә торган булганнар. Моның төбендә элекке кешеләрнең: ир кеше ул — бүре, бүре ул — ир кеше дигән карашы ята.

Моннан ике мең еллар элек язылган бер тарихи әсәрдә (Бань Гуның «Хань-шу» дип аталган тарихи әсәрендә) төрки хуннуларның шу-

лай ук бер мәкале теркәлгән. Бамбук таякларына язылган бу беренче мәкальнең төркичә әйтелешен без инде белә алмыйбыз, ләкин аның мәгънәсе болайрак булган: бер бүре үтерелсә, мең сарык таралып бетә, дигәннәр хуннулар [1].

Кызык бит — бүре, имеш, сарык көтүенең башлыгы булган! Андый дәрәҗәгә ничек ирешә икән ул? Әллә мәкаль юри шаяртып «сөйләнәме»? Юк, әлбәттә. Монда да шул ук нәрсә: кеше белән бүре арасында бернинди аерма юк дигән фәлсәфә чагыла. Борынгы хуннулар мәкалендәге бүре — гаскәр башлыгын, мең сарык сугышчыларны белдергән.

Борынгы язмаларда хуннуларның нинди дә булса хайванга табынулары яисә табынмаулары турында ачыктан-ачык берни әйтелмәгән. Мәкаль исә, күргәнебезчә, бүренең аларда изге хайван булуы турында сөйли. Моңа өстәп тагын шуны да әйтергә була: моннан ике мең еллар элек язылган шул ук кытай язмаларында хуннуларның Фули, Пули дигән кеше исемнәре телгә алына. Әлеге Фули, Пулиларның чынында Бүре икәнлеген аңлау кыен эш түгел. Көтү башлыгы булган бүре турындагы мәкаль дә, Бүре дигән кеше исемнәре дә хуннуларның төркилегенә өстәмә бер дәлил булып торса, шул ук вакытта бу — кешенең бүре белән дуслыгы турындагы иң борынгы язма чыганакларның берсе булып та исәпләнелә ала.

Иң борынгы чыганаклар турында авыз ачкач, монда тагын бер-ике сүз әйтеп китәргә кирәк. Фәндә «күрәзә язулары» яисә «күрәзә сөякләре» дип аталган нәрсә бар. Бу «күрәзә язулары»н безнең эрага кадәр XIV—XV гасырларда Хуанхэ елгасы бассейнында яшәгән Инь (Кытай) кешеләре язып калдырганнар. Терлек сөякләренә, ташбака кабырчыкларына язылган «күрәзә язулары»нда борынгы Инь кешеләрен чолгап алган илләрдән артык чит ыру-кабилә исемнәре бар. Шунда төрле хайван, үсемлек исемнәре белән аталган кабиләләр арасында эт, ат, сарык һ. б. хайваннарга табынучы ыру-кабиләләрнең исемнәре телгә алына. Дөрес, аларның нинди телдә сөйләшүләре турында анда бер сүз дә юк. Ләкин хунну бабаларының борын-борыннан кытайлар белән күрше булып яшәүләрен һәм аларның бүрегә табынуларын исәпкә алсак, әлеге язулардагы кайбер кабиләләр, һичшиксез, хуннулар (төркиләр) булган булырга тиеш дип уйлый алабыз.

Этка-бүрегә табыну соңгырак гасырларда да көчен югалтмаган. Безнең эраның VI — VIII гасырларында күтәрелеш чоры кичергән Алтай төрекләре дә, борынгы уйгурлар да бүрегә табынганнар. Борынгы хуннуларның бер тармагы һәм дәвамы булган Алтай төрекләре, уйгурлар үзләренең турыдан-туры бүредән яралулары турында легендалар сөйләгәннәр һәм бу легендалар тарихи язмаларда сакланып калган.

Төрки халыклар, билгеле, этка-бүрегә генә түгел, башка хайваннарга да, кошларга, еланнарга да табынганнар. Монысы инде, күрәсең, этка-бүрегә табына башлаудан соңгырак чорларда һәм бөтенләй башка шартларда барлыкка килгәндер дип әйтергә була. 922 елда Идел буена килеп киткән гарәп язучысы Ибн Фадлан X гасырдагы башкорт ыруларының еланнарга, балыкларга, торналарга табынулары турында яза. Ибн Фадлан башкортларның торналарга кайчан, ничек табына башлаулары турында легенда сыман бер хикәя дә теркәп уза. Бу исә теге-бу хайванга, кошка, балыкка табынуны нигезләү өчен элекке заманнарда төрле легендалар-истәлекләр сөйләнүенә бер дәлил булып тора.

Төрки халыкларның шулай ук аюга, барыска, куянга һ. б. җәнлекләргә, хайваннарга табынулары бәхәссез нәрсә. Гомумән, төрки халык-

---

[1] Материалы по истории сюнну. Икенче чыгарылыш. Мәскәү. 1973 ел. 164 бит.

лар кыргый хайваннар һәм йорт хайваннары белән гасырлар буена «дус-тату» яшәгәннәр. Бу «дуслык» төрки халыкларның телендә, мифологиясендә, фольклорында, сәнгатендә җуелмаслык эз калдырган. Хәзерге заман зоопаркларының башы нигездә төркиләр эшчәнлегенә кайтып кала. Беренче зообакча X гасырда Мисырда төрки Тулуннар династиясе хакимлеге чорында оештырыла[1]. Төрки кеше исемнәре арасында элек хайваннар, кош-кортлар нәселендәге атамалар шактый күп булган, һәм алар иң дәрәҗәле, иң изге исемнәрдән саналганнар. Бүгенге көндәге авыл атамаларында яисә төрле кушаматларда сакланып калган Аюлар, Бүреләр, Ябалак, Карчыга, Бөркет, Куян, Торналар һ. б.— болар барысы да шул борынгы заманнар калдыгы.

Шулай итеп, бик күп гасырлар буена төрки халыклар аңында этбүре изге хайван саналган. **Бүресе улый** сүзенең бүгенге көнгә чаклы уңай мәгънәдә сакланып килүе бу фикерне аеруча көчәйтә төшә. Ләкин безнең әле **эт улавы**быз да бар. X гасырда болгарлар эт улавын изгегә юраганнар, эт уласа туклыклы, имин ел килә дип уйлаганнар. Казан шәһәренең салынуы турында халыкта әле булса шундый бер легенда яши. Шәһәр салучыларга хан әйткән, имеш: беренче булып кемне күрсәгез, тере килеш шуны нигезгә салыгыз, дигән. Беренче булып хан углы күренгән. Төзүчеләр, хан углын кызганып, аның урынына эт салганнар.

Үзеннән-үзе монда шундый нәтиҗә сорала: этка, бүрегә табыну төрки халыкларда шундый көчле һәм дәвамлы булган икән, димәк, иң беренче булып этне-бүрене алар кулга ияләштергәннәр.

## Борынгы кешенең табыны

Заман үтү белән халыкның кайбер дини-мифик карашлары шактый үзгәргән, я булмаса бөтенләй онытылып беткән. Тик шулай да туган тел — җанлы сөйләм теле безгә бик борынгы бабаларыбыздан «ялкынлы сәлам» авазлары китереп җиткергән. **Бүресе улый, эчемдә көчекләр өрә, эттән туган** кебек сүзләр шуның мисаллары булып тора. Бүгенге көндә этка, эт улавына карата кире караш та нәкъ шул турыда сөйли: халык үзенең борынгы дустына мөнәсәбәтен үзгәртсә үзгәрткән, шулай да аңа битараф калмаган.

Эт-бүре турында безнең әлеге мисаллардан да сәеррәк сүзләребез бар. Бик ачыккан кеше, мәсәлән, югарыда әйтелгәнчә, эчтә көчекләр өрә башлады дип тә, **бүре башы кимерердәй булдым!** дип тә ычкындырырга мөмкин. Күз алдыгызга китерегез: кыргый кеше бүре башы кимерү турында хыяллана! Баш ите иң начар, туклыксыз ит санала, ләкин әлеге кыргый бабабыз ачыгуның иң соңгы дәрәҗәсенә җиткән— ул хәтта баш итенә дә риза.

Туктагыз әле, нәрсә соң бу? Болай булгач, безнең сөекле бабаларымыз эт-бүре ите ашаганнар булып чыгалар түгелме соң? Тфү, тфү, булмас! Татар беркайчан да андый нәҗесне ашамас!

Бүгенге кеше, әлбәттә, шулай дип уйлаячак. Ләкин, нихәл итмәк кирәк, сөйдергән дә тел, биздергән дә тел, дигән кебек, тел-тарих безгә шул турыда сөйли. Кулга ияләштерелгән эт яисә бүре, күрәсең, тикмәгә генә беренче йорт хайваны булмагандыр. Кыргый кешенең ул баштарак аты да, эте дә, сарыгы да, якын дусты да булган.

**Бүре башы кимерүгә** тагын «Этнең башын табакка салсаң, сикереп торыр» дигән мәкальне дә өстәргә була. Этнең башын табакка салалармы, һәм салсалар, ник салалар? Без монда шундыйрак сорау куя алабыз, һәм бу безгә берни белән аңлатып булмастай мәгънәсезлек булып тоела. Ләкин элекке кеше өчен бу, күрәсең, гадәти нәрсә булган

[1] Адам Мец. Мусульманский Ренессанс. Мәскәү, 1966 ел, 320 бит.

һәм шул гадәти нәрсә, ягъни этнең башын табакка салып ашау нигезендә хәтта мәкаль дә барлыкка килгән.

Димәк, безнең кыргый бабаларыбыз эт һәм бүре ите ашаганнар булып чыга. «Кыргый бабаларыбыз» гына микән әле! Бүгенге көндә без: «Эт тә симез — ашарга ярамый», дибез. Моның белән без: һәр нәрсә һәр очракта файдалы яисә дөрес була алмый, дип әйтергә телибез. Әмма бу мәкаль барлыкка килгән заманнарда моның мәгънәсе: этем симез дә симезен, ашый алмыйм шул — мулла абзый кушмый кебегрәк булмады микән әле?! Хәер, «мулла абзыйлар» заманында эт-бүре ите ашау инде искергән йола калдыгы рәвешендә генә кулланылган булырга мөмкин. Аннары этнең кайчандыр гомумән ерткычны, киекне, җәнлекне аңлаткан булуы ихтималын да күз алдында тотарга кирәк.

Монда тагын бик тә әһәмиятле бер детальгә игътибар итеп китик. Бу деталь — **эт** атамасы. Уйлап карагыз әле, **эт** сүзе **ит**нең яисә, киресенчә, **ит** сүзе **эт**нең фонетик вариантлары гына түгелме соң?! Төрки телләрнең күпчелегендә (казакъ, уйгур, кыргыз һ. б.) ит — **эт**не, эт **ит**не белдерә.

Бер нәрсәне икенче нәрсә белән бутау юкмы монда? Әлбәттә, бар, ләкин мин «бутарга» мәҗбүрмен, чөнки, югарыда әйтелгәнчә, эт белән бүре бертуган. Бүре турындагы әйтем — эткә, эт турындагы әйтем — бүрегә кагыла. Нәтиҗәдә бу безгә гомумән халык аңының нигезен ачыкларга ярдәм итә. Ләкин борынгы халык үзе эт белән бүрене шулай «буташтыргандыр» дип әйтеп булмый. Берәүләр эткә табынса, икенче берәүләр бүрегә табынганнар һәм бу хайваннарга карата мөнәсәбәт тә төрле кабиләдә төрлечәрәк булган. Моның шулай булуын без беркадәр күреп үттек инде. Аннары без шуны да белдек: төрки хуннулар, хуннулардан соң тарих сәхнәсенә чыккан Алтай төрекләре бүрегә табынганнар.

## Кем син, Бүре?—Атаң кем дә, анаң кем?

Бүре этимологиясе бүгенге көнгә кадәр тиешенчә хәл ителмәгән. Венгр галиме Г. Вамбери бүрене **бөр, бор** (соры) сүзеннән чыгып аңлаткан. Совет галиме А. М. Щербак моңа каршы килә һәм **бүре**не һинд-европа (согдак, санскрит, Авеста) телләренә таянып аңлатмакчы була [1]. Тарихчы С. Г. Кляшторный да шундый ук караштa тора һәм, **бүре**нең һинд-европа телләреннән алынган булуы ихтималына нигезләнеп, Алтай төрекләренең халык-кабилә буларак формалашуында һәм аларның культура тормышында иран халыкларының роле зур булган дигән нәтиҗә ясый [2]. Башка кайбер галимнәр дә **бүре**не һинд-европа телләреннән алынган дип исәплиләр. Немец тюркологы В. Банг [3] 1917 елда ук инде: бүре сүзенең мәгънәсен тюркологик чаралар белән аңлату мөмкин түгел дигән. Бу фикер бүгенге көнгә чаклы үз көчендә кала бирә.

Шулай итеп, тюркология фәнендә хакимлек иткән караш буенча, бүре сүзе иран телләреннән алынган булып чыга.

Бу мәсьәләдә галимнәрнең авторитетлы сүзләренә күз йомып, үз бүребезне без үзебезчә аңлатырга тырышып карыйбыз.

---

[1] А. М. Щербак. Названия домашних и диких животных в тюркских языках. «Историческое развитие лексики тюркских языков» дигән китапта. Мәскәү, 1961 ел, 132 бит.

[2] С. Г. Кляшторный. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. Мәскәү, 1964 ел, 111—113 битләр.

[3] Шул ук китап, 111 бит.

Бүре сүзе ике кисәктән тора: **бү-ре**. Ничегрәк якын килергә моңа, кай җиреннән капшап карарга моны? Бәлки бу **бү-ре** түгелдер, **бүр-е**-дер? Ахыргы **е** — тартым кушымчасы. **Бүр** нәрсә, алайса? Вамбери әйткәнчә, **соры** (серый) мы?

**Сыер агы** турында уйланып йөргәндә кинәт күз алларым яктырып китте. Монда да шундый ук закончалык ята түгелме соң?! Ягъни **бүре** дә **агы** тибындагы сүз түгелме? Шулай булган очракта, **бүрне** без **бүз** дип «төзәтә» алабыз, чөнки төрки телләрдә **р** белән знең чиратлашуы мәгълүм нәрсә (мәсәлән, күз-күр). **Бүргә** караганда **бүз** бүгенге көндә аңлаешлырак, тәэсирлерәк. **Бүз** ул акның синонимы. **Акбүз ат** дигәндә **акбүз** парлы сүз булып тора (ак + ак). Хәер, **бур-бүр** дә **акны** белдерә. **Акбур** дигәндә дә **акбүз** дигәндәге хәл кабатлана, тик акбур белән акбүзнең мәгънәләре генә төрлечә.

Без инде **ак** сүзенең төрки телләрдә төрле мәгънәдә кулланылуын беләбез. **Ак** белән **бүз** бер-берсенә тиңдәш булгач, **бүз (бүр)** сүзе дә элек **бай, көчле, изге, хөрмәтле** мәгънәләрен белдергәндер дип әйтергә тулы нигез бар. Шулай итеп, **бүре** дә, (сыер) **агы** кебек үк, нәрсәнеңдер агы (бүзе-бүре) булган булып чыга. Ләкин нәрсәнең **бүзе** (изгесе, көчлесе, бае) булды икән соң ул бүре дигән ерткыч?

Бик борынгы төрки телләрдә **аң** дигән актив бер сүз булган. **Аң** ул киекне, кош-кортны, гомумән ауларга мөмкин булган барлык кыргый хайванны белдергән. Бүгенге төрки телләрнең кайберләрендә, бигрәк тә Алтай, Себер якларында **аң** әле дә шул ук мәгънәдә кулланыла. Ау-чы сүзенең борынгы формасы **аңчы** булган һәм **ау** сүзе дә шушы **аңнан** ясалган. Ау гына түгел, **уй-фикерне** белдергән **аң** да, **ант** та (аң-эт) җәнлек-киек мәгънәсендәге **аңның** адашлары булса кирәк. Төрки телләрдәге сүз ясаучы актив **ан** кушымчасы менә бу **аңнан** үзгәргән. Мәсәлән: куй-**ан**, том-**ан**, бал-**ан**.

Бүгенге татар телендә **аң бул!** дигән сүз бар. Хәзер бу: уяу бул, сак бул! дигәнне белдерә. Элегрәк бу сүз: **аң** кебек сизгер һәм уяу бул! дигәнне аңлаткан булырга тиеш. Бездә шулай ук **анду, андып тору** кебек сүзләр дә сакланып калган. Бу сүзләрнең тамыры да шул ук ерткыч **аңга** барып тоташа. Күрәсең, бүгенге **бүре** дә ерткыч-киек мәгънәсендәге әлеге **аңның бүзе** (агы) булгандыр.

Баштарак мин шулай дип уйладым. Ләкин Татарстанның административ бүленеш китабын актаргалаганда мин кинәт **Аш Бүзе** дигән авыл исеме очраттым. Бу авыл Кукмара районында икән. Мин уйга калдым. Шулай да **аңнан** баш тартырга туры килде. Бу теге күктән эзләгәнне җирдән тапкан кебек булды. Шулай итеп, **бүре** сүзенең мәгънәсе бер татар авылы исемендә сакланып калган булып чыкты. Һәм чуалган йомгакны сүтү дә менә шушы **аштан** (Аша-Бүзедән) башланды да инде. Үзем дә сизмәстән, мин төрки телләрдәге үлән баскан җәнлек сукмагына тап булдым. Бу сукмак мине ерак гасырларга алып китте.

Димәк, **бүре** — аң бүзе түгел, **аш бүзе**!

Шулаен шулай да, ашка ничек итеп фәнни аңлатма табарга? Бер генә сүзлектә дә **ашның** киек, ерткыч, хайван, ягъни **аң** мәгънәсе сакланып калмаган. Бу очракта хәтта Мәхмүд Кашгари да берни киңәш итә алмый. Бердәнбер җеп очы — **ас** дигән җәнлек. **Ас**, билгеле, җинел генә **ашка**, **ачка** яисә, киресенчә, аш үзе **ачка**, **аска** әйләнә ала. Бу сүзләр арасында мәгънә уртаклыгы барлыгы бернинди шик тудырмый. Ләкин **ас** җәнлегенең элекке **аш** (дөресрәге, ерткыч хайван) белән мәгънәдәш икәнлеген аңлату өчен бу гына аз.

Ас җәнлеге белән ерткыч бүренең туганлыгын ачыклауда мина икенче бер аңлашылмаган сүз ярдәмгә килде. Ул да булса — **ашина** сүзе.

Алтай төрекләре тарихында **ашина** иң атаклы сүзләрнең берсе санала. Ерак Көнчыгыштан алып Кара диңгезгәчә киң территориядә дәүләт һәм дәүләтләр төзегән, атаклы гаскәр башлыклары һәм дәүләт эшлеклеләре — Билге каган, Көл тәгин, Төнйокук кебек шәхесләр биргән Алтай төрекләренең нәселе, имеш, **Ашина** дигән мифик **Бүре-ана**дан башланган. Бу хакта кытай язма чыганакларында әйтелгән. Ашина сүзенең мәгънәсе: Бүре-ана. Монысы билгеле.

Тик, әлеге дә баягы, бу Ашинаның кем сүзе булуы да, нинди сүзләрдән ясалуы гына ачыкланмаган. Хәер, бу сүзне дә галимнәр... төрки түгел диләр. Берәүләр моны ярым кытай, ярым монгол сүзе ди. **А** авазы кытайча хөрмәт дигәнне аңлата икән, монголча **шоно-чино** сүзе **бүре** дигәнне белдерә. **Ашина** яхшы, изге бүре дигәнне аңлата, ди Л. Н. Гумилев. С. Г. Кляшторный исә Ашина сүзен янә дә иран телләренә кайтарып калдыра. Кызык бит: халкы — төрки, ташка уеп язылган тарихлары — төрки, тик менә аларның нәсел башы булып исәпләнгән, дәүләт башында торган кешеләре генә төрки түгел.

Ярар, гипотезаларны бер читкә куеп торыйк. Ашина сүзендәге **аш** тамыры билгеле түгел дип уйлаганда да, **ина** сүзенең мәгънәсен аңлавы читен булмас иде кебек. **Ина,** ягъни **инә** — шул ук **ана, әни** инде ул. Ашинаның язма чыганакларда теркәлгән мәгънәсе Бүре-ана булгач, **ина-инәне ана, әни дип «тәрҗемә» итү үзеннән-үзе** сорала түгелме соң? Әйтергә кирәк, әни мәгънәсендәге **инә** сүзе татар теле диалектларында бүген дә актив кулланыла. Инәдән үзгәргән **инәй, инәкәй** дә бар әле.

Аш сүзе кайчандыр ерткыч хайван, бүре мәгънәсендә йөргәндер дип уйлау беренче карашка шиктый мәгънәсезлек булып тоелырга да мөмкин. Аш ул **ас** кына түгел бит әле, аш ул, барыннан да элек, — **азык, ашамлык! Аш**тан яңа мәгънәле күп кенә сүзләр ясалган һәм алар барысы да ашка, ашауга бәйле (мәсәлән, ашлык, аш-су, ашау, ашлама һ. б.). Анысы гына җитмәгән, бу аш сүзен дә кайбер галимнәр иран теленнән алынган дип уйлыйлар!

Ләкин эт белән ит сүзенең бер үк тамырдан чыгуын искә төшерсәк, ашның да кайчандыр ерткыч хайван, җәнлек, бүре булуы ихтималына ышана алырбыз дип уйлыйм. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, ашау төшенчәсен һәм азык төрләрен аңлата торган сүзләр эт белән бүредән (аштан) гына алынмаган. Мәсәлән, шул ук азык сүзе **аюга**, азык-төлектәге **төлек** сүзе **төлкегә** кайтып кала түгелме соң?! (Аюның борынгыча әйтелеше **адзык, адыг, адуг, айуг** булган.) Бу хәл безнең бик ерак бабаларыбызның чыннан да ерткычлар белән «кан кардәш» булулары һәм, яхшы кардәш буларак, алар исәбенә туенып-киенеп яшәүләре турында янә тагын бер мәртәбә искә төшерә. Монда тагын шуны да теркәп узыйк: **аң** дигәч ерткычның уй-фикерне белдергән абстракт мәгънәсе булган кебек, **аш** сүзенең дә шундый мәгънәсе бар. Чувашча **ас** хәтер дигәнне белдерә. Татарчада **аш**ның ас-ис варианты шулай ук **хәтерне, уй-фикерне аңлата.** (Мәсәлән, исемдә, исемнән чыккан, исәпләү, истән язган, исем китте һ. б.)

Шулай итеп, ашны без ерткыч, киек мәгънәсендәге **аң**ның бер синонимы дип карый алабыз. **Аш бүзе дигәндә** аш гомумән ерткыч хайванны аңлатса, **ашинә** дигәндә инде ул конкрет бүрене, дөресрәге, Бүре-ананы белдергән. **Ач** (ашсызлык), **иш** (дус, туган) сүзләре дә шушы ерткыч хайван мәгънәсендәге аштан үзгәргән булса кирәк. Аш сүзе тора-бара азык-җим мәгънәсендә активлашып киткәч һәм кеше үзенең кан кардәшеннән ерагая башлагач, **аш бүзе** тезмәсендәге **аш** үзеннән-үзе төшеп калган һәм сыер агы дигәндәге **агы** кебек, бүзе (бүре) дә аерым сүзгә әйләнгән.

Бүгенгә татар телендә **аш-ас** тамырыннан ясалган тагын ике сүз бар. Аларның берсе — **асаба**, икенчесе — **әшнә**. Асаба инде онытыла барган сүз, шулай да әле картлар телендә ишетелгән. **Асаба** ул варисны, төпчек ир баланы белдерә. Русның дәрәҗәле кеше, шәхес мәгънәсендәге **особа** (особый, особенный) сүзе минә шушы асабадан алынган булса кирәк. **Әшнә** (дус, сердәш-фикердәш) — шактый актив һәм шомарган сүзләрнең берсе. Асаба белән әшнәнең мәгънәләре хәзер төрлечәрәк булса да, алар нигездә бер үк сүзләр. **Асаба**дагы **аба** борынгы төрки телләрдә **ата-ананы** һәм гомумән **нәсел-ыру башын** белдергән. Әшнәдәге **нә** кушымчасы **инә** (әни) сүзенең соңгы иҗеге булса кирәк.

Шулай итеп, асаба да, әшнә дә иң беренче мәгънәләре буенча анабыз Бүрене, ягъни ерткычларның иң изгесе, иң көчлесе Аш бүзен аңлата булып чыга.

**Аш-ас** тамырлы сүзләрне без төрки халыклар яшәгән төбәкләрдә — авыл, елга һәм кеше исемнәрендә шактый күп очрата алабыз. Мәсәлән, Кабарда-Балкар автономияле республикасында аш тамырлы берничә топонимик атама бар. Бу атамаларның барысы да балкар теленә карый. Балкарлар, мәгълүм булганча, борынгы болгарларның бер төркеме (кабиләсе) булып исәпләнеләләр. Әлеге атамаларның берсе шактый игътибарга лаек.

Төньяк Кавказда, Чегем елгасының уң як ярында, Нумала (Думала) авылы янында **Аштотур ташы** дигән атаклы бер таш бар икән. Бу мәгълүмат Җ. Н. Коков һәм С. О. Шаһморзаевның «Балкар топонимик сүзлеге» дигән китабыннан алынды. Китап авторлары әлеге сүз астына: «Бу ташка элекке заманнарда ук аучылар табынган», дигән аңлатма биргәннәр. **Аштотур** дигән сүзнең мәгънәсен алар билгесез дип уйлыйлар, ләкин минә бу аучылар табынуы турындагы җөмлә мәсьәләгә ачыклык кертә. **Аштотур ташы**, күрәсең, аучыларга **аш** (җәнлек, киек) ауларга ярдәм итә торган «изге» таш булгандыр.

Татарстандагы Ашыт суының, Яңа Ашыт, Иске Ашыт, Ашабаш, Апас, Апаз кебек авылларның, Кыргызстандагы Ош, Идел буе болгарларының Ошәль (Аш-ил) шәһәрләренең исемнәре һ. б. бик күп атамалар, һичшиксез, әлеге ерткыч **ашка** бәйле рәвештә барлыкка килгәннәр.

## Аксөякнең дәвамы

**Аш**ның ерткыч хайван, бүре мәгънәсен исбатлау өчен мисаллар эзләгәндә мин **ашык** дигән сүзгә «юлыктым». Бүгенге телдә ашык искерәк, ятрак сүзләр рәтенә карый. Ләкин ашык сүзе барлык төрки телләрдә дә диярлек бар. Борынгы телләрдә ул, күрәсең, иң гадәти сүзләрдән саналган. М. Кашгари сүзлегендә **ашук** (ашык)ның ике мәгънәсе бирелә: 1. Тубык сөяге; 2. Сугышчының баш киеме [1].

**Ашык**ның баш киеме мәгънәсе әлегә безне бик үк кызыксындырмый. Безне әлегә **тубык сөяге** булган ашык кызыксындыра. Ашык ул мал-туарның (башлыча, вак малның) тояк белән тез сөяге арасындагы кечкенә буын сөяген белдерә. Кеше аягында мондый сөяк юк, һәм, күрәсең, минә шуның өчен дә ул **ашык** дип, ягъни мал-туар, хайван сөяге дип аталгандыр да. Шулай булган очракта, әлеге сүздәге **аш** иҗеге без тикшергән **аш**ның чыннан да хайван (һәм шулай үк ерткыч хайван) булуына өстәмә бер дәлил булачак.

---

[1] Древнетюркский словарь. Ленинград, 1969 ел, 64 бит. Моннан соң — ДТС.

Анысы шулай, ләкин ашыктагы **ык** кушымчасын ничек аңлатырга? Нәрсә ул **ык** яисә **ук**? Төрки телләрдә **ык-ек, ук-үк** белән тәмамланган сүзләр шактый күп. Бу ык-ек кушымчаларының мәгънәсен һәр очракта да төсмерләү, сиземләү мөмкин дә түгел. Монда мин мәгънәләре ачык төсмерләнгән берничә сүзгә генә тукталып үтәм. Сез, мәсәлән, **тубык (туб-ык)** сүзенең нәрсә аңлатканын төгәл генә әйтә аласызмы? Тубык ул тезнең ике якка кабарып торган аркылы сөяге була. Ләкин минем туган якта бу сөякне **шаталак сөяге** диләр, ә тубык дип **тез башына** әйтәләр. Тез башы урынына кайчагында **тубык башы** дигән сүз дә кулланыла. Димәк, тубык сүзе һәр очракта да бер үк сөякне аңлатмый икән.

Тубык сүзенә якын булган тагын **тубыр, тубырлау** сүзләре дә бар. **Тубыр** сүзе ике кисәктән тора: **туб-ыр.** Беренче иҗек **туб** (туп) кабару, шешүне белдерсә, **ыр** (ыры-оры) тигез җирдә үсеп чыккан чит тукыманы (каты шешне) белдерә. Мәсәлән, агач оры (гөмбәсе, мәшкәсе). Шулай итеп, тубыр туп кебек кабарып торган шешне, төерне аңлата торган сүз була. Болай булгач, **тубык** сүзендәге **тубны** да калку, кабарынкы **ык**ны белдерә дип әйтә алабыз. Тездән түбәнге **тубык** сөяге дә туптай кабарынкы, калку һәм шулай ук **тез башы** да тупбай кабарынкы, калку. Тез башын да, шаталак сөяген дә **тубык** дип атаган борынгы кеше бу әгъзаларның иң элек тышкы формасына игътибар иткән, һәм ул ялгышмаган.

Шундый күренексез булган тубык сүзенә шулай киң тукталып тору гаҗәбрәк тоелырга да мөмкин. Ләкин моның үзенә күрә бер сере бар. Кеше әгъзаларын аңлаткан менә мондый күренексез сүзләр кыргый кешенең сөйләм теле бик ярлы вакытларда барлыкка килгән. Мәсәлән, әлеге **ык** дөньяда адәм баласының **иң беренче** (әйе, әйе, иң беренче!) сүзе булырга мөмкин. Телсез яисә сакау кешенең телле кешегә бирәр нәрсә аңлатырга тырышканда, көчәнеп **ык-ыг!** дигән авазлар чыгаруын ишеткәнегез бардыр. Теле ачылмаган яшь бала да иң элек **ыгы-ыгы** дип, **мәм-мәм** дип сөйләнә түгелме соң? Менә шуның кебек бик ерак бабабыз Бичин углы Маймыл да моннан фәлән йөз мең еллар элек шулай **ык-мык** дип сөйләнә башлагандыр дип әйтергә була.

Янә шуңа да игътибар итик: бу беренче сүзләр-атамалар — барысы да безнең кыргый ата-бабаларыбызның үз сүзләре, һәм монда да: иралнан, санскриттан, Авестадан дип исбатларга тырышучы авторитетлар булса, алар безне ышандыра алмаячаклар. Төрки телләрдә төрле конкрет һәм абстракт мәгънәләрне аңлаткан күп кенә сүзләр менә шушы **ык-мык**лардан, **ук-үк**ләрдән тармакланып киткән. **Ык-мык**ларның иң беренчел мәгънәләрен дөрес аңлау исә көтелмәгән этимологик ачышларга китерергә мөмкин.

Ашык белән тубык сүзләрендәге **ык**ның сөяк мәгънәсен белдерүенә игътибар иткәнсездер дип уйлыйм. Ашык сүзе, күрәсең, баштарак ерткыч хайван, соңга табарак гомумән хайван, мал-туар сөяген аңлаткан һәм кешеләрнең уен коралы буларак та шул мәгънәдә кулланылган. Хәтта кыргый кеше дә кеше сөяге белән уйнап күңел ачмагандыр лабаса!

Ашыкның **баш киеме** мәсьәләсенә килгәндә, бу шактый кызык факт. Металл эшкәртү уйлап табылганчы борынгы кеше (сугышчы) үзен-үзе саклау өчен агачтан, таштан һ. б. шундый арзанлырак нәрсәләрдән киң файдаланган. Бик борынгы заманнарда гына түгел, хәтта соңгырак чорларда да (мәсәлән, урта гасырларда) ярлы сугышчылар эре сөякләрдән, хайван тоякларыннан тезеп, җыйнап тегелгән каты киемнәр кия торган булганнар. Шуңа күрә, М. Кашгари әйткән баш киеме мәгънәсендәге ашыкны, бәлки, гомумән **каты кием** дип аңларга кирәктер?

Димәк, **ык**ның беренче мәгънәләреннән берсе **сөяк** булган. Беренче мәгънәләреннән берсе димен, чөнки иң-иң беренче мәгънәнең нинди булуын бүгенге көндә ачыклау мөмкин түгел. Сөяк мәгънәсеннән соңга таба күп төрле яңа мәгънәләр барлыкка килгән. Аларның бер төрлесе кеше, хайван әгъзаларын белдерсә, икенче төрлесе бер бөтеннең кисәген (аерым **ык**ларын) белдерә, өченче төрлесе исә сөяктән ясалган төрле әйберләрне, коралларны аңлата.

Мәсьәләгә формаль яктан килгәндә, сөяк мәгънәсендәге **ык** төрки телләрдә өч төрле юнәлештә үскән: 1. **ук-үк**; 2. **ак-әк**; 3. **ык-ек** юнәлешләре. Болар хәзер сүз ясагыч кушымчалар һәм аларның барысы да диярлек бүгенге телдә актив кулланыла.

**Ук**ның сугыш һәм ау коралы булуын һәркем белә. Ләкин **ук(ок)** сүзе борынгы язмаларда **ыру, кабилә** мәгънәсендә дә очрый. Мәсәлән, «он ок каганы». Моның кайсы беренчел — сугыш коралы **укмы**, ыру-кабилә **укмы**? Фәнни әдәбиятта бу мәсьәләдә тулы ачыклык юк. Әлеге «он ок каганы» тезмәсендәге «он ок» (ун ук) русча «десять стрел» дип тә тәрҗемә ителә, ягъни ыру-кабилә мәгънәсендәге **ок(ук)** сугыш коралы ук (ок) белән тәңгәл итеп карала.

Күренгәнчә, **ук-ок** сүзенең төпле этимологиясе табылмаган. Ук-үк, ак-әк тибындагы исем-атамаларның мәгънәсен ачыклаганда (һич югы, шартлы рәвештә) чишмә башы итеп сөяк яисә каты, нык әйбер һәм бөтеннең бер кисәге мәгънәсендәге ык сүзе алынса, күп кенә аңлаешсыз нәрсәләр ачыклана төшәр иде дип уйлыйм.

Сугыш коралы мәгънәсендәге **ук**ның сөяк мәгънәсендәге **ык**тан үзгәрүен аңлатуы бик җиңел нәрсә. Металл башлы уклар барлыкка килгәнче таш, сөяк башлы уклар булган. Моны археология дә раслый. Сөяк башлы уклар хәтта металл башлы уклар барлыкка килгәч тә киң кулланылган. Ярлырак сугышчыларның кораллары, әйтелгәнчә, гомумән арзанрак материалдан эшләнгән.

Шулай итеп, иң борынгы ук башы сөяктән булган. Ләкин шул ук вакытта, күреп үткәнчә, ыру-кабилә төшенчәсе дә сөяк (ык) төшенчәсенә туры килә. «Аксөяк» бүлегендә без бу турыда киңрәк тукталдык. Анда әйтелгәннәрне кабатлап тормастан, ыру сүзенең борынгы формасы **уруг** сүзендә дә сөяк(ык) катнашуын искә төшерү җитәр дип уйлыйм. Сөяк яисә бер бөтеннең кисәге мәгънәсендәге **ык-ук** шулай ук угыл сүзендә дә катнаша.

**Ык**ның **ак**ка күчкән варианты бүгенге телдә аеруча күп очрый. Мәсәлән, тойак, сыйрак, шаталак, кимерчәк кебек сүзләрдәге **ак-әк** кушымчыларының **сөяк** мәгънәсе ачык төсмерләнә. Шулай ук **пычак**тагы **ак**ны да җиңел аңлатып була. Бу сүзнең әүвәлге формасын **пыч-ык**, ягъни кисә торган сөяк (каты әйбер) булган. Беренче пычакларның таштан яисә мал-туар сөягеннән ясалуы бернинди шик-шөбһә тудырмый. **Ак** кушымчасы, **ык** кебек үк, ыру-кабилә мәгънәсендә дә кулланылган. Алтай төрекләре заманында Урта Азиядә, мәсәлән, **согдак** дип аталган халык булган. Кеше әгъзаларын аңлата торган атамаларның күпчелеге **ак-әк** белән тәмамлана. Бу билгеле, очраклы хәл түгел. Мәсәлән, яңак, ий-әк, бөер-әк, йөр-әк, кол-ак һ. б.

Тюркологиядә күп бәхәсләр кузгаткан сүзләр-атамалар бар. Шуларның берсе — **төрек** сүзе. Бу мәсьәләдә академик А. Н. Кононов гипотезасы әлегә соңгы сүз булып санала. А. Н. Кононов төрек сүзен **түркүн**нән ясалган дип исәпли. **Түр (төр)** тамырын ул төрки халыкларда киң таралган **түр** (өйнең түре) сүзеннән чыгып аңлата һәм бик ышандыргыч итеп аңлата. **Түр**дән күп кенә яңа сүзләр аерылып чыккан: түр — алгы, хөрмәтле урын, түрә — йола, закон, башлык, баш кеше, төс — өйне, учакны саклаучы изге рух һ. б. **Көн**нең мәгънәсе дә шулай ук билгеле: **көн(күн)** ул халыкны — кабиләне белдерә (илем-көнем).

Тик шулай да А. Н. Кононов гипотезасы ышандырып җиткерми. Беренчедән, әгәр дә мәгәр **төрек** сүзенең башлангыч формасы **түркүн (төркүн)** булган булса, бүгенге көндә дә ул шулай бернинди үзгәрешсез кулланылган булыр иде, чөнки ике иҗектән торган бу кыска сүзнең соңгы **үн(өн)** кушымчасы гына төшеп калып та, **к** авазы гына сакланып калу өчен бернинди сәбәп юк. Икенчедән, А. Н. Кононов нишләптер төрки телләрдәге сингармонизм законын исәпкә алмый һәм **төрек** янсә **түрек** сүзен түгел, бәлки **түрк** сүзен тикшерә. **Төрек**тәге **к** көн(күн) сүзеннән торып калган очракта да соңгы иҗек **ек** булыр иде, чөнки төрки телләрдә төрк(түрк) дип әйтү теленең табигатенә туры килми. **Ек**, белгәнебезчә, сөяк мәгънәсендәге **ык**ның нечкә әйтелеше генә ул. **Төрек** (түрүк, түрек, төрүк) атамасы, шулай итеп: түрдәге, изге, көчле, хөрмәткә лаек ыру-кабилә булачак. Кыскасы, бу шул ук **аксөяк**нең икенче төрле әйтелеше генә булып тора.

## Ашык-кашык һәм башкалар

Безнең **ык** кушымчалы тагын бер хикмәтле сүзебез бар. Бу сүз — **кашык** булыр. Аш кашыгы, бал кашыгы... теләсә нинди кашык. Гадәти, күренексез бер сүз. **Кашык** ул әлерәк кенә без тикшергән **ашык**ның туганы. Алай гына да түгел, алар — игезәкләр. Бу **кашык**ның да иң беренчел мәгънәсе ерткыч хайван һәм гомумән хайван сөяге булган. Гаҗәп, аш ашый торган коралга каян килгән тагын ерткыч сөяге? Аннан соң, нинди **къ** авазы соң әле бу сүз башында?

Борынгы халыкларның күпчелек азыгы иттән-сөттән гыйбарәт булган. Сыек азыкларны әлегрәк, күрәсең, туп-туры агач, тире савытлардан һәм чүлмәкләрдән эчкәннәрдер (ашаганнардыр) дип әйтергә була. Пешерелгән, кыздырылган итләрне казаннан, учактан алу өчен, тотып ашау өчен, күрәсең, очлы, нечкә сөякләр кулланылган. Менә шундый нечкә сөякләр беренче **кашык**лар булган. Монголиядәге Ноин Ула каберлегендә, хунну башлыклары күмелгән җирдә борынгы күп әйберләр арасында шундый сөяк кашыклар да табылган.

Кашыкны без, әйтелгәнчә, **хайван сөяге** дип аңлыйбыз. Без әзәрлекләгән **ерткыч хайванның** чын исеме-атамасы, болай булгач, **аш** түгел, **каш** булып чыга түгелме соң?! Кайсы борынгырак моның — **ашмы, кашмы**, әллә соң бу бер үк тамыр сүздән тармакланган төрле вариантлар гынамы? Моны хәл итүе җиңел түгел. Һәм мин моны тулысынча хәл итәрмен дип ышанмыйм да. Әлегә минем максат — борынгы сүзләрнең мәгънәләрен һәм мәгънә үзгәрешләрен телдәге мисаллар белән ачып күрсәтү. Мисаллар исә шуны сөйли: **къ** белән башланган кайбер сүзләрнең беренче авазы еш кына төшеп кала һәм шул нигездә яңа сүзләр барлыкка килә. («Къ» белән дип кистереп әйтүе дә кыен, чөнки бүтән авазлар белән башланган сүзләрнең дә беренче «хәрефләре» еш кына төшеп калгалый.) Мәсәлән, әлеге аш-каш сүзләреннән тыш шундый сүзләрне күрсәтергә була: **калфак**(калпак) — **алпак.** Калфак — бүгенге баш киеме, алпак — борынгы сугышчының баш киеме, **ашык**ның тәрдәше. **Кадаш-адаш.** Кадаш — борынгы телдә иптәш, дус; адаш — хәзерге телдә иптәш, атташ, исемдәш.

Шулай итеп, **аш-каш**ны мәгънәдәш сүзләр янсә бер үк тамыр сүзләре дип танырга туры килә. Кашыктан башка безнең тагын **кашаяк** дигән сүзебез дә бар әле. Кашаяк ул хәзерге телдә савыт-саба дигәнне белдерә. Халыкта, кашаяк шалтырамый тормый, дигән әйтем дә бар. Монда тагын, ямьсез булса да, **кашаяк мунчаласы** дигән сүзне дә хәтергә төшерергә була. Игътибар белән карагыз әле: аерым-аерым алганда, **кашы** да, **аягы** да бер-берсе янына урынсыз китереп куелган сүзләр булып тоелмыймы? Хәер, **аяк** сүзе борынгы төрки телләрдә савытны һәм шулай ук савыт-сабаны белдергән. Монысын сүзлекләрдән

дә табарга була. Шулай да ник кашаяк соң бу? Җавап бер генә: ашамлыклар, бигрәк тә ит салып ашый торган аякны (савыт-сабаны) белдерә бу сүз. Сыек эчемлекләр өчен кулланылган савыт-саба кашаяк булмаган. Кашаяк балчыктан, агачтан, металлдан ясалган.

Менә бу кашаякның **ташаяк** дигән варианты да бар. Иске Казанда, Кремль астында, Болак буенда атаклы **Ташаяк базары** булган. Бүгенге Казанның Кремль тавыннан аска, Үзәк стадионга таба сузылган кечкенә урамы әле дә Ташаяк урамы дип атала. Ләкин ташаяк, ул, бәлки, кашаякның варианты түгелдер? Бу сүз, бәлки, таштан, балчыктан ясалган чүлмәк савыт-сабаларны аңлатадыр? Мондый шик тумасын өчен тагын бер мисалны күздән кичерик. Бу мисал — **коштабак-таштабак** сүзләре.

Коштабакны **каш**-табак дип уйласак та, **кош**-табак көенчә калдырсак та, мәгънә үзгәрмәячәк. Коштабак белән каштабак урынына **таш**-табак дип әйтсәк, мәгънә үзгәрерме? Юк, үзгәрмәс. Бу «шүрлеккә» без тагын **аш** табагы дигән «табак»ны да китереп куя алабыз. Күрәсез, барысы да бер үк төсле, бер үк формалы, бер үк материалдан һәм бер үк максат өчен эшләнгән «табаклар»!

Аш, каш, кош, таш... Һәммәсе дә **ерткыч хайванны** яисә **гомумән хайванны** (һәм, әлбәттә, **кошларны** да), шулай ук **ит азыкларын** да аңлата. Моны хәтердә тотыйк — бу әле безгә кирәк булачак.

## Бүренең адашлары

Бүренең исеме барлык төрки телләрдә дә Бүре түгел. Үзбәкләр, мәсәлән, бүрене **кашкыр** диләр, чувашча шул ук сүз **кашкар** дип, казакъча, каракалпакча, уйгурча **каскыр** дип әйтелә. Кашкыр-каскыр дигәндәге **каш-кас**ның без тикшергән **аш-каш-таш** оясындагы сүз булуын исбат итеп торуның кирәге юк дип уйлыйм. Безгә монда **кыр-кар** яисә **кар-кыр** иҗегенең нәрсә икәнлеген генә ачыкларга кирәк.

Кашкыр-каскырдан тыш, бүренең тагын **корт-курд** дигән исеме дә бар әле. Корт-курд күбесенчә төрки телләрнең угыз группасында: әзербәйҗаннарда, төрекләрдә, төркмәннәрдә кулланыла. **Каш** белән **кортны** кушып әйтсәң, **каш-корт** булачак. Каш-кортны чак кына үзгәртеп **кош-корт** дип әйтсәк, хәзерге телдә бары тик йорт кошларын гына аңлата торган җыелма сүз килеп чыгачак. Кош-кортның **корт**ын гына куллансак, татар телендә бу һәр төрле бөҗәкләрне, чебеннәрне, бал кортларын һәм шуның ише ваграк «йорт хайваннарын» аңлата торган сүз булачак.

Шулай итеп, кашкыр-каскырдагы соңгы **кыр** (чувашча: **кар**) **бүре-ерткыч** мәгънәсендәге **корт** сүзе белән бертуган икән. Дөресрәге, алар — игезәкләр (синонимнар).

Кашкыр-каскыр мәсьәләсен хәзергә ачыкланды дип исәплик. Ләкин **корт-курд** сүзе нилдирәк **бүре** соң ул? Менә монысы әлегә ачыкланмады һәм аны ачыклау өчен безгә күп кенә археологик катламнарны актарып карарга туры киләчәк.

Төрки телләрдәге йорт хайваннарының һәм кыргый хайваннарның исемнәрен тикшергән А. М. Щербак **корт**ның этимологиясе турында да мәгълүматлар бирә. Бүре мәгънәсендәге **корт** сүзе ул **бөҗәк**не белдергән корттан үзгәргән димәкче була, ягъни бүре исемен атарга ярамаган да, бүре дип әйтәсе урынга, имеш, корт (бөҗәк) дип әйткәннәр. (Мәсәлән, кандала дип әйтәсе урынга кибәк дип читләтеп әйткәндәге кебек. Ләкин кибәк дип әйтү читләтеп әйтү микән ул?!)

Мондый гипотезаны кабул итүе кыен. Корт сүзендәге соңгы **т** авазын мин **эт-ит**нең калдыгы дип исәплим. Корт-курд дигән ерткычның чын исеме, шулай итеп, **кор эт** яисә **кур ит** булган дип әйтәсем килә.

**Кор-кур** оясы төрки телләрдә иң борынгы, иң бай һәм иң изге оя. Саф кор-кур тамырыннан гына торган һәм шул көе кулланышта булган хайван, җәнлек атамасы бүгенге телдә сакланып калмаган бугай. Кор-кур һәм аның күп санлы фонетик вариантлары башка төрле тамыр сүзләр (шулай ук җәнлек-хайван төшенчәсендәге сүзләр) белән бергә яңа төр атамалар ясауда катнашалар.

Бездә гарәпнеке дип уйланылган **кор**-бан сүзе бар. **Кор-бан чалу, корбан бәйрәме, корбан ите**... Корбан чалуга, корбан бәйрәменә бөтенләй катнашы булмаган **корбан балыгы** бар. Әллә катнашы булды микән соң? Хәер, безнең тема өчен моның әллә ни әһәмияте дә юк. Ләкин **корбан** сүзенең гарәпнекеме, түгелме икәнлеген шулай да ачыклап китми ярамас. Ни өчен гарәптән кергән дип уйланыла соң бу сүз? Гарәп телендә дә булган өченме? Ислам дине гарәпләрдән кергән, димәк, корбан сүзе дә, һичшиксез, аларныкы булырга тиеш. Шулаймы? Әлбәттә, шулай дип уйлый күпчелек. Ләкин **корбан чалу** йоласы ни өчен безгә гарәптән керергә тиеш соң? Төркиләр борын-борыннан терлекче булганнар һәм борын-борыннан корбан чалганнар. Бу хакта бәхәс булуы дә мөмкин түгел. Әгәр корбан чалу һәм корбан бәйрәме гарәпләрдән кергән булса, безнең күлләрдәге корбан балыгына да исем гарәп теленнән алынган булыр иде. Монысы инде тагын да мәгънәсезрәк — **корбан балыгын** гына түгел, гомумән балыкны беркайчан да беркем дә корбан итеп чалмаган һәм аны чалып та булмый.

Корбан бәйрәме дә, корбан чалу да, корбан балыгы да — барысы да саф төрки сүзләр һәм төрки төшенчәләр. **Корбан**ның төркилеген бик тә әһәмиятле бер этнографик деталь белән исбатлап була. Корбан чалу дигән сүздә **чалу** бик үк аңлашылмый сыман. Чалу ул егуны, тайпылдыруны белдерә. Гадәттә кешегә **аяк чалалар**, юлда **чана салулый** (чалулый). Корбан чалганда исә малны егып, аударып (аяк чалып) кына куймыйлар, суялар да! Чалу сүзенең **сую** мәгънәсе юк. Сую мәгънәсендәге **чалу** бары корбан хайванына карата гына кулланыла. Ник? Моңа җавап башка урында булыр.

Төрки телләрдә алынма сүзләр темасын кузгаткалбыз икән, бу хакта тагын бер-ике сүз әйтеп китәсе килә. Төрки телләрдә гарәптән, фарсыдан кергән дип уйланылган, ләкин чынында саф төрки булган сүзләр турында күптән түгел немец тюркологы Дөрфер язып чыкты. Мәсәлән, ул моңарчы гарәпнеке дип йөртелгән **мал** сүзенең төркилеген исбат итә. Әйтергә кирәк, мондый сүзләр әлеге **мал, корбан** янсә **бүре, ашина** кебек сүзләр белән генә чикләнми. Без теләпме, теләмичәме, гарәпләргә, фарсыларга «биргән» сүзләрнең исәбе-хисабы юк. Безгә киләчәктә сүзлекләребезне яңабаштан карап чыгарга һәм «алынма» дип йөртелгән бик күп сүзләрнең чыгышын ачыкларга кирәк булачак.

Бер таҗик дустым, **түбә** сүзе төрки сүз дигәч, шаккатты. Ул: **түбә (тәпә)** — таҗик сүзе дигәч, мин шулай ук шаккаттым. Мондый шаккатулар, билгеле, сүз арасында гына булды, һәм без беребез дә фәнни исбатлау белән шөгыльләнмәдек. Ләкин безнең кайбер телче галимнәребез мондый сүзләрне тырышып-тырышып үзебезнеке ... түгел дип ышандырмакчы булалар. Бездә, мәсәлән, Минзәлә, Нократ (Вятка) атамаларының гарәптән алынуы ихтималы турында язалар. Аныса әле бик үк кытыкка да тими — гарәпчә атамалар бездә чыннан да еш очрый. Алар нигездә гарәпчә кеше исемнәреннән ясалган атамалар. Ләкин **чишмә**нең фарсы сүзе икәнлеген ничек аңлатырга? Чишмә, имеш, фарсыча **чәшмә**дән үзгәргән диләр. Шул рәвешчә, Башкортстандагы **Чишмә** дә, безнең һәр авылда диярлек чылтырап аккан салкын **чишмә**ләребез дә тюркология фәнендә төрки исәпләнми. Чишмә сүзенең культура-үсеш дәрәҗәсенә әллә ни катнашы юк, шулай да моның тирән мәгънәсе бар: төркиләргә кадәр безнең җирләрдә, имеш, иран тел-

ле кабиләләр яшәгән һәм **чишмә** сүзен дә «бүләккә» алар калдырган.

Ләкин чишмә сүзендәге **мә** — төрки кушымча. **Мәгә** тәмамланган сүзләр төрки телләрдә шактый күп (сөзмә, тезмә, кисмә, күчмә һ. б.). Ярар, алайса, **чиш** нәрсә? **Чиш**не сүзлекләр буенча гына чишәргә азаплансак, берни хәл итеп булмаячак. Казан артында әле бүгенге көндә дә чиш, чишен дип әйтәсе урынга **тиш, тишен** дип сөйлиләр. Шуңа күрә чишмәнең әүвәлге формасы ниндидер кабилә телендә **тишмә** булгандыр дип әйтә алабыз. **Тишмә** ул җирдән тишелеп чыккан, җир тишегеннән чыккан су булачак.

**Минзәлә** атамасына килгәндә, соңгы **ләне** мин **ле** дип аңларга һәм эзләнүне шуннан башларга кирәк дип исәплим. **Минне** без **меңгә** әйләндерә алабыз. Казагыстандагы Мангышлак атамасының ман иҗеге төбендә мең сүзе ята (Мангышлак — Мең кышлак). Минзәләне дә **Меңзә-ле** дип үзгәртсәк, нәрсәдер ачыклана башлады сыман. **Зәне җәя** дип аңлап буламы? Була кебек. Меңне төп-төгәл мең дип уйлау мәҗбүри түгел. Мең монда күп, бик күп төшенчәсендә килә. Җәя — мәгълүм сугыш коралы. Бу очракта ул конкрет җәяне түгел, бәлки уклы-җәяле сугышчыны аңлата ала. Минзәлә, шул рәвешчә, **мең җәяле, мең ирле (мең өйле)** ыру-кабилә атамасы була.

**Нократ**ның төзелеше шулай ук төрки. Ләкин моның элементлары бик борынгы һәм бик нык үзгәргән. **Нок-нук** иҗеген мин **бог-буг** дип аңлыйм (нок-мок-буг; бога-буга). Нократ (Вятка) елгасы тамагыннан бераз читтәрәк урнашкан **Алабуга** шәһәре булуы нок-нук тамырының **бог-буг**тан үзгәргән булуы ихтималына ышаныч тудыра. Вятка елгасы башыннан алып койган җиренә кадәр түгел, бәлки шул Алабуга тирәсендә генә (түбәнге агымында гына) Нократ дип аталгандыр дип әйтәсе килә.

Болгар тарихында **Кубрат** дигән атаклы бер исем бар. Кубрат VII гасырда Азак диңгезе буйларында барлыкка килгән беренче Болгар дәүләтенең ханы була. Кубрат үлгәч, болгарлар төрле якка таралалар. Кубратны төркичә берничек тә мәгънәле итеп булмый. Әгәр без аны **Курбат** итеп үзгәртсәк, мәгънә ачыклана төшәчәк. **Кур**ны беләбез, **бат**ны белербез. Бүгенге көндә Курбатов фамилиясе татарларда да, русларда да очрый. Русларда **Кур**-ас-ов, **Кур**-аш-ов фамилияләре дә бар.

Кор-курның **кар** варианты, әйтелгәнчә, чувашча **кашкарда** сакланып калган. **Карга** әлеге **бат** тамырын кушсак, **Кар-бат** (Карпат) таулары килеп чыгачак. Шулай ук атаклы **Урал** тавының атамасы да кор-кур оясына карый. Уралның әүвәлге формасы **Кур**-ал булган. **Кар** җанвары шон-**кар** (сун-**кар**) дигән бөркет исемендә дә, **кар**-га, **кар**-чы-га, **кар**-лыг-ач дигән кошлар исемендә дә бар.

Кор-курның **кой-куй** вариантында **куй** (сарык), **куй**-ан, **коз-куз** вариантына **коз**-гын, **кол-кул** вариантына **кол**-ан-**кул**ан, **кол**ын, **кон-коң** вариантына **кон** (сарык), **коң**-гыз мисалларын китерергә була.

Кор-курның шулай ук **кот-кут** варианты да мәгълүм. Моңа безнең бөр-**кет** дигән мисалыбыз әзер. Кор-кур ерткычы күп кенә борынгы төрки исемнәр ясауда катнаша. Моңа огузларның атаклы дастан герое **Кур, Гур** һәм **Коркут** исемнәрен күрсәтергә була. **Уразмәт** исеменең дә нигезе **Кур**-аз-мат сүзләренә кайтып кала. 1369 — 77 елларда Алтын Урдада **Урыс** дигән хан була. Бу ханның исеме бүгенге рус атамасыннан алынмаган. Бу **Урыс** шул ук **Ураз** (Курас)ның беркадәр үзгәртелгән формасы гына.

Аш-каш-ташның яисә кашкыр белән кортның һәм бүренең нәсел-нәсәбен энәсеннән җебенә кадәр тикшергәч, без, ниһаять, иң четерекле һәм иң тоттырмас атама-җанварларның берсенә якынлаштык. Сез инде сизенгәнсездер дә — сүз монда **башкорт** атамасы турында бара.

Әгәр **башкорт**ны да әлеге **каш** һәм **кор-кур** тибындагы сүзләр янына куеп карасак, ничегрәк булыр икән? **Башкорт**тагы **корт** сүзен без гомумән ерткыч дип тә, бүре дип тә аңлый алабыз, чөнки ничек аңлаганда да аның төп мәгънәсе үзгәрмәячәк. Иң авыры монда — **баш** сүзе. Һәм менә шушы **баш** күп кенә галимнәрнең башын катыра да инде.

Безгә дә, баш катмасын өчен, **баш**ның хәзерге мәгънәләрен онытып торырга туры киләчәк. Аш-каш-таш сүзләренең беренчел мәгънәләре билгеле булганлыктан, без әлеге **баш**ны да шулар белән янәшә куеп карый алабыз. Кашның башка яисә, киресенчә, башның кашка, ташка, ашка әйләнүен без, билгеле, авазлар чиратлашуы белән дә аңлата алыр идек. Фәлән аваз төгән авазга әйләнгән, фәлән диалектта **каш** кулланыла, төгән диалектта **баш** кулланыла дип монда җиңел генә котылырга да булыр иде, мөгаен. Ләкин **баш** сүзенең, ерткыч хайван яисә **азык, ашамлык** мәгънәләре булган мисаллар тапмыйча торып, аның чыннан да ерткычлар белән тугандаш икәнлеген исбатлап булмаячак.

Бүгенге татар телендә **баш** тамыры **аш, азык** мәгънәсенә туры килгән берничә сүз бар. Шуларның берсе — **башак.** Арыш, бодай һ. б. башагы. **Башак** үсемлек башында булган өчен шулай аталган дип, ягъни үсемлекнең баш өлеше **башак** була, дип уйларга да була, билгеле. Ләкин үсемлекнең баш өлеше чынында баш түгел, **оч** булырга тиеш. Башакны үсемлекнең **ашарга яраклы** өлеше дип аңлау дөресрәк булачак. Бу фикерне без тагын бер-ике мисал белән ныгыта алабыз. Атка, сыерга әлек авыл агае **башак** болгатып бирә торган иде (хәзер **курмы** бирәләр, ахрысы). Бу **башак**ны арыш, бодай башакларыннан торган азык дип күз алдына китерә күрмәгез тагын. Башак ул туралган, вакланган салам була, шул саламны җылы су белән чылаталар да бераз он сибеп болгаталар. Менә сезгә **башак**! Бу инде турыдан-туры **азык, аш, җим** дигәнне белдерә. Арыш, бодай һ. б. ларның орлыкларына карата кулланыла торган **ашлык** сүзе дә менә бу **башакка** кайтып кала. (Аш-лы-ык, ягъни ашарга яраклы ык. Ыкның сөяк, каты әйбер, кисәк, өлеш мәгънәсенә янә бер мисал.)

Башактан башка әле безнең **башмак (башмак тана, башмак бозау)** дигән сүзебез дә бар. **Башмак** дип алты айлыктан алып бер яшькә кадәр булган бозауга әйтәләр. Бөтен гомерләрен терлек белән бергә уздырган күчмә халыклар мал-туар мәсьәләсендә иң оста белгечләр саналалар. Бездә, мәсәлән, яңа туган бозауны, бәрәнне, колынны сөю булмаган һәм юк. Сәяхәтче һәм галим Н. М. Пржевальский монголларда да яшь терлеккә карата шундый ук мөнәсәбәт булуы турында яза. Монгол яңа туган бәрәнне яисә бозауны сөюны гөнаһ саный, ди Н. М. Пржевальский. **Башмак**ның чын мәгънәсе, шулай итеп, **ашамак, ашарлык** дип әйтә алабыз. Башмактагы баш сүзе **ашны, азыкны** гына түгел, шулай ук хайван дигәнне дә белдерә.

**Ташбака, ташкабак, ташбаш** кебек атамаларны да шушы ашарга яраклылык күзлегеннән чыгып карый алабыз. Ташкабак, ташбака сүзләрендәге **таш** катылык мәгънәсенә дә туры килә, әлбәттә. Шулай да бу **ташның** беренче мәгънәсе **аш-азык** һәм **ерткыч хайван** булырга тиеш сыман. Моның шулай икәнлеге ташбаканың төркмәнчә әйтелешендә ачык чагыла. Төркмәнчә бу бака **пышбага** яисә **пышдылмага** дип атала икән. Менә бу көтелмәгән **пыш** төрки телләрдәге тагын бер серле «тау

куышына» юл күрсәтә кебек. **Пыш** ул **пешнең** калын әйтелеше. Татарча **пеш** башкортча **беш** була. **Беш** белән **баш** — бертуган. Димәк, **беш-пеш-пешеру** — болар барысы да баштан аерылып чыккан сүзләр.

**Башкорт** термины, шулай итеп, каш-кор, кош-корт сүзләре белән мәгънәдәш булып чыга. **Башкорт**ны без гадиләштереп шул ук **кашкыр** (бүре) дип әйтә алабыз. Бүрегә бер башкортлар гына табынмаганлыгын без инде беләбез. Гыйракта иран телендә сөйләшүче **курд** (корт-бүре) халкы бар. Курдлар, димәк, төркиләшкән фарсылар булып чыга. Таҗиклар турында да шуны ук әйтергә туры килә. **Таҗик** этнонимының мәгънәсе бүгенге көнгә кадәр ачыкланмаган. Ахыргы **ик**не без **ек-ык,** ягъни сөяк-ыру дип аңлый алабыз. **Таҗ** дигәне — каш-башның югарыда тикшергән **таш** варианты. Таш **таҗ**га әйләнгән. Тик шулай да, ышанычлырак булсын өчен, икенче бер мисалны да күздән кичерик. Урта гасырларда атаклы булган **бәҗәнәкләр** атамасын тюркологиядә төрлечә аңлатып карыйлар. Берәүләр моны гарәп сүзе ди, икенче берәүләр (һәм күпчелек) төрки **бажа** сүзеннән үзгәргән ди. Ләкин, миңа калса, **бәҗәнәк** атамасы бажадан түгел, баштан башланган. Аның әүвәлге формасы **баш-ан-ак** булган. Баш **бажга, бәҗгә, печкә** әйләнгән һәм башка кисәкчәләрне дә үзенә яраштырган.

Таҗик этнонимын **таштан** чыгаргач, безгә **ташлы** тагын бер атамага тукталырга туры килә. Монысы — **Ташкент.** Гарәпчә, фарсыча язма чыганакларда Ташкентның **Шаш, Чач** вариантлары да мәгълүм. Шуннан чыгып кайберәүләр Ташкентның иң борынгы формасы Шаш, Чач булгандыр диләр. Ләкин бу шаш, чач — **ташның** башкача әйтелеше генә. Ташкент кайчандыр төрки **таш** кабиләсенең **(таш-ыкларның)** бер торагы (кәнте) булган, дип әйтә алабыз.

**Таш-тас** элек нииндидер **ерткыч кошны** белдергән һәм бу кошка бик борынгы төркиләр табынган. Моның калдыклары Тува халкының мифологиясендә әле дә саклана[1]. Хәзерге һәм элекке заман төркиләрнең бик күбесендә **таш-тас** кабиләсе һәм ырулары булган. Мәсәлән, туба-кижеләрдә (тувалыларда), алтайлыларда — **тастар** ырулары, күчмә үзбәкләрдә — **тас** кабиләсе, аргыннарда **таз** буыны, найман кабиләсендә — **ак-таз** һәм казакъларның Кече җузында — **таз,** кыргызларның Сарыбагыш кабиләсендә — **таздар** һәм **таздар-кыргыз** таулары, башкортларда — **тазлар** кабиләсе булуы мәгълүм[2].

Монда без тагын урта гасыр гарәп язучылары телгә алган һәм Идел буенда яшәгән нииндидер **буртас**ларны да искә төшерә алабыз. Татарстанда Буртас (Бортас) авылы да бар.

Кыскача нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: төрле хайван, җәнлек, кош, балык, кеше, ыру-кабилә исемнәрендә, топономик атамаларда кабатлана торган аш-каш-таш-башлар, курлар-корлар нииндидер мәгънәсез авазлар чиратлашуы гына түгел. Бу кыска иҗекле сүзләрдә борынгы реаль тарих яшеренеп ята. Төрки халыкларның үткәнен дөрес аңлауда моның әһәмияте бик зур.

Сүз уңаеннан **татар** атамасы турында да бер-ике фикер әйтеп китәсе килә. **Татар** сүзе әлегәчә тиешенчә ачыкланмаган. Дөрес, бүгенге көндә **тат**ны башка кабилә кешесе сымаграк аңлату өстенлек итә. **Тат**ны да **таш-тас** тибындагы хайван, кош атамалары белән мәгънәдәш сүз итеп карасак, дөресрәк булмас микән? **Тат** ул **тас**ның иң якын туганы. Каш-кас, кор-кур нәселле җанварлар булгач, таш-тас нәселле кош булгач, тат, тар, тай, тан, тал нәселле җанварлар да (кошлар да) булгандыр дип уйлау дөресрәк булмасмы? Мәсәлән, **тар** тамырына без **тарпан**

---

[1] Л. Н. Потапов. Очерки народного быта тувинцев. Мәскәү, 1969 ел, 381 бит.
[2] Е. Д. Турсунов. Тюрко-монгольские версии сказания об ослеплении циклопа. «Советская тюркология» журналы, 1975 ел, 3 сан, 36—43 битләр.

(кыргый ат), **тар**-ак-ан дигән җанварларны, Кыргызстандагы **Тар** елгасын һәм **Тар**аз, **Тар**ас кебек башка бик күп атамаларны күрсәтә алабыз. **Тай** тамырына яшь ат **тайны** һәм шулай ук топономик **тай**ларны күрсәтергә була (мәсәлән, Ал-**тай**). Тан тамырына сыер баласы **тан**аны мисал итеп алабыз. Дон елгасының исеме элек **Танаис** дип аталган. Ахыргы **ис** — грек теле кушымчасы, ахрысы. Төрки кушымча булган очракта да Танаис (Тана-ас) мәгънәсез сүз булмаячак. **Тал** тамырының хайванлыгын исбатлау өчен без бай-**тал**ны искә төшерә алабыз. Монда тагын Кыргызстандагы атаклы һәм бик борынгы **Тал**асны да онытырга ярамый.

Шулай да мин **тат** тамырлы бернинди хайванны да искә төшерә алмадым. Шуңа күрә татардагы бу **тат**ны без борынгы төрки этнос атамаларында һәм хайван исемнәрендә очрый торган **бат-мат** оясы янында калдырып торыйк.

Бүре биографиясен тәмамлар алдыннан тагын бер-ике фаразга туктальп китик. Төркичә **ир** сүзе турында да кайбер тюркологлар **ираннан** (арий сүзеннән) алынган диләр. Ләкин **ир**нең тамыры дустыбыз бүрегә барып тоташа сыман. **Кашкыр**дагы **кыр** шуңа ишарәли. Мәсәлән, **айгыр** сүзендә бу ачык күренә (айгыр-азгыр, айгыр-өйгер, өег, ыры, ире). Тува телендә хатын иренең **ашак-ашаа** дип аталуы да башка төрки телләрдәге ир үзенең **кор-кыр-ыр**дан үзгәрүен ачыклый төшә. Татар теле диалектларында ир кешегә яратмыйча **айгыр-ашак** диләр. М. Кашгари сүзлегендәге: **ир** бала туса — **бүре** туды ...дигән тегe мәкальнең мәгънәсе монда бөтенләй яңача яңгырый сыман тоела. Тагын шунысы да бар — безнең хәтта үз **башы**быз да аш-таш-каш-баштан алып аталмады микән әле?! Булмас дип тә булмый. Кыргый ата-бабаларыбыз юкка гына табынмаганнардыр лабаса анабыз Бүрегә! Якутлар, мәсәлән, әле дә бүрене **таңара уола** (тәңре углы) дип атыйлар.

*Дәвамы бар.*

# ТОЛЫМБАЙ АВЫЛЫ

*Үзең яшәгән авылның яки шәһәрнең тарихын өйрәнү — әһәмиятле эш. Тарих үткәнне бүгенге белән чагыштырырга мөмкинлек бирә.*

*Журналыбызның бу санында без укучыларыбызга «Толымбай авылы» дигән язма тәкъдим итәбез. Бу — әлеге авыл биографиясенең нибары бер генә сәхифәсе. Анда Татарстанның Буа районында урнашкан һәм бүгенге көндә «Адав-Толымбай» исемен йөртүче авылның кайчан, нинди шартларда килеп чыгуы, шулай ук аның якын-тирә күршеләре турында кайбер мәгълүматлар бирелә. Әнә шул мәгълүматларга нигезләнеп, авылның бүгенге тормышына яңа гадәтләр кертү турында уйланасы иде. Әйтик, авылның туган елын, анда беренче мәктәп ачылу датасын, дуслык, бердәмлек, интернационализм рухының хезмәттә чагылышын ел саен тантаналы төстә билгеләп үтү — болар һәммәсе яңа гадәтләр туууга нигез булып торыр иде шикелле. Һәрхәлдә, мондый уйланулар өчен авыл тарихында материал җитәрлек.*

Илебезнең киң күкрәгенә җәелеп утырган меңәрләгән башка авыллар кебек үк Толымбай авылы да бүген мул тормыш белән яши. Аның урнашкан урыны — җәйлы, тирә-ягы — ямьле, кешеләре — эшчән, өлкәннәре — зирәк, яшьләре — тәртипле, балалары — күндәм.

Авылның җитештерү көче нык, куәтле: дистәләгән тракторлар, комбайннар, чәчү һәм йөк машиналары, аларны эшкә җигүче уңган механизаторлар, күп кырлы колхоз хуҗалыгын алып баручы белгечләр, төрле-төрле һөнәр ияләре — бүгенге Толымбай авылының җитештерү көчләре менә шулар. Башка авыллардагы шикелле үк, Толымбайда да хезмәт кешесенең тормыш шартлары бик нык үзгәрде. Хәзер һәр йортта Ильич лампалары балкый, көнкүрешкә газ керде, радио-телевизор керде, газета-журнал керде. Бу казанышлар — Бөек Октябрь революциясе нәтиҗәсе, бөек Ленин партиясенең фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсе. Толымбайда бу хакыйкатьне һәркем яхшы аңлый. Шуңа күрә дә авыл хезмәт ияләренең Ленин партиясенә, совет хөкүмәтенә рәхмәте тирән, мәхәббәте чиксез.

Ә бу авылның үткәндәге тормышы ничек булган соң? Авыл үзе кайчан барлыкка килгән? Аның беренче кешеләре кемнәр булган?

Бүгенге Толымбай авылына нигез салучы — патша һәм дин әһелләренең көчләп чукындыру политикасын кире каккан, үзенең ана телен ташларга теләмәгән һәм шуның нәтиҗәсендә качак хәлендә яшәргә мәҗбүр ителгән кешеләрнең берсе була. Толымбай дип аталган бу кеше үзенең дусты Илбай белән бергә Кырлангы ягыннан Зөя буена — хәзерге көндә Чиялек исемендә йөртелә торган җиргә килеп сыена. Шөгыльләре шул була: балык тоталар, җәнлек аулыйлар, кош-корт асрыйлар. Тормыш өчен шул җитә — ясак түләргә кирәк түгел, салым юк. Чөнки алар — качаклар, беркая да исәптә тормыйлар. Аларны беркем белми.

Көннәрдән бер көн, шулай гадәттәгечә ауда йөргәндә, боларны оброк җыючы, оброкка җир бирүче Нюнеп Чураев исемле татар очрата. Дуслашалар, Чураев иләшеп китә. Толымбай белән Илбай янына балык шулпасы ашарга йөри башлый, аларның ау мажараларын уртаклаша. Шулай йөри торгач, ул Толымбай белән Илбайга үз карамагындагы оброк җиренә күчеп утырырга тәкъдим итә. Свияжск Приказ йортында аларның утрак тормышын рәсмиләштерергә вәгъдә бирә.

Качак тормыш мәшәкатьләреннән туйган Толымбай белән Илбай аның тәкъдименә каршы килмиләр. Яшь тә бара, законлы тормыш та сагындыра, дип фикер йөртә алар.

1655 елда Толымбай һәм Илбай, Зәя буен ташлап, хәзерге Толымбай авылы күле буена килеп төпләнәләр. Нюнеп Чураев аларга йорт салып, гаилә корып җибәрергә ярдәм итә, Черкен авылы кызларына өйләндерә. Шулай итеп, 1655 елда хәзерге Толымбай авылы барлыкка килә һәм шушы елдан аның тарихы башлана.

Авылның урыны тормыш итү өчен уңайлы була. Су дисәң, су бар: Зәя елгасы да ерак түгел, Зур күл дә — каршыда гына. Өстәвенә күлнең тармаклары бихисап. Алар үзләре кечкенә-кечкенә мөстәкыйль күлләр хасил итәләр. Үсемлек дөньясы бай: урманнарда имән үсә, карама, усак, өрәңге үсә, шомырт, балан, чикләвек, миләш куагы үсә, каен, тал үсә. Җәнлекләрдән куян очрый, төлке, бүре, бурсык очрый. Кошлар дисәң, алар да җитәрлек: урманда — сандугач, көртлек, суер, күке, ябалак, карчыга, козгын, боҗыр, чилән, саескан, басуларда — бүдәнә, тургай, бытбылдык, кыр тавыгы, суларда — кыр казлары, үрдәкләр, баклан, ләкләк, саз кошы, тәкәрлек, чуллык. Су җәнлекләре дә юк түгел: кондыз бар, сусар бар. Күлләрдә: кәрәкә, сазан, чуртан, кара балык, елан балык, алабуга, шыртлака... чабак, җәен.

Мондый бай, матур урын авылның үсешенә, шөбһәсез, уңай йогынты ясый. Тиздән Толымбай исеме бу торак урынның атамасына әйләнә. Руслар аны, үз әйтемнәренә җайлаштырып, «Тулумбаево» диләр һәм бу исемне шушы формасында 1719 елга кадәр рәсми документларда кулланалар.

Нюнеп Чураев карамагындагы оброк җирләрен файдалануда Толымбай һәм Илбай ялгыз булмый. Аларга хәтле үк инде биредә Черкен авылы кешесе Айтуган Дельбышев иген игә. Ләкин ул кыргый һәм шомлы булып күренгән бу җиргә бөтенләйгә күчеп килми. Кыр эшләре беткәнче генә тора да яңадан Черкенгә кайтып китә. Ләкин Толымбай белән Илбайның биредә төпләнеп калуын күргәч, аңарда да бөтенләйгә күчеп килү теләге кабына.

Ниһаять, 1666 елда Айтуган Дельбышев белән бергә тагын 5 гаилә Черкеннән Толымбай авылы тирәсенә килеп утыра. Торак урыны итеп — Тутай чокыры янындагы күл буе сайлана. Килүчеләрнең исем-фамилияләре Юлдаш Сарбаев, Юлдаш Тимкиев, Сөеш Анисимов, Айтуган Дельбышев, Урмәт Бикбулдин, Мишка Баракаев була.

Аларның бу торак урыны 1666 елдан башлап мөстәкыйль авыл булып китә һәм Сөеш, ә русча «Сиушево» дип йөртелә башлый. Шулай итеп, Толымбай авылы янында яңа авыл барлыкка килә. Толымбай җирләре хәзерге урта һәм кырый урам буйлап наратлыкка һәм Алмакайга табан сузылган булса, Сөеш авылы басулары хәзерге Карлы ягына — Мүкле саз дип аталган урынга табан сузыла. Һәм карлы авылы җирләре белән чикләшә.

Карлы авылына 1662 елның 7 августында нигез салына һәм аны 1859 елга кадәр русча «Байбулатово», татарча «Байбулат» дип йөртәләр. Авылның беренче кешеләре — патша гаскәрендә хезмәт итеп кайткан Байбулат Борисов һәм аның иптәшләре — барлыгы кырык кеше була [1]. Соңыннан алар янына атлы гаскәрдә хезмәт итеп кайткан рейтарлар килеп төпләнә. Авыл зурая, ишәя. Байбулат авылы кешеләре Сөеш авылы җирләренә кул суза башлыйлар: аларның Мүкле саз тирәсендәге печәнлекләрен кереп чабалар. Ике авыл арасында бәхәс куба. Шушы уңай белән Юлдаш Сарбаев һәм Юлдаш Тимкиев Сөешнең барлык кешеләре исеменнән 1688 елның май аенда Свияжскидагы Приказ йортына гариза язалар. Анда болай диелә: «1666 елда безгә — ясак түләүче татарларга — Сөеш Анисимовка, Айтуган Дельбышевка, Урмәт Бикбулдинга, Мишка Баракаевка, Юлдаш Сарбаевка Нюнеп Чураевның оброкка дигән басуыннан 40 загонлык чәчүлек җир, 30 дисәтинә болынлык бирелгән иде. Бу җирләрнең Сөеш авылына бирелүе турында 1667 елда Свияжск Приказ йортыннан алынган кәгазь бар. Анда басу чикләре дә күрсәтелгән: Зәя елгасының бу ягында — Зур күл каршы якта — застава юлы, Карлы валы буенда — князь Аклычев манарасы һәм Толумбаев межасы».

«Байбулат авылы кешеләре,— диелә аннары гаризада, — Сөеш авылының басу чикләрен бозалар, печәнне кереп чабалар». Гаризаның авторлары Свияжск Приказ йортыннан килеп басу чикләрен кабат билгеләп китүне сорыйлар [2]. Бу документ шул ягы белән игътибарга лаек, анда Сөеш авылы һәм Толымбай авылы беренче мәртәбә

[1] Материалы исторические и юридические... Симбирск, 1904 г. том 4, стр. 207—208.
[2] Материалы исторические и юридические района бывшего приказа Казанского дворца. Симбирск, 1904 г. ст. 64—66.

рәсми рәвештә телгә алына. Сөеш авылының исә беренче кешеләренең исем-фамилиясе күрсәтелә.

1670 елда Степан Разин җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы вакытында бик күп крепостной крестьяннар аллавытта хезмәт итүне ташлап китәләр. Шундый крестьяннардан торган бер төркем чувашлар һәм татарлар 1676 елда Сөеш авылы татарлары янына килеп сыеналар. Яңа авыл барлыкка килә. Аны Яңа Сөеш авылы дип йөртәләр. Бу авылның күпчелеге Протопопово, Рунга авылларыннан киткән чувашлар һәм татарлар була.

1683 елда Сөеш авылының көньяк читендә, Зөя буенда тагын бер авылга нигез салына. Бирәдә Никифор Матвеевич Ивашов үзенең Муромдагы 6,5 дисәтинә җиренә өстәмә рәвештә 125 дисәтинә җир ала һәм күршедәге бай кызы Мария Костливцевага өйләнеп, үзенә яңа утар җайлый. Крепостной крестьяннарының бер кадәресен Муромнан монда китерә һәм хуҗалык итәргә керешә. 1683 елдан алып бу торак урыны хуҗасының исеме белән Ивашовка дип йөртелә башлый. Никифор Матвеевич 1707 елда үлә, хуҗалык мәшәкатьләре хатыны Мария җилкәсенә төшә. Бары тик 1739 елда гына бу мәшәкатьләрне, подполковник дәрәҗәсендә отставкага чыгып, әтисе утарына кайткан Семен Никифорович үз кулына ала. 1756 елда аның утарында эшләүче крепостной крестьяннарның саны 30 кешегә җитә.

1781 елда Зөя буенда Кугольня авылы төпләнә. Ул авыл барлыкка килү белән Толымбай авылы тәмам бөҗра эчендә кала. Аны һәр яктан башка авыллар урап ала. Бөҗраның бер буынын төньякта Бикмураз авылы хасил итә. Бу авыл үзе болай барлыкка килә. Туктамыш исемле кеше белән бергә өч хуҗалык 1638 елда Бикәй дип аталган күл буена килеп төпләнә. Башта яңа торак урынын «Бикәй юмрасы» дип йөртәләр. Соңыннан бу исем «Бикмураз»га өйләнә [1].

Толымбай авылының төньяк-көнбатыш күршесе булып Буа шәһәре тора. Бу торак урыны 1682 елга кадәр Янбулат исемен йөртә. Аннары руслар аны 1730 елга кадәр Опонасово-Афанасово дип атыйлар. 1730 елдан башлап ул Архангельскига әйләнә. 1780 елдан алып Буа шәһәр булып исәпләнә.

Буадан соң Толымбай авылының күршеләре мондый тәртиптә урнашалар, көнбатышта — Байбулат авылы, көньякта — Ивашовка, көнчыгышта — Кугольня.

Үткән 100 елдан артык вакыт эчендә Толымбай, Сөеш һәм Яңа Сөеш авыллары сизелерлек үзгәрәләр, үсәләр. Ниһаять, өч авыл бергә кушыла һәм барысы бер исем белән — русча «Адав-Тулумбаево» дип йөртелә башлый.

1790 елда авылның бер өлешендә яшәгән чувашлар христиан динен кабул итәләр. Аларга өстенлекләр бирелә. Шуннан соң чувашлар яшәгән як исеме белән авыл Сөеш авылы дип атала. «Адав-Тулумбаево» исеме рәсми документларда җәяләр эчендә генә күрсәтелә.

1794 елда үткәрелгән бишенче ревизия, ягъни халык санын исәпкә алу авыл турында түбәндәге мәгълүматларны бирә:

«Сөеш авылы, шул ук Толумбай да — ясак түләүче татарлар һәм яңа чукындырылган ясак түләүче чувашлар авылы.

Хуҗалык саны — 58, ирләр — 164, хатын-кызлар — 112, җире — 2083 дисәтинә, 2259 сажин, чәчү җирләре — 669 дисәтинә, 886 сажин, печәнлекләр — 284 дисәтинә, 2111 сажин.

Авыл исемсез күл буена урнашкан. Авылның кырлары буйлап Карлы елгасы үтә, уңда — Зөя елгасы, сулда — исемсез чокырлыклар. Күлнең ике ягында һәм Зөя елгасы ясаган култыкта — тирәклек, җәйге чиләдә Зөянең киңлеге авыл янында — 20 сажин, тирәнлеге бер аршыннан алып бер сажинга кадәр.

Карлы елгасының киңлеге — 10 сажин, тирәнлеге — бер аршыннан ике аршынга хәтле. Исемсез күлнең киңлеге — 50 сажин, тирәнлеге — бер аршыннан алып бер сажинга кадәр. Күл тармагының киңлеге — 5 сажиннан алып 15 сажинга кадәр. Чокырлыкларда су кибеп бетә. Елгаларда, күлләрдә һәм аларның тармакларында җәен, корбан, кушбаш, судак, чуртан, алабуга, шыртлака, налим, кәрәкә балыклары эләгә.

Утынлык урман — 900 дисәтинә, 2167 сажин.

---

[1] Материалы исторические и юридические района бывшего приказа Казанского дворца. Симбирск, 1904 г., т. 4, стр. 57.

Урманда каен, имән, өрәңге, карама, усак, чикләвек, шомырт, балан, миләш, тал агачлары.

Җәнлекләр: куян, төлке, ас.

Урман кошлары: карчыга, көртлек, урман тавыгы, саескан, ябалак, козгын, күке.

Су кошлары: киек каз, баклан, торна, төрле кыр үрдәкләре: саз кошы, чуллык.

Бөртекле культуралардан арыш яхшы уңа, бодай, солы, тары уңа.

Авыл утырган җир — 13 дисәтинә, 1452 сажин.

Авыл халкы җирне үзе сөрә, үзе чәчә, үзе ура, үзе суга.

Хатын-кызлар кыр хезмәтеннән тыш өйдә эшлиләр, бәйләү бәйлиләр, киндер, йон эрлиләр, үзләренә һәм сату өчен киндер сугалар» [1].

Моннан соң авыл ничек үскән, үзгәргән соң? Барыннан да элек авылның исеме вакыты-вакыты белән үзгәртелә. Башта өч авыл һәркайсы үз исемен йөртә. Аннары, Толымбай, Сөеш, Яңа Сөеш өчесе бергә кушылгач, авыл бер исемдә — Адав-Толымбай исемендә кала. Бу исем 1719 елгы документка шулай теркәлгән дә. Инде 1790 елда чувашлар христиан динен кабул иткәч, әлеге исем җәяләр эчендә генә күрсәтелә башлый. Беренче планга Сөеш исеме чыга. 1859 елдан алып авылның берлеге бетә, ул икегә — Сөеш һәм Адав-Толымбай авылларына аерыла. Ләкин 1896 елда алар яңадан берләштереләләр. Авылның исеме рәсми кәгазьләргә Сиушево (Адав-Тулумбаево) формасында теркәлә.

Инде авыл халкының яшәү шартларына килгәндә, барыннан да элек ул бик зур тыгызлыкта яшәгән. Мәсәлән, 1719 елда бер йортка 4 кә якын кеше туры килсә, 1859 елда бу сан 9 га күтәрелә. Гаилә саен тугызар кеше — бу, шөбһәсез, зур кысанлык.

Шулай ук аң-белем ягыннан да Толымбай авылында наданлык, рухи караңгылык хөкем сөргән. Беренче дөньяви мәктәпнең бары тик 1896 елда гына ачылуы — моңа ачык дәлил.

Тагын бер деталь. 1859 елдан башлап авылның күленә исем бирелә: аны Иркул дип атыйлар.

1859 елда салынган мәчет каршында 1884 елда мәктәп эшли башлый. 1905 елда игълан ителгән дин ирке турындагы патша манифестыннан соң элек христиан динен кабул иткән чувашларның байтагы яңадан мөселман диненә кайта. Нәтиҗәдә авылда икенче мәчет барлыкка килә.

Инде калган чувашлар христиан динен ташлый күрмәсен дип, поплар авылга рус гаиләләрен күчереп утырталар. Янәсе татарларга күз-колак булырлар, чувашларга юлдан язарга ирек бирмәсләр. Шушы ук максаттан чыгып, авылда чиркәү салына һәм ул тиз арада эшли дә башлый. Шулай итеп, бүгенге Толымбай авылы егерменче гасыр башында өч милләтле авылга әйләнә, зурая, ишәя. 1913 елда андагы хуҗалыклар саны 240 ка, ирләр саны — 812 гә, хатын-кыз саны — 805 кә җитә. Авыл Беренче бөтендөнья империалистик сугыш елларына шушы хәлдә килеп керә. Аннары Бөек Октябрь социалистик революциясе. Гражданнар сугышы. Бөек җиңү. Тормышның яңача башлануы.

Социалистик революция илдә изүчеләр хакимлеген җимерә. Дин башлыкларының көчләп руслаштыру политикасын төбе-тамыры белән йолкып ташлый, милли телләрне кысуны бетерә һәм илдәге барлык милләтләр өчен эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культура төзү мөмкинлекләрен ача. Бөек Ленин партиясенең фидакарь эшчәнлеге белән милләтара мөнәсәбәтләрдә тигезлек, дуслык, туганлык, татулык урнаша. Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә халык коммунистик җәмгыять төзү юлына баса.

Толымбай авылы — менә шушы үзгәрешләрне үзендә гәүдәләндерүче меңләгән мисалларның берсе. Бүгенге көндә аның хезмәтчәннәре — татарлар, чувашлар, руслар — партия чакыруына фидакарь хезмәт белән җавап бирәләр һәм коммунизм төзү юлыннан якты киләчәккә атлыйлар. Аларның бердәмлеге — нык, күңелләре — көр, ышанычлары — зур, дуслыклары — какшамас.

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН,**
**Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр кафедрасы мөдире, доцент.**

[1] Экономические примечания Буинского уезда. ЦАГА, фонд 1355.

# ШИГЪРИЯТ һӘМ... ЭВМ

Партиябезнең ленинчыл күрсәтмәләре белән илһамланып, татар галимнәре сәнгать һәм әдәбият тарихының моңа кадәр кузгатылмаган күп кенә яңа тармакларын эшкәртергә керештеләр. Соңгы елларда гына да борынгы культурабызның теге яки бу мөһим мәсьәләләренә багышланган зур-зур хезмәтләр дөнья күрде.

Күптән түгел алар янына тагын бер зур фәнни хезмәт өстәлде — күренекле галим, филология фәннәре докторы, профессор Хатип Госманның «Шигырь төзелеше» дигән китабы[1] басылып чыкты.

Бу китапның беренче битләрен ачуга башта күңелдә шик туа: электрон-исәпләү машинасы (ЭВМ) өчен культура түгелме соң бу? Механика-математика факультетында укучы студентларның дәреслеге күз алдына килә. Шундый ук геометрик шәкелләр тезмәсе, хисапсыз күп саннар һәм һәр төрле шартлы билгеләр белән чуарланган таблицалар... Җитмәсә, моннан 4—5 ел элек Тукай клубында Хатип Госман, өлге-плакатлардан файдаланып, шигырь төзелеше турында лекция укыганда, бер шагыйрьнең авыз ерыбрак: «Бу таблицалар шигырьнең матурлыгын аңларга, начар шигырьне яхшы шигырьдән аерырга булышалармы?» — дип сораганы искә төшә.

Шигърият һәм ЭВМ... А. Пушкин, Пугачев восстаниесе турында материаллар эзләп Казанга килгәч, университетның ул чактагы ректоры, математик Н. Лобачевский белән очраша. Кызганычка каршы, бу ике даһиның нәрсә турында сөйләшүләре билгесез. Әмма бу очрашудан соң бераз вакыт узгач, А. Пушкин үзенең көндәлек дәфтәренә: «Геометрия өлкәсендә дә, поэзиядәге кебек үк, илһам кирәк», — дип язып куйган. Шуның белән бергә, Н. Лобачевскийның үз заманындагы шагыйрьләр (мәсәлән, И. Великопольский) белән ярыша алырлык шигырьләр язуын беләбез. Безнең көннәрдә физикларны лирикларга каршы куярга теләүчеләр дә булды. Ләкин бу ясалма проблема, сабын куыгыдай шартлап, бик тиз юкка чыкты. Кешелекнең иң бөек математиклары һәм физиклары, аларның биографияләреннән күренгәнчә, шигърият белән мавыкканнар. Монысы әле мәсьәләнең бер ягы гына. Ә инде математиканың турыдан-туры катнашына килгәндә, нәкъ менә иҗек саннары, аларның үлчәмле кисәкләре — метрик буыннар теге яки бу шигырьнең ритмик дулкынында, яңгырашында һәм аһәңендә үзенчәлекле аермалыкны китереп чыгаралар икән ләбаса!

«Шигырь төзелеше»н бер талпынуда укып чыктым. Кайчандыр үзенең повестьхикәяләре белән безне куандырган әдип каләме һәр җөмләдә сизелеп тора. Әйдәгез, берничә абзацны бергәләп укып карыйк әле:

«Галимнәрнең махсус лабораторияләрдә чеби ничек яралуын күзәтүләре искә төшә. Йомырка, күзәтергә җайлы итеп, яктыртылган урынга куела. Аңа тереклек яралгысын уятып җибәрерлек җылы бирәләр. Ул тиешле күләмнәрдә өзлексез бирелә тора. Бер заман йомырка эчендә бик кечкенә кызыл нокточык пәйда була. Бераз да үтми, аңардан төрле якка бик һәм бик нечкә кызыл җепләр йөгереп китә. Аларның очлары, төрле урыннарда очрашып, ялганышалар. Ноктачык кинәт сискәнеп ала һәм тибә башлый. Шулай йөрәк һәм кан йөреше юллары туа. Йөрәк җибәреп торган дулкыннан хәрәкәт итеп, кан тамырлары көн дими, төн дими чебинең әгъзаларын туктаусыз тукыйлар. Чеби, өлгереп җиткәч, күкәй кабыгын ватып якты дөньяга чыга».

[1] Х. Госман. Шигырь төзелеше. Татарстан китап нәшрияты, 1975 ел.

Шигырьне тудырачак «йөрәк һәм кан йөреше» тарихи яктан җанлы сөйләм эчендә туган, ул җанлы сөйләм агымына кушылып хәрәкәт иткән. Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» әсәреннән бер мисал алыйк:

«Җәйнең аяз, матур айлы кичләреннән бере иде. Егет асыл киемнәрен киде, сөекле тулпарын Байчабарны иярләде... Ат җилдереп, Алтын Күлгә, Сарсымбай җәйләвенә килде».

Беренче фразага игътибар итегез. Моның үзендә шигырь ритмының «кызыл нокталары» бар дип, әсәрне укыган кешеләрдән кем дә булса уена китерде микән? Хәлбуки, ул монда бар. Сузылып киткән «кызыл җеп» тә бар, тик ул шундый ук икенче «кызыл җеп» белән тоташмаган гына.

Фразаны аерып алыйк та, очлары тоташсын өчен, үзебездән уйлап, аңа тиң килгән икенче фраза куйыйк:

| | | |
|---|---|---|
| **Җәйнең аяз,** | **матур айлы** | **кичләреннән бере иде,—** |
| **Бере иде** | **күптән көткән** | **матур бәйрәм төне иде.** |

«Җепләрнең» очы очка ялганды һәм чыннан да нәрсәдер гүяки сискәнеп алды; фраза башындагы «җәйнең аяз» дигән өлеш, ачык бүленеп, үз көчен җыйнап, калкынып куйды — метрик буын туды. Аңа тигезләнеп, башка буыннар дулкын-дулкын калкып чыктылар: «матур айлы», «кичләреннән», «бере иде»...

Җанлы сөйләмнең теләсә нинди фразасында шигырь ритмының шушындый объектив яралгысы бар. Ләкин ул күзгә бәрелеп тормый, аңа үзен күрсәтү, калкынып чыгу өчен **п а р л а ш к а н  х ә р ә к ә т** кирәк. Шунда гына ул үзенең бөтен көчен-куәтен эшкә җигә ала, шунда гына үзенә хас яңгырашка ирешә. Шигырь строфаларының ким дигәндә ике тезмәдән торулары да шуңа бәйләнгән...

«...Чеби йөрәге бер урында торып тибә, үзеннән дулкыннарны кан тамырларына бер-бер артлы озата тора. Тезмәдә дулкынны беренче метрик буын кузгатып җибәрә, аннан икенче буын, өченче буын кузгала. Ягъни биредә дулкынны кузгату көче һәр буынның үзендә туа. Әгәр дә буынны чыннан да йөрәк белән тыңласак, биредә йөрәк гүяки һәр буынның үзенә күчә-күчә тибә. Шунсыз мөмкин дә түгел, чөнки метрик буыннар бер калыпка салынган авазлар җыелмасы гына түгел, аларның һәрберсе хистойгы белән сугарылган яңа төшенчә, яңа мәгънә китерә». (31—32 һәм 34—35 битләр).

Шигырьгә чын күңелдән гашыйк булган, аңа күп еллык иҗади хезмәтен багышлаган галим генә аның турында әнә шулай сурәтле итеп фикерли ала.

Язма төрки-татар шигыренең ун гасырлык тарихы булса да, аның үзенә генә хас сыйфатлары, закончалыклары турындагы фән аерым бер системага салынмаган, хәтта башлангыч гыйльми төшенчәләре — терминнары да эшләнмәгән иде әле. Дөрес, урта гасырларда галимнәр төрки шигыренең төзелешен гарәп шигырь теориясе «гаруз» ярдәмендә аңлатырга омтылып караганнар. Һәм шуның нәтиҗәсендә төрки-татар шигыренең гарәп шигыренә охшаш яклары ачылган, строфа өлгесен һәм иҗек саннарының уртак тәртибен билгеләүдә гарәп чаралары кулланышка кертелгән. Ләкин бу чаралар, төрки-татар теленең үз эчке хасиятләреннән тумаганлыктан, шигъриятебезнең бик тирәндә яткан үзенчәлекләренә үтеп керергә мөмкинлек бирмәгәннәр.

«Шигырь төзелеше»нең авторы, фәннең хәзерге казанышларына таянып һәм тарихилык юлын тотып, төрки-татар шигыренең эчке закончалыгын, структурасын ачуны, аңлатуны үзенең бурычы итеп куя. Моның өчен аңа халыкның иң борынгы заманнардан алып язма шигырь барлыкка килгәнчегә кадәр туктаусыз үсә барган авыз иҗатын — мәкальләрне, җырларны, табышмакларны һәм такмазаларны, аларда шигырь күзәнәге ничек яралуын һәм тәрәккъый итүен өйрәнергә кирәк булган. Аннан соң ул бу шигырь күзәнәгенең ничек язмага күчүен һәм безнең заманнарга килеп җиткәнче нинди үсеш, үзгәрешләр кичерүен җентекләп тикшергән. Кыскасы, автор безнең шигърият тарихыбызга кагылышлы бай хәзинәне үзенчә яктырта. Һичшиксез, киләчәктә дә бу өлкәдә тирән эзләнүләр алып барырга кирәк булачак әле. Шулай да Хатип Госманның «Шигырь төзелеше»нә карата кайбер файдалы нәтиҗәләрне инде чыгарырга мөмкин.

Беренчедән, бу хезмәт белән танышкач, бүген гамәлдә булган шигырь төзелеше элементларының, нихәтле ерак заманнарда туып, нихәтле озын тарихи юл үтүләрен ачык күрәбез.

Икенчедән, төрки-татар шигыренең башлангыч нигезләре турындагы фән университет һәм педагогия институтларының филология факультеты уку планында үзенең ныклы урынын алырга тиешлеге ачык аңлашыла.

Өченчедән, халык авыз иҗатыбызның һәм шигъриятебезнең борынгы хәзинәсен (китапта китерелгән үрнәкләрен ләззәтләнеп укыйсың), хәзерге телебезгә күчереп, кичектермичә бастырып чыгару һәм киң массага җиткерү кирәклеге күренә.

Ниһаять күп еллар буе җитди эзләнүләр нәтиҗәсендә дөньяга килгән китапның исеме җисеменә төгәл туры килмәвен әйтергә кирәк. Хатип Госман, артык тыйнаклык күрсәтеп, үзенең хезмәтен «Шигырь төзелеше» дип кенә атаган. Хәлбуки, аның эчтәлеге төрки-татар шигыренең башлангыч нигезләрен, бөтен бер тарихын чагылдыра һәм ул, безнең уебызча, шул мәгънәдә аталырга тиеш булгандыр да.

**Җәвад ТӘРҖЕМАНОВ.**

# ИНКЫЙЛАП БАЙРАКЧЫСЫ

*Конкурска килгән рецензия*

Бөек Октябрь революциясе тарихын өйрәнгәндә безнең илдәге милли-азатлык хәрәкәтен читләтеп үтеп булмый. Чөнки революция үзе Россиянең төрле өлкәләрендә милли-азатлык хәрәкәте көчәеп киткән бер чорга туры килә. Алай гына да түгел, большевиклар партиясенең буржуаз-демократик революцияне социалистик революциягә әйләндерү өчен алып барган көрәшенә милли өлкәләрдәге революцион-демократик оешмалар зур ярдәм күрсәтәләр. Моны үзебезнең Казан губернасы мисалында да бик ачык күрергә була.

Социалистик революцияне хәзерләү һәм тормышка ашыру чорында безнең якларда җәелгән милли-азатлык хәрәкәте аз өйрәнелгән дип булмый. Шул ук вакытта бу мәсьәләнең ныграк ачыклый төшәсе яклары да бар әле. Мөселман социалистлар комитетының эшчәнлеген өйрәнү, мәсәлән, шундый мәсьәләләр рәтенә керә. Татарстанда Октябрь көннәрен өйрәнүче галимнәр күпмедер күләмдә бу мәсьәләгә дә кагылып узалар. Тик тулысы белән Мөселман социалистлар комитетын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр әлегә күп түгел. Шулай да ул галимнәрнең игътибарын торган саен ныграк били бара, белгечләр өчен дә, киң катлау укучылар массасы өчен дә кызыклы мәгълүматларга бай яңаданяңа хезмәтләр языла. Алар янына соңгы көннәрдә тагын бер хезмәт өстәлде — Татарстан китап нәшрияты Р. Нуруллинаның Мөселман социалистлар комитеты органы «Кызыл байрак» газетасына багышланган китабын [1] басып чыгарды.

Монография авторы «Кызыл байрак» газетасы битләрендә басылган материалларны барлау, өйрәнү һәм аларны системага салу буенча зур эш башкарган. Бик күп конкрет фактлар нигезендә ул газета редакциясенең татар хезмәт ияләре арасында социализм һәм большевизм идеяләрен пропагандалау, аларны пролетариат революциясе ягына тарту буенча башкарган зур эшен күрсәтә.

1917 елның март-апрель айларында күренекле татар революционеры, В. И. Ленинның якын көрәштәше Мулланур Вахитов җитәкчелегендә төзелгән Мөселман социалистлар комитеты Татарстанда совет властеның җиңүен тәэмин итү эшендә мөһим роль уйнаган. Г. Сәйфетдинов, Я. Чанышев, К. Саттаров, Ш. Әхмәдиев, Х. Гайнуллин, В. Шәфигуллин, К. Якупов, Ә. Мөхетдинова кебек җәмәгать эшлеклеләре бу комитет эшенә якыннан торып катнашкан. М. Вахитов иҗатына багышланган монографиясендә профессор Р. Нәфиков бик дөрес билгеләп үткәнчә, «Мөселман социалистлар комитеты большевиклар партиясенең татар хезмәт ияләренең эшчеләр сыйныфы идеологиясе белән сугарылырга өлгермәгән, әмма монархиягә кире кайтырга теләмәгән, ә бәлки республикалар төзү ягында торган һәм буржуазия хакимлегенә каршы көрәшкән өлешенә үз йогынтысын ясый торган үзен-

[1] Р. Нуруллина. «Кызыл байрак» газетасы. Казан, 1976 ел.

чәлекле оешма формасы булган»[1]. Р. Нуруллина хезмәте тагын бер тапкыр шул фикернең дәреслеген раслый.

Политик юнәлешләренә, тоткан мәсләкләренә карап, галим революциягә кадәрге көндәлек матбугатны дүрт төркемгә (большевистик, революцион-демократик, либераль-буржуаз һәм реакцион матбугат органнары) бүлеп йөртә. «Кызыл байрак» шуларның революцион-демократик юнәлештәгесе була. «Кызыл байрак» белән бергә, хезмәттә «Ирек», «Аваз» һәм «Чулпан» газеталарында басылган материалларга да зур урын бирелгән. Шул ук вакытта автор шактый уңышлы төстә әлеге газеталарны үзара янәшә куеп, чагыштырып карый, һәр газетаның гомуми юнәлешен һәм әһәмиятен ачыкларга омтыла. Тик нигәдер Мөселман социалистлар комитетының берәз соңрак рус телендә чыга башлаган икенче органы — «Красное знамя» газетасы читләтеп үтелгән. Бик матур башланган эшен автор алга таба дәвам иттерсен иде, «Кызыл байрак»тагы традицияләрнең әлеге газетада ничек үстерелүен күзәтсен иде, дигән теләк белдерәсе килә.

Хезмәтнең баштагы өлешендә Р. Нуруллина Февраль революциясеннән соң Казандагы катлаулы обстановка белән таныштыра. Көчәеп килгән милли-азатлык хәрәкәтен үз мәнфәгатьләренә хезмәт иттерү турында хыялланган буржуаз интеллигенция вәкилләренең реакцион эшчәнлеге нәтиҗәсендә хәл тагын да кискенләшә төшә. «Шушы шартларда, — ди Р. Нуруллина, — РСДРП(б)ның Казан комитеты алдына татар хезмәт ияләрен милли буржуазия йогынтысыннан йолып алу, милли-азатлык хәрәкәтенең барлык революцион көчләрен бергә туплау бурычы килеп баса» (9 нчы бит). Китап ахырындагы нәтиҗәләрдән күренгәнчә, бу бурыч күп кенә дәрәҗәдә Мөселман социалистлар комитеты һәм аның органы «Кызыл байрак» газетасының эшчәнлеге нәтиҗәсендә үтәлә.

Автор «Кызыл байрак» газетасына багышланган хезмәтләргә гомуми күзәтү ясый, аның төп үсеш этапларын билгели. Ул 30—40 нчы елларда язылган хезмәтләрдәге җитешсез якларны бик хаклы рәвештә күрсәтеп үтә. 50 нче еллар башыннан Мөселман социалистлар комитеты һәм аның органы «Кызыл байрак» газетасының политик йөзен билгеләүдә яңа тенденцияләр барлыкка килә, галимнәр элекке берьяклы фикерләрне дөресләү, МСК эшчәнлегенә объектив бәя бирү юлына басалар, ди. Ихтимал, шушы урында партиянең эчке тормышында һәм безнең демократиядә, шул исәптән тарих фәнендә, мөһим ленинчыл принципларны тормышка кайтару юлында партиянең XX съезды карарлары нинди роль уйнавын да билгеләп үтәргә кирәк булгандыр. Автор Р. Нәфиков, М. Мөхәррәмов, Р. Хәйретдинов, Я. Шәрәпов, И. Ионенко һәм И. Таһировларның Мөселман социалистлар комитетының эшчәнлеген яктырткан хезмәтләренә югары бәя бирә. Историография хакында сөйләгәндә, бу мәсьәләгә караган кайбер башка хезмәтләрне дә, әйтик, В. Шәфигуллинның истәлекләрен[1] дә искә алып китәргә мөмкин булыр иде. Р. Нуруллина С. Кәримованың «Большевистик «Рабочий» газетасы массалар өчен көрәштә» дигән хезмәтендә очраган кимчелекләрне тәнкыйть итеп чыга. Мөселман социалистлар комитетының политик юнәлешенә тукталып, С. Кәримова: «Мөселман социалистлар комитетының вак буржуа асылы аның шәһәр думасына сайлауларда социалистлар белән бер блокта баруында һәм II Бөтенроссия мөселманнар съездының милли-культура автономия кабул итү турындагы карарын шатланып каршы алуында күренде», дип язган иде. С. Кәримованың хакыйкатьтән ерак бу фикерен монография авторы конкрет фактлар, «Кызыл байрак»тан алынган өзекләр ярдәмендә кире кага.

Автор «Кызыл байрак» газетасының Октябрьга кадәр чыккан саннарын үзенә аерым, Октябрьдан соңгы чыкканнарын үзенә аерым тикшерә, газета эшчәнлеген илдәге гомуми обстановка белән бәйләп карый. Әгәр газетаның беренче саннарында социалист-революционерлар программасына хас идеяләр урын алса, ди автор, 1917 елның июль аеннан соң чыккан саннарында нигездә РСДРП(б)ның политикасын пропагандалаган материаллар басыла.

Китап кечкенә-кечкенә аерым бүлекләрдән тора. Һәр бүлектә газета редакциясе эшчәнлегенә караган берәр мәсьәлә карала. Анда шактый җентекле төстә «Кызыл байрак»ның интернационализмы хакында сөйләнә, аның большевистик матбугат белән булган бәйләнешләре искә алына,

[1] Р. Нафигов. Мулланур Вахитов. Историко-биографический очерк. Рус телендә. Казан, 1975 ел, 108 бит.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1924 ел, 7 ноябрь; «Кызыл Татарстан» газетасы, 1927 ел, 4 ноябрь саны.

газетаның большевистик лозунгларны пропагандалавына аеруча нык басым ясала. Шул уңайдан «Кызыл байрак»та басылган «Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре!» дигән сүз ни дигән сүз?», «Россиядә эшче социал-демократлар партиясе», «Эшче Бауман», «Социал-демократлар ни телиләр?», «Шәһәр идарәләре хакында социал-демократлар платформасы» дигән һәм күп кенә башка мәкаләләр махсус өйрәнелә. Хезмәтнең «Бөтен власть — Советларга!», «Бетсен империалистик сугыш!» дигән бүлекләре дә кызыксыну белән укыла. Әлеге бүлекләрдә халыкны борчыган күп мәсьәләләрне, шул исәптән милли мәсьәләне дә, хәл итә алмаган Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәш турында сүз бара. Вакытлы хөкүмәтнең буржуаз асылын фаш иткән, аның империалистик талау сугышына мөнәсәбәтен ачкан мәкаләләргә аеруча нык басым ясала. Хәтта бу бүлектәге мәкаләләрнең исемнәре дә шул хакта сөйли: «Сугыш кайчан бетәчәк?», «Россия сугышка күпме акча тота һәм ул акчалар кайдан алына?» һ. б. Газетаның империалистик сугышка мөнәсәбәтен белдергән материалларны җентекләп өйрәнеп чыкканнан соң: «Газета барлык мәсьәләләрне дә империалистик сугышны туктату, кан коюны бетерү белән бәйли, ә сугышны бетерү хакимиятне эшче, солдат, крестьян Советлары кулына тапшырганда гына мөмкин булачак!», дигән нәтиҗә ясала.

Хезмәтнең буржуаз милләтчеләргә каршы көрәш, хатын-кыз азатлыгы кебек мәсьәләләргә багышланган бүлекләре дә кызыксыну уята.

Китапта «Кызыл байрак» газетасына язышкан авторларның исемлеге китерелә, аларның псевдонимнары күрсәтелә. Автор газетаның һәр саны кайчан чыгуын һәм кайда саклануын ачыклый. Дөрес, китапта кайбер хаталар да киткән. 19 нчы биттә, мәсәлән, «Кызыл байрак»ның икенче саны 23 нче июньдә чыга дип, ә 52 нче биттә газетаның өченче саны 1917 елның 27 июнендә чыга дип күрсәтелгән. Хәлбуки, газетаның икенче саны 21 июньдә, ә өченче саны 28 июньдә чыккан.

Авторның төп фикерләре бәхәссез һәм ышандыра. Чыннан да, Бөек Октябрь революциясенә хәзерлек көннәрендә һәм революциядән соң «Кызыл байрак» газетасы күп кенә мөһим мәсьәләләрдә большевистик карашларда тора, хезмәт ияләре арасында РСДРП(б) программасын, марксизм идеяләрен, большевистик лозунгларны, халыклар дуслыгы һәм интернационализм идеяләрен пропагандалый, татар хезмәт ияләрен буржуаз милләтчеләр йогынтысыннан йолып алырга булыша. Боларның һәммәсе Татарстанда совет власте урнаштыруда зур ярдәм итә.

«Кызыл байрак» газетасының эшчәнлеген бәяләгәндә Р. Нуруллина аның журналистиканы үстерүдәге һәм сәләтле журналистлар хәзерләү өлкәсендәге эшчәнлегенә дә югары бәя бирә. Газетада басылган материаллардан тыш, автор архивларда бик күп казынган, шул темага караган фәнни әдәбиятны өйрәнгән.

**Рөстәм БӘДЫЙГОВ,**
**Казан дәүләт университеты аспиранты.**

≈≈≈≈≈≈

# МӘГЪРИФӘТ УЧАГЫ

Шушы елның сентябрь аенда Казан татар укытучылар мәктәбенең ачылуына 100 ел тула. Ул бездәге алдынгы иҗтимагый фикер һәм культура үсешенә тирән эз салган уку йортларының иң күренеклесе дияргә була.

Татар укытучылар мәктәбенең шактый гыйбрәтле һәм бай тарихы бар. Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләр көчәеп килгән бер чорда — 1870 елның 26 мартында — патша хөкүмәте Идел буе татарлары өчен рус-татар мәктәпләре ачу турында карар кабул итә. Озак та үтми, әлеге карарны тормышка ашыру максаты белән, Казан укыту округында махсус инспектор штаты булдырыла, төрки телләре буенча күренекле галим В. Радлов шул урынга инспектор итеп билгеләнә.

Сүз дә юк, патша хөкүмәте рус-татар мәктәпләрен татар халкын руслаштыру максатын күздә тотып ача[1]. Шуңа да халыкның байтак өлеше, бигрәк тә руханилар, аларга теш-тырнаклары белән каршы торалар. Татар халкының К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, М. Мәхмүдов, Ш. Әхмеров кебек алдынгы карашлы вәкилләре исә әлеге мәктәпләрне хезмәт ияләрен милли йомыклыктан чыгару, аларның аң-культура дәрәҗәсен күтәрү чарасы итеп файдаланырга тырышалар. Шуңа күрә дә алар инспектор В. Радловка яңа мәктәпләр ачуда, ачылганнарының эшен юлга салуда төрлечә ярдәм күрсәтәләр. Татар мәгърифәтчеләренең якыннан ярдәме белән яңа типтагы мәктәпләр челтәре елдан-ел киңәя бара.

Ләкин шул чак икенче бер кыенлык килеп чыга. Рус-татар мәктәпләрендә укытыр өчен татар халкының үз арасыннан чыккан кадрлар җитешми башлый. Көн тәртибенә дөньяви фәннәр һәм алдынгы методика белән коралланган, рус телен яхшы үзләштергән укытучы кадрлар хәзерләү проблемасы, башкача әйткәндә, Казанда татар укытучылар мәктәбе ачу мәсьәләсе килеп баса.

Шул мәсьәләне тормышка ашыруны үтенеп, 1873 елның 15 гыйнварында В. Радлов Мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать итә[2]. Министрлыкта, бүлмәдән-бүлмәгә күчеп, өч еллап йөргәннән соң, ниһаять, инспекторның үтенече уңай хәл ителә. 1876 елның 26 сентябреннән Казанда татар укытучылар мәктәбе эшли башлый[3]. Мәктәп интернат тибында булып, анда укучылар дүрт ел буена казна хисабына яшиләр. Ислам диненнән кала, барлык фәннәр рус телендә укытыла.

Казан укытучылар мәктәбен «барлык татар мәктәпләре өчен үзәк үрнәк мәктәпкә әверелдерү»[4] өчен В. Радлов һәм мәктәпнең беренче инспекторы (хәзергечә директоры), күренекле татар мәгърифәтчесе Мөхәммәтгали Мәхмүдов күп көч куялар. Алар укыту эшенә фәнни хезмәтләре һәм алдынгы карашлары белән танылган күренекле галимнәрне тарталар, укучыларга белем бирүнең отышлы алымнарын эзлиләр.

Казан укытучылар мәктәбендә төрле елларда Ш. Әхмеров, Ш. Мәрҗани, Ш. Таһири кебек күренекле татар галимнәре эшли. Шул мәктәптә эшләгән В. Радлов, В. Богородицкий, А. Анастасиев, И. Петяев, М. Васильев кебек рус галимнәре рус теленнән һәм әдәбиятыннан татар мәктәпләре өчен беренче дәреслекләр төзиләр, татарларга рус телен өйрәтү методикасына фәнни нигез салалар.

Казан укытучылар мәктәбенә 1875 елда университет каршында оешкан лингвисти-

---

[1] Бу мәктәпләрнең бер өлеше «Русско-татарское начальное училище» дип, икенчеләре «Русский класс при медресе» дип аталып йөртелгән.

[2] ТАССР ҮДА, 92 фонд, 1 тасвирлама, 10961 эш, 7 бит; СССРның Ленинградтагы ҮДТА, 733 фонд, 170 тасвирлама, 765 эш, 25—26 битләр.

[3] ТАССР ҮДА, 92 фонд, 1 тасвирлама, 12335 эш, 40 бит.

[4] Шунда ук, 13158 эш, 6 бит.

ка мәктәбе зур методик ярдәм күрсәтә. Лингвистика мәктәбенең берничә галиме татар укытучылар мәктәбендә дә эшли. Алар рус телен укытуны фәнни нигезләргә салырга булышалар. Казан университетының алдынгы карашлы галимнәре П. Траубенберг, Н. Любимов, С. Болберг, Д. Адо, М. Прянишковлар бер үк вакытта укытучылар мәктәбендә дә дәресләр бирәләр. Болар барысы да Казан татар укытучылар мәктәбенең рус-татар культура элемтәләре өлкәсендә иң әһәмиятле үзәкләреннән берсе булуы турында сөйли.

Татарларны руслаштыру һәм аларны царизмга бирелгәнлек рухында тәрбияләү максаты белән ачылган мәктәп, киресенчә, алдынгы фикер учагына әйләнә. Анда рус һәм татар халыкларының алдынгы уллары кулга-кул тотынып бергә эшлиләр. Ахыр чиктә боларның һәммәсе мәктәпнең эшен демократик юнәлештә оештыруга китерә, рус телен һәм фән нигезләрен яхшы белгән педагоглар хәзерләүгә ярдәм итә. Менә шуңа да татар руханилары һәм рус миссионерлары бу мәктәпне даими рәвештә дошман күрәләр, бөтен көчләре белән аның эшенә аяк чалырга тырышалар. 1876, 1884 һәм 1897 елларда Мәгариф министрлыгы һәм Синод каршында татар укытучылар мәктәбен ябу мәсьәләсен күтәрәләр[1]. Патша хөкүмәте мәктәпне саклап кала, әмма шул ук вакытта аның материаль базасын киңәйтү һәм укучылар контингентын арттыру буенча бернинди чара күрми.

1881 елда мәктәпнең инспекторы итеп Шахбазгәрәй Әхмеров билгеләнә. В. Радлов 1885 елда, академик булып сайланып, Петербургка күчкәннән соң, Ш. Әхмеров Казан укыту округының инспекторы булып та кала. Югары культурага ия кеше буларак, ул күп тапкырлар Казан укытучылар мәктәбен ябылудан коткарып кала һәм андагы уку-укыту шартларын яхшыртуга зур көч куя.

Казан татар укытучылар мәктәбе 1917 елның июлендә семинария, ә 1919 елның 1 октябреннан педагогик курслар итеп үзгәртелә. Бу соңгысы инде сыйфат ягыннан бөтенләй башка характердагы уку йорты була.

43 ел яшәү дәверендә бу мәктәпне биш йөзләп кеше тәмамлый. Алар шәһәр һәм авыл мәдрәсәләре каршындагы рус классларында балалар укыталар. Бу мәктәпләрдәге татарларны һәм башкортларны рус теленә, рус әдәбиятына өйрәтәләр, аларны бөек рус культурасына якынайталар, балаларга табигать, география һәм тарих буенча фәнни төшенчәләр бирәләр, рәсем ясарга, җырларга өйрәтәләр.

Рус теле классларында һәм рус-татар мәктәпләрендә уку-укыту эшенең уңышлы оештырылуы дини мәктәп-мәдрәсәләргә дә уңай йогынты ясый. Укытучылар мәктәбендә белем алып чыккан кешеләрдән Гайнетдин һәм Шиһап Әхмеровларның рус телендәге әлифбалары, Ш. Таһири һәм М. Корбангалиевның аваз методы буенча татарча әлифбалары, Габделкаюм Коләхметовның арифметика һәм тарих, С. Сүнчәләйнең гигиена дәреслекләре Октябрь революциясенә кадәрге чорда татар мәктәп-мәдрәсәләрендә киң кулланылган. Рус-татар мәктәпләрендә эшләгән һәр укытучы диярлек дәреслек язу белән шөгыльләнгән. XX йөзнең унынчы елларында гына да алар тарафыннан 20 ләп исемдәге әлифба, 70 ләп исемдәге уку китабы, 20 ләп исемдәге география, 50 гә якын исемдә тарих һәм башка дәреслекләр төзелә[2]. Октябрь революциясеннән соң бу эшне М. Корбангалиев, М. Фазлуллин, Р. Газизов, Г. Сәйфуллиннар уңышлы төстә дәвам итәләр.

Казан татар укытучылар мәктәбе укытучылары һәм аны тәмамлаучылар рус классиклары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эшен башлап һәм көчәйтеп җибәрүчеләр булалар. Укытучы Таип Яхин 1897 елда «Сабый вә сабыялар өчен кызыклы булган хикәяләр вә мәкальләр», 1902 елда «Малайлар вә кызлардан ялкаулыкны җибәрү» исемле китапларын бастыра. Бу китапларның беренчесе нигездә И. Крыловның проза белән тәрҗемә ителгән мәсәлләреннән тора. Икенче китабына Т. Яхин А. Н. Афанасьевның 1855—1858 еллар арасында басылган «Народные русские сказки» исемле җыентыгыннан аерым үрнәкләр, А. С. Пушкинның «Балыкчы һәм балык турында әкият»ен тәрҗемә итеп урнаштыра. И. А. Крылов мәсәлләре бу җыентыкта да шактый зур урын алып тора.

---

[1] СССРның Ленинградтагы ҮДТА, 733 фонд, I тасвирлама, 898 эш, I бүлек, 62—64 битләр; 171 тасвирлама, 656 эш, I бүлек, 85 бит.

[2] Я. Коблов. Конфессиональные школы казанских татар. Рус телендә, Казан, 1916 ел, 105 бит.

1902—1905 елларда укытучы Ибраһим Терегулов А. С. Пушкинның «Капитанская дочка» һәм Н. В. Гогольнең «Старосветские помещики» повестьларын, «Ревизор», «Женитьба» комедияләрен тәрҗемә итеп чыгара. Шулай ук Европа һәм Америка әдәбиятыннан да кайбер тәрҗемә үрнәкләре күренә башлый. С. Сүнчәләй Һейненең «Әльмансур» трагедиясен, Байронның «Шильон тоткыны» поэмасын, Г. Алпаров, М. Ибраһимов белән берлектә, Г. Бичер-Стоуның «Том агай алачыгы» романын тәрҗемә итә. (Соңгы әсәр «Бичара колның тормышы» исеме белән басыла.)



Укытучылар мәктәбендә тәрбияләнгән яшьләр татар театры оештыруда, аның эшен юлга салуда үзләреннән зур өлеш кертәләр. 1904 елда мәктәпне тәмамлаган Ильяс Кудашев (Ашказарский), мәсәлән, профессиональ татар театрын оештыручыларның берсе санала. Ул оештырган труппада бу мәктәпнең тагын берничә кешесе була. Укытучылар мәктәбендә тәрбия алып чыгучылар, сәхнәдә уйнау белән беррәттән, театр сәхнәсе өчен репертуар булдыру өстендә дә актив эшлиләр. Күренекле артист Г. Мангушевның «Килен», «Бәхет эзләүчеләр», «Мөхәррир» комедияләре, И. Казаковның «Казанга сәяхәт»е, С. Сүнчәләйнең «Мансур» драмалары заманында күп сәхнәләрдә уйнала. Татар пролетар әдәбиятына нигез салучы революционер язучы Гафур Коләхметов та күбрәк сәхнә өчен иҗат итә. Ул «Ике фикер» һәм «Яшь гомер» драмалары белән татар сәхнәсенә социализм идеяләре, эшче образлары алып килә.

Мисаллардан күренгәнчә, укытучылар мәктәбендә уку татар егетләренә демократик традицияләргә бай рус культурасын үзләштерергә, алдынгы рус культурасы үрнәгендә татар культурасының күп тармакларын үстереп җибәрергә ярдәм иткән. Иң әһәмиятлесе шунда, рус телен яхшы үзләштерү аларга рус пролетариатының алдынгы отряды белән якынаерга, марксизм-ленинизм идеяләрен үзләштерергә, башка халыклар белән кулга-кул тотынып, шул идеяләр өчен актив көрәш алып барырга мөмкинлек биргән.

Билгеле булганча, татарлар арасында беренче социал-демократик оешма 1904 елда Казан татар укытучылар мәктәбендә төзелә. Октябрь революциясеннән соң беренче татар комсомол ячейкасы да шушында оештырыла. Болар һәммәсе мәктәпнең даими рәвештә большевиклар тәэсире астында булуын күрсәтә. Казан социал-демократлар оешмасы бу мәктәпне татарлар арасында революцион эшне көчәйтергә иң кулай урын дип санаган. Нәтиҗәдә татар иҗтимагый хәрәкәте тарихында, татар хезмәт ияләренең революцион хәрәкәтенә социалистик аң кертүдә җитди роль уйнаган большевиклар, пролетар интернационализм рухы белән сугарылган җәмәгать эшлеклеләре Казан татар укытучылар мәктәбендә тәрбияләнә.

1903 елның январеннан башлап революцион прокламацияләр, марксистик әдәбиятны татарчага тәрҗемә итү, бастыру һәм тарату, татар эшчеләре арасында беренче социал-демократик түгәрәкләр оештыру, татарча беренче большевистик «Урал» газетасы чыгару, массаларның политик көрәшенә җитәкчелек итү, пролетар әдәбиятка нигез салу кебек данлы тарих сәхифәләре Казан татар укытучылар мәктәбендә укыган Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов, Гафур Коләхметов исемнәре белән бәйле. Шулай ук халык бәхете өчен революцион көрәштә үзләрен аямыйча катнашкан Борһанетдин һәм Морат Юскаевлар, Исхак Казаков, Гыйлемдар Баймбетов, Габделкаюм Коләхметовлар — укытучылар мәктәбе укучылары [1].

Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаучыларның иң зур күпчелеге Бөек Октябрь социалистик революциясен хезмәт ияләре белән берлектә алдынгы сафларда каршылый, илдә совет властен урнаштыру һәм саклап калу өчен көрәштә фидакарьлек үрнәкләре күрсәтә. Акгвардиячеләргә, соңрак басмачыларга каршы көрәшләрдә күрсәткән батырлыклары өчен укытучылар мәктәбендә белем алган Хөсәен Мәүлетов һәм Якуб Чанышев татарлардан беренче булып Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнәләр.

Октябрь революциясеннән соң Исхак Казаков, Насыйх Мөхетдинов, Мөхетдин Корбангалиев, Хатип Мөхетдинов, Мөхәмметхан Фазлуллин, Риза Газизов, Габбас Сәйфуллин һәм башкалар партия, совет оешмаларында эшлиләр, турыдан-туры мәк-

---

[1] Аларның революцион эшчәнлеге Р. Н. Нәфиковның «Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли» (Казан, 1964) исемле китабында тулы яктыртыла.

гәпләр эшен үзгәртеп кору белән җитәкчелек итәләр, татар совет мәктәпләре өчен программалар һәм яңа дәреслекләр төзиләр. Казан укытучылар мәктәбеннән чыккан кешеләрдән Мөхетдин Корбангалиев, Мөхәммәтхан Фазлуллин, Гыйбад Алпаров, Фатыйх Мөхәммәдъяров, Гыйлем Камай, Насрулла Вәселевлар, профессорлык дәрәҗәсенә ирешеп, совет фәнен үстерүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Алда китерелгән фактлар Казан татар укытучылар мәктәбенең татар халкының алдынгы иҗтимагый-политик фикере формалашуда һәм татар культурасын үстерүдә күренекле роль уйнавын күрсәтә. Татарстанда культура һәм мәгариф үсеше тарихында бу мәктәп күренекле урыннарның берсен алып тора.

**Х. ХӘКИМОВ,**
**педагогия фәннәре кандидаты.**
**З. ШӘРӘФЕТДИНОВ,**
**пединститут аспиранты.**

# ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ

*Хәлил Әбҗәлиловның тууына 80 ел*

Гомеренең соңгы елында СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов болай дип язды:

«Үземнең үткән юлыма әйләнеп карaганда, мин бөтен җаваплылык белән хәзер шуны әйтә алам: юк, шома һәм ансат юл түгел иде ул. Анда эзләнүләр, уңышсызлыклар һәм уңышлар да булды. Һәм кайсы да булса бер актер үз гомерендә бер генә тапкыр да уңышсызлыкка очрамадым дип әйтә икән, — ышанмагыз аңа. Бу дөрес түгел». Бу сүзләрдә бөтен сәхнә гомерен киеренке хезмәттә үткәргән Х. Әбҗәлиловның тынгы белмәс характеры ярылып ята. Хәлил ага, татар театрының бөтен тарихын күздә тотып әйткәндә дә, иң үзенчәлекле, кабатланмас актерларның берсе иде. Аның кайнар темпераменты, үткен һәм аек акылы ул тудырган образларда һаман да яши. Образлары исә бик күп төрле, һәрберсе үзгә, кабатланмас билгеләре белән аерылып торалар. Актер беркайчан да үз-үзен кабатламаска тырышты. Һәр яңа роль аның өчен күп сораулары билгесез булган катлаулы мәсьәлә иде. Роль өстендә эшләү процессы ничек кенә газаплы булмасын, ул һичкайчан кем дә булса башка берәүнең табышын файдаланырга теләмәде. Шул ук вакытта Х. Әбҗәлилов үз коллегаларының иҗатларын өйрәнүне мөһим бурыч итеп саный. Король Лир образы өстендә эшләгәндә ул исемнәре дөньяга билгеле дистәләрчә актерның бу рольне ничек уйнаулары турында язылган материалларны укый.

Хәлил Әбҗәлилов чатнап торган реализм мәктәбе художнигы булып формалаша. Модага иярү, ультра яңа алымнар белән тамашачыны шаккатыруны ул яратмый, артист-реалист иҗаты өчен вакытлы мавыгулар ят нәрсә иде. Ләкин ул консерватизмнан да ерак тора. Сәнгать күренешләрен ул тормыш хакыйкате белән үлчи һәм бәяли. Станиславский системасы үз вакытында аны таңга калдырган ачыш була. Әбҗәлилов — гәүдәләндерү осталыгының нечкәлекләренә ия булган актер. Кайбер актерлар гумоз ярдәмендә йөз-кыяфәтләрен танымаслык дәрәҗәдә үзгәртә алалар. Моның ише «битлек кию»не, әлбәттә, гәүдәләндерү дип аңларга ярамый. Андый «иҗат» актерның тәҗрибәсезлеген яисә сәләтенең чамалы булуын гына күрсәтә. Әбҗәлилов исә андый алымнарга кызыкмый. Ул эчтән үзгәрә һәм бу үзгәреш аның күзләрендә чагыла. Алар әле Хуҗа Насретдиннең шаян хәйләкәрлеген чәчеп ялтырыйлар, әле «Банкрот»тагы Сираҗетдиннең комсыз нәфес уты белән яналар, яисә Тихонның («Яшенле яңгыр») кашлары астыннан боегып карыйлар. Әбҗәлиловка үз героеның хис-кичерешләрен аңлату өчен сүзләр кирәк түгел, ул хакта аның күзләре сөйли. Эчке кичереш, психологиянең хаклыгы актерны бөтенләй икенче кеше итә, аның хәрәкәт ритмын, сүз сөрешен билгели. Персонажның рухына, хисләр дөньясына шул дәрәҗәдә тирән үтеп керүе Әбҗәлилов образларын кабатланмый торган итә. Аныңча уйнау, аның уен рәвешен күчереп алу авыр, хәтта мөмкин булмаган эш. Һәм кайчан да булса аңа ияреп, аңа охшатып уйнарга тырышкан кешеләр уңышсызлыкка очрый-



лар, зур художникның тонык копиясе булып кына калалар.

Әбҗәлилов тамашачы алдында характерның чыныгу-ныгу, усү яисә таркалу-деградация процессын күз алдына бастыра. Аның геройларының күбесе, актерның үзе кебек ук, югары интеллектка ия булган, сизгер күңелле, гаять кешелекле кешеләр. Кешеләр бәхете өчен янып, башкалар кайгысын кайгыртып, алар гаять зур газапларга, хәтта һәлакәткә дучар булалар.

Әбҗәлилов башкарган рольләрнең саны өч йөздән артып китә. Әлбәттә, аларның барысы да ачыш дәрәҗәсендә түгел иде. Рольләре арасында хәтта очраклы һәм күренексез булганнарын да табарга мөмкин. Иҗат юлына яңарак аяк баскан чорда актерга уйналган әсәрләрнең драматургик яктан кимчелекләрен санап, сайланып торырга туры килми. Танылган актер булгач та әле кызыксыз һәм йомшак эшләнгән рольләрдән арынып бетүе ансат эш түгел. Иҗат галереясендә сәнгать хәзинәсен баетырлык бер яки ике дистә образны саный алабыз икән, без андый актерны зур художник итеп таныйбыз. Хәлил Әбҗәлилов та нәкъ шундый актер. Сәнгатьтә ул тапталган сукмаклардан түгел, ә үз юлын ярып барды. Һәр яңа рольгә ул зур дулкынлану белән керешә, һәрберсен үзе тапкан төсбуяулар белән баетырга тырыша иде.

Ул театрда нинди дә булса яңа мәктәп тудырмады, үз алдына андый максатны куймады да. Барлык талантын һәм тормышын ул реалистик татар театрын ныгытуга һәм үстерүгә, андагы яшь көчләрне тәрбияләүгә багышлады. Татар академия театрында бүген аның күп санлы шәкертләре иҗат итә.

Хәлил Әбҗәлилов татар театрының демократик традицияләрен үстерүгә үзеннән гаять зур өлеш кертте. Шуңа күрә аның иҗаты һәр чак заманча яңгырый. Әбҗәлилов үз халкын яхшы белә, халкы белән горурлана һәм аның рухи байлыгын арттыру өчен армый-талмый эшли белә иде. Милли драматургиядә ул үзенең таланты чәчәк атарлык иҗат җирлеге таба. Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт һ. б. драматургларның әсәрләрендә ул халкыбызның уй-хыялларын, теләк-омтылышларын, аның рухын чагылдырган бай материал күрә, шул нигездә аның иҗаты ныгып канат җәя. Әнә шуңа күрә дә халыкның милли характеры аның иҗатында ифрат нечкә һәм төгәл гәүдәләнә.

Шул ук вакытта Хәлил Әбҗәлиловның иҗат мирасы тирән интернациональ сыйфатларга ия. Милли репертуарны ул гомум-кешелек идеяләре белән сугара белде. Киң колачлы художник буларак, Шекспир, Лопе де Вега, Шиллер, Островский, Горький кебек чит ил һәм рус классиклары әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә дә югары иҗат үрнәкләре калдырды. Сәхнәдә ул тудырган кабатланмас һәм онытылмас Хуҗа Насретдин, Биктимер («Ташкыннар»), Сиражетдин, Король Лир, Тихон, дивизион командиры Харитонов («Диңгездәгеләр өчен»), профессор Мамлок, Захар Бардин татар совет театр сәнгатенең зур казанышы булып әверелде.

Әбҗәлилов гомеренең ахыргы көннәренә кадәр сәхнәдән төшмәде. Үләренә бер атна кала, ул Горькийның «Дошманнар» әсәре буенча куелган яңа спектакльдә Захар Бардин ролен башкара. Киләчәк алдында өркеп, җаны калтырап торган капиталист образын актер зур осталык белән ачып сала.

СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов ярты гасырга якын иҗат юлы үтте. Образлары белән ул тамашачыга тормыш хакыйкатен, иске буржуаз җәмгыятьнең череп таркала баруын, якты киләчәкнең тантана итүе өчен көрәшүче совет кешесенең гүзәллеген күрсәтте.

**Х. КУМЫСНИКОВ.**

# ИР ЯЗМЫШЫ

*Идрис Туктарга 80 яшь*



Гаҗәп бу табигать дөньясы. Әнә кара таш. Гасырлар буе ятып мүкләнеп беткән. Шуның кырыннан зәңгәр чәчәк үсеп чыккан. Урыны да гөл бакчасы түгел, тамыр җибәрер җире сары ком да кызыл балчык. Ә ул, бернигә карамый, сабак арты сабак чыгара, чәчәк арты чәчәк ата.

Әрсез язмыш иляәре дә шулай. Ярлы крестьян гаиләсендә туган Идрисне дә башыннан сыйпап кына үстермиләр. Ун яшеннән аңа да тормыш арбасына җигелергә туры килә. Гасырлар буе мүкләнеп яткан кара таш кебек авыр дөньяның шыксыз җилләре аны да яшьләй сыгылдыра, таптап, изеп китәр чаклары да аз булмый. Әмма егет сынмый, яшәргә тырышу, үзе кебек ярлы-ябагайга терәк булып яшәргә тырышу аңа көч бирә.

Озын бер гомер юлын үткән кешеләр инде 80 яшен тутырган Идрис ага Туктарның биографиясенә күз салсалар әйтерләр иде: бу бит безнең дә тормыш юлыбыз, безнең дә язмышыбыз. Каһәрле дөньяның салкын зинданнарында без дә газап чиктек, без дә революция ялкыннарында яндык, бишьеллыкларның беренче гигантларын, беренче колхозларны оештыручылар алар — без дә идек.

Әйе, алар барысы да бер чор кешеләре, тезләнеп рәхмәт әйтерлек эшләр эшләп калдырган буын вәкилләре. Яшәгән җирләре, эшләгән эшләре генә төрле-төрле. Мәгънәләре бер үк. Идрис ага Туктаров дөньяда яшәүнең шушы бөек мәгънәсен үзенең күп санлы хикәяләрендә күрсәтеп бирергә омтылды. Аның «Ике егет» романында гыйбрәтле шундый сүзләр бар: «Өләшкән саен арта барган байлыкка, кизәнгән саен ныгый барган көчкә, яшәгән саен үсә барган шатлыкка лаеклы булыр өчен юллардан озын юллар гизүдән, ачыдан-ачы кайгы-хәсрәтләр татудан, карадан-кара төннәр үткәрүдән зәррә кадәр генә дә курыкмаска кирәк».

Патша тәхетен яклап сугышуның никадәр мәгънәсез эш икәнен аңлаган һәм коралын ташлап приискага кайткан Шәйхи солдат сөйләгән әкият героеның сүзләре ул. Ә солдат әкият сөйләп кенә калмый, соңыннан, китапханәче булып эшләгән елларында, Колчак бандасына каршы агитаторга әйләнә, шуның аркасында дошманның үлем эшелонына эләгә. Бары тик партизаннар һөҗүме аркасында гына азатлыкка чыгып, яшь совет иле өчен көрәшен дәвам итә.

Язучы һәр әсәрендә үз тормышының бер генә кисәген булса да чагылдырмый калмый дигән караш бар. Идрис аганың иҗатында аның биографиясеннән кергән моментлар аз түгел. Гражданнар сугышында башыннан кичкәннәрне исә ул, тулысы белән дип әйтерлек, «Ике егет» романында сурәтли.

Идрис ага Туктаров яшь вакытын эшчеләр арасында, алтын приискаларында, күмер шахталарында эшләп үткәрә. Аның беренче әсәрләре дә алар тормышыннан. 1932 елда ук басылып чыккан «81 нче штольня» дигән китабында ул авыр көннәрен уен-көлке, җор сүзләр белән җиңеләйтеп яшәгән эшчеләр тормышын күрсәтә.

Үткен сүз, җорлык, ягымлы юмор Идрис Туктарның иҗатына гомумән хас. Соңгы елларда ул афоризмнар рәтендә йөрерлек үткен-үткен «Җөмләләр» иҗат итә.

— Тауга карап тау булып булмаса да, кешегә карап кеше булып була.

— Мин дип басым ясадыңмы, басылдың да калдың.

— Ялкауга кашык кына җиңел.

— Алга бармаган да тик тормый, артка чигенә.

Күп санлы «Җөмләләр»нең бирегә китерелгәннәреннән дә аларның никадәр үткен, тыгыз мәгънәле, матур яңгырашлы сәнгатьчә әйтемнәр икәнен күрергә мөмкин.

Шушы тапкырлык авторга, акыл сатмыйча гына, балаларга тормыш сабагын өйрәтергә ярдәм итә. Ул балаларның, бигрәк тә кече яшьтәгеләрнең озак-озак сөйләп торганны яратмауларын, күңелсез нәсихәтләрне сөймәүләрен яхшы аңлый. Балалар өчен язылган һәр хикәясе аның кыска һәм кызык булыр. Аларда я бик тиз ышанучан, ярдәмчел, йомшак күңелле, я ялкау, хәйләкәр, куркак малайларның һәм кызларның сөйкемле образларын тудыра. Шул ук вакытта әсәрләреннән авторның үз образын сиземләве дә бик җиңел. Гүя каршыңда ак сакаллы, көләч йөзле, балалар шикелле бераз гына хәйләкәр дә, алар кебек уенчак та, ләкин бик акыллы, дөньяны күп күргән ил карты утыра. Әнә шулай итеп Идрис ага әсәрләренә үз тормыш юлын гына түгел, үз холкын, характерын да сала.

Язучылар союзыннан читтә яши ул. Гомеренең кырык елдан артыгын Казан артындагы Зеленодольск дигән агачка-гөлгә күмелгән матур шәһәрдә үткәрә. Җыелышлар булса, йомышы төшсә, я дусларын-яшьтәшләрен күрәсе килсә, Казанга килеп чыга. Күрешергә кул сузуы ук уен-көлкедән башлана:

Син сагынганны белмәдем,
Үзем сагынып килдем мин,

— ди дә калын тавышы белән гөрелдәтеп көлеп куя.

Бәхетле кеше ул Идрис ага. Таш астыннан калыккан үлән кебек дөньяның авырлыгын татып үскәнгә, туган иленә иң хәтәр минутлар килгәндә, гражданнар сугышында да, Бөек Ватан сугышында да дошманнарга каршы гомерен аямый сугышканга көннәренең тәмен, рәхәтен белеп яши. Эшли-эшли укып алган белемен дә, тормыш сабагын да бөтене белән яшьләргә тапшырып калдырырга тырыша.

**Л. ИХСАНОВА.**

# ЗАМАНАСЫ ШУНДЫЙ

*Габдрахман Минскийга 70 яшь*

Ул үзен яшьләрчә хис итә: һаман җитез, дәртле, тынгысыз. Кайчан күрсәң дә — йөзе көләч, карашы җылы булыр. Картлыкны белмәс, яшьлектән аерылмас бу кеше, карасаң, җиде дистәне тутырырга да өлгергән икән.

...Әстерхан шәһәре бистәләренең берсендә үскән малай мәктәптә укыган елларында ук инде Александр Пушкин шигырьләрен, Габдулла Тукай әкиятләрен яттан белә, Максим Горький һәм Фатих Әмирхан пьесаларының геройлары белән таныша. Яшүсмер күңелен иҗатка шулар җилкеткәндер, кулга каләм алып, аны тибрәтеп карарга рухландыргандыр, илһам биргәндер, әлбәттә. Туган бистәсе клубында үндүрт яшьлек Габдрахманның беренче пьесасы — «Наданлык» — 1920 елда сәхнәгә куела.

1926 елда Минский Казанга килә. Монда — һади Такташ, монда — Гадел Кутуй... Монда — иҗади мохит, яшь талантларның илһам чишмәсе. һәм шул егет, ике елдан, нәкъ менә үзен бөтереп алган өермәдәй көннәр турында «Заманасы шундый» дигән беренче китабын чыгара. Шул ук вакытта Татар дәүләт театры сәхнәсендә аның «Мансуровлар гаиләсе» дигән пьесасы да уйнала...

Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәндә Габдрахман Минский «Шлем» дигән пьеса яза. Ул еллар өчен актуаль темага багышланган бу әсәр шулай ук Татар дәүләт театры сәхнәсенә күтәрелә.

Ул еллар — искелек белән яңалык арасында кискен көрәш барган чор. Такташның Мохтар карты ике «мин» булып яшәгән вакытлар, Габдрахман Минский әсәрләрендә дә шушы каршылыклар чагыла, яңа кеше тәрбияләү өчен барган көрәшнең кайнар сулышы сизелеп тора.

Әдип кичергән еллар дәвамында заман авазы өзлексез яңгырады — күп тапкырлар герөик хезмәт фронтына да, туплар гөрселдәгән сугыш кырларына да чакырды ул. Ул аваз кая әйдәсә — язучы һәм журналист, гражданин һәм солдат Габдрахман Минский шул якка атлады.

Утызынчы еллар. Чиләбедә трактор заводы салына башлый. Беренче бишьеллыкның зур төзелешенә Татарстаннан бик күп энтузиастлар китә. Анда «Төзү ударнигы»

дигән газета чыгарыла. Габдрахман Минский — шул газета редакциясенең җаваплы секретаре. Ул совет кешеләренең фидакарь хезмәте, илне индустрияләштерү өчен барган көрәштәге батырлыгы турында яза, завод төзүчеләрнең тарихи эшләрен җанлы эпизодларда, публицистика алымнары белән сурәтли.



Әдәбиятта замандашлар образын сәнгатьчә иҗат итү серләрен тагын да киңрәк һәм тирәнрәк үзләштерергә омтылыш әдипне Мәскәүгә — Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтына китерә. Биредә Габдрахман Минский сценарий факультетын тәмамлый. Эшкә Баку киностудиясенә җибәрәләр. Шул елларда экранга «Артем атавы», Әзербайҗан нефтьчеләренә багышланган «Яңа тормыш үзәне» дигән документаль картиналар чыга. Сугышның беренче айларында «Ватан улы» исемле нәфис фильм эшләнә. Бу тасмаларның сценарий авторын күрсәткән титрларында Габдрахман Минский фамилиясе язылган.

Сугыш елларында Габдрахман Минский яу кырларында булды, контузияләнеп, госпитальләр һавасын да сулады. Солдат язмышы аны кайларда гына йөртмәсен, нинди генә хәлләрдә калдырмасын — язучы кулыннан каләмен ташламады. Көннәре шундый иде — иң оператив, иң сугышчан жанрларда язуны таләп итте. Совет кешеләренең сугышта күрсәткән батырлыгы турында язды солдат әдип.

1952 елда Габдрахман Минский яңадан Казанга кайта. Иҗатка, җәмәгать эшләренә чума. Бу өлкәдә аны активлыкка, тынгысызлыкка әйдәп торучы үрнәкләр бар: кайчандыр Галимҗан Ибраһимов аңа җылы киңәшләрен әйткән, Һади Такташ һәм Гадел Кутуйларның ялкынланып йөрүләре күңел түрендә...

Кайсы гына жанрда язмасын, нинди генә җәмәгать эше башкармасын — Габдрахман Минский заман рухын тирән тоеп иҗат итә. Язучы йөрәге партия сүзенә, халык тормышына сизгер. Ул яшәү матурлыгына, кешеләргә, табигатькә соклана. Бу тойгы аның хикәяләренә, алардагы образларга күчә. Күңелләре шундый җылы хискә бай булган геройлар аз түгел аның әсәрләрендә. «Карт имән» хикәясендәге Мохтар картны искә төшерик, «Ана мәхәббәте»ндәге ана образын хәтерлик, «Язның беренче көне»ндәге Әминәне күз алдына китерик. Аларның һәркайсы — үзенчә игелекле, кешелекле, олы җанлы, саф йөрәкле. Әминә, мәсәлән, үзе эшкә килгән Ташлытау авылында яшәүче кешеләрдә якты хисләр, уңай сыйфатлар тәрбияләү өчен көрәшә. Бу — язучының гражданлык активлыгы. Уңай герой образы аша ул гади, көндәлек хәлләрнең этик мәгънәсен, эстетик әһәмиятен ачарга омтыла. Коммунист әдип тормышның якты якларын күбрәк күрергә, туган илнең бөеклеген яхшырак аңларга, табигать хәзинәләрен сакларга, ышәйтергә чакыра.

Аның тормыштагы вакыйгаларга, чынбарлыкка, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә пролетар интернационализм биеклегеннән карый белүе — заман сулышын дөрес сиземләү өчен бик кирәкле сыйфат. Бу җәһәттән язучының «Яшенле яңгыр» исемле тарихи-революцион повесте аеруча характерлы. Әсәрдә Әстерхан шәһәрендә булган революцион вакыйгалар, аларда катнашкан төрле милләт вәкилләренең образлары сурәтләнә. Андрей, Катыйм, Хәйдәр, Петя һ. б. — барысы да уртак бер максат өчен — пролетариатның азатлыгы хакына көрәшәләр. Халыклар дуслыгы темасы биредә, тарихи чынбарлыктагыча, революцион ситуацияләрдә катнашучы хезмәт ияләренең изүчеләргә каршы бердәм көрәшен чагылдырган вакыйгаларда ачыла.

Габдрахман Минский тугандаш әдәбиятлар арасында иҗади элементләрне ныгыту юнәлешендә дә әһәмиятле хезмәтләр башкарган әдипләребездән берсе. Әзербайҗанның күренекле язучысы Җаббар Җаббарлының «Айдын», Мәһди Хөсәеннең «Апшерон» романын татар укучылары аның тәрҗемәсендә укыйлар.

**А. СӘЛӘХЕТДИНОВ.**

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ

21—25 июньдә Кремльнең Зур Сараенда СССР Язучылар союзының VI съезды булып үтте. Бу съездда, беренче тапкыр буларак, әдәбиятның төрле проблемалары турында зур җитди сөйләшү алып барган ун комиссия эшләде. Татарстан делегатларыннан Гариф Ахунов җитәкчесе В. М. Кожевников булган, «Шәһәр һәм авылларагы эшче сыйныфы темасының матур әдәбиятта чагылышы һәм фәнни-техник прогресс проблемалары» дигән мәсьәләне тикшерүче комиссиядә катнашты һәм чыгыш ясады. «Коммунистик шәхеснең формалашуы һәм тормышта, әдәбиятта социаль-әхлак проблемалары» (җитәкчесе В. М. Озеров) комиссиясендә Сибгат Хәким, «Туганлаш әдәбиятларның үзара бәйләнешы һәм әдәби тәрҗемә проблемалары» (җитәкчесе Н. П. Бажан) комиссиясендә Фатих Хөсни, Рафаэль Мостафин, Равил Фәйзуллин һәм Туфан Миңнуллин, «Язучы — китап — укучы» дигән комиссиядә (җитәкчесе С. В. Сартаков) Атилла Расих һәм Геннадий Паушкин, «Яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү, урта мәктәп һәм ПТУ эшчәнлегендә матур әдәбиятның роле» дигән комиссиядә (җитәкчесе С. Михалков) Зәки Нури, Ләбибә Ихсановалар катнашты.

Бу комиссияләрдә сөйләнгән кайбер доклад һәм чыгышларда татар әдәбияты турында да сүз булып, аерым әсәрләргә уңай бәя бирелеп үтелде.

* * *

Съездда яңа идарә составына Гариф Ахунов һәм Зәки Нури сайланды.

* * *

СССР Язучылар союзының I съездында, Максим Горький тәкъдиме белән, делегатларның башкала хезмәт ияләре белән очрашулары уздырылган иде. Бу традиция өзлексез дәвам итә. Язучыларның VI съездыннан соң да делегатлар, бернечә төркемгә бүленеп, әдәби кичәләр үткәрделәр. М. Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркының Яшел театрында уздырылган шундый кичәдә шагыйрь Зәки Нури катнашты.

## ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ

Азия һәм Африка халыклары бердәмлегенең Совет комитеты оештырылуга 20 ел тулуга багышлап, Баку шәһәрендә комитетның IV конференциясе уздырылды.

Татарстаннан философия фәннәре докторы Камил Фасеев һәм шагыйрь Илдар Юзеев шушы конференциядә катнаштылар.

Бөтенсоюз комитетының яңа составына республикабыздан филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин, философия фәннәре докторы Камил Фасеев, Җәлил премиясе лауреатлары Илдар Юзеев һәм Мирсәет Яруллин сайланды.

## НЕМЕЦ ЯЗУЧЫСЫ КАЗАНДА

Муса Җәлил иҗатын өйрәнүче, аны тәрҗемә итүче, «Проблема мира и социализма» журналының баш редакторы, немец язучысы Леон Небенцаль Казанда булды. Ул Татарстан Язучылар союзында Муса Җәлилнең каләмдәш дуслары Шәйхи Маннур, Әхмәт Исхак, Муса Җәлилнең сугышчан тормышын, иҗатын өйрәнүче Рафаэль Мостафин, Язучылар союзы председателе Гариф Ахунов, союзның җаваплы секретаре Равил Фәйзуллиннар белән очрашты. Әдипләр, кунак белән бергә, яшь җәлилчеләр-пионерлар янында булдылар. Җәлил һәйкәленә чәчәкләр куелды.

## ЯШЬЛӘР КИҢӘШӘ

25—30 май көннәрендә Казанның халыкара «Волга» лагеренда республикабыз иҗади яшьләренең семинары узды. Анда яшь язучылар, рәссамнар, артистлар, архитекторлар, музыкантлар һәм композиторлар очрашып, бүгенге әдәбият һәм сәнгать турында сөйләштеләр, зур хәзерлек белән үткәрелгән лекция-консультацияләр тыңладылар. Көн тәртибендә кайбер яшьләрнең хезмәтләре турында фикер алышулар булды. Мәсәлән, яшь язучылардан Азат Ганиев (Әлмәт), Камил Кәримов (Казан), Рәшит Хәйретдинов, Нурулла Габдуллиннарның (Чаллы) әсәрләре тикшерелде. Фикер алышуларда шагыйрьләрдән Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов, прозаиклардан Аяз Гыйләҗев катнашты.

## АЛЬМАНАХ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Язучылар союзы идарәсендә яшьләр өчен чыга торган «Идел» альманахының бүгенге хәле, алдагы саннары һәм киләчәктәге перспективасы турында зур сөйләшү булды. Анда Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Зәки Нури, Әхсән Баянов,

Аяз Гыйләҗев, Шамил Рәкыйпов, Илдар Юзеев, Фарваз Миңнуллин, Мәдинә Маликовалар чыгыш ясап, альманахның яшьләребезгә рухи тәрбия бирү буенча зур эш алып баруын билгеләп үттеләр. Республикада яшь иҗат көчләренең талантлы һәм күп санлы отряды эшләвен, елга бер чыга торган бу альманахның аларга мәйдан биреп бетерә алмавын, шуңа күрә аны ешрак чыгарырга кирәклеген әйттеләр.

Идарәнең бу утырышында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетыннан С. Шәймәрданова, Р. Закиров, Художниклар союзыннан Р. Имашев һәм Ш. Әхмәдиевләр дә катнашты.

## ИҖАТ КӨЧЛӘРЕ СЕМИНАРЫНДА

Партиянең Татарстан өлкә комитеты каршында оештырылган иҗат хезмәткәрләре семинары быелгы соңгы утырышын нефть районнарында тәмамлады. Язучылар, композиторлар, художниклар һәм артистларның зур бер төркеме Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә шәһәрләрендә партия һәм совет җитәкчеләре, нефть промышленносте белгечләре, фәнни-тикшерену институты хезмәткәрләре белән очраштылар, буровойларда, Лениногорск шәһәрендәге нефть музеенда, Г. Тукай исемендәге шәһәр китапханәсендә булдылар. Әлмәт шәһәрендә һәм Лениногорск районының Зәй-Каратай авылында зур әдәби-музыкаль кичә үткәрделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Тәнкыйть һәм драматурглар секцияләре, ВТОның Татарстан бүлеге каршындагы театр тәнкыйте секциясенең берләштерелгән утырышы булды. Анда «Татар драматургиясендә һәм театрларда трагедия жанры» дигән темага Һәнүз Мәхмүтов доклад сөйләде. Фикер алышуларда Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Габдрахман Минский, Хәсән Хәйри, Баян Гыйззәт, Флүн Мусин, Диас Вәлиев, Ильтани Илялова һ. б. катнашты.

* * *

Тәнкыйть секциясенең чираттагы утырышында тәнкыйтьче Илдус Ахунҗановның иҗаты тикшерелде. Рафаэль Мостафин үзенең докладында аның иҗатына тирән анализ ясады. Фикер алышуларда Ибраһим Нуруллин, Зәет Мәҗитов, Мәҗит Рәфыйков, Диас Вәлиев, Флүн Мусин, Фарваз Миңнуллин һ. б. катнашты.

* * *

Тәнкыйть һәм проза секцияләренең берләштерелгән утырышында «Хәзерге татар әдәбиятында эшче образы» дигән темага Фәрит Хатипов доклады тыңланды. Фатих Хөсни, Флүн Мусин, Әмирхан Еники, Хәсән Сарьян, Мөсәгыйть Хәбибуллин һ. б. язучылар фикер алышуларда катнашты.

* * *

Балалар әдәбияты секциясендә Роза Хәлиуллинаның нәниләр өчен язган поэмасы тикшерелде. Шәүкәт Галиев, Шамил Рәкыйпов, Гариф Гобәй, Гарәфи Хәсәнов, Ләбибә Ихсанова, Нур Гайсин, Марсель Галиев, Зәкия Туфайлова шагыйрәгә күп кенә файдалы киңәшләр әйттеләр.

## ӘДИПЛӘРЕБЕЗ ТУГАНДАШ РЕСПУБЛИКАЛАРДА

СССР Язучылар союзының VI съезды ачылыр алдыннан татар язучылары тугандаш республикаларда булып узган әдәби съездларда, әдәби атналыкларда, иҗат бәйрәмнәрендә катнаштылар. Алар анда чыгышлар ясап, татар әдәбияты ирешкән уңышлар һәм тугандаш әдәбиятлар белән бәйләнешләр турында сөйләделәр. Гариф Ахунов Таҗикстан Язучылар союзы съездында, Мөхәммәт Мәһдиев Белоруссия язучылары съездында, Равил Фәйзуллин Алма-Атада казакъ язучылары съездында, Әхсән Баянов Төркмәнстан һәм Габдрахман Минский Кара-Калпак Язучылар союзы съездларында катнаштылар, шул республикалардагы күп санлы укучылар белән очраштылар.

* * *

Июнь башы зур әдәби бәйрәм — Пушкин көннәре белән билгеле. А. С. Пушкин көннәре менә ничәнче ел инде Горький өлкәсенең Большое Болдино район үзәгендә дә үткәрелә. Анда илебезнең барлык өлкәләреннән әдәбият вәкилләре килә. Бу елгы тантанада Татарстан әдипләре исеменнән Ринат Харисов катнашып, партия, Ватан, халыклар дуслыгы темасына язылган шигырьләрен укыды.

* * *

РСФСР Язучылар союзы идарәсе партиянең 25 съездына багышлап Краснодар өлкәсендә иҗади бәйрәм уздырды. Анда Украина, Белоруссия, Үзбәкстан республикаларыннан, Мәскәүдән һәм Ленинградтан, Ярославль, Омск, Иваново, Вологда, Казан шәһәрләреннән кырыклап әдип катнашты. Уңдырышлы Кубань җирләрендә уздырылган әдәбият көннәрендә шулай ук ГДР, МНР, Польша, Чехословакия, Румыния, Югославиядән чакырылган кунаклар да катнашты. Бу бәйрәмгә Татарстан язучыларыннан вәкил булып Зәки Нури барды.

* * *

Мәскәүнең Некрасов исемендәге китапханәсенең Сокольникидагы СССР халыклары әдәбиятлары бүлегендә Г. Тукайның тууына 90 ел тулу уңае белән поэзия кичәсе үткәрелде. Кичәдә Казаннан барган шагыйрьләр Илдар Юзеев, Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт, драматург Туфан Миңнуллин, Мәскәүдә яшәүче прозаик Миргазыян Юныс катнашып, Тукайга багышланган әсәрләрен укыдылар.

* * *

Чыга башлавына 50 ел тулу уңае белән тугандаш удмурт язчылары журналы «Молот»ны Ижевск шәһәрендә үткәрелгән иҗат бәйрәмнәрендә котлап, шагыйрь Зәки Нури чыгыш ясады, Татарстан Язучы-

лары союзыннан һәм «Казан утлары» журналыннан юбилярга бүләк итеп Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил бюстларын тапшырды.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ БАШКА ТЕЛЛӘРДӘ

Казагыстанның «Жазучы» нәшрияты Муса Җәлилнең шигырьләр җыентыгын басып чыгарды. Шигырьләрне күренекле казакъ шагыйрьләре Абдильда Тажибаев, Олжас Сөләйманов, Гали Орманов, Хәмит Ергалиев һ. б. лар тәрҗемә иткән.

* * *

«Литературная газета» журналының 26 май санында Гомәр Бәшировның Хәсән Туфан иҗатына багышланган «Все человеческое донести» дигән мәкаләсе басылып чыкты.

* * *

Шкетанә исемендәге Мари музыкаль һәм драма театры Илдар Юзеевның «Сандугачлар килде безгә» исемле пьесасын сәхнәләштерде. Пьесаны мари теленә драматург Арсений Волков тәрҗемә иткән.

* * *

Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшриятында басылган «Поэзия» альманахының 15 нче чыгарылышында Шәүкәт Галиевның балалар өчен язылган шигырьләре урнаштырылган. Шигырьләрне Вадим Кузнецов тәрҗемә иткән.

* * *

Шул ук нәшриятта чыга торган «Молодежная эстрада» журналының бу елгы 1 санында Муса Җәлилнең С. Липкин, В. Тушнова, К. Арсенова тәрҗемә иткән берничә шигыре басылган. Шул ук санда Динас Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» пьесасыннан өзекләр бирелгән.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында Г. Кариевның туууына 90 ел тулуга багышланган фәнни конференция узды. «Г. Кариев — татар театрына нигез салучы», «Г. Кариев — режиссер», «Г. Кариев — актер», «Г. Кариев һәм сәхнә мәктәбенең күренекле вәкилләре» дигән темаларга галимнәр һәм театр белгечләре Баян Гыйззәт, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Шириязданн Сарымсаков, Һәнүз Мәхмүтов, Ильтани Илялова, Дания Гыймранова, Фәүзия Кадыйрова докладлары һәм чыгышлары тыңланды. Өлкән актерларыбыздан Татарстанның халык артистлары Касыйм Шамил, Хәким Сәлимҗанов юбиляр хакында истәлекләр сөйләделәр.

* * *

Шул ук театр бинасында татар театрына нигез салучыларның берсе, атаклы артист һәм режиссер Габдулла Кариевның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Г. Кариевның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге хакында филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт докладь тыңланды. Академия театры һәм Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары катнашында концерт куелды.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Татарстан АССР хатын-кызларын коммунистик тәрбияләү буенча нәтиҗәле эшләве, аларны хуҗалык һәм культура төзелеше бурычларын үтәүгә туплавы өчен, **«Азат хатын»** журналы **«Почет билгесе»** ордены белән бүләкләнде.

* * *

Хореография сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының балет солисткасы **Сания Хәсәновна Хантимеровага Татарстанның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ЯЗУЧЫЛАР ТУРЫНДА ДИАФИЛЬМНАР

Әдәбият укытучысы Вәли Хаҗиев язучылар турында мәктәпләр өчен шактый санда диафильмнар эшләде.

«Татар халык шагыйре Габдулла Тукай». Шул исемдәге ун кисәктән торган диафильм производствога тапшырылды. Бу диафильмның дүрт кисәге Г. Тукайның 90 еллык юбилее көннәренә чыкты, калган алты кисәге яңа уку елына өлгертелде. Бөек шагыйребезнең тормыш юлы һәм иҗаты анда шактый киң яктыртыла. Тукайның сабый чорлары, Кырлайда, Җаекта үткәргән еллары, типографиядә эшләгән вакытлары, Тукай биографиясенең Казан чоры, Тукай гомеренең соңгы айларына аерым бүлекләр багышланган. Шулай ук Тукай иҗаты буенча тикшеренүчеләрнең хезмәтләре, татар, рус һәм тугандаш халык язучыларының Тукайга багышланган әсәрләре, Тукайның замандашлары белән таныштырган, «Тукай — театр һәм музыка сәнгатендә» дигән бүлекләр бар. Тукай премиясе лауреатлары турында да мәгълүматлар китерелә. Мәктәп программасына бәйләп, Тукайның егерме алты әсәренә анализ-иллюстрацияләр бирелә.

«Татар совет шагыйре Һади Такташ» диафильмы алты кисәктән тора. Аларның берсе шагыйрьнең биографиясе белән таныштыра, калганнарында мәктәп программасына кергән әсәрләренә анализ-иллюстрацияләр бирелә. Такташ турында татар совет язучылары, шагыйрьнең иҗатын өйрәнүчеләрнең фикерләре китерелә. Такташ белән бер чорда яшәгән, бергә эшләгән язучылар, журналистлар, редакция эшчеләре турындагы хәбәрләр, фотоиллюстрацияләр дә кызыклы. Диафильмда 200 дән артык фотоиллюстрация тупланган.

«Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар совет язучылары» исемле диафильмда Ватаныбыз азатлыгы өчен корбан булган 32 язучының

фоторәсемнәре бирелә, әсәрләре белән таныштырыла. Диафильм аларга бәйле 86 фотоиллюстрация белән тулыландырылган.

«XIX йөздә татар мәгърифәтчеләре, язучылары» исемле өч кисәкле диафильм беренче татар типографиясе оештырылу, Г. Утыз Имәни, Г. Кандалый, Ибраһим Хәлфин, Ш. Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Гали Мәхмүдов, К. Насыйри, М. Акъегет, З. Бигиев, Г. Ильяси, Ф. Халиди, З. Һади һәм Ш. Күлтәсиләр иҗаты һәм эшчәнлеге хакында сөйли.

«4 нче класс әдәбият дәреслеге», тәҗрибә буларак, диафильмга салып бирелде. Диафильмда 16 язучының тормышы, иҗаты яктыртыла, анда 200 дән артык фотоиллюстрация файдаланылган.

Бу диафильмнарны теләгән кешеләр, оешмалар сатып та ала алалар. Һәр диафильмның аерым кисәге — 50 тиен. Адресы өчен адрес: Казан, Профсоюз урамы, 15, Татарстан педагогия җәмгыяте. Ничә комплект кирәклеген күрсәтеп язарга, ә хакын Госбанкның Татарстан республика конторасына 470 052 номерлы счетка җибәрергә кирәк. Акча счетка кергәч, диафильмнар почта белән җибәрелә.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлеге язучылары һәм Әлмәт татар дәүләт драма театры художество Советының берләштерелгән утырышында драматург Юныс Әминовның табигатьне саклау мәсьәләләренә багышланган «Сөймим дисәң дә» исемле комедиясе тикшерелде. Фикер алышуда Гамил Афзал, Сәҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, театрның баш режиссеры Гали Хөсәенов, театр артистлары катнашты. Әсәрне театр репертуарына тәкъдим итәргә дигән фикергә киленде.

* * *

Әлмәт шәһәренең өченче номерлы китапханәсендә Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» исемле повесте буенча китап укучылар конференциясе үткәрелде. Китап укучылардан чыгыш ясаучылар «Яшьлек утравым» әсәренең яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйнавы турында сөйләделәр. Конференциядә катнашкан автор китап сөючеләрнең күп төрле сорауларына җавап бирде.

* * *

Җәмит Рәхимовның «Җөйсез җәрәхәт» исемле яңа повесте тикшерелде. Әсәр Татарстан нефтьчеләре алдында торган зур проблемаларны чишү, яңалык өчен көрәш һәм мораль темаларын эченә алган. Шамил Бикчурин, Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал, Мәхмүт Хәсәнов, Клара Булатова, Юныс Әминов, Сәет Кальметов повестьтагы образларны үстерү, камилләштерү буенча авторга төпле киңәшләрен әйттеләр.

* * *

Башлангыч татар мәктәпләре укытучыларының Әлмәттә үткәрелгән районара киңәшмәсендә язучылардан Сәет Кальметов һәм Клара Булатова чыгыш ясады. Алар татар әдәбиятына кагылышлы мәсьәләләр турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Татарстан нефтьчеләренең «Ромашкино» санаториясендә ял итүчеләр Сәҗидә Сөләйманова белән очраштылар. Шагыйрә яңа повестеннан өзекләр һәм яңа шигырьләрен укыды, күп төрле сорауларга җавап бирде.

* * *

Лениногорск районының Сугышлы авылында Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Чоңгыллар» исемле әсәре буенча китап укучылар конференциясе үткәрелде. Авыл эшчәннәре, механизаторлар әсәр турында кызыксыну белән сөйләделәр. Конференциягә нефтьчеләр ягында яшәүче язучы Шамил Бикчурин һәм яшь язучы Әсрар Галиев катнашты. Соңыннан язучылар һәм авыл үзешчәннәре көче белән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

* * *

Рафаил Төхфәтуллин Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылы урта мәктәбен тәмамлаучылар алдында чыгыш ясады, яңа әсәрләреннән өзекләр укыды, әдәбият һәм тормыш турында кызыклы әңгәмә үткәрде.

* * *

Клара Булатова Азнакай пионерлары лагеренда ял итүче балалар белән очрашу үткәрде, пионерларга шигырьләрен укыды.